ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

8.2011



## Татарстан Республикасы Президенты
## УКАЗЫ

*«Татарстан Республикасы Халык шагыйре»*
*дигән мактаулы исем бирү турында*



Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм татар әдәбияты үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Комитеты рәисе, һөнәри шагыйрь **Вәлиев Разил Исмәгыйль улына** «Татарстан Республикасы Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н.МИҢНЕХАНОВ**

*Казан, Кремль, 2011 ел, 12 июль*

---

## Татарстан Республикасы Президенты
## УКАЗЫ

*«Татарстан Республикасы Халык язучысы»*
*дигән мактаулы исем бирү турында*



Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм татар әдәбияты үсешенә зур өлеше өчен һөнәри язучы **Родионов Григорий Васильевичка** (Гәрәй Рәхимгә) «Татарстан Республикасы Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н.МИҢНЕХАНОВ**

*Казан, Кремль, 2011 ел, 12 июль*

**Казан утлары**

**Qazan utları**

2011

# 8

**(1066)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
***«ТАТМЕДИА»***
***ачык акционерлык җәмгыяте***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—562-10-62.
Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.
Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рәшит ӘХМӘТҖАН. *Шигырь* ..... 5
Рәфкать КӘРАМИ. Сөеп туймас чакларың. *Роман* ..... 6
Луиза ЯНСУАР. Риваятьләргә без–яңа исем... *Шигырьләр* ..... 37
Рәзинә МӨХИЯР. Кем биргән соң безгә очар канат? *Шигырьләр* ..... 41
Альберт ХӘСӘНОВ. Данәгөл. *Роман* ..... 44
Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ. Төнге күктән бага... ат күзләре. *Шигырьләр* ..... 80
Булат ИБРАҺИМ. Өй артына... яңа заман килгән. *Шигырьләр* ..... 83
Рахман ШӘФИГУЛЛИН. Тауиле гарасаты. *Кыйсса* ..... 86
Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Номерың кем? *Хикәя* ..... 122

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

Зөлфәт ХӘКИМ. Бармы ришвәткә дәва?.. *Сатирик комедия* ..... 95

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Игътибар үзәгендә–балалар әдәбияты *(И. Ибраһимов, Г. Гыйльманов, Р. Зәйдулла, Р. Рахмани, Л. Минһаҗева, Р. Корбан чыгышлары)* ..... 130

«Татар энциклопедиясе» битләреннән ..... 154

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ..... 157

**ХӘТЕР**

Ләйлә МИНҺАҖЕВА. Имәннең дә имәне иде... *(Ибраһим Салаховның тууына 100 ел)* ..... 160
Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр* ..... 179

**ЮБИЛЕЙЛАР**

«Алга – гасыр тирәнлекләренә!» *(Рөстәм Галиуллинның Фаяз Хуҗин белән әңгәмәсе)* ..... 164

**АК ҖИЛКӘН**

*Бәләкәйләр.* Бәләкәй Гаташ ..... 170
Роза ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА-ХӘМИДУЛЛИНА. Ишек шыгырдавы. *Хикәя* ..... 175
Балык Бистәсе районының Ямаш мәктәбе укучылары иҗаты *(Р. Сафин, Т. Мостафина, Р. Гаязова)* ..... 176

«Казан утлары» архивыннан ..... 128,186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы Р. КАРАМИ «Пора прекрасной любви», А. ХАСАНОВА «Данагуль»; рассказы Р. ШАФИГУЛЛИНА, Р. ГАЛИУЛЛИНА; стихи Р. АХМЕТЗЯНА, Л. ЯНСУАР, Р. МУХИЯР, И. ФАЗЛУТДИНОВА, Б. ИБРАГИМА.
«Сенной базар». Конкурс сатирических произведений.
«Литературная критика»: «В центре внимания—детская литература» (доклады И. Ибрагимова, Г. Гильманова, Р. Зайдуллы, Р. Рахмани, Л. Мингазовой, Р. Курбана).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.).
«Память»: статья Л. МИНГАЗОВОЙ, посвященная 100-летию И. Салахова; дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«Наши юбиляры»: интервью Р. ГАЛИУЛЛИНА с Ф. ХУЗИНЫМ.
«Белый парус»: Р. ГАТАШ. «Маленький Гаташ»; рассказ Р. ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ.
«Наш календарь».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Вечно молодая древняя Казань; поэт Рустем ЗАКУАН.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novels by R. KARAMI «It's time to perfect love», A. HASANOV «Danagul»; stories by D. SHAFIGULLIN, R. GALIULLIN; poems by D. AHMETZYAN, L. YANSUAR, R. MUHIYAR, E. FAZLUTDINOV, B. IBRAHIM.
«Hay market». Competition of satires.
«Literary Criticism»: «In center of attention: children's literature» (reports by I. IBRAHIMOV, G. GILMANOV, R. ZAYDULLA, R. RAHMANI, L. MIMGAZOVA, R. KURBAN).
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation.)
«Memory»: article by L. MINGAZOVA dedicated to 100th anniversary of I. Salahov; diaries by F. YARULLIN.
«Our jubileers»: interview with F. GALIULLIN with F. KHUZIN.
«White Sail»: R. GATASH. «Little Gatash»; story by R. GIZZATULLINA.
«Our calendar».
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Forever young old Kazan; poet Rustem ZAKUAN.

*The magazine edits monthly*

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.08.2011, график буенча 01.08.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–1077. Тираж 3810.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел.

## Рәшит Әхмәтҗан

***

*(«Ачлык мәйданы» циклыннан)*

**Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча**
**Кузгалып китү юк быелгы җәемнән.**
**Башкае киселгән нәселем Агачы**
**Тамырдан таралып, дөньяга җәелгән.**

**Җәелгән җиремә—үлемсез агачым,**
**Иелмәс иңнәре биеккә үрелгән.**
**Яшәргә! Яшәргә! Яшәүләр—кешегә**
**Мең кабат газаплы булса да үлемнән.**

**Коллыкны яндырып каныбыз дөрләсен,**
**Дөрләсен, сүнмәсен—ант итик, Ватанчы:**
**Йә бозлы йортыма азатлык яуларбыз,**
**Йә янып бетәрбез—көл булып калганчы!**

**Илемә багышлап үземне, сүземне**
**Ачлыкта утырам шул газиз нигездә.**
**Яшәүне сөям мин!..**
**Сөягем белән, Ил,**
**Иреккә илтүче юлларны тигезлә!**

*1991*

Рәфкать
Кәрами

# СӨЕП ТУЙМАС ЧАКЛАРЫҢ

РОМАН

## VI

...Габделнур ияләнде рәхәт тормышка: атнага бер тапкыр Аля янында кунып кайта. Ул бүлмәдәшләреннән үзенең кайда йөрүен яшереп тормады. Кемдер аңа кызыгып карады, кем өчендер аның кайда, кем белән кунуы барыбер иде. Тулай торак шундый җир инде: бер яктан караганда, ул сине мөстәкыйльлеккә, кешеләр белән аралаша белүгә, бүтәннәр мәнфәгатен дә санга сугарга, үз-үзеңне яклый белергә, ашарга пешерергә, юарга, кулга энә тотарга (төймә тагар өчен генә булса да), кыскасы, үз көнеңне үзең күрергә өйрәтсә, икенче яктан, син—бер башың: нигә иртә китәсең дип тыкшынучы, ник соң кайттың дип желегенә төшүче, кая бардың дип сорау алучы, кайда һәм кемнәр белән йөрдең дип, сиңа бәбәген терәп, тикшерепчокчынып торучы юк.

Монда син ирекле кош: кай тарафка телисең—шул якка очасың, кайсы тал күнеленә хуш килә—шуңа кунасың, көнеңне ничек, кем белән телисең—шул рәвешле үткәрәсең. Шуңа күрә Габделнур артык нечкә тойгыларга бирелмичә, гыйшык-мыйшык уйнамыйча, мәхәббәт учагында дөрләп янмыйча, гамьсез битарафлык белән, салдан аерылган ялгыз бүрәнә кебек, акрын гына тормыш агымында йөзеп бара иде кебек. Аля—ирдән аерылган хатын, бала-чагасы юк, ә фатиры бар, коры куык түгел—киләчәккә гамәлгә ашмастай планнар кормый, өйлән, дип бәйләнми, кайбер пумала башлар кебек, нәрсәгәдер өметләнеп, егет күңелен кайтарырдай юк-бар таләпләр куймый, туктале, бу алтын балыкны эләктереп калыйм, дип җәтмә салмый, кыскасы, бернинди дә дәгъвасы юк, ә килүгә—өстәл әзер, шешәсе дә кукыраеп-сузаеп утыра. Нәрсә кирәк тагы?!

Дөрес, болар берсе дә егет өчен, аңа ярарга тырышыр өчен эшләнми. Аля фәкать үз мәнфәгатен кайгырта, үз рәхәте өчен генә тырыша: егет тиешенчә аны канәгатьләндерсен, иркәләсен-назласын!

Габделнур берчакны, сынап карар өчен генә:

—Күлмәк якасы каралган икән,—диде.

Хатынның реакциясе тиз һәм бик кискен булды, төксе чырае кара янды, кызарып чыкты.

—Мин сиңа прачка түгел!—дип кырт кисте.

Һәм кабат күлмәк түгел, кулъяулык юу турында да сүз булмады.

Икенче юлы исә Габделнур үз сүзен сүз итте. Хатын аны Казанда эшләүче

*Дәвамы. Башы узган санда.*

бердәнбер чиркәүгә—Бауман урамына алып бармакчы иде.

—Кызык өчен генә, болай гына карап кайтырбыз,—диде ул.—Минем Сергиево-Посадта булганым бар. Монда ничек икән.

—Юк, мина ярамый,—дип бу юлы егет хатынның булмастайны таләп иткән авызын томалады.

Ә калганы—килем-китемле тормыш—элеккечә матур гына дәвам итте.

Шулай да бервакыт тыныч кына аккан бу чиста елгага болганчык су килеп кушылды—бер мичкә нефть түгелде сыман.

Габделнурның ваннада чагы. Бу юлы ул душ астында гына түгел, ә ылыс төнәтмәсе порошогы салынган, чыршы-нарат исләре аңкып торган яшькелт су тулы ваннада ята иде. Армиягә хәтле ул мондый рәхәтне күрмәде дә күрмәде инде, солдат хезмәтендә дә гомуми мунча—сафка тезелеп барасың, тиз-тиз юынып чыгасың да, әле шуңа да сөенеп, җинеләеп, көр күңел белән, бераз тугарылып, казармаңа кайтып китәсең, тулай торакта исә, ванна түгел, душ та юк,—янә шәһәр мунчасы. Кыскасы, мондый «бәхет»кә ул гомерендә тәүге тапкыр ирешкән иде: бөтен гәүдәң белән диярлек суга күмелеп ятасың (баш кына өстә), суы җылы-талгын, изрәтә, йокыны китерә, йөрәгеңнең талгып типкәнен тоясың... Егет ята-ята оеп китә язган иде инде, кинәт алгы бүлмәдә кыңгырау чыңлады. Ул кисәк кенә күзен ачты, сагая калды.

Аля барып ишек ачты, ахры, ир-ат тавышы ишетелде. Ләкин коридордан ары узмады булса кирәк (бәлки атлап та кермәгәндер), бусага аша гына сөйләшкән кебек тоелды.

Егет җәһәт кенә судан күтәрелде, алан-йолан каранды. Сугышырга туры килсә, нидер эләктерергә кирәк иде. Ләкин ванна бүлмәсендә кулга тотардай җайлы нәрсә күренмәде. Берәү генә бугай, әйберсез дә бирешмәс. Ул җәлт кенә сөлгегә үрелде, сөртенеп, трусигын киеп, ишек янагына колагын куйды, тыңлап тора башлады. Аляның, юк, кермисең, дигән сүзләрен аермачык ишетте. Ир-ат тагын нидер мыгырданды. Бу юлы хатынның тавышы катырак һәм кырысрак чыкты.

—Бар, яңадан килмә!

Тагын бераз вакыт быдыр-быдыр сөйләшкән аваз ишетелде, аннары ишек ябылды һәм йозакта ачкыч чыртлады. Габделнур трусигын салып атты да, чайпалдырмаска тырышып, тиз генә суга чумды. Аля ишекне ачып, ванна бүлмәсенә күз ташлады.

—Әле син чыкмадыңмыни?

—Хәзер чыгам. Кем иде ул?

—Элекке ирем. Һаман бимазалап йөри.

Авыз тутырып, көнчелек корты кимерүе, дип әйтергә ярамаса да, ниндидер көнләшүгә тартым хис туган иде егетнең күңел түрендә. Шуңа күрә ул, гадәттәгечә мендәргә аркасын терәп, бра яктысында китап укып утырганда, сорап куйды.

—Иреңне әйтәм, кем соң ул? Кайда яши?

Аля да, үз нәүбәтендә, китаптан аерылып, әкрен генә сөйли башлады. Әлбәттә, аңа хатирәләр яңарту җинел түгел, ләкин даими килеп йөрүче сөяркәсе белән ике арада сер калмасын өчен ачыклык кертүне, яшермичә сөйләп бирүне кирәк тапты.

—Ирем Казандагы зур бер завод директорының улы. Без—укыганда таныштык, мин, Мәскәү кызы, китапханә институтында укыйм, ә ул Бауман училищесы студенты. Соңгы курста өйләнештек тә, тәмамлагач, Казанга кайттык. Мин китапханәгә эшкә урнаштым, ә ул—әтисе эшләгән заводка инженер булып.

—Училище гына бетергән килешме?

—МВТУ—югары белем бирүче бик дәрәҗәле институт, электән калган

гадәт буенча гына училище дип йөртелә,—диде хатын аңлатма биреп.—Әтисе аркасында фатирлы да булдык. Ярты ел әйбәт, тату гына тордык. Аннан иремнен эчә, эштән соңга калып кайта торган гадәтләре барлыкка килде; шуның өстенә үзе үтә дә көнче булып чыкты; бер сәбәпсез миңа кул күтәрә башлады. Берчакны, бик каты кыйнагач, милициягә барып әйттем. Ул уйлагандыр инде, өйләнешүгә үк фатирлы, үзе зур түрә малае да булгач, әйтмәс дип. Ә мин бардым. Чөнки бөтен тәнем кара янган, күгәргән иде. Белешмә дә юнәттем медиклардан. Аны кулга алдылар... Әти-әнисе килеп үгетләргә тотындылар. Ә мин әйттем: аның белән тормыйм, аерылам.

—Ә үзе нәрсә диде соң?

—Ни дисен? Аерылышмыйк, гафу ит, моннан соң бармак белән дә чиртмәм, ди. Ә мин аның тасма теленә ышанмадым, тукран тәүбәсе. Беренче тапкыр гына түгел бит. Әти-әнисе риза булдылар. Миңа, төрмәгә генә утыртма, диләр. Мин һаман үземнекен тукыдым: утыртам, квартираны бүләм. Шуннан алар миңа, квартира бөтенләе белән үзеңә калыр, утыртма гына, дип ялындылар. Мин ризалаштым.

—Ә ул монда пропискададыр бит?

—Юк. Бөтенесен закон нигезендә эшләдем. Квартира—минеке генә.

—Ә балаң булмадымы?

—Аллага шөкер, өлгерә алмый калдык. Узмадым...

Бу минутларда Габделнур ике төрле тойгы кичерде: беренчедән, шушы нәфис, назлы гүзәл затның ничек җәберләнүен ишетеп аны җәлләсә, икенчедән, шушы бәләкәй генә хатынның үз-үзен яклый алырдай көч табуы аңарда соклану уятты.

—Ә хәзер нәрсәгә килгән соң?

—Кушылыйк, ди, мин сине яратам, ди. Мин, бер кискән икмәк кире ябышмый, күрәсем дә килми, дидем. Мине теле белән юмакчы була.

—Ярык чүлмәкне камыр белән сыламакчы,—диде егет.

—Ә мин аңа ышанмыйм. Менә шул...

Аннары Габделнур сүзне икенчегә борды: үзенең Мәскәүдә командировкада (партиягә кабул иттеләр, димәде) булуын әйтте, гәрчә шәһәрне белмәсә дә, хатынның кай тирәдә яшәгәнлеге белән кызыксынды... Шулай итеп аны ире турындагы ямьсез уйлардан арындырды, үзе дә онытырга теләде.

Ә беркөнне исә Аля аның башына таяк белән суккан кебек итте. Кухняда ашап утыралар иде.

Хатын, аңа туры карап:

—Әгәр сине үтереп ташласалар да беркем дә кайда икәнеңне белми инде,—диде.

Габделнур, бу сүзләргә шаккатып, чәенә тончыга язды, ләкин сиздермәде. Бер-ике секунд әйле-шәйлерәк утыргач, аның башына тапкыр уй килде һәм ул алдады.

—Нишләп белмәсеннәр? Беләләр, —диде тавышы сүнгәнен хатынга сиздермәс өчен сүзләрен өзек-өзек әйтеп.—Мин бүлмәдәге егетләргә синең телефонынны бирдем.

Хатынның коңгырт кашлары күтәрелеп китте, сәерсенеп карады.

—Нигә?

—Кисәк кенә кирәгем чыкса.— Егеткә тавышының элекке ныклыгы кайтты.—Өйдән телеграмма-фәлән килсә... Минем әти-әни олы яшьтәгеләр бит инде; әбиләр бар әле, дөнья хәлен белеп булмый...

Аля серле генә карап торды, менә сиңа кирәк булса, янәсе. Аннан әйтте:

—Син—хәйләкәр татар.

Шул көннән башлап егетне шикләнү корты кимерә башлады. Борынгылар әйтмешли, мәхәббәт дулаган җирдә һичшиксез кан коелырга

тиеш микәнни?

Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, бер кичне, Аля яшәгән подъезд төбендә икәү, Габделнур килгән якка карап, тәмәке тартып торалар иде. Аны күргәч, егетләр папиросларын тиз генә читкә ыргытып, җәһәт кенә подъездга кереп юк булдылар. Габделнур шикләнә калды. Шулай да адымын туктатмады, сөяркәсе янына керү ниятеннән ваз кичмәде.

Тышкы ишектән үрелеп карады: кеше юк. Икенче ишек ябык. Ул аны ачты, ә үзе кермәде. Шул секундта ук нәкъ аның башы турысына сул яктан кисәк кенә йодрыгы йомарланган кул сузылды. Габделнур аны күз ачып йомганчы беләзегеннән эләктереп тә алды һәм, аска тартып, артка каерып та куйды. Ә каршыда торган икенче кеше Габделнурга ташланып өлгергәнче егет кулы каерылган гәүдәне аңа таба бөтен көченә этеп тә җибәрде. Соңгысы башы белән иптәшенә килеп бәрелде. Габделнур, гәүдәсенең бөтен авырлыгын салып, җан көченә аның артына да китереп типте. Тегеләр идәндә ах-вах килгән арада чыгып та сызды.

Теге бәндәләр өчен генә түгел, үзенә дә көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты бу бәрелеш. Күрәсең, армиядә бераз вакыт бокска һәм самбо көрәшенә йөрүнең файдасы калган—реакциясе тонықланмаган.

Ул Аля яшәгән йорт ягына әйләнеп тә карамады. Чөнки кыска арага йөгерүдә дә әле алай булыр-булмас теләсә кемгә бирешерлек түгел иде. Кем булды алар? Нинди максат белән бәйләнделәр? Берсе Аляның ире идеме әллә? Күрәсең, шул булгандыр. Юкса тора салып бәйләнмәсләр иде. Күзәтеп йөргәндер. Хатыны янына кем килгәнен сизеп алгандыр. Шулай фараз кылды Габделнур, әмма чын дөресен белә алмады.

Ул кичне сөяркәсе янына кермәде, кабат әйләнеп кайтмады.

Һәм шул хәлләрдән соң хатын белән ике арадагы эчкерсезлек, гамьсезлек эреп юкка чыкты, аңа булган ихлас карашы үзгәрде. Дөрес, боларны ул тыштан, ягъни, аңа карата мөгамәләсендә сиздермәде. Үзенә Аля яшәгән йортның подъездында һөҗүм итүләрен дә әйтмәде. Анысы очраклы гына шулай туры килгәндер, хатынның аңа катнашы юк шикелле. Һәрхәлдә, сизелми. Ул иренең ни эшләп йөргәнен белми дә торгандыр. Ләкин, шикле—шикләнер, иске чикмәнен бөркәнер, дигәндәй, хатынга да ышаныч беткән иде инде. Шуңа күрә ул хәзер абай булырга, һәр сүзен кат-кат уйлап, чәчелмичә сөйләргә (хәер, ул элек тә уйламыйча сөйли торган кеше түгел иде), гади генә эшен дә җиде кат үлчәп, бер тапкыр кисәргә—гамәлгә ашырырга тырышты. Һәр агуга дару булырга тиеш, дигән принциптан чыгып эш йөртте. «Хатын ни өчен әйтте икән әлеге сәер сүзләрне?—дип баш ватты ул.—Болай гынамы? Юкса, ак-караны аермый торган акылсыз баш түгел. Куркытып кую өченме?» Ләкин егет аңа бер начарлык та эшләмәде һәм... җыенмый да. Әгәр күнеленә ошаган, язмышын бәйләрдәй башка берәүне таба икән, турыдан-туры егетнең үзенә әйтә ала, комачауламас, бәрәңге бакчасындагы эт эчәгесе кебек аягына уралмас. Габделнур буш вәгъдәләр биргәнен дә хәтерләми. Әллә берәр төрле план корып маташамы бу тәкъва хатын? Алай дисәң, берчакны үзенең фатир алыштырып, туган шәһәренә күчәргә җыенуын да сиздерде. Шул эшне җайга салу өчен Мәскәүгә барып кайтты. Әти-әнисе белән телефоннан сөйләшкәндә дә шул хакта барган сүз егет колагына чалынды. Бәлки сынар өчен генә әйткәндер? Ә ник аны сынарга? Алай булса, шаяртса—әйтми калмас иде. Бәлки иренең күзәтеп йөреп, сагалап торып нидер эшләвеннән шикләнәдер. Андый шиге булса, нигә Габделнур белән уртаклашмаска? Кайсы яктан гына керсә дә бу карурман—табышмакның серенә төшенә алмады. Һәм ул, аң булып тору өчен, тулай торакта моны Иреккә дә сөйләде, шик-шөбһәсен житкерде.

Дусты башта шаркылдап көлде.

—Кит аннан?! Нәкъ шулай дидеме? Вот зараза... Да, Старый, икмәк югы ямандыр, каты-коты кимертә, хатын югы ямандыр, әллә кемнәр сөйдертә. Димәк, өйләнергә кирәк һәм... немедленно!

—Китсәнә, юкны лыгырдама.

Ирекнең әле һаман авызы ерык иде.

—Юкса башыңа җитәрләр.

—Җитми генә торсыннар.

—Алай димә. Картлач, синең «батырның үлеме маржадан» дигәнне ишеткәнең бармы?

—Юк.

—Алайса—ишет, колагың булмаса тишек. Әйдә, бәхилләшик...

—Кит әле...

—Эшләрең хөрти бит,—диде Ирек көлеп һәм бераздан, уйга калып, җитди тонга күчте.—Ә нидән чыгып әйтелде икән соң ул сүзләр? Менә башваткыч... Нәрсәдер уйлап табарга кирәк.

Куркак егетләр түгел, моны уенга алып, үткәреп җибәрергә, сүзне шул урында тәмам итәргә дә булыр иде. Ләкин болай гына калдыру да ярамас, икенче вакыт авызын үлчәп ачсын, теле ни әйткәнне колагы ишетсен, кем белән бәйләнгәнен белеп торсын. Иплән кенә акылга утырту зыян итмәс. Дустының инде уйчанланган йөзенә карап, Габделнур үз фикерен әйтте.

—Әйдә, без болай итик... Атна-ун көн узгач, мин анда чагында син шушы номер белән шалтыратырсың...

...Трубканы гадәтенчә Аля алды.

—Хәерле кич. Габделнурны чакырыгыз әле,—диде ят ир-ат тавышы.

—Хәзер.—Аля, аптырап, залда телевизор карап утырган сөяркәсен дәште.—Сине сорыйлар.

—Кем?—дип сорады егет урыныннан кубып.

—Белмим.

Габделнур алгы бүлмәгә чыкты.

Ирек икән. Һәм ул дусты белән ана телендә җыен юк-барны сөйләшә башлады.

—Дустым, нихәл? Теге нәмәстә янында түгелме?

—Юк.

—«Эш»тән бүлмәдемме?

—Юк.

—Шулай-шулай эшләр, тора-бара нишләр. дигәндәй, син—сорадың, мин—шалтыраттым. Калганын үзең беләсең... күпме... Нык тырыш, әйбәтләп «бөкелә», рәнҗерлек булмасын. Юкса, гөнаһысын кая куярсың? ...Бәхетле кешеләр бар инде, мин әйтәм, безнең кебек казык башында йокламыйсың...

—Аңладым.—Хатынның «башы тишек» булмаса да сак кыланды.—Бүген китмәм инде. Иртәгә иртән барырмын. Хәзергә.

Габделнур трубканы куйды. Кашын җыерып, борчылган кыяфәткә керде, маңгаенда барлы-юклы җыерчыклар хасил итте, чыраен караңгылатты. (Зерәгә генә техникумда режиссура фәнен үзләштереп, спектакльләр куеп йөрмәделәр бит.) Артист булмаса да аңа гына сәләте җитә иде. Кайчагында трамвайдан төшкәндә тукталышта кеше күп булса, ул, күзенең агын әйләндереп чыгара да, сукыр кеше кыяфәтен китереп, кулы белән, ажгырып-ярсып очсызлы транспортка утырырга талпынучыларның башларын капшый, борыннарына үрелә, чырайларын сыпыра иде. Трамвайга алданрак утырырга чамалаучылар момент юл яралар. Аннан, бераз киткәч, алар иптәш егетләре белән урам яңгыратып көләләр. Хәзер дә ул, йөзен чытыкландырып, залга керде.

Аля зал уртасында басып тора, аны көтә иде.

—Кем шалтырата? Нигә?

—Апа чирләгән, кызы вахтерга шалтыраткан, мине эзләткән. Казанда бер апам барын әйткән идем бит.

—Китәсеңмени?

—Белмим инде. Хәзер китсәм...

Ләкин хатынның инде дәрте кузгалган, төнне әрәм уздырасы, ярты юлда бүленеп каласы килми.

—Бәлки иртәгә барырсың? —диде ул серле йомшак тавыш белән һәм дәрт ташып торган кайнар тәне белән сөяркәсенә сарылды.

—Ярар,—дип «бик авырлык» белән генә ризалашты егет.

Тагын бер ай чамасы «кияүләп» йөргәч, Габделнур бу өйгә эзен суытты. Чөнки хатынның теге сүзләре исенә төшсә, тәне чымырдап китә иде. Әлбәттә, ул соңгы вакытта бик сак кыланды. Аля эшләгән китапханә, ул яшәгән йорт тирәсендә шикле кешеләр күренмиме, дип алан-йолан каранды, бусагадан узу белән кием элгеченә, аннары балконга күз төшерә торган булды. Тик үзенә җәбер-җәфа китерердәй нәрсә сизелмәде. Ләкин күнеле кайткан иде инде. Элеккеге кебек күрергә атлыгып тору да, янына барасы килү дә, аны күргәч рухлану-дәртләнү дә юк. Бер гайрәт чиккәч, рәхәт булса да бу фатирны онытырга кирәк тапты.

Аннары, Аля да чынлап та фатирын Мәскәүгә алыштырырга йөри иде. Чөнки ана кемдер шалтыратты һәм сүз тагын фатир алмашу хакында барды булса кирәк. Ләкин егет моны ишетмәмешкә салышты, сүз кузгатмады, чит кеше эшенә тыгылмады.

## VII

Ә аннан соңгы көннәр эш, конторда стена гәзите чыгару, уку кебек мәшәкатьләр белән үз җаена ага торды.

..Атна ахырында, эштә, Раил янына дип, электриклар будкасына «Таксист» керде. Ләкин аның йомышы Раилдә түгел, ә Габделнурда булган икән. Ул, авызындагы саргылт алтын тешләрен күрсәтеп, киң елмаеп, җай гына сүз башлады.

—Шеф, сине тагын борчысак ни әйтерсең икән?

Габделнур, ниндидер куркыныч янаганын сизеп, колакларын шомрайткан ат кебек, башын күтәрде, тын калды, сагайды, җавап бирергә, сүз әйтергә ашыкмады. «Тагын монысының да туган көне җитә микәнни?»—дип уйлап куйды. Ләкин эш башкачарак, йомыш бүтәнчәрәк икән. Сүзгә Раил дә кушылды.

—Бер әйбер алып киләсе иде. Бөтен ышаныч синдә. Зур түгел, кесәгә сыярлык кына.

Габделнур сүзләрен, учына йомарлаган үзле балчыкны бармак арасыннан кысып чыгарган кебек, теш арасыннан теләр-теләмәс сыгып чыгарды.

—Булдыра алсам...

Теле әйтте, ә үзенең һич тә болар кубызына биергә исәбе юк иде. Үз жаргоннары белән әйткәндә, плинтустан түбән төшәргә ярамас дип уйлады. Юкса «шестерка»га әйләнүеңне көт тә тор.

Ләкин шул ук вакытта, каты бәрелеп, хәтерләрен калдырып, араны катлауландырасы килми иде. Аннары, бөтен өметләре анарда, күрәсең, андый гозерне үтәрдәй бүтән кеше дә юктыр мөгаен. Мастер-прорабларга сүз ката алмыйлар. КППдагы солдатлар да үзләре кебек бушлатлы егеттән шикләнмиләр. Зеклар моны да истә тоталар булыр. Пирог алып килгәннән соң Раил ана гадәттә төзәтү учреждениеләрендә ясала торган «ширпотреб»—матур бизәкле авторучка бүләк итте. Аласы килмәгән иде Габделнурның, әмма... баш тартырга кыймады.

—Үзең әйт,—диде Раил чакырылмаган кунакка.

Ул ышанычлы кулдашының бу йомышны да үтәячәген аңлап алды.

«Таксист» уч төбе хәтле генә кәгазь кисәге тоттырды Габделнурның кулына.

—Менә шушы адрес белән барырсың. Укы да ертып ат. Ә монысы—«бабки». Җыеп куй.

Габделнур нәкъ теге әйткәнчә эшләде: адресны укыгач, шиге калмасын өчен, зекның күз алдында кәгазь кисәген тураклап ташлады, акчаны эчке түш кесәсенә шудырды.

—Ә бу «малява»ны хуҗага бирерсең,—дип «Таксист» тагын дүрткә бөкләнгән кечкенә кәгазь кисәге сузды.—Үзе өйдә булмаса, икенче кабат килермен, диген дә чыгып кит. Вообще-то өйдә булырга тиеш. Килешенгән.

...Тулай торактан чыгып, берничәсе ике, өч-дүрте биш катлы булган йортлар арасыннан беркавым баргач, Габделнур автобуслар йөри торган олы урамга чыкты. Аның өстендә көзге пәлтә, башта ак фуражка, аягында—юка табанлы туфли.

Төнлә кар яуган. Көн салкынча. Берничә таныш кеше очрады, алар белән тегене-моны сөйләшкән арада җиденче номерлы автобус та килеп җитте. Ял көне—якшәмбе булса да халык күп иде, көч-хәл белән этелә-кысыла керде.

Габделнур яшәгән микрорайонга Каравай бистәсе терәлеп диярлек тора. Бистә Беломорская урамының сул ягында, ә уңда—бушлык, ике тукталыш узгач кына агачлык һәм бәләкәй өйләр—бакчачылык ширкәте күренде.

Үзенә кирәкле Мариупольская тукталышында егет автобустан төшеп калды. Юл аркылы чыкты. Монда бөтен нәрсә авылча: йорт-җир, каралты-кура, мунчалар, капка-коймалар, куак-агачлар. Тик авылдан күпмедер дәрәҗәдә аерылып та торган шикелле, чөнки йортлар барысы да зур, таза, күбесе силикат яки кызыл кирпечтән, калай белән япкан, иске-москы, кыйшайган түбәле өйләр юк. Йорт яңартырга җыенучылар да күренгәли: каршыларында кирпеч, такта өемнәре. Янәшәдә генә завод төзелә башлагач, бистәдә яңа йортлар салу бермә-бер артты, чөнки чая егетләр әйләнеч юллар белән рубероид, цемент, такта, кирпеч ише нәрсәләрне ярты бәясенә китереп кенә тора. Мастер-прорабларның да, бригадирларның да сирәк-мирәк тамак чылатасы килә, ә хәләл хезмәт хакына гаиләне асрарга кирәк.

Урамдагы этләрнең бер-икесе капка төбе саклый, кайберләре биләмгә чыккан; тавыклар, командирлары әтәч күзәтүе астында әллә ни ерак китмичә нидер чүпли, чемченә; сирәк-мирәк бала-чага, ир-ат яки хатын-кыз күзгә чалына.

Бераз баргач, исендә калдырган адреслы йортны эзләп тапты. «Таксист» белеп әйткән: хуҗаның өйдә—ишегалдында чагы туры килде. Ул башта хәрбиләрчә төз гәүдәле, буй-сыны белән көрәшчеләрне хәтерләткән, йөз чалымнары аңа таныш оператив хезмәткәрләргә тартымрак җитди кыяфәтле егеткә шикләнебрәк карады. Сәлам бирүенә теләр-теләмәс кенә җавап кайтарды. Дүрткелле кәгазь кисәген алганда татуировкалы бармаклары дерелдәде. Тик «Таксист»ның кульязуын таный иде булса кирәк, сүз озайтып тормады, өенә кереп китте. Тиз генә киенеп чыкты, болдырда аны озата чыккан хатынына нидер пышылдады.

Автобуска утырып бер-берсенә сүз катмыйча, Челюскин урамына чаклы бардылар. Андагы баракларның берсенә кереп, почмак бүлмәдәге хуҗаны дәштеләр. Үзара чыш-пыш килгәч, Каравай кешесе, юлдашын калдырып, чыгып та сызды. Яңа хуҗа, егетне ияртеп, транспорт тукталышына юл алды—Ленинград урамына таба түбән төшеп киттеләр.

Соцгородта, троллейбустан төшүгә, Габделнур Казанда бергә хезмәт иткән Вадим атлы егетне күрде. Хезмәттәше дә таныды.

—О, служак!—дип килеп күреште ул.

—Сәлам,—диде Габделнур да ачык чырай белән.

—Хәлләр ничек?

—Әйбәт. Синең?

—Минем дә яхшы. Ял итәм.

—Ничек? Әле эшләмисеңмени?

—Эш бүре түгел—урманга качмас,—дип көлде энәдән-җептән киенгән, таза гәүдәле, чиртсәң кан чыгардай кызыл түгәрәк йөзле Казан егете.—Әнәрсә, өч ел ватанга әҗәтне түләгәннән соң бераз ял итәргә дә ярыйдыр. Армиядә ничек әйтә идек әле: эш, син бездән курыкма, без сиңа тимәбез. Ә син эшлисеңме?

—Әйе.

—Кайда?

—Төзелештә. Син кабат заводка керәсеңдер инде, шулай истә калган. Безнең шикелле саз ермассың.

Габделнур аның Кремльдәге хәрби часть клубында вербовщик сөйләгәндә, янәшә утырган солдатлар ишетерлек итеп кенә: тапкан юләрләрне, саз ерырга үзең бар, дип әйткән сүзләрен хәтерендә яңартты.

—Шулай дип торам,—диде Вадим.—Кире уйламасам. Монда бер җиңелрәк эш килеп чыгарга тора, әти белешкән, санаторий-профилакторийга завхоз итеп чакыралар. Көне буе станок артында тору булмас.

—Үзең карыйсың инде.

Тагын бераз сөйләшеп торгач, Вадим:

—Син кая юл тоттың?—дип сорады.

—Кереп чыгасы җир бар иде.

Вадим:

—Ярый, хәзергә,—дип кул сузды.

—Сау бул,—диде Габделнур соңгы ике-өч айны бергә хезмәт иткән егеткә чын күңелдән уңышлар теләп.

Вадим, сулга таба карады да, якынлашып килүче такси машинасын туктатып, китеп тә барды.

Троллейбуста да Габделнурны белмәмешкә салышкан адәм, егетләр сөйләшкәндә бөтенләй читкә китеп, арты беләнрәк басып тора иде. Янына Габделнур килеп баскач, шикләнебрәк сорап куйды.

—Кем иде ул?

—Армиядә бергә хезмәт иттек.

—Хәзер кайда эшли? Милициядә түгелме?

—Юк. Әле эшкә кермәгән, ял итә.

Кузгалдылар. Юлдашына ияреп барышлый егет уйлап куйды. «Ирек белән без бер көн дә ял итмәдек, кеше бәйрәм иткәндә дә вагон бушаттык. Ә бу... ял итә, арган, имеш... Өч ел шахтада күмер чапканмыни?! Шулай инде, шәһәр малае бит, берәүләрнең кадерле баласыдыр, ата-анасы хәлле кешеләрдер... Их дөнҗа, әй саен морҗа, чыгадыр төтен, без мескеннәрнең...»

Каршыдагы биек йортның ишек алды ягына чыгып, өченче катына күтәрелделәр. Габделнурны яңа хуҗага тапшырып, тегесе китеп барды. Монысы да, артык сүз куертмады, егетне ары таба алып китте. Фәкать Ленин урамындагы иске бер коммуналкада, Габделнур «Таксист»тан алган акчаны биргәч кенә, аның кулына бармак башы хәтле генә кәгазь төргәк тоттырдылар. Төргәк димәсәң, хәтере калыр, ләкин ул юан кара җеп белән урап-бәйләп куелган иде. Егетне бирегә алып килүче чыгып киткән иде инде. Бүлмә хуҗасына рәхмәт әйтеп (уймак кадәрле генә ул нәрсә үзенә

булмаса да), йомышчы, җинел сулап, китеп барды.

Кемнәр алар, нәрсә бирде соңгысы—ул төпченеп тормады—аның вазифаларына керми. Аның бурычы—йомыш үтәү. Ә калганы... Шулай да ул эченнән генә фикер йөртте: конспирацияләре көчле, болардан Ленин бабай үзе көнләшерлек шәп революционерлар чыгар иде. Беренче кеше фәкать икенчене генә белә, ә калганнарын юк, икенче—соңгысын күрми, өченче—беренче белән очрашмый, дүртенче—беренче һәм икенче белән аралашмый. Кызык система... Алай-болай эләксәләр... Ләкин бу турыда уйлыйсы килмәде егетнең. Ул бит кәгазь эчендә нәрсә ятканын белми. Хәтта ничә сум түләгәннәрен дә... Шулай да бу үз-үзенне алдау, борчулы күңеленне тынычландырырга тырышу гына иде. Чөнки Габделнур үзе дә ниндидер ярамаган эшкә бәйләнде. Биш яшьлек сабый түгел, ак белән караны аера ала, күзе белән күрмәс борын ук аның ниндидер тыелган әйбер икәненә төшенде бит. Димәк, алар кулланачак нәрсә дә, алар кылачак гамәл дә канун кысаларына сыймый торгандыр... Аннары, ул—барысын да таный. Дөрес, аның бу алыш-бирештә дәхеле юк, ул очраклы рәвештә генә мона дучар ителгән кеше. (Егет үзен шулай дип юатты.) Әмма моның ахыры хәерсез бетәргә мөмкин, дигән гасабилы халәт, пошынулы уйлар, аны бимазалап, юл буена озата барды. Малай чактагыча суга таш ыргытсаң, түгәрәк хасил була һәм ул зурая-зурая тарала. Әнә шул бер бәләкәй генә ташның суга төшүе кирәк... Ә монда, күрәсең, аның беренче тапкыр йомыш үтәве хата булгандыр. «Соңгы тапкыр булсын. Гелән генә сүз тыңлап, баш өсте дип тору ярамас, аңардан йомышчы малай ясамасыннар,—дип салкын кан белән фикер йөртте.—«Ул» халыкта иман юк. Этне дә бит, җаны чыкканчы этлеген итә, диләр. Әгәр өзлексез бәйләнә, үтенә башласалар, бүтән участокка күчерүләрен сорармын. Теге электрик та бәлки болардан туеп больниска кереп яткандыр әле. Энергетикка хәлне аңлатырмын, мин болардан чистый гарык булдым, диярмен...

## VIII

Дүшәмбе көнне, эшкә килгәч, Габделнур төксе чырай күрсәтмәде, кечкенә төргәкне Раилгә бирде. Егетнең башы күккә тиде.

—Рәхмәт, рәхмәт,—диде шатлыктан авызын җыя алмыйча.

Һәм ул, элек тә карусыз егет, кая басканын да тоймыйча, Габделнур ни кушса, шуны йөгерә-йөгерә үтәде.

Төштән соң, бераз югалып торды да, сөмсере коелып, кайтып керде.

—Хана! Анда—шмон!—диде ул һәм кулдашының алар телен-жаргонын бигүк аңлап җиткермәвен сизенеп, шәрехләп бирүне кирәк тапты.—Тентү. Бөтен җирне актарганнар. Бер падла аркасында... Итәкләрен җыеп йөрмиләр... Баландадан юньлерәк «хава»—ризык күрсәләр, дөньяларын оныталар... Габделнур, егетләрне монда дәшсәм, ачуланмассыңмы?

—Килсеннәр,—диде Габделнур иннәрен сикертеп.—Ничәү соң алар?

—Өчәү. Үз кешеләр.

—Ярар.

Ризалык алгач, Раил:

—Габделнур, үзеңә генә бер сүз әйтимме?—диде.

—Нәрсә?

—Минем корешлар сиңа ни генә тәкъдим итсә дә, алардан әйбер алма, файдаланма.

—Ә минем уйлаганым да юк.

—Бик дөрес эшлисең. Алардан бәйле булуың бар. А я не хочу чтоб ты «на крючке был». Бу сөйләшү икебезнең арада гына калсын. Мин сиңа аны әйтергә тиеш түгел идем.

—Анладым.

Аннары Раил әшнәләрен чакырды. «Кунаклар» хуҗаларны көттереп ялыктырмады. Алар берәм-берәм җыелдылар: инде таныш «Таксист», икенчесе—озын буйлы, тар җилкәле, авылчарак кыяфәтле егет, өченчесе—агарган чырайлы, какча гәүдәле, усал карашлы яшь кенә бер нәрсә. Барысы да «кер күтәрә» торган кара киемнән.

Әле шушы минутта гына ашыгыч эше булмаганлыктан, хуҗа тышка күз салып керде дә будкада калды.

Башларыннан бүрекләрен, өс киемнәрен салгач, «Таксист» кесәсеннән Габделнурга таныш бәләкәй кәгазь төргәкне чыгарды. Яшь адәм газит ертты, Раил, папиросның тәмәкесен изеп, теге улаксыман итеп тоткан газиткә бушатты. «Таксист», әлеге дә баягы кәгазь төргәкне сүтеп, газит өстенә бераз гына ниндидер яшькелт нәрсә койды. Калганын кире төреп, кесәсенә яшерде. Орчык хәтле «кәҗә сыйрагы»н кадерләп, төкерекли-төкерекли тәмәке төрделәр. Габделнур көлеп куйды. Элек авылда ир-атлар шулай итеп, җилдә яргаланган иреннәре белән ялый-ялый махра төрәләр иде. Раил, шәһәр егете булса да, авыл агайларыннан ким кыланмый: бик пөхтә итеп, ипләп, ашыкмыйча гына, рәтен белеп эш итә. Күрәсең, бу «җаваплы» эшкә беренче мәртәбә генә алынуы түгел. Аннары өлкән иптәшенә сузды.

«Таксист» аны авызына капты, көйрәтеп җибәрде. Ике-өч тапкыр төтен йоткач:

—Мә,—диде.

Раил дә, тулышып торган кызгылт яңакларын эчкә батырып, тирән-тирән итеп өч мәртәбә суырды һәм ач яңаклыга тәкъдим итте. Озын торык, моны абайламыйчарак, кулын сузган иде, кечкенә егет ана күзенең агы белән генә карады.

—Ашыкма, үз җеназаңа һәрвакыт өлгерерсең,—диде ул авызын кыйшайтып, мыскыллы елмаеп.—Халык спорты белән шөгыльләнмәкче буласың.

—Нәрсә ул?

—Халявага яшәү.

—Нишләп кеше исәбенә, бушка булсын, мин бит бирдем.

Сүз акча турында бара иде, күрәсең.

—Ярар, шаярттым. Барыбер, үбешергә ашыккан шәрә хатын кебек кыланма, өлкәннәрдән алда кулыңны да сузма. Әле монда без—«фартовой егетләр» бар. Не надо «переть буром»!

—Кем өлгер—шул ашый,—дигән булды теге ялагай елмаю белән елмаеп.

Кәтәнә егет, нәкъ тегеләр кебек итенгәч, «кәҗә сыйрагын» дүртенчегә бирде. Габделнур шуңа игътибар итте: берәү дә өч тапкырдан артык суырмады. Һичкем, миңа арыслан өлеше тия, дип дәгъваламый. Аннары, шул рәвешле, тәмәке тагын бер әйләнеш ясады.

—Ништяк!—диде Раил күзләрен йомып.

—Клево!—дип раслады кечкенә егет.

Чит кеше йогынтысына җиңел бирелүчән озын егет әле тегеләр кебек караклар жаргонында сөйләшә белми икән.

—Шәп!—дию белән канәгатьләнде.

«Таксист», үз кеше итеп, Габделнурга:

—Друган, бер генә суырып кара,—диде.

—Юк, мин тәмәке тартмыйм.

—Бу бит—«план».

—«Женатая дура»,—дип сүз кыстырды бәләкәч.

—Анысы нәрсә?—дип сорар булды Габделнур үзенең ни-нәрсә алып килгәнен белер өчен генә.

—Урта Азия якларында аны бик яраталар,—дип кенә әйтте «Таксист».

—Ярар, үзегез генә рәхәтен күрегез инде,—диде будка хуҗасы көлеп.—Ә мине, биредә юк, дип уйлагыз.

Габделнур бу алтын тешле адәмнең «балык»—ягъни шома кеше икәнен сизеп алган иде инде, теге ачылып китмәгәч ул да соравын кабатламады.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар: әгәр син аларның тәмәкесен тарттың, яисә ризыгын каптың икән, икенче юлы үзең сыйларга тиеш буласың. Бу—шулай кабул ителгән һәм аны бозарга беркемнең дә хакы юк. Бозган кешегә—җәза! Монда озак еллар нарда ятучылар яңа килгән яшь-җилбәзәк хулиганнарны, аңгырарак беренче тапкыр эләккәннәрне әнә шулай башта сыйлап, ашатып кулга төшерәләр. Әгәр түли алмаса—«натуралата».

Кронштадтта үзбәк егетләре белән хезмәт итсә дә Габделнурның «план» турында берни дә ишеткәне юк иде. Аларның мондый нәрсәне авызларына алганын да күргәне булмады, хәер, гомумән тәмәке дә тартмыйлар иде бугай. Бәлки яшь булганнардыр «затлы» нәрсәләрнең тәмен белергә. Егетнең исенә төште: авылда вак салучы бер-ике агай бар иде. Насвай дип йөртәләр иде шикелле тел астына сала торган ул тәмәкене. Мөгаен шул ук гадәти махорка булгандыр инде ул. Гади авыл кешесенә каян тәтесен кыйммәтле «план» ише нәрсәләр?! (Габделнур гашиш, анаша кебек әйберләрнең зеклар жаргонында «план» дип йөртелүен бу участоктан киткәндә дә белмәде.)

Бераздан тегеләрнең дүртесенең дә йөзләре кызарып-бүртенеп чыкты, күзләре түгәрәкләнде, бер-беренә карап, тиктомалдан елмая-көлә—ягъни, кылтыйлана башладылар. Тартынып тору да бетте: бәләкәй гәүдәле, кара курткасын салып, майкачан гына калды. Аның бер кулбашына «Бог не фраер—все простит» дип язылган, ә икенче кулында «Крови нет—менты попили» дигән татуировка.

Буыны сыекланган Раил, артка авыбрак, сул кулы белән төртеп күрсәтеп, тәне язулы егеткә карый.

—Чиграш, ты че в натуре?! А?

Наколкалы да елмая, аның да бөтен саны йомшаган, ул да Раилгә таба бармагы белән төртә.

—Кореш, әйдә японча «чирикать» будем!

—Японнарның гайбәтен сатабыз, диген.

—Япон кызы белән урыс егете танышалар икән. «Сукасимо», ди японка. «Кобель Иван», ди егет.

—Юк, кыз белән түгел, егет белән таныша урыс. Теге әйтә: «Накасико Сукосино». Ә Иванның ачуы килә: «Накоси сам сукин сын»,—ди.

Боларның кыланышларына карап утыра торгач, Габделнурның исенә төште: малай чакта, чишмәдән югарырак урында, яр өстендә тилебәрән үсә иде. Өлгергәч, малайлар аның орлыгын учка уып ашыйлар һәм әйлешәйле йөриләр иде... Олыларның, тилебәрән орлыгы ашаган нәрсә, дигән сүгенү сүзләре дә хәтерендә. Малайлар ул эшне балалык юләрлеге белән, кызык өчен эшлиләр иде.

Ә болар... Болар исә минутлык ләззәт алыр өчен, кәеф күтәрү өчен, күпмедер вакытка гына булса да мондагы ачы тормышны онытып тору өчен үз-үзләрен мәҗбүр итәләр: теләсә нәрсә кабалар, тарталар, эчәләр. Уйлап карасаң, аларның ни шатлыгы бар соң? Айлар, еллар буена сузылган гел бертөрле ялыктыргыч, кешене изә, сыта торган, бүгенге көн кичәгесеннән берние белән дә аерылмый торган яшәү шартлары. Әйләнә-тирәндә һаман шул аксыл чырайлы, каш астыннан сөзеп карарга гадәтләнгән ачулы йөзләр, такыр башлар, кара кием; усал «вертухайлар»—контролер һәм надзирательләр; кая барсаң да өстеннән чәнечкеле тимер чыбык сузылган биек койма, каравылда торучы кораллы часовойлар—солдатлар, өстенә ябырылырдай

булып һаулап өрүче усал овчаркалар; көненә алтмыш тиенгә генә исәпләнгән, туклыклыгы ташка үлчим булган гел бертөрле затсыз, ярлы ризык—бурда (анысы да җитми), шуның нәтиҗәсе буларак туберкулез һәм башка авырулар... (Габделнур кебек тулай торакта яшәүче егетләр гади ашханәләрдә дә бер утырганда бер сумлык ашыйлар.) Һаман шул бер үк кешеләр, усал юморга, төрттерел әйтүгә, чеметтерү-тешләүгә корылган шаярыш-үртәш, авызга алмастай оятсыз сүзләр... Кешенең кешелеген изү, түбәнлеккә төшерү, хәкарәт кылу һәм аны мәсхәрә итү өчен, бу «тормыш»ны белмәгән ир затларның да (хатын-кызны әйткән дә юк) уена килә алмастай ысуллар куллану... Туган-тумача, кардәш-ыру, агай-эне дип, якыннарың белән йөрешү юк, кунак-төшемнең ни икәнен оныту; хатын-кыз итәге күрергә тилмереп узган гомер, ярату, сөю-сөелү кебек изге хисләрдән мәхрүм калган яшьлек еллары... Бүген дә шул, иртәгә дә, берсекөнгә дә... Түзеп кара шуңа үкереп еламыйча! Сыгылып төшмичә башыңны югары, гәүдәңне төз тотып йөреп кара! Дошманыңа түгел, дустыңа да сер бирмәскә тырышып яшәп кара!.. Блатной җырларда гына бар ул төрмәнең, тоткын булуның романтикасы...

Кечкенә егет, Раилгә карап:

—Ә син хәтерлисеңме?..—диде.

Шуннан ул үзара булган нindидер күңелле хәлне сөйли башлады. Аны «Таксист» бүлдерде. Ул да мәлҗерәгән, күзләре пыялаланган.

—Казанда бер генә кара такси бар иде, ул да булса—минеке. Их... әле әбекәй, ягъни, теща искә төште. И бу сыйлый мине, и сыйлый, мине ярата икән, дип уйлыйм. Ә баксаң, аның рәте бар икән: ул, зараза, кызы өчен тырыша икән, минем гайрәт көчле булсын, кияү кызның күңелен яхшылап күрсен, дип тырыша икән.

Изелеп төшкән озын егет, урталай бөгелеп, мәхәббәт маҗараларын искә ала.

Әңгәмә шулай дәвам итә, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә «кәеф тоталар». Кисәк кенә кемдер көлеп җибәрә дә дәррәү ана кушылалар. Бәләкәй генә будка эче ашу-гөр килеп тора, чак кына күтәрелеп китми.

Берсе әкрен генә җыр сузды.

> Не надо печалиться,
> Вся жизнь—впереди.
> Вся жизнь—впереди,
> Разденься и жди...

Аны бүлдереп, икенчесе такмаклый башлады. Үзе бармаклары белән өстәлгә сугып такт биреп тора.

Бераздан Раил, уйга талып, моңсу җыр көйләде. Тавышы ярыйсы гына иде егетнең: җыр сүзләренә тәңгәл килә торган, моңлы аваз.

> ...Эх судьба, моя судьба,
> Ты как кошка черная...

Габделнурга аларның кыланышларын күзәтү кызык булса да, колагы һәрчак сак, ишек ягына таба борылган иде. Тагын бераз тыңлап утырганнан соң ул кузгалды. Чөнки будка эче зәп-зәңгәр булды, кем әйтмешли, хет балта элеп куй. «Кәҗә сыйрагы» отыры кыскара барган саен тегеләр тирәнрәк итеп суыралар да төтенен, башларын күтәреп, акрын гына борын тишекләреннән чыгаралар, үпкәләренә агу гына сеңеп кала. Раил бая ук бу якның ишеген ачып куйса да төтен таралып бетә алмый иде. Габделнурның күңеле болгана башлады, башы түбал булды. Ләкин ул моны сәбәп итмәде.

Сәгатенә карап алды да:

—Мин чыгып керим әле, кеше-кара килеп, бәлагә тарымыйк тагы,—диде.

Озын егет аңа:

—Син, фраер, бар, шухерда тор!—дип ямьсез итеп эндәште һәм урынлы-урынсыз әйтеп куйды.—Кем безгә иярми, ул—безгә каршы. Төрмәдә утырмаган кеше—кешемени ул, ул чын тормышны белми...

Габделнур кисәк борылды, Раил моны шундук күреп алды һәм ике арада кабына язган низаг утына дөрләп китәргә ирек бирмәде.

—Син, «дурогон», «прикуси болтало»!—диде ул акаеп озын торыкка.—«Базар фильтруй»! Син нәрсә, кишка, ырылдыйсың? Утыр шунда почмакта һәм ике тишегенә мышна! Иначе сам будешь стоять на атасе! Кем аркасында мондый рәхәткә тиенгәнеңне онытма! Юкса мин синең «кабагыңны сытармын»!

Ни гаҗәп, Раилдән бер башка озын егет шым булды. Чөнки «Таксист» та аңа күзенең агы белән ачулы карашын төбәгән иде.

Ә какча егет, сикереп тә торды һәм:

—Оборзел? Умри!—диде дә, күз ачып йомганчы тегенең янагына чалтыратып та алды.

—Үзебезнекеләрне кыйна—читләр курыксын,—диде «Таксист» көлеп.—Нәрсә, алдыңмы кирәгеңне. Мә, «чинарик»ны кесәңә салып куй.

—Бир.

«Таксист» озын егеткә тәмәке төпчеген бирде.

—Мы тебя «пригрели», рәхмәт әйт.

«Шул гына җитмәгән иде,—дип уйлады Габделнур кашларын җыерып.—Бүтәннәр дә түбәли инде бу егет сәләмәсен. Борынгыларның, эт өере берекмәс, дигәннәре хак икән. Хәзер чәкәләшү башлана... Бу «кодла» белән бәйләнсәң...»

Берәү булса, кечкенә зекны тәпәләп атар иде. Ләкин гауга шул төштә тукталды. Күрәсең, эш буйда гына түгел иде.

Теге колгасар, түбәнчелек белән елмаерга тырышып:

—Китте хәзер халык: вак, бүксәле, б...лы,—диде блатной булырга тырышып.—Чыраена төкерсәң, сугыша башлый.

Ә үзе бәләкәй егеткә ачуланмады, каршы сугар өчен бармагын да кыймылдатмады. Башта Габделнур аны авыр табигатьле, сабыр адәм, дип уйлаган иде. Ләкин, төче елмаеп, тегеләргә ярарга тырышуын, дәү этләр алдында койрык болгаган өйалды асты көчеге кебек ялагайлануын күреп тору—косасын китерде. «Шул гәүдәсе белән... Теге орык-торыкка сдача бирмәде, хет бер кәррә ипи шүрлегенә менеп төшмәде, и бичара»,—дип уйлады ул үз-үзен түбәнсеткән мәми авызга рәнҗеп.

Раил кулдашына:

—Все путем,—диде.—Син үпкәләмә инде, гафу ит. Ил каһарманнар көтә, ә...

—Ярар,—дип кул гына селтәде Габделнур.

—Сезгә гел мач килеп тора, тагын «мохнатая кража» белән эләккән берәүне китергәннәр,—диде «Таксист», күрәсең ул үзе вакланмый, боларга катышмый, андый нәрсәләрдән өстен, ерак тора иде.

—Әйе, лафа,—дип аның белән килешкәндәй итте бәләкәй егет һәм ачы елмаеп өстәде.—Суга батып үлгән кешегә җай чыккан кебек.

Габделнур сүзнең кем турында барганын аңлады, болар жаргонынннан әзме-күпме хәбәрдар, берничәсен отып та калган иде инде. Алар телендә «мохнатая кража»—хатын-кыз көчләүче дигәнне аңлата, андыйларны монда «төшерәләр». Ә болар—бәләкәй егет—«гоп-стоп» белән эләккән, ягъни, кеше талап йөргән, Раил—«щипач»—кесә карагы, озын егет—«очраклы пассажир» җинел статья белән беренче мәртәбә хөкемгә тартылган. Биредә фатир басучылар да бар,

участокта эшләүче бригадада олы яшьтәге бер адәм «медвежатник»—сейф ачучы. Хәер, алар арасында кемнәр генә юк! Алар сүз эзләп тә кесәгә кермиләр, хәйләгә дә оста, башларын да эшләтә беләләр. Кичә Раил узган ел булган бер хәлне сөйләде. Авылда кибет басып төрмәгә кергән берәүгә анасы зарланып хат яза: «Улым, бәрәңге бакчасын ничек казырмын инде син булмагач...» Бу зинданнан хат җибәрә: «Әнкәй, мин кайтканчы берүк бакчага кул тидермә, кибеттән чәлдергән бөтен акчаны да, әйберләрне дә шунда күмеп калдырдым». Җавап хаты озак көттерми: «Улым, милиция трактор белән килеп, бакчаны кат-кат актарып китте, әйберләреннә генә тапмадылар...» Улы янә хат юллый: «Әнкәй, бакчаңны сөрдереп бирдем, бәрәңгесен алуны үзең кара инде...»

Зеклар гәп корудан—корыны бушка әйләндерүдән тукталмаганнар иде әле. Боларнын «тормыш фәлсәфәсе»н, дөресрәге, сафсатасын тыңлыйсы килмичә, будка хуҗасы урамга, саф һавага чыгып китте. Чөнки күңеле болгана иде.

Озакламый «кунаклар» да берәм-берәм таралыштылар.

## IX

Габделнур апрель башында ук кирәкле кәгазьләрне хәстәрли башлады. Ә алар шактый күп булып чыкты. Идарә башлыгы белән баш механик һәм профсоюз комитеты рәисе кул куйган характеристика-тәкъдимнән тыш, әле тагын партия оешмасыннан да аерым кәгазь таләп ителә икән. Алар шелтәсез эшләгән тырыш электромонтерны берсүзсез фәкать уңай яктан гына тасвирладылар. Тәрҗемәи хәлен үзе язды, хезмәт кенәгәсеннән өземтәне кадрлар бүлегеннән алды. Поликлиникадан медицина карточкасын юнәтүдә дә кыенлык тумады—сәламәтлеге яхшы иде. Хәтта йортлар идарәсеннән дә белешмә кирәк булып чыкты.

—Уф,—диде ул, Иреккә зарланып, авыр эш эшләп талчыккан кешедәй.—Армиядә бу кадәр күп кәгазь җыйдыртмаганнар иде.

—Чагыштырдың тагын... Гражданкада волокита күп инде.

Узган елгы абынудан соң, кабат бер елны җилгә очырмас өчен, ул «аяк астына карабрак йөри» башлады—көн-төн диярлек китап кимерде.

Тулай торакта бүлмәдәшләре, күзгә күренеп ябыккан Габделнурны:

—Коры сөяккә калды егет,—дип җәллиләр иде.

Үзе, китабына кадалган хәлдә, баш күтәрми генә:

—Кая инде,—диген була.

—Ие шул, бер дә бирешмәгән әле,—дип аны яклагандай итә Ирек һәм, көлә-көлә кабыргасына төртеп, өсти:—Коры сөяк—тач май...

...Шушы арада аларның тормыш-көнкүрешендә яңалык булып алды: Габделнурлар Жилплощадка бистәсеннән Коллективная урамына күчтеләр. Восстание һәм Кызыл Байрак урамнарындагы ирләр тулай торакларында урын җитмәгәнлектән, (яшьләр күп, һаман өстәлеп тора) шул тирәдәге урамда яңа төзелгән биш катлы эре панельле йортның бер подъездын вакытлыча тулай торак итәргә булганнар икән. Моны Габделнурга партия оешмасы секретаре Митрохин әйтте һәм үзе үк, тиешле кешеләр белән сөйләшеп, егеткә анда күчәргә булышты.

—Син читтән торып уку бүлегенә керәсең бит?

—Әйе, Афанасий Федорович.

—Барыбер университетка якынрак булуың хәерле. Ярты ел саен сессия: сынау-зачетлар, контроль эшләр, семинарлар, китапханәдә казынырга кирәк... Минем малай да эшләп укыды.

Бишенче каттагы өч бүлмәле фатирның бер кечерәк бүлмәсенә Ирек белән икесе кереп утырдылар. Габделнур Митрохинга дусты хакында да әйткән иде; милиция бүлегеннән дә кәгазь юнәттеләр.

...Егерме сигезенче май көнне иртән Габделнур университетка китте.

Беренче имтихан рус теле һәм әдәбиятыннан язма эш иде.

—Ни жон, ни каурый! —дип көлеп калды Ирек юри татарчалап.

—Жен-пәриләр янына олаксын!—дип җавап кайтарды дусты читкә төкереп.

Кич очраштылар.

—Эшләр ничек?—дип сорады дежурдан кайткан Ирек өс киемнәрен салганчы ук.

—Ярыйсы.

—Ерып чыктың алайса. Изложение яздыгызмы?

—Әйе,—диде Габделнур һәм Ирек бил каешын, портупеяларын, калын табанлы, гармун кунычлы күн итекләрен салган арада сөйләп бирде.—Сугыш темасына багышланган «Энекәш белән икәү» дигән язма эш. Афанасий Живин атлы бер солдатның дустын немес снайперы атып үтерә. Шуннан соң бу карачкы ясый да таяк белән окоптан кеше башы күрсәтә, чак кына өскә күтәрә. Снайпер бәрә моңа. Ә Живинга шул гына кирәк тә—чамалый фрицның каян атканын... Шулай итеп бик күп фашистны чүки...

—Икенче имтихан телдәнме?—дип сорады Ирек кулына сабын-сөлге тотып чыгып барышлый.

—Әйе.

Габделнур анысын дүрткә бирде, иншага да «яхшы» билгесе куйганнар икән. Егетнең эченә җылы керде. Янә китапка капланды. Һәм СССР тарихыннан хәтта бишле эләктерде. Шнейдер янында тагын бер ир-ат укытучы бар иде. Ул да, баш катыргыч сораулар биреп, әллә ни азапламады, егеткә каныкмады.

—Хәзерлек курсларына бик теләп йөрде,—дип Семен Моисеевич яклады.—Кичәге солдат бит, тәртипле егет. Белеме дә җитәрлек.

Шулай итеп, өченче август көнне белдерүләр тактасына эленгән приказда Гаделҗанов дигән фамилия дә бар иде. Куанычы эченә сыймады егетнең. Ул үзе өчен бик кадерле булган әлеге боерыкның номерына тикле хәтерендә калдырды: йөз дә унынчы. Үз күзләренә үзе ышанмагандай, игълан тактасына янә бер карады, аның яныннан китәсе килмәде. Димәк, ул—студент! Узган ел керергә омтылган юрфак булмаса да, барыбер—университет студенты! Ниһаять, хыялы тормышка ашты. Иренмичә укы гына, сынатма!

Аннан инде башланды: юнәлеш бирү сессиясе, контроль эшләр, сынау-зачетларга әзерләнү. Фәннәре дә бихисап: борынгы, СССР, КПСС тарихлары, этнография (монысы колак ишетмәгән нәрсә иде), өч тел: борынгы рус, немец һәм латин. «Тарихларын китаптан укырсың инде, ә менә телләрен ничек өйрәнәсе?—дип хафага төште яшь студент.—Бу бүлектә укуы авыр булачак икән. Хәер, берсендә дә җинел түгелдер инде. Юкка гынамы, энә белән кое казу, дигәннәр».

Башына төшсә, башмакчы буласың, диюләре дөрес икән. Тәки тырышырга, җаен табарга туры килде. Үзенә генә ышанычы аз, ерып чыгу ихтималы икеле, шунлыктан ул, деканаттан рөхсәт алып, кичкеләр белән йөри башлады. Ә нигә йөрмәскә? Өендә елап утырган бала-чагасы, нигә соң кайтасың, дип әрләүче, колак итен ашаучы хатыны юк! Иң мөһиме: укуы гына барсын.

## X

Кичке бүлектәгеләр аны, чит көтүгә эләккән ят бәрән дип, кыерсытмадылар, ә киресенчә, беренче көннән үк, аралашучан, дары иснәп кайткан эшче егетне үз иттеләр. Чөнки монда да күбесе дөнья күргән кешеләр—гаиләле ир-атлар һәм хатын-кызлар иде. Хәер, араларында узган ел яки быел гына урта мәктәп бетереп парта арасыннан чыкканнар да бар. Менә шул яшь-җилкенчәкләрнең берсе—студент кыз Габделнур өчен аерата якын дуска әверелде.

...Аудиториягә кергәч, Габделнур алан-йолан каранды да, буш урын күреп (бер кыз ялгызы гына икән), шунда таба атлады.

—Мөмкинме?

—Рәхим итегез.

Егет чак утырып өлгерде—уртача буйлы, затлы костюм кигән күзлекле укытучы хатын килеп керде. Пиджагы билен кысып тора, итәге тезләрен каплаган; ана утыз-утыз биш яшьләр биреп булыр иде. Ул өстәл артына утыруга занятие дә башланды.

Габделнур анын «Гутен абенд» дигән кичке исәнләшү сүзен генә анлап өлгерде, ә калганына зиһене житмәде. Көлеп куйды. Кронштадтта ГДР эсминцы матрослары белән якыннан аралаша алмадылар шул. Хәзер кирәге чыккан булыр иде. Мунча юлындагы гәпләшү фәкать икешәр фразадан гына торды: безнекеләр «Гитлер капут!» дип «тәбрикләделәр», ә тегеләр «Руссиш швайн!» дип «зурлап» жавап кайтардылар. Дипломатлар теле белән әйткәндә, эчкерсез, дусларча әнгәмә шунын белән вәссәлам. Габделнурның немец телен белү-анлавы моның белән генә бетмәгән икән әле. Германиядә хезмәт иткән абыйсы урамда кызлар очраса: «Вас заген зи?» дип тегеләрне аптырата иде. Ягъни, нәрсә дип әйтәсез? Кызлар, сукыр тавыкка бар да бодай дигән шикелле, анламасалар да шырык-шырык көләләр. Гатуф абыйсы тагы немецча жибәрә: «Вас лахен зи?» Ягъни, нигә көлүләрен беләсе килә. Кызларга тагын кызык. Койма ярыгында бармак күргәч көлгәнне, нindидер ят телдәге сүзләрдән көләләр дә көләләр инде алар. Немец телен яхшы белүчеләр авылда да бар: әсирлектә өч ел жәфа чиккән жизнәсе. (Галләм абзыйның уртанчы сенлесе Миннафа түтинен ире.) Бераз «төшерсә», ул тозлап-борычлап фашистларны үз телләрендә искә ала иде. Ә монда, занятиедә... «Күп яттык без мәдрәсәдә, анламадык бернәрсә дә...» дигән шәкертләрдәй, Габделнур бер сәгать чит кеше капкасы төбендә аптырап торган мингерәү сарык шикелле авыз ачып мөгаллимәгә карап утырды.

Күрәсен, анын шикелле «ангыра бәрән»нәрнен аудиториядә шактый булуын сизенгәндер—икенче сәгатьтә укытучы рус теленә күчте.

—Ана жинел, ул ике телне дә су урынына эчә,—диде Габделнур янындагы кыз, гәрчә үзе укытучы әйткәннәрне яхшы ук төшенә иде бугай.

Мөгаллимә үзе немец кавеменнән, зыялы гаиләдән икән: атасы республикада билгеле рәссам, әнисе танылган музыкант. Кыз әүвәл консерватория тәмамлаган, бер-ике ел филармониядә эшләп алган, авыргач, сәхнәдә чыгыш ясарга ярамагач, чит телләр факультетында укыган.

Моны Габделнурга янында утырган кыз пышылдап кына әйтте. Егет ана бер-ике мәртәбә күз сирпеп тә алды. Ул кыска чәчле, бер тотамы кыйгачлап мангаена төшеп тора, ләкин биек мангаенын өчтән бер өлешен генә каплый. Соргылт чәче астыннан колак очлары һәм аларга тагылган алтын алкалары күренеп тора. Чәче төсендәге күзләре артык зур түгел, әмма бик тере, жанына керердәй булып үтәли карыйлар. Озын керфекле күзләрен сирәк йома, монысы—ихтыяр көче зур булу билгесе. Дугайланып килгән кашлары калынча. Тулы күкрәкле кызның өстәлдә яткан куллары ап-ак, озын бармакларынын тырнаклары житү түгел, әмма лакланган-буялган—аларга бертөрле нәфислек бирә. Кызнын үзеннән затлы хушбуй исе бөркелә иде.

Занятиеләр беткәч Габделнур аны күрми дә калды—соргылт чәч тиз арада каядыр юкка чыкты. Икенче көнне Энже (кызнын исеме шулай икән) аны үзе чакырып алды: әллә янә буш урын булган, әллә махсус алып калган—монысы егет өчен караңгы иде. Хәер, ул бу турыда артык баш ватмады—бөтен дикъкате занятиеләргә тупланган. Бәләкәй чакта малайлар

урамда такмаклыйлар иде: «...Кызлар кайгысы юк әле, ашарга бетеп бара». Шуның шикелле, бөтен күнелен укуга салган егетнең әле бу тирәдә кызлар куарга исәбе дә юк иде. Дөресен генә әйткәндә, бу чибәр кызның: «Алдыр алъяпкычлары, гөлдер алъяпкычлары, юк дисәң дә бардыр әле күңел юаткычлары», дигән җырдагыча егете дә юк түгелдер.

Шул рәвешле ике атна узды, әмма...

Бүген Энҗе, Габделнурны беренче тапкыр күргәндәй, аңа текәлеп карады һәм кырыс кыяфәтле, буй-сыны килешле егет хакында, ярыйсы гына икән бит, дип фикер йөртте. Ул аның кыска кара чәчле һәм куе кара кашлы булуына да, яңак сөякләре чыгынкырак ябык йөзенең чиста икәненә дә, иягенең урталай аерылып торгандай булуына да, зәңгәр күзләренең беркатлы кешеләрнеке сыман юашрак каравына да игътибар итте. Дөрес, киеме энә-җептән түгел, ләкин бар булганы юылган-үтүкләнгән, галстугы да кыйшаеп тормый, армиядән калган пөхтәлек тә сизелә.

Һәм үзеннән-үзе шулай туры килде: алар университеттан бергә чыктылар, җәяүләп Ленин урамы буйлап Кремльнең ап-ак Спасс башнясына карап киттеләр, Кави Нәҗми урамы чатына житкәч сулга борылдылар... Андый чакта аяк та атлый тора, сүзе дә табыла тора...

Троллейбуста һәрвакыттагыча кеше күп—тыгын, шуңа күрә Габделнур каршына баскан Энҗе бөтен гәүдәсе белән аңа сыланып, беләгенә ябышып кайтты. Ул башын борганда йомшак соргылт чәчләре егетнең яңагына тиеп-тиеп китә, колак яфрагын кытыклый иде.

—Сез кайсы тирәдә торасыз?

—Чистопольский тукталышында төшәм.

—Анда йортлар юк бит.

—Ник булмасын?

—Мин зур, биек йортлар, дип әйтмәкче идем.

—Ә миңа үз йортымда яшәргә ярамыймыни?

Чыннан да, ник ярамасын—бик ярый, билгеле. Ләкин барыбер Габделнурга Энҗе кебек бик модный киенгән, баш-аягы белән шәһәрнеке икәне әллә каян күренеп торган кызның гап-гади авыл өендә (ә ул тирәдә нәкъ шундый йортлар гына бит) яшәве бераз сәеррәк тоелды. Ул бит төзелештә буяучы, бетончы, подсобница булып эшләргә язмыш тарафыннан мәҗбүр ителгән авыл кызларының берсе түгел...

Озын буйлы, таза тәнле, ләкин аны симез дип әйтеп булмый, шулай да берәр бала тапкан хатыннарныкыдай тулышып торган гәүдәсенә бик килешле затлы көзге пальто, тыгыз балтырлы озын, төз аякларына кыска кунычлы матур сапожки кигән Энҗенең менә хәзер, бераздан, авылча салынган һәм җиһазланган өйгә кайтып керүен егет күз алдына китерә алмады.

Янә үзеннән-үзе шулай килеп чыкты: егет троллейбустан Энҗе белән бергә төште һәм янәшә атлап китте. Кыз, озатма, миңа тагылма, дип сүз куертмады, аны каршы алучы егет-җилән дә күренмәде.

—Курыкмыйсыңмы?—дип сорады Энҗе тукталыштан берничә адым киткәч һәм, башын кыңгыр салып, сынаулы караш ташлады.

Егет:

—Нәрсәдән?—ди сорауга сорау белән җавап кайтарды.

—Безнең тирә егетләреннән.

—Алар шулай куркынычмыни?

—Кем белә...

Габделнур сөйләшүне уенга борды, «еламсырап»:

—«Апа», мине үзегезнең оч малайларыннан якларсың инде, кыйнаттырмассың, яме,—диде.

Энҗегә юмор ошады, кычкырып көлеп җибәрде, егетне култыклап алды.

—Ярар, «энекәш». Мөмкинчә тырышырбыз.

Берникадәр юл үткәч, Габделнур туктап, артка борылды һәм, заманында чиркәү булган, ә хәзер «Октябрь» кинотеатрына әверелгән зур кызгылт бинага—сулга таба төртеп күрсәтте.

—Әнә тегеләр килә.

Үз уйларына чумган Энҗе аңышмыйча калды, ахры, җитди тонга күчеп сорады.

—Кемнәр?

—Койрыклы җеннәр!

Бу юлы икесе дә көлделәр, аннары гәпләшә-гәпләшә ары юлландылар. Сөйләшкәндә Энҗенең тавышы әллә каян йөрәк түреннән чыккан кебек—тонык, саңгыраурак сыман, ләкин тупас түгел, мөнәҗәт әйткәндәй көйле-матур чыга. Ул тавыш ничектер монотонно, кешене үзенә җәлеп итә торган, хәтта ки, әгәр шулай әйтергә яраса—моңлы тавыш.

Габделнурның бу тирәне транспортта узып барышлый ерактан гына күргәне бар иде. Ләкин хәзерге кебек, алма бакчалары, таза өйләр, төзек ихаталар тезелеп киткән урамы буйлап узганы юк иде әле. Егеткә таныш Каравайны хәтерләтә иде бу Савиново бистәсе, тик яше өлкәнрәк булса кирәк—иске йортлар күп.

—Тулай торакта яшәве читенме?—дип сорады Энҗе

—Бер өйрәнгәч әллә ни түгел. Мин авылдан ундүрт яшьтән чыгып киттем... Армия дә шул ук тулай торак инде, режимы гына катырак...

—Ә мин яши алмас идем.

—Башыңа төшсә—башмакчы булырсың.

Шуннан кыз үз фикерен әйтер булды.

—Минем уйлавымча, бер күчкә өелеп яшәү—дөрес түгел. Табигатьне генә алыйк. Агач ботаклары ни өчен тарала, өскә таба үрли, ян-якка омтыла? Чөнки яшәү өчен шартлар кирәк: туклану, яктылык, бер-береңә комачау итмәү... Кешеләр дә тарау яшәргә, һәркемнең үз йорты булырга тиеш. Ә тулай торак нәрсә? Ул—табигатькә каршы килү.

«Сиңа сөйләве җинел», димәкче иде дә, Габделнур дәшмәде, тагын ни әйтер икән бу иркә шәһәр кызы дигәндәй, Энҗене тыңлап карарга булды. Ә кыз дәвам итте.

—Мин аңлыйм: төзелеш, авылдан килүчеләр күп, аларны каядыр урнаштырырга кирәк, фатирлар юк... Үзең укып беләсең: совет чорының башлангычында гомумән абсурд, мәгънәсез фикерләр булган, янәсе, кешеләр күмәк йортта, бер юрган астында яшәргә, гомуми ир һәм хатын, бала-чага...

Габделнур түзмәде, үз фикерен кыстырды.

—Монысын арттырып җибәргәннәр инде. Алай булмый. Кыргый җанварлар да аерым-аерым оя кора. Дөрес, төркем-төркем булып җан асраучылар бар, кешеләр дә кабилә-кабилә булып көн күрә...

Егет моны бигрәк тә кызның уй сөрешен аңлар өчен әйтте. Ләкин Энҗе аңа тел төбен белгертмәде, ә җайлап кына бу темадан читләште. Ул китап күп укый икән, әле хәзер өстәлендә Джон Голсуорсиның «Форсайтлар турында сага» романы икән. Кыз опералар ярата булып чыкты. Джакомо Пуччининың «Чио-Чио-Сан», «Турандот», «Тоска» операларыннан Калаф, Каварадосси, Чио-Чио-Сан арияләрен санап үтте, рус композиторларының исемнәрен атап, аларның әсәрләреннән дә мисаллар китереп сөйләде. Әлбәттә, болар Габделнур өчен билгеле нәрсәләр түгел иде. Шунлыктан ул кызны тыңлап кына барды. Һәм гарьләнү хисен тоеп, аның ни өчен бу

темага кагылуы хакында баш ватты. «Чыннан да сәнгатьнең ул жанрын яратамы, әллә мине сынар өчен генәме?» Кыз шушы араларда Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында «Шүрәле», «Миссисипи чәчәге», «Севастополь вальсы» спектакльләрен караган икән.

—«Качкын»га бармадым, аны бер күргән идем инде,—диде ул.—Ә менә «Аккош күле»н тагын бер рәхәтләнеп карадым.

Бу өлкәдә бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел икәнен исбатлау өчен, Габделнур, бергә хезмәт иткән Мәскәү егетеннән ишеткән, итальян композиторы Россинига кагылышлы мәзәк сөйләп ташлады.

—«Бер таныш байның җәзалау кораллары тупланган зур коллекциясе бар»,—ди икән моңа күршесе. «Ә аның фортепьяносы бармы?»—дип сораган Россини. «Юк»,—дип җаваплаган күршесе. «Димәк, аңа бала чакта музыка укытмаганнар»,—дип әйткән ди Россини.

Энже көлеп куйды.

—Желегенә төшкәннәр икән мескеннең.

Татарча сөйләшкәндә Энже кайчак сүз таба алмыйча интегә, күнелендә туган уен тиз генә әйтеп бирә алмыйча аптырый, гажизләнә, чөнки ул аны урысчадан татарчага тәрҗемә итәргә мәҗбүр була. Кыз җәфалана, әмма вата-җимерә булса да ана телендә әйтергә омтыла. Андый чакта ул колакка ятышсызрак сүзләр дә ычкындыргалый, Маяковский шикелле яна сүзләр уйлап чыгара. Мисал өчен, гәүдәләндерә сүзе анынча гәүләндерә була, кыз, шуның аркасында, дип әйтә белми, ул аркада, ди, Советлар Союзы күләмендә диясе урынга, ул Советлар Союзының күләмендә дип әйтә, фәлән галим фәлән ачылыш ясады, ди...

Өтегрәк телле шәһәр кызы белән янәшә атласа да гел үз авылы урамыннан кайткан шикелле тоелды егеткә, аерма тик шунда: юлга асфальт җәелгән дә өйләргә газ кергән. Һәм ул ничектер кимсенү, рәнҗү тойгысы кичерде. «Илленче еллардан бирле нефть чыга, тирә-юньне яктыртып, кирәкмәгәнгә басу җылытып көне-төне газ яна, ә халык утын ягып чиләнә,—дип уйлады ул туган авылы халкын җәлләп.—Утын әзерләргә урманы булса иде ичмаса...»

Урам яктан өч тәрәзәле, юан нарат бүрәнәдән салынган биек йорт каршында туктадылар. Ике тәрәзәдә ут яна, гөлләр күренә, челтәрле пәрдәләр корылган. Өч баганалы биек урыс капка ихата эчен күрсәтми каплап тора, ә менә өй каршындагы койма араландырып рәшәткәдән коелган, тәбәнәк. Яшьләр килеп туктауга ук бәләкәй капка ачылды һәм өстенә бишмәт кигән, башына яулык бәйләгән бер хатын-кыз пәйда булды. Күрәсең, ул кызын көтеп торган ана кеше булса кирәк.

—Тагын кем белән торасың?

Энже теләр-теләмәс кенә җавап бирде.

—Курсташ озата килде, борчылма. Хәзер керәм.

Бүтән бер сүз дә әйтмичә хатын капканы эчтән япты, ләкин биге шакылдаганы ишетелмәде.

Кыз егеткә озатып куюы өчен рәхмәт әйтте, Габделнур аңа тыныч йокы теләде. Берсенең дә озаклап торырга исәбе юк иде.

Кайта-кайтышка егет кызның әнисе сүзләрен хәтерендә яңартты: «Тагын кем белән...» Димәк, еш алыштыра булып чыга. «Хәер, миңа дисә, ник көн саен бүтән берәү озатмый...»

Ләкин бүтән берәү түгел, ә Габделнур үзе Энҗене озата башлады. Бер мәртәбә өйләренә дә керде. Анысы, шул тирәдәге йортларның берсендә янгын чыга язып, Габделнурның шырпы белән шаярган дүрт-биш яшьлек малайны коткарганнан соң булды.

Өй эчендә ут күреп алган кибет каравылчысы, акрын гына гәпләшеп

кайтып килүче пар каршына ашыга-кабалана килде.

—Энже, яхшылабрак карагыз әле, кызым, Раузаның өендә ут бар түгелме?

Чыннан да, абзый күрсәткән өйнең караңгы тәрәзәләрендә сыек кына ут шәүләсе уйнаклый иде.

Габделнур озын-озак уйлап тормады.

—Бабай, бир кожаныңны! Өйдә кемнәр булырга мөмкин?

—Анда бәләкәй малае белән ялгыз хатын гына тора,—диде озын гәүдәле, түгәрәк сакаллы карт кожан төймәләрен ычкындырып.

Егет тиз генә аның башлыклы брезент кожанын киде дә атылып ихатага керде. Өйалды ишеге тыштан таяк белән терәтелгән иде... Габделнур, караңгы булса да, өй ишеген дә тиз генә таба алды. Бәхеткә, идән уртасында палас кына яна иде. Кожанын салып, башта утны кыерлады, аннары бөтенләй томалады. Ул арада каяндыр бала елаган аваз ишетелде. Егет ишек катындагы выключательне тапты. Караватт астыннан аягы күренеп торган баланы сөйрәп чыгарды... Эш зурга китмәде... (Соңыннан ачыкланды: анасы, баласын яткызып, йомыш белән шул тирәдәге иптәш хатынына киткән булган. Бала йокламаган, торып, шырпы кабызган.)

...Инде биредә үзенең кирәге югын аңлап, Габделнур, кыз белән саубуллашып, китеп бармакчы иде. Энже аны ай-ваена карамыйча өйләренә дәште, юындырды. Кызның әбисе егетнең пешкән кулына нindiдер май сөртте. Шунда Габделнур йорт хуҗалары белән дә танышты. Энже аны хәтта куна калырга да кыстады, ләкин егет риза булмады. Бу хәл аларны тагын да якынайтты, кыз каршында ул бермә-бер үсеп китте. Шул четерекле минутларда каушап калмаган куркусыз егет кызның якыннарына да ошады.

Габделнур да эш кешеләре булган бу гади семьяны үзенчә якын күрде. Энженең әтисе шәһәр яны маршрутында йөрүче автобуста эшли икән, әнисе—билет сата, кызлары да шул ук автохуҗалыкта—диспетчер.

...Радио тавышына уянып киткән Габделнур күзләрен ачты һәм күрде: сул як дивар алсу-шәмәхә төскә кергән, анда тәрәзә рамнарының һәм пыялага ябыштырылган чәчәкнең күләгәләре бар; бераздан дивардагы алсу-шәмәхә төс әкрен генә юкка чыкты, утыны янып беткән учак кебек сүнде.

Егет, торып, тәрәзә каршына килде. Башнялары белән Кремль аермачык беленеп тора. Торбалардан күтәрелгән төтен алсу-кызыл төскә манылган, ике сажин чамасы өскә күтәрелгән кояш бераздан болытлар арасына керде. Шулай да аның нурлары бөтен офыкны яктырта, Казансу елгасының теге ягында, калкулыкта, бик биек булып кукраеп утыручы радио мачтасы нәкъ кояш турысында һәм ул урталай киселгән кебек күренә.

Габделнур яшәгән йорттан ерак түгел тезелешкән кечкенә сарай түбәләре бүген ап-ак, кар яуган кебек, чөнки кырау төшкән; сазлыкта җыелган сулар каткан булса кирәк.

Савиново бистәсе бүген ничектер матурланып киткән—ак түбәле өйләр күбәйгән, югыйсә күбесе кызылга буялган калай түбәле иде; агачлары саргая башлаган, ә бу тирәдәгеләр инде күптән сап-сары, яфраклары да коелган.

«Энже ни хәлдә икән? Торды микән? Әллә иркәләнеп ятамы җылы йомшак мамык юрган астында?» Аның өстендә Габделнурныкы кебек юка казна одеялы түгелдер. Ничәмә-ничә еллар инде егет шул юка одеалларны ябынып ята: Алабугада укыды—тулай торак, Әлмәттә эшләде—тулай торак, өч ел армия һәм Казан... Нигәдер ямансу булып китте егеткә... Уйламасаң—рәхәт. Юкка гына: «Исәпләсәм—исем китә, исәпләмимен генә...» дип әйтмиләрдер инде. Әйе, артык уй, исәп итү—үзеңә зыянга гына.

Егет, үзе гадәттәгечә физзарядка ясый, ә карашы шәмәхәсыман булып күренгән мәдәният һәм ял паркы тирәсенә, еракка күчә. Анда саргылт

яисә түмгәк-түмгәк сыман урыннар күп. Әллә каян читтән агылучы авыр болытлар әкрен генә шәһәр өстенә ишеләләр.

Якында кар бөртекләре хасил булды: сирәк-мирәк очкан күбәләкләр кебек уйнакладылар, тәрәзә турысыннан үткәләделәр, ахырда бөтендәй югалдылар. Аларны каргалар, чәүкәләр алыштырды.

...Якшәмбедә, көндез, Энже белән «Октябрь» кинотеатрында «Яшәгән ди бер кыз» фильмын карап чыккач, егет аны тулай торакка чакырды. (Ирек дежурствога киткән иде.) Кызны үзенеке итү өмете дә юк түгел иде. Һәм ул ялгышмады: бик җиңел генә, бернинди каршылыксыз теләгенә дә иреште.

...Габделнур кызны коча, үбә башлагач, Энҗенең тутырган тавык кебек таза, тиресе калынайган тәне тәмам мәлҗерәп төште—хәлсезләнде, үзе егеткә сарылды, суырып-суырып үбәргә тотынды һәм йомык күзләрен ачмыйча гына пышылдады.

—Ишегеңне бикләә инде...

...Кичен янә шул ук кинотеатрда «Оклахома» дигән картина карадылар. Егет кызны өенә хәтле озатып куйды. Энҗенең аны тиз генә җибәрәсе килмәде: озаклап-озаклап назлады, иреннәрен кабартканчы кат-кат үпте...

## XI

Габделнур участок почмагындагы электр баганасы янына килде. Аның бер кулында «тимер тырнак»лар, икенчесендә, картон кәгазь эчендә, бала башы хәтле, биш йөз ваттлы зур лампочка, билендә—чылбырлы киң брезент каеш. Ул ашыкмыйча гына резин итек өстеннән «тимер тырнак»лар киде, аларның каешларын яхшылап эләктерде. Багана төбенә якын ук килеп, чылбыр белән аны уратып алды да карабинлы очын каешның уң ягындагы боҗрага кигертте. Багана төбендәге лампочканы сул кулына тотты. Уң аягын чак кына күтәреп, «тимер тырнак»ны агачка батырды. Шулай иплән кенә, аякларын алыштыра-алыштыра багана башына менде. Прожектор турына җиткәч (ә ул сузылган алюмин чыбыклардан астарак иде), уң кулын баганадан ычкындырды, гәүдәсен арткарак авыштырды, әйләнә-тирәгә күз салды.

КПП янындагы зур капкадан үзбушаткыч машина кереп килә, икенчесе кран янындагы тимер әрҗәләргә бетон бушата. Башнялы кран, бер әрҗәне күтәреп, фундамент турысында түбәнрәк төшерүгә, ике зек, чүкеч белән шак-шок бәреп, әрҗәне ача һәм тактадан корылган опалубка эчендәге тимер арматуралар арасына чажлап бетон коела. Ул да булмый, кара киемле ир-атлар бетон тыгызлаучы вибраторларны эшкә җигә: бөтен тирә-якка үзенә бер көйле тавыш чыгарып гөжләгән аваз тарала.

Габделнур, багана башына менсә, һәрчак аны ниндидер аңлатып бирә алмаслык эчке бер халәт—горурлык хисе диикме, биләп ала, күңелендә шатлык тойгысы барлыкка килә. Чөнки бу процесста, гомумән, участоктагы бөтен эшләрдә аның да өлеше бар кебек тоела: ул аларны электр энергиясе белән тәэмин итә, төрле механизмнарның һәрвакыт сафта төзек булып, өзлексез эшләвен оештыра, һәрчак күзәтеп тора. Бүген дә әлеге хис уянды, куллары күнегелгән эшне башкарган хәлдә колагы участок шау-шуының гадәтләнгән тавышын тыңлады.

Ул, прожекторның пыяла ишеген ачып, янып чыккан зур лампочканы борып алды да аның урынына патронга яңаны беркетте. Иске лампочканы картон эченә тыгып, сул кулына тотты. Артка каерылыбрак прожекторның түгәрәк капкачын ябарга дип үрелгән генә иде, кинәт якында гына гөрселдәтеп туптан аткандай каты шартлау тавышы ишетелде. Шул мизгелдә үк аңардан йөз-йөз илле метр чамасы ераклыктагы фенол-ацетон цехлары

өстендә куе кара төтен пәйда булды. Авылда, яшен сугып йә бала-чага шырпы белән шаярудан янып киткән өй, мунча, каралты-куралардан мондый төтен чыкмый. Моны армиядә үзләре сүндергән сарайлар өстендәге төтен белән дә чагыштырып булмый. Габделнур Әлмәт якларында эшләгәндә, скважина янындагы нефть базларына ут капкач кына шундый куркыныч күренеш хасил була иде. Бу да нәкъ шулай: кара-кучкыллы төтен әкияти аждаһа авызыннан бөркелгән шикелле ургылып-ургылып өскә күтәрелә башлады.

Габделнур, тиз генә прожектор капкачын ябып, ашыга-кабалана түбән төште, каешының баганаңы чалдырып алган чылбырын ычкындырды, «тимер тырнак»ларын салды.

Ул арада завод идарәсе ягыннан янгын сүндерү машинасының ачы сиренасы тынлыкны ярды. Һәм тавыш, отыры көчәя барып, болайга таба якыная башлады. Үкерә-үкерә килгән машина авазы да аермачык ишетелә иде.

Участок та җанланды: будкасыннан прораб атылып чыккан, ана таба ашыга-ашыга мастер килә, бер корпус нигезенә бетон коючы зеклар бригадасы эштән туктап катып калган, КППдагы солдатларның берсе зона эченә кергән һәм алан-йолан карана.

Габделнур «тимер тырнак»ларын чөйгә элеп маташканда бетончылар яныннан Раил кайтып керде.

—Нәрсә булган анда?—дип сорады ул кызгылт йөзенә чыккан борчуын яшерә алмыйча.

—Фенол цехы шартлады, ахры,—диде Габделнур һәм, каешын да ычкындырып, кадакка элеп куйды.—Мин карап кайтыйм әле.

—Мин монда булырмын.

—Ярар.

Габделнур проходнойдан чыкты. Кизү торучы сержант белән икенче солдат ишек төбендә таптаналар, ләкин кызыксынулары көчле булса да постларын ташлап китә алмыйлар. Шуңа күрә сержант Габделнурга үз итеп дәште.

—«Картлач», син белеп кайт инде.

Аның бераз аптырап калуы да сизелә. Чөнки мондый очракның әлегәчә булганы юк, ә аның кул астында нихәтле кеше.

Асфальт юлдан берничә кеше унга таба йөгерә, сул якта сирена улатып җан-фәрманга чабып килүче тагын ике кызыл машина күренде, ә икесе инде цех тирәсенә килеп туктаган, урнашкан һәм ак брезент робалы, яшел каскалы, противогаз кигән сүндерүчеләр үз эшләренә керешкәннәр.

Габделнур тротуардан тиз-тиз атлап бара башлады. Янгын сүндерү машиналары артыннан кызыл хачлы ашыгыч ярдәм машинасы чинап-улап ажгырып узып китте... Ә цехлар өстендә кара төтен әллә кая биеккә ургыла, торган саен бинаһая югарырак күтәрелә... Бер карасаң, гүя кап-кара болыт кисәге цехның биек корылмалары өстенә ишелеп төшкән дә, астан үрләгән куе кызыл ялкын аны актарып-таратып җибәрә сыман. Икенче карасаң, ул кара болытны көчле куллардагы озын таяклар болгатып, күтәреп чөеп җибәргәндәй тоела. Җанны өшетә торган бу гарасатның дәһшәте бөтен тирә-якка тарала, кешеләр күңеленә шом сала. Вакыты белән кызгылт ялкын телләре бер-беренә комачау итеп бәргәләнүче алагаем зур кара «туплар» арасында искәрмәстән күренеп-күренеп китә, уйнаклый, тоташы белән куе кан төсенә кереп, отыры өскә үрли.

Завод идарәсеннән кай арада килеп җиткән ыспай киемле, галстуклы агайлар—инженер-техник хезмәткәрләр цех тирәсенә беркемне дә якын җибәрмәделәр. Ул арада кызыл хачлы машина, бәлагә дучар булганнарны алып, кире китеп тә барды.

Килгән кешеләр, ачык авыз—карап торучылар бер-беренә сорау бирә.

—Үлүчеләр юкмы? Нәрсә булган?

Ләкин анык кына җавап ала алмыйлар, чөнки төгәл белүче юк. Белгәннәре—ләм-мим, авызына су капкан.

Габделнур янәшәдә генә ике хатынның сөйләшүен тыңлап торды.

—Аппаратчы Әлфияне алып киттеләр,—диде берсе яшьле күзләрен сөртеп.

—Исәнме соң?

—Исәнен исән...

—И бичара! Балалары ятим кала күрмәсен инде... Фәрит тә авыр хәлдә... Теге слесарь егет...

Алар янында торган бер ир:

—Әле узган елның маенда гына җүнләп эшкә тотындык, продукция чыгара башладык,—диде үзалдына әйткәндәй.—Инде икенче тапкыр шартлый. Теге юлы болай әшәке шартламаганые.

Габделнур колагына янә теге хатыннарның үзара әңгәмәсе чалынды.

—Әйткәннәр иде аны, куркыныч та, сәламәтлеккә дә зыянлы, дип...

—Бездә бит кияүгә чыкмаган кызларны, әле бәби тапмаган яшь киленнәрне эшкә дә алмыйлар.

—Нигә?

—Тиеш түгел. Зарарлы.

—Үзең дә бүтән цехка күчмисеңме соң?

—Юк. Минем ике бала бар бит инде.

—Булса да...

—Монда пенсиягә иртәрәк китеп була, акчасы да әйбәт төшә. Ходай язмаган эш булмас, ди торган иде безнең әби, күрәчәгең булмасын...

Шулай да, сораштыра-тыңлаштыра торгач, Габделнур тәгаен белде: цехта реактор шартлаган, ике кеше җәрәхәтләнгән, үлүчеләр юк.

Химия заводының ни-нәрсә икәнен, анда эшчеләрне һәрдаим хәвеф сагалап торганын егет беренче мәртәбә шунда аңлады. Цехлар яныннан узганда газ исеннән борын җыерырга мәҗбүр булу гына әле, кем әйтмешли, пүчтәк икән. Һәм, алга китеп булса да әйтик, төзелештә эшләү дәверендә Габделнурга мондый хәтәр хәлләрне берничә мәртәбә ишетергә дә, күрергә дә туры килде. Иң аянычы шул: кайвакыт анда эшләүчеләрнең яшь гомерләре дә өзелә иде.

Чыбыксыз телефон фаразлары буенча, завод тулы куәтенә эшли башлагач, җил уңаена агылган газ исе бөтен Жилплощадканы һәм Каравай бистәсен тутырачак икән әле. Ләкин хәзергә бу турыда әллә ни сүз куертмыйлар, фәкать ике арадагы буш мәйданга агач утырту белән генә шөгыльләнәләр, үзенә күрә барьер ясыйлар, яшел зона булдыралар.

...Янгын сүндерүчеләр эшләрен тиз тотты: ярты сәгать тә узмагандыр, цех өстенә кара сөрем күтәрелмәс булды.

Ни гаҗәп, цехтагы шартлау турында шау-шу купмады. Шәһәрдә сүз булмады. Кыскасы, яман хәбәр читкә таралмады. «Нәкъ хәрбиләрдәге кебек»,—дип уйлап куйды Габделнур. Чөнки армиядә һәм флотта булган хәвефле хәлләр дә гади, ягъни, граждански халыкка барып ирешми, фәкать частьләрдә һәм корабльләрдә теге яки бу вакыйга уңаеннан министрның ябык приказы гына укыла иде.

Хәер, шәһәр кешеләренең күпчелеге төзелештә эшләүче контингент хакында да бихәбәр иде.

Төзү идарәсенең дивар гәзите мөхәррире буларак та, гомумән, ил-көн тормышы белән кызыксынучан кеше буларак та Габделнур трестның күптиражлы гәзитләрен (алар ике телдә—татарча һәм русча чыга иде) даими караштырып бара иде. Ни анда, ни җөмһүрият, ни союз матбугатында—

беркайда да комсомолның Бөтенсоюз удар төзелеше булган заводны коруда катнашкан toткыннар турында да игълан ителмәде. Барча гәзит-журналлар, радио-телевидение көн-төн комсомол-яшьләрне, коммунистларны, остаз-тәрбияче хезмәт алдынгыларын гына мактап күккә чөйде.

Бер уйласаң, монда әллә ни искитмәле нәрсә дә юк. Төзелештә меңләгән кеше эшли. Ә зеклар—бер-ике бригада гына. Анда да алар, стройбат солдатлары кебек, кара, авыр эшләрне генә башкаралар. Корпус, эстакада, җиһаз нигезләренә бетон кою—ул әле эшнең башы гына. Аннары килеп, моның өчен әллә ни һөнәри осталык та соралмый, технологик процессны карап-тикшереп тору өчен мастер-прорабла куелган. Булачак цехларны күтәрү, ишек-тәрәзәләр кую, буяу-сылау, канализация үткәрү һәм башка бик күп эшләрне тәҗрибәле, чын профессионаллар башкара. Ә җылылык бирү, электр һәм башка җиһазларны монтажлаудан гыйбарәт катлаулы операцияләрне, билгеле, теләсә кемгә ышанып тапшырмыйлар, аның өчен шәһәрдә субподрядчы трестлар, махсус идарәләр бар. Хәтта илнең бүтән калаларыннан да килеп эшлиләр. Шуның өчен ул Бөтенсоюз төзелеше дип атала да. Чит илләрдән кайтарылган җиһазларны урнаштырып көйләүдә әле шул мәмләкәтләрнең инженерлары һәм белгечләре дә катнаша.

...Бу участокка Габделнур вакытлыча гына дип килгән иде, әмма ул ел ярымга сузылды һәм, ниһаять, егет бүген янадан электр цехына әйләнеп кайтырга тиеш булды. Бирегә энергетик икенче кешене алып килде.

Моннан киткәнче Габделнур, Раил белән икәүдән-икәү генә калып, күзгә-күз карашып сөйләшеп алырга ниятләде. «Авызга сукмас әле, минем әйтүем дөрес булсын. Калганы—үз эше»,—дип фикер йөртте.

—Бер сүз әйтсәм ачуланмыйсыңмы?—диде ул инде будкадан чыгып, КППга таба берничә адым атлагач һәм туктап калды.

—Юк. Әйт.

—Раил, без синең белән бер чама, яшьтәшләр диярлек, акыл сата димә, яме. Теге вакыт сезгә баргач, әниеңне җәлләдем, үземне каты бәгырьле кеше дип санасам да, күңелем тулып, юньләп саубуллаша да алмадым. Таксида ярты юлны дәшми кайттым... Уйлап кара: син әле яшь, тормышыңны яңабаштан башларга, семья корырга кирәк... Акылга утырырга вакыт җитмәде микән? Энең бар. Аны да уйла. Аңа әти кирәк. Ә ул юк. Димәк, син аңа абый гына түгел, ата урынына да калган кеше. Шулай булырга тиеш. Ул да синең юлдан китсә, анагызны вакытсыз гүргә тыгасыз бит. Ачуланма, үпкәләмә. Әгәр минем каршыда бер юньсез кеше булса, мин авыз чайкап тормас та идем. Ә син... мин моны әйтмичә китә алмадым. Мондагы тормыш... Әлбәттә, син югала торган малай түгел. Ләкин бу тормышны син миннән яхшырак беләсең: юньлегә алып бармый, ахыры хәерле бетми... Каракны тудырган ана кабереннән кычкырыр, диләр. Ананның рәнҗеше төшүдән курык һичьюгы. Үпкәләмә дә, күңелеңә дә авыр алма минем болай әйтүне...

—Юк.

—Кемнеңдер кайтырга, торырга урыны юк—аңа кайда да бер. Монда әле көн саен ашаталар, ятарга урын бирәләр, мунчасы дигәндәй... Ләкин синең өең бар. Өеңдә әниең, энең—сине дүрт күз белән көтәләр...

—Не дави на психику!

—А что ты хотел?! Гафу ит, әлбәттә, бу—минем эшем түгел. Мин сиңа—кем? Син дә миңа шулай ук. Ләкин безне тугыз ай карынында йөрткән, интегеп тапкан, төннәрен керфек какмый баккан Аналарыбыз бар! Минем дә, синең дә... Менә мин өч ел армиядә булдым, отпускыга кайта алмадым. Әнинең ничек тилмергәнен беләм. Ул чишмәгә суга барганда минем «әни!» дип кычкырган тавышымны ишетә торган булган. Синеке дә шулайдыр.

Гафу ит, билгеле.

—Рәхмәт яхшы сүзенә.

—Ачуланма.

—Уйлап карармын.

—Син акылсыз егет түгел, кулында һөнәрең дә бар,—диде дә Габделнур, Раилнең йомшак, нәзек бармакларына күз ташлап, җитди сөйләшүне берникадәр йомшартып җибәрде.—Мин тегесен әйтмим, әйбәт электрик икәнеңне истә тотып әйтәм. Сау бул.

—Хәзергә.

## XII

Үзенең чатнама суыклары, ишелеп-ишелеп яуган карлары белән кайчагында тәнеңне өшетеп, кайчагында җаныңа җылы өреп кыш та узып китте. Уку туктап тормаган кебек Энже белән ике арадагы мөнәсәбәт тә дәвам итте. Алар еш очрашалар, ләкин икәүдән-икәү генә калу—сирәк эләгә. Андый минутлар икесе өчен дә бәхет-сәгадәткә, ләззәт-назга әверелә иде. Җылы, көләч йөзле кояшлы, бакча-скверларда тәүге мәртәбә аваз салган сандугач тавышлары, боз өстенә калкып чыккан сулары белән яз да җитте. Көннәр җылынган саен яшьләрнең өмет-сөенечләре дә арта торды. Алар театрларда спектакльләр карарга гына түгел, паркта ял итәргә дә вакыт табалар иде. Ә анда—үзенә бер дөнья: таганнар, «очкыч»та яки карусельдә әйләнүләр, алагаем зур күзәтү тәгәрмәченә утырып биектән шәһәрне тамаша кылу, кешене әллә нинди рәвешләрдә күрсәтүче төрледән-төрле көзгеләргә карап көлүләр... Шунда ук биек койма белән әйләндереп алынган түгәрәк танцы мәйданчыгы... Әмма беренче курсны уңышлы төгәлләү сөенече—барыннан да өстен иде.

...Бүгенге көнне дә Габделнур Энже белән үткәрергә булды. Алар, «Кольцо»да троллейбустан төшкәч, кая барыйк дип фикер алышканнан соң, Кабан күленә таба юл алдылар.

Бетоннан коелган тәбәнәк барьерга егет башта газета салды, аның өстенә кесәсеннән кульяулыгы чыгарып җәйде, юри аңа кат-кат өреп тә алды. Моны Энже күрде, билгеле, һәм, күңеле булып, гадәтенчә суктырып әйтте.

—Өрмәгән җиргә дә утыртмам дисең инде.

—Тәртибенә карарбыз.

—Үзең әйтмешли, тәртип—биш, уку—икеле.

Каршыда җәелеп яткан кин күлнең теге ягында яннарында бакчалары булган бер катлы агач һәм ике катлы таш йортлар күзгә чалына. Хәер, бу иске йортлар арасында аскы өлеше кирпечтән, ә өсте бүрәнәдән булганнары да бар. Аларның бүрәнәләре каралган—йөз ел торалардыр, мөгаен. Кайбер йортлар такта белән тышланган һәм яшелгә, зәңгәргә буялган, аларның тәрәзә йөзләре бизәкле—кунакчыллык билгесе булып әллә каян балкып торалар.

Унда, халык телендә «Электростанция» дип йөртелгән шактый биек кызыл бина. Ә арырак, Болак буйлап, ике-өч катлы иске таш йортлар тезелеп киткән. Хәрби хезмәтенең соңгы ике ай ярымын Казанда узган Габделнурга берсе яхшы таныш—аларны, сафка тезеп, мунчага алып баралар иде.

Каршыдагы өйләр уртасында, эчтәрәк, кыйблага караган алтын айлы мәчетнең юан, тәбәнәк ак манарасы калкып күренә: ул солдатларга күз-колак булыр өчен махсус пьедесталга бастырып куелган сержант кебегрәк булып тоелды.

Егет шул уен кызга да әйтте. Энже көлеп җибәрде.

—Син әле һаман армияннән аерыла алмыйсың.

—Өч ел муштровать итсеннәр әле...

—Ул Казанда эшли торган бердәнбер мәчет, минем бабай үлгәнче шунда җомгага йөрде.

Еракта беренче ТЭЦның биек юан торбаларыннан чыккан карасу төтен өскә күтәрелә. Аннары Габделнур сул яктагы өч катлы, сыек зәңгәргә буялган озын бинага төртеп күрсәтте.

—Теге йорт янарак ахрысы?

—Юк, иске. Ул җиңел промышленность техникумы. Анда Октябрь революциясенә кадәр инородецлар семинариясе булган, аннары җиңел промышленность техникумы ачылган, берзаман Совнархоз урнашкан, кабат элекке хәленә кайткан—студентларга белем бирү урынына әверелгән. Мин шунда кермәкче идем, аннары кире уйладым, урта мәктәпне бетердем.

Алга китеп булса да шуны әйтик: Габделнурга бу техникумда укучы бер студент кыз белән дә танышу бәхете тәтеде.

Әлеге бинадан арырак кызыл кирпечтән төзелгән иске корылмалар шәйләнә. Энҗе аларның элек заманда Александровлар, Крестовниковлар биләмәләренең бер өлеше икәнен, анда стеарин, шәм, сабын, машина майлары, олеин кислотасы, глицерин, купорос мае, гудрон эшләп чыгаруларын әйтте.

—Хәзер сабын, кер юу порошоклары чыга,—диде ул.

—Гөлҗиһан сабыны дигәнен ишеткәнем бар иде.

—Алар күп төрле булган, хәзер дә шулай.

—Син боларны каян беләсең?

—Әни башта Вахитов химкомбинатында эшләде, аннары гына әти янына кондуктор булып күчте.

—Алафузов фабрикасы да шундамы?

—Юк. Анысы—Бишбалтада, Киров районында.

—Син зерә генә тарих бүлегенә кермәгәнсең икән, экскурсовод булып эшләрлегең бар.

—Безнең ише авыл гыйбадларын агарта аласың, дип әйтүеңме?

—Ярар, ул кадәр эчкә кермик. Замнем для ясности.

Кояш сабын күбеге сыман күпереп торган сирәк болытлар арасыннан бер чыгып, бер югалып торса да көне җылы. Әнә аны тагын бер болыт каплаган һәм кояш нурлары ана килеп бәрелгәннәр дә, ялтыравык су тамчылары кебек, төрле якка таралганнар. Габделнурга алар кичен прожектордан сибелүче нурларны да хәтерләтте. Егетнең аркасын кояш кыздыра иде, күлмәген салмакчы булды, ләкин читенсенде. Әмма бераздан түзмәде—салып куйды.

Алдагы зур күл өстендә сирәк-мирәк акчарлаклар оча, яр буенда бака ефәге һәм яшел үсентеләр, шуңа ахрысы, су үзе дә яшькелт булып күренә. Егет тирә-ягына каранып:

—Монда көймә станцияләре күп икән,—диде.

Энҗе аңлатып бирүне кирәк тапты.

—Әнә теге яктагысы, каршыдагысы, ДОСААФныкы, унда, пыяла кафедан бирерәк, күпер тирәсендәгесе «Динамо» спорт җәмгыятенеке, бу якта, сулда, тагын берәү—«Спартак»ныкы.

—Син боларны каян беләсең?

—Мин ике ел байдаркада йөздем, аннары соң ташладым.

Энҗе Габделнурга дөресен әйтмәде. Чынында исә йөргән егете академик ишү спорты белән шөгыльләнгәндә кыз аның янына килгәләп йөри иде. Шуңа күрә ул бу тирәләрдә еш булырга ярата—хисләрен янарта. Бу як ярда, сулда, көймәләр станциясе. Ишеге ачык зур сарай каршында, тактадан

ясалган киң басма өстендә, берничә спортчы мәш килә—көймәләрен күнегүләргә хәстәрли. Бирерәк бер хатын кер чайкый, янында баласы—кечкенәсе су коена. Алардан ерак түгел резин итекле абзый озын саплы кечкенә ятьмә күтәреп килә: балык каптырырга җим әзли булса кирәк—кармагы юк.

Су уртасында, байдаркага майкачан гына утырган бер кыз, ике калаклы ишкәге белән, ходка җибәрелгән насос кебек, әле унга, әле сулга селтәнә.

—Моның ишкәге безнең авылда ипи сала торган агач көрәккә охшаган,—диде Габделнур әкрен генә ишеп килүчегә күрсәтеп.—Ләкин бер аермасы бары: сабы бер генә, ә калагы—икәү, таякның ике башында да.

Тар, озын көймәдә ике егет киерелеп-киерелеп ишәләр—шәп йөзәләр. Киң, баш башы озынча каноэда да икәү—сул аяклары белән көймә төбенә тезләнгәннәр дә бер ритм белән алдырыпмы алдыралар.

Якында бала-чага су коена, кайберләре машина тәгәрмәче камерасына коткару түгәрәгенә ятып йөзәләр.

—Әни, тегендә стирать итәргә яхшы таш бар,—диде яр буенда йөгереп йөргән бер сабый.

—Ярар, кызым,—диде керләр салынган калай тас күтәргән анасы.

Алда, аргы якта, борын-борыннан татар халкы укмашып яшәгән, аның каймагы—зыялылары, күп малга ия байлары-сәүдәгәрләре, урта хәлле һөнәрчеләре, завод-фабрика цехларында чиләнеп нужа чигүчеләре туып-үскән, көн күргән булса, артта исә, бу як ярда, асфальт тротуары, аллеялары, өзлексез кошлар сайраган куаклары һәм биек агачлары белән, сирәк кенә узган машина гөрелтесенә күмелеп Суконный бистәсе ята. Бистә Петр Беренче заманында оеша, чөнки патшага армия һәм флотны киендерергә кирәк була. Бистә белән Шаляпин, Пугачев, Пушкин исемнәре бәйле. Соңгысы «Горлов кабагы»на да сугылып чыккан булса кирәк. Шул тирәдәге кызыл пәрдәле йортларга кереп чыгуы турында мәгълүмат юк. Ә менә Гришка Распутин анда булган, күрәсең, чөнки бер «кыз»ны урам буйлап куып йөргән, диләр. Кайсыдыр мәҗлестә урта яшьләрдәге бер абзыйдан ишеткән җыр егетнең хәтерендә яңарды: «Ай җаный, вай җаный, Суконныйга бар, җаный, Суконныйга барсаң, җаный, маржа кочсаң да ярый». Күрәсең, элек анда күпчелек урыслар яшәгәндер. Боз өстендә ике як кара-каршы килеп кул сугышлары оештырган... Ә хәзер инде кайда кем күпме яшәгәнен аермачык белерлек түгел—буталып беткән. Чөнки «Спартак» фабрикасыннан ерак түгел баракларда Габделнурларның ерак туганнары яши, Мәһрүсә апасы да Жданов урамында.

Энҗенең тонык, саңгыраурак тавышы егет колагына килеп ирешә. Ул шәһәрне биш бармагы кебек белә икән. Һәр сүзе Габделнур өчен яңадан-яңа мәгълүмат...

Кайчак җил исеп китә дә балык һәм саз исе борынга килеп бәрелә, өзлексез балык чиртә, уйный.

Габделнурның күптәннән болай иркенләп ял иткәне, хозурланып шәһәр караганы юк иде бугай. Шуңа күрә ул колагы белән Энҗене тыңлаган, күз карашы белән тирә-юньне барлады.

Әнә яр буенда ак яулыклы, кызгылт-соры чуар күлмәкле бер әби аяк киемен—чүәген салып моңаеп утыра. Аның янына сумка тоткан ахирәте килеп туктады һәм алар гәпләшә башладылар. Алардан бирерәк бер кечкенә бала велосипедта йөри. Габделнур өчен ике заман бергә килеп кушылгандай булды: әнә Энҗе үзенең бабасы, аның моннан ерак түгел урнашкан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укуы, халкыбызның мәшһүр улларын күреп белүе, озак еллар мәктәптә мөгаллимлек итүе хакында сөйли. Теге ике

карчык та аның бабасына чордаш түгел микән? Һәм менә замана «аты»на атланган сабый. Ул инде икенче чор кешесе булып үсәчәк. Хәлбуки, Энже үзе дә, бабасы һәм әбисе белән үссә дә, замананың шаукымына ияргән шәһәр кызы: әле кияүгә чыкмаган—ир-ат куенының бөтен кайнарлыгын, тәмен татыган, моның өчен вөҗдан газабы кичергәне дә сизелми. Дөрес, бәлки беренче төнен балавыз сыгып та алгандыр, әмма бу анасы сыгудән шүрләп кенә булгандыр шикелле.

Габделнурга бу үткен, елгыр кыз кайчагында гел чын дөресен генә сөйлидер сыман тоела, ә кайчагында эчкерсезлекнен, кем әйтмешли, әчмүхәсе дә калмый—күзенә карап ялганлый һәм... ышандырырлык итеп. Бу—үзара мөнәсәбәткә кагыла. Ләкин ни генә булмасын, кыз—күп укыган, зиһенле. Аның янында егет үзенең белеме аз булуын, мәдәният-сәнгать мәсьәләләрендә генә түгел, халкының тарихын да бөтенләй белмәвен тоя иде. Кемнәр без? Борынгы бабаларыбыз кемнәр булган? Аларны түгел, хәтта узган һәм бу гасыр башында яшәгән бөек шәхесләрне дә белмәвен шәйләде егет. Хәер, боларын Энже дә белмидер, ләкин ул барыбер егет алдында үзен өстенрәк итеп, иркенрәк тота. Бу—Габделнур-солдат кунакка кайткач мунчада бер кич уздырган гыпытыу кызы Наташа түгел, колагына «токмач» элдертми. Әмма егет хәзер аңа шултиклем ияләште—ташлап китә алмый.

Торналар кебек тезелешеп өч көймә бара. Күл өстендә вак дулкыннар тәгәрәшә, теге як ярда яшел таллар тирәсендәрәк, балыкчылар кармак сала, ачык урында ак башлыклы балалар су коена. Хәер, андый сабыйлар бу якта да бар—төркемнәре белән килгән бакча балалары—шаулашалар, яр буенда уйнап мәш киләләр.

Күзлекле апалары:

—Әгәр дә тыңлаучан булсагыз, ярга якын киләбез,—диде.

Балалар, тигезле-тигезсез авазлар чыгарып, дәррәү кычкырдылар.

—Тыңлыйбыз! Тыңлыйбыз!

Асфальтта әлсерәп утырган чыпчык аларның тавышыннан куркып очып китте. Тәрбияче кызның борчылуы аңлашыла: бу бик сихри һәм серле, ваемсызлыкны гафу итми торган үзенчәлекле борынгы күл. (Габделнур бая искә алган туганнарының бер малайлары суга батып үлгән иде.)

Тирә-юнен, күлне, шәһәрне күзләсә дә егет монда кем белән килүен, янында кем утыруын онытмый иде. Ул аңа әледән-әле яннан күз ташлый, сүз ката. Энҗе дә егетнең игътибарлы булуына җавапсыз калмый: аңа карап елмая, яратуын сиздерергә тырыша.

Энҗе кечкенә сумкасын аксыл-соры итәге өстенә куйган, соргылт чәчләрен әкрен искән җил тарый, зәңгәр кофтасының изүе ачыла төшкән, эсседән тулы йөзе кызарган, көмеш йөзекле сул кулы тезендә ята, биек үкчәле туфли кигән аяклары яшел чирәмгә тиеп тора. Шәһәр уртасы булса да, табигать кочагында утыру икесе өчен дә рәхәт иде.

Алар янына өч-дүрт яшьләрдәге ике малай килеп урнашты: берсе әзер кармагын кизәнеп суга да салды; кечкенәрәгенең муенында алтын чылбырга асылган алтын тәре, беләгендә уенчык сәгать, ул вак таш алып, суга ата башлады.

Ак дулкыннары белән күл уртасын икегә аерып катер узып китте. Егет белән кызның сүзләре күпме генә сөйләшсәләр бетәрлек түгел иде. Тормыш, яшәү рәвеше, уку, эш, чираттагы ял—барысы да телгә алынды.

—Әйдә безгә,—диде Габделнур шактый вакыт утыргач.

—Ирек өйдәдер бит?

Егет сәгатенә карап алды.

—Ул апаларына барасы иде, киткәндер инде.

Энҗе ялындырып тормады, башын кыңгыр салып, очкынланып янган

соргылт күзләрен Габделнурның елмаюлы йөзенә төбәп, егетнең аңа таба сузылган зур кулына дымлы учын салды.

Габделнур, кияргә дип, бетон барьерга пөхтәләп бөкләп куйган күлмәгенә үрелгән генә иде, кинәт машина тәгәрмәче камераларына ятып йөзүче бала-чага арасында шау-шу купты. Кайсыдыр йөрәк өзгеч тавыш белән сөрән салды.

—Коля бата! Коткарыгыз!

Габделнур белән Энже тавыш килгән якка борылдылар. Чыннан да бер малай (камерасыннан егылып төшкән, күрәсең) су эчендә бата-чума быкырдый иде.

Егет сикереп торды, җәлт кенә чалбарын салып ташлады, барган унайга туфлиләрен чөеп атты һәм суга сикерде. Колач салып йөзеп барды да (ярый әле ярдан ерак китмәгәннәр) нәни куллары белән суны чәбәкләүче, чапыр-чопыр тыпырчынучы, су эчәргә өлгергән авызын югары күтәреп үкереп елаучы малайны уң кулы белән эләктереп тә алды.

—Аркага атлан! Муенны кысма!..

Яр буена йөзеп чыккач, малайны бүксәсе беләк үзенең сул тезенә салды, башын аска идерде.

—Кос!—дип әмер бирде.

Малайның авызыннан шактый гына су чыкты...

## XIII

Милициядә эшләү Ирек өчен зур сынау булды. Монда физик көч тә, рухи ныклык та кирәк, һәрчак киемеңне һәм үзеңне үрнәк тәртиптә тоту да сорала, хәтта иң катгый рәвештә таләп ителә. Әлбәттә, өч ел солдат каешы буып йөргән егет өчен болары чит нәрсә түгел, өйрәнелгән. Авыл малае да буларак Ирек ару-талуны белми эшләде: суык дип тормады, буран дип карышмады, яңгыр дип сыкранмады, кирәк чакта, иптәшләрен алыштырып, тәүлек буена да постын ташламады, кыскасы, хезмәтен җиренә җиткереп башкарды. Аның эше, дәресрәге, хезмәт вазифасы шуңардан гыйбарәт: урамда йөреп патрульлек итү, тәртип саклау. Монда ул шәһәр тормышының гади күзгә чалынмаган, күпчелек гражданнарның игътибарыннан читтә кала биргән бик күп тискәре якларының да шаһиты була иде, болар—караклык, эчкечелек, сугышу һәм башка шуның ише яман нәрсәләр, тәртипсезлекләр. Гелән генә начар кешеләр белән аралашу, еш кына шундыйларга тап булу, бозык юлга басканнарга юлыгу—холык-фигыленә дә тискәре йогынты ясый башлады: ул хәзер һәр узган-барганга шикләнеп, сынап карый торганга әйләнде. Андый вакытларда яшь милиционер тормышның матур яклары турында уйларга тырыша, үрнәк тәртипле кешеләр күбрәк бит, әнә минем белән дежурга чыккан дружиначылар завод-фабрикаларда, төзелешләрдә эшлиләр, мәктәпләрдә балалар укыталар, хастаханәләрдә авыруларны дәвалыйлар, техникум-вузларда укыйлар, җәмгыятькә зыян салырдай бернинди начарлык кылмыйлар, дип уйлый. Ямьсез уй-фикерләрен үз тирәсеннән ераккарак куып җибәрергә тырыша.

Хезмәттә бер хәл, аңлашыла анысы, ләкин ул хәзер кайда гына булмасын, үз-үзендә җаваплылык хисе тоеп яшәргә, урамдамы, транспорттамы, кинотеатр яки ял паркы иҗе җәмәгать урынындамы, үзе яшәгән тулай торактамы, кыскасы, һәркайда, хәтта формасын кимәгән чакта да шаһит булган һәр тәртип бозуга үзенең мөнәсәбәтен белдерергә, күз йомып китмәскә, вакытында чарасын күрергә тиеш, аңа мөрәҗәгать иткән гражданнарның үтенечен кире какмаска бурычлы.

Моның шулай һәм фәкать шулай булырга тиешлегенә дусты Габделнур да төшенде. Ә бит армиядә чакта бу аларга кагылмый, гражданский

халык тормышы өчен алар җавап бирми иде (гадәттән тыш хәлләрне искә алмаганда).

Бервакыт тулай торакка нииндидер исерекбаш керә. Вахтерны санламыйча, эчкә үтмәкче була. Бәләкәй генә карчык—вахтер апа моны тоткарлый. Ә теге үзенекен итмәкче.

Нәкъ шул вакытта Ирек белән Габделнур каяндыр кайтып киләләр иде.

Вахтер апа, аларны күрү белән:

—Егетләр, менә моны тыегыз әле,—дип озын буйлы, таза гына салмыш адәмгә күрсәтте.—Кермәкче була. Әйтәм, әйтәм, һич тыңламый. Чыгып китми.

Ирек формадан түгел иде. Әдәпле генә итеп сорау бирде.

—Син монда торасыңмы?

—Юк.

—Кем янына килдең?

Теге ык-мык итте. Вахтер сүзгә катышты.

—Биредә беркеме дә юк аның.

Габделнур әлегә бер сүз дә дәшмичә читтәрәк тора бирде.

Ирек, бу юлы тавышын күтәрә төшеп:

—Алайса нәрсәгә керден?—дип сорады.

Теге телгә килде.

—Кызлар янына.

—Нәрсә? Монда бит кызлар тормый. Бар, чык.

Үзеннән шактый тәбәнәк гәүдәле егетне санга сугарга исәбе юк иде, ахрысы, үзсүзле сәрхуш бәндәнең.

—Синең миндә ни эшең бар?—диде ул дорфа гына.

—Мин—милиция хезмәткәре. Тагын кабатлыйм: бар, чык. Яхшы чакта ычкын!

Ирекнең кискен, катгый рәвештә әйтелгән соңгы сүзләре колгасар адәмгә ошамады, күрәсең. Ул, өстән аска карап, калын кашларын җыерып һөҗүмгә үк күчте.

—Ах син, мусор несчастный, әле син минем өстән командовать итмәкчеме?

—Нәрсә?!—диде дә Ирек күз ачып йомганчы тегенең бер кулын артка каерып та куйды.—Габделнур, әйдә бу шакшыны чыгарып томырабыз.

Дусты, чакырганны көтеп тормыйча, җәһәт кенә алар янына килеп җиткән иде инде, ә, дигәнче тегенең икенче кулын эләктерде. Һәм алар, сәрхушның башын тезенә хәтле идереп, тышкы ишеккә таба алып киттеләр.

—Җибәрегез!

—Нигә акырасың, фәлән нәрсәнне көзән җыерамы әллә?—диде Ирек ачу белән.

—Авырта!

Ләкин аның ай-ваена, кычкыруына игътибар итеп тормадылар, биек, авыр ишекне башы белән ачтырып, асфальтка чыгарып аттылар.

—Бар, йөгер! Юкса, хәзер машина чакырам,—диде Ирек ярсуын көчкә басып.

Исерек, җирдән торып, артына борылып карарга да онытып, Ибраһимов проспектына таба элдертте.

Егетләр бүлмәләренә үткәндә вахтер әби аларга рәхмәт әйтеп калды.

Әлбәттә, шуныңише хәлләргә бер генә юлыкмагандыр Ирек. Шуңа да карамастан, ул хезмәтен яратты. Аннары, теләгенә дә ирешә—юрфакка читтән торып укырга керде. Шуның өстенә, кызлар белән очрашырга да вакыт таба иде.

Ул Габделнурга Совет районындагы ашханәләрнең берсендә эшләүче пешекче кыз белән танышканын әйтте.

Дусты, армия хәлләрен исенә төшереп, төрттереп алды.

—Повар белән дуслык—сәламәтлек нигезе.

—А как же!—дигән булды Ирек, юк корсагын кабартырга тырышып, учы белән шапылдатып суккалап.—Бик кызыксаң, сиңа да табам. Иптәш кызы бар. Пирожкины бик тәмле пешерә. Әле йөри торганың янга калыр. Берсе—кешелеккә, берсе—эшлеккә.

—Ярар инде, без үзебез эшләп ашарбыз,—дигән булды Габделнур сер бирмәскә тырышып.—Ладно уж, мы уж, так уж, сами как-нибудь!

Рәхәтләнеп көлештеләр.

Чынлыкта, дуслар эшләренең көйле баруына, бер-берсенең уңышларына бик шат иделәр.

Икенче көнне Габделнур Мәһрүсә апасының хәлен белеп кайтасы итте. Колхоз базарына сугылып, өрек һәм күрәгә алды. Акча түләп, китеп барганда гына кемдер аны исеме белән дәште.

—Габделнур!

Борылып караса—япон окисындагы зонада аның кулдашы булып эшләгән егет.

—Раил?! Сәлам.

Күрештеләр. Габделнур игътибар итте: элекке зекның кул кысуы ирләрчә көчле, учы кытыршы, сөялле иде. «Ни булган моңа?—дип аптырады Габделнур.—«Шипач»ның кулы йомшак, бармаклары сизгер булырга тиеш бит».

—Нинди җилләр ташлады?—дип сорады егет, гадәттәгечә инициативаны кулына алып, үзе сүз башлап.

—Менә, апага бераз күчтәнәч алдым. Ә син?

—Мин дә җимешкә чыктым. Иртәгә әнинең туган көне.

—Сәлам әйт,—диде Габделнур, —әгәр мине онытмаган булса.

—Юк, ул сине еш искә ала. Миңа үрнәк итеп куя.

—Сөйләмә инде юкны.

—Чын әгәр. Кстати, мин дә сине искә төшерәм. Теге сөйләшүдән соң башта бераз үпкәләгән дә идем. Аннары, уйлый торгач, үзең беләсең, анда вакыт күп, синең хаклы булуыңа инандым... Бер генә тапкыр яшибез бит дөньясында... Минем эш урыны янәшә генә, үткән-сүткәндә кереп чык.

—Кайда?

—Эталон заводында. Базар артында, Киров урамында.

—Өеннән ерак түгел икән.

—Әйе. Чын әйтәм.

—Чифир белән сыйларсыңмы?—диде Габделнур ихлас елмаеп.

Раил дә көлде.

—Дуслар хакына табарбыз башкасын. Хәзер иректә бит... Мине сорасаң, чакырырлар.

—Нинди эштә?

—Электрик. Так что, сиңа рәхмәт.

Тагын бераз сөйләшеп торгач, аерылыштылар.

—Әниеңә сәлам әйтергә онытма!..

—Ярар.

Үзеннән бигрәк, Раилнең анасы өчен сөенде Габделнур. Димәк, картлык көнендә өмете, терәге бар.

*Ахыры киләсе санда*



Луиза
Янсуар

# РИВАЯТЬЛӘРГӘ БЕЗ—ЯҢА ИСЕМ...

## Мәсих

*(шәрех)*

*...әзер булыгыз,*
*чөнки Адәм Улы сез уйламаган сәгатьтә килер.*
Матфей тәгъбир иткән Изге Инжил, 24:44

### 1.ЯХЪЯ

**Вәсвәсәле еллар өеренең**
**Әнчекләре һәр пот каршында**
**Иман алыштыра. Рия ысы**
**Сеңгән җаны исән калсынга.**

**Гөнаһларын кемнең икърар итмәс**
**Бу замана, кемне кичермәс,—**
**Учларыннан канлы бер дәверне**
**Төче сулар юып төшергәч.**

**Алларына егылып яңа потның,**
**«Дога» пышылдаучы иреннәр**
**Дарга күтәрергә әзер янә**
**Бер токымны, аерып күгеннән.**

**Тәүбәсеннән бары дәгъва исе**
**Аңкып торган кавем, котырып,**
**Гыйбадәткә килә. Изгеләрен**
**Кабер бугазына томырып.**

**Вәгазь-юрауларны шикләндерә—**
**Күзләрендә шомлы шәүлә бар.**
**Касәләрдән, кайнап, тәүбә суы**
**Күтәрелә... Яңа пәйгамбәр**

*Луиза ЯНСУАР—шагыйрә; «Күзен ача умырзая», «Болан кызы», «Без җан өргән учак» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Иңүенә инанулы кемдер
Таныганда насыйп ул көнне...
...Гамьсез күзләрендә бер гүзәлнең
Биер аның кыргый үлеме...

## 2. ИУДА

Сатлык аркадашлар намусыннан
Берни калмас—хәкарәттән башка.
Карашларда дар агачы булып
Чайкалыр тик үлем—шаша-шаша.
Сытылыр бер исем—иреннәрнең
Куырылып кипкән чәрдәгеннән.
Кургаш тамчы булып, кемнәрнеңдер
Бәддогасы чәчрәр бәбәгенә.
Янчык авырлыгы кадәр генә
Булмас каһәр, эремәс ком-җирдә.—
Ярлыкачы! Ярлыкачы, зинһар!—
Ялваруын бөтереп, туң җилләр
Илгә чөяр... Дарга элен гәндәй,
Бәргәләнер телдә яман аты.
Дөнья—шул ук.
Безнең хисапларны
Рабби, өмет өзеп, күптән япты.

## 3. ҖӘЗА

Мәйданнарда ирек даулар алар,
Өер-өер яңартырлар иман.
Күзләрендә янган утны гына
Танымаслар—
Онытылган сыман.
Кабатланыр мизгел,
Актарылып,
Иңәр кабат зарлы хәтереңә.
Сиңа әзерләнгән таҗны болгап,
Ыргылырлар...
Затсыз әмеренә
Буйсынырга әзер һәр йолкышның
Бу акылдан язган дөнья...
Талган
Учларыңны учка алам—
Анда
Җәза эзе
Җөйләнмәгән һаман.
...Мәйданнардан хөкем укыр алар,
Өер-өер кабартырлар иман.
...Җанны коткарырлык утны гына
Табалмаслар—
Убылганда җиһан...

## 4. ХАЧТАН КУПТАРЫЛУ

Хачтан купканда да җаның тырнап,
Җиргә тартып торыр шул бер сорау—
Адәмнәрнең асылында ни бар?—
Кыйблаларны алыштырып уйнау.

Бер көнлекме, әллә мәңгелекме
Син торгызган храмның диварлары?—
Әле җиһан бу көнгәчә юрый
Мәсихме ул, диеп, диванамы...

—Мәсихме?
—Кем?!
Булса, терелер дә,
Янә туар иде—бүгенгедә...
Куптарыл да шунда, сабыр җуеп,
Дога урынына... сүген генә!
Хачың үпкәндә дә... шиккә калып,
Ваемлыйлар: чын син, әллә ялган.
...Үрсәләнеп көйли ак күгәрчен
Канатларын—җиргә чылбырланган...

### 5. МАГДАЛИНА

Чәчләреннән хуш үләннәр исе
Аңкып торган берәү, әсәренеп,
Дәшәр сине... һәм күтәрер җилләр
Талгын гына җиңел җәсәдеңне.

Җөйләнмәгән яра сулык-сулык
Сызлар шул мәл, ертып уч сүрүең...
Кыйбласыннан кайтмаганнар өчен
Мөмкин—өр-яңадан терелүең.

Мөмкин—карашында шәүләң күреп,
Укталуың бары бер мизгелгә.
Кемнәр өчен—вәгазь, кемгә—иман
Синең сүзләр... Соңы бер гозергә

Сыеп бетәр куш уч дөньялыкның
Котылуы чынга ашмас ул көн,
Сүзсез генә озатыр сине берәү,
Күзләреңнән укып күкнең төсен...

### 6. ИЯРЧЕННӘР

Ятьмәләрдә чәбәләнгән хакыйкатьне
Эзләүчеләр антлар эчәр, диңгез кичәр.
Тик артыңнан хачка менмәс берәве дә,
Кулыңдагы бау-богауны бары чишәр.

Аннан, хакың хаклаучылар булып, җирдә
Калдырырлар язылмаган канун—синнән.
Дөнья таныр көтеп алган пәйгамбәрен,
Тик... айнымас монафикълык дигән чирдән.

Юк, син үткән юлны сайлап, берәве дә
Үз иблисе белән калмас кара-каршы.
Хакыйкатьнең кулларында богау һаман.
Календарьдә—чиген көткән гасыр башы.

***

*Здесь, похоже, идет война за любовь...*
Светлана Сурганова

1

**Сүзләреңә табынганнар, ятьмә чөеп,**
**Көтә сине, аулый чатлар ышыгында.**
**Мин ишелгән күкне алам иңнәремә,**
**Күләгәләр сеңә җиргә мыштым гына.**

**Ә узгыннар, урамнарга шом таратып,**
**Әверелә тораташ төн сурәтенә.**
**Алар белми кай мизгелдә күченгәнен**
**Канатлының канатсызлар өммәтенә.**

**Тәрәзләрдән ага төтен—алка-алка...**
**Сабырлыкның сынар мәле... шундый якын—**
**Атылырга әзер соңгы ядрә булып**
**Чигәләргә терәлгән дә... сорый хакын.**

**Үткелләрнең үтемсезен кичкәнче үк**
**Бу уенның кануннарын алсак җиңә...**
**Кем дә безне гаепләмәс, бар кыйммәте**
**Түләнелгән. Һәм ябылган исәп—җирдә.**

2

**Мин сине җуямын... Төзәлер-төзәлмәс**
**Яралар—иске дә, яңа да.**
**Шәһәрнең мең япьле буталчык юллары**
**Кемнедер уздыра арага.**

**Очарга кыймыйча, иңгәрәк елыша**
**Бу язда талчыккан канатлар.**
**Күзләрең нәфрәтле. Аларның түрендә**
**Эзләп тә табылмас җавап бар.**

**Кем кемнән ирекле, кем кемгә: «Бигайбә!»,**
**Кем әзер өр-яңа камауга...**
**...Чигәдә чатнаган уйлардан сискәнеп,**
**Бәбәген киергән таңнарда**

**Мин сиңа елышам. Мизгелме? Мәңгегә...**
**Искерә сораулар, җаваплар.**
**...Төзәлер-төзәлмәс җөй эзе беләктә,—**
**Тик таныш ырымны кабатлау...**

*2010*



Рәзинә
Мөхияр

# КЕМ БИРГӘН СОҢ БЕЗГӘ ОЧАР КАНАТ?

ТӘҮБӘ СОНЕТЛАРЫ

Ак-карадан торган бу дөньяда
Каралмыйча ничек яшисе?—
Ак сыйфатлар алып яшьнисе?!—
Ымсындыргыч фаллар торса алда?!

Йокламыймы шайтан дигәннәре,
Караны да ап-ак күрсәтә,
Аклыкларга каршы өсләтә,
Баш өстендә оча тилгәннәре...

Аллаһыдан ярый Коръән иңгән,
Кешелек тә шуңа бик кинәнгән,
Аллаһ сүзе булса иң алдан.

Юлым якты, көнем тыныч үтә,
Аллаһ сүзе булса иң алдан.
Каралыклар миннән читкә китә.

***

Хәерлегә юрыйк бар эшләрне:
Яхшы-яман—бар да Аллаһыдан.
Дога кылып сорыйк Аллаһыдан
Бары яхшы изге гамәлләрне.

Яманлыклар, яман бер чир кебек,
Бик тиз йога, кирәкми тырышу.
Яхшылыкка кирәк гел тырмашу.
Күңелләрне пакьлик без иң элек.

Изге эшләр белән күңелләрне пакьлик,
Әхлаклылык, иман нурын яклыйк!
Яшәүләре булыр бит тынычрак.

Савапларны күбрәк эшли алсак,
Яшәүләре булыр бит тынычрак.
Җир йөзеннән юылыр кер-пычрак.

Рәзинә МӨХИЯР—*шагыйрә, галимә; «Алиһә», «Тыңла мине», «Җидегән йолдыз» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

***

Тагын бер көн китә тарих төпкеленә,
Бүгенге көн җирдә тагынниләр булды,
Күпме аналарның күңелләре тулды,
Күпме гамәл кылдык Аллаһ хөкеменә?

Гамәлләрнең(кылган) ниндилеген уйлыйм:
Кайсы газап өчен, кайсы савап өчен,
Их, беләсе иде савапларның көчен!
Белер өчен, уйланудан туймыйм.

Гомер буе күпме гамәл озатканын,
Газапкамы, савапкамы ук атканын—
Барсы өчен килер җавап тотар бер көн.

Уйландыра бик еш кайтып кабат-кабат,
Барсы өчен килер җавап тотар бер көн.
Кем бирер соң безгә шунда очар канат?!

***

Шайтан керә төрле кыяфәткә,
Күпме кеше сизми дә азганын,
Азып йөреп ныклап бик тузганын,
Дучар итеп башын бер горбәткә.

Адашуы җиңел, туры юлга
Кире кайту, ай-һай, бик тә авыр;
Үзгәргәчтен синең йөрәк-бавыр,
Кереп баткач сазлык—пычрак суга...

Зур ихтыяр, иман көче кирәк,
Иман гына адашканга терәк!
Иманыңа кайту—ул зур җиңү.

Коръән барыр юлда маяк булса,
(Иманыңа кайту—ул зур җиңү)
Кеше дигән сүзгә лаек булсаң.

***

Яшь вакытта гомер алда кебек:
Вакытның да кадерләре булмый,
Кеше өчен әҗерләре булмый,
Күпме вакыт үткән чәйнәп чүбек.

Кадерләре арткач вакытларның,
Таулга менеп җиткәч, син беләсең,
Артка карап, шуны да күрәсең:
Дәрәҗәсе китә ваклыкларның.

Уфтанасың таудан төшкән чакта,
Коры җилләр булса тик кочакта:
Тормыш юлым үткән дип ни хакка?!

Сорау туа, башта уйлар кайный:
Тормыш юлым үткән дип ни хакка?!
...Азан моңы... кушылып кошлар сайрый.

***

**Һәрбер чорның үзгә матурлыгы,**
**Яшь чак үтте диеп һич уфтанмыйм,**
**«Кире кайтыйм»,—диеп ник укталыйм:**
**Һәрбер чорның үзенең зурлыгы.**

**Безгә язган ике гасырның да**
**Үзгәрешле шундый күп еллары,**
**Меңгә тармакланган зур юллары—**
**Ак-карасы ике гасырның да.**

**Авыр булса булды күчешләре,**
**Җәмгыятьнең кискен кичешләре:**
**Безне нидер тотып торды кебек.**

**Читтән чиккә артык ташланмадык,**
**Безне нидер тотып торды кебек,**
**Шөкер, Аллаһ безне ташламады.**

***

**Үтте еллар. Артта күпме юллар..**
**Барсын колачлаган тәкъдир-язмыш.**
**Өстәлгәндер тагы аһ-зар, каргыш,**
**Тар сукмаклы куе чытырманнар.**

**Алга адым... тагын кире бардым,**
**Дөреслекне кат-кат тикшердем:**
**Үз-үземне күпме «өшкердем»,**
**Вакыт-вакыт тәмам югалдым.**

**Кайсы юлны сайлыйм дип торганда,**
**Чарасыздан бик нык баш катканда,**
**Аллаһының тиде ярдәмнәре.**

**Авырлыкны җиңдем шуңа,шөкер,**
**Аллаһының тиде ярдәмнәре,**
**Шуңа хәзер әйтәм кат-кат зекер.**

***

**Бар явызлык хәмердән ул чыга,**
**Шайтан күптән инде аны белә.**
**Адәмнәрнең иманнарын теләә,**
**Имансызлар берсен-берсе чага.**

**Туу-үлү, килү-китү... көннәр**
**Исерткечсез үтми шартласаң да,**
**Иманыңны күпме якласаң да.**
**Исерткечнең эчләрендә җеннәр:**

**Адәмнәрне тәмам аздыручы,**
**Кешеләрне юлдан яздыручы.**
**И Аллаһым, күрсәт туры юлны!**

**Аунап ята адәм актыклары,**
**И, Аллаһым, күрсәт туры юлны!**
**Җирдә юктыр җанның артыклары!**

Альберт
Хәсәнов

# ДАНӘГӨЛ

***

Чиксез диңгез уртасындагы күпсанлы вак утрауларның берсе иде бу. Унбиш-егерме метрлар өскә күтәрелгәч, текә тау битендә—штольня. Ишектән кергәч үк, як-якка берничә коридор китә. Штольня эчендәге электр лампалары бик тонык, коридор түрендә күрешле түгел. Тар гына рельсларны, кечерәк кенә вагонеткаларны шәйләде Таһир. Әмма бу мәгарәдән тышка тик шушы ике якка ачылышлы тимер ишек аша гына чыгарга мөмкин. Кыскасы, бу зинданнан качу турында уйлыйсы да, хәтта башыңа китерәсе дә юк. Бар икән әле күрәселәре егетнең... Әмма башына резин таяк белән сугуга ук сыгылып төшмәде ул. Соңгы чигенә кадәр көрәшергә булды. Ачлык игълан итте. Биргән ризыкларын ашамады, алдына куйган суларын эчмәде.

Ләкин ун көн ризык капмау аңа берни бирмәде. Синең шул рәвешчә протест белдерүеңне хупларлык халык юк монда. Хуҗаларның исләре китә, бик тә! Ун көн эчендә ул нык ябыкты, хәлсезләнде. Утырган җиреннән галлюцинацияләр кичерә, саташа башлады: үзен һәрчак карабта хис итте. Йә үзләре баталар, йә давыл-шторм, йә батучыларны коткаралар. Вакыт-вакыт үзе дә сизмәстән, кычкырып елап та ала.

Аны бу зинданга ябучыларның күзләре җете, тәҗрибәләре дә житәрлек. Таһир аларның беренче коллары гына түгел. Аның ачлык игълан итүенә бик тыныч карадылар. Бу бичара шулай саташып утырып, бөтенләй акылдан шашмагае, дип тә борчылучы булмады.

Бер көнне, кичке якта, Таһир ачлык игълан иткән бүлмәгә ике кеше килеп, аңа ашарга ризык, кайнар чәй, сигаретлар калдырып киттеләр. Мөгамәләләре иптәшләрчә, хәтта аталарча яхшы, йомшак булды. Егет төшенде: болар да—әсирләр, зиндан тоткыннары...

Таһирның хәленә кереп, теләктәш булуларын сиздерделәр. «Дускай, ашарга кирәк, юкса, син бөтенләй бетәсең,—диделәр.—Безнең хуҗа күтәрәмгә калганнарны яратмый. Андыйларны төпсез коега гына тондырта,—диделәр. Башка хәлләр турында сүз кузгатмадылар. Гәрчә йөзләре ачык булса да, иркенләп сөйләшеп китәргә мөмкин дә түгел, яннарында резин таягын тотып Горилла тора бит.

Ул кадәресен Таһир соңыннан белде. Гаиләләре, якыннары, җан сөйгән ярлары өчен хәбәрсез-нисез югалучылар бу зинданда егермедән артык иде. Бирегә шулай ук урлап китерелгән геолог француз Пьер житәкчелегендә, әлеге бичаралар, штольняның аргы башында ниндидер руда казыйлар. Комга охшаш, сибелүчән токым. Аның составында ниндидер бик

*Ахыры. Башы узган санда.*

кыйммәтле металл булса кирәк. Чөнки чагыштырма авырлыгы гаять зур. Бер чиләген ике кеше күтәрешле түгел. Бу тау токымы гаять кыйммәтле стратегик чимал икән.

—Бу металл атом бомбалары ясаганда ин төп компонентларнын берсе,—диде Пьер.—Анын тоннасы түгел, мыскалы меннәрчә долларлар тора булыр. Ә биредә без аны хуҗаларга бушлай чабабыз. Балеар архипелагындагы бихисап күп утраулар арасында шундый рудник барын бик азлар гына белә булыр.

Таһир һәм анын иптәшләре үзләре коллыкка төшкән бу утраунын кайсы тарафларда, кайсы географик кинлекләрдә булуын да аларнын берсе дә чамалый алмый. Чөнки аларнын барысын да бирегә эчертеп, исертеп, йоклатып алып килгәннәр. Тыштан, дингез кинлекләреннән караганда, бу коры җир кисәге кайчандыр вулкан атудан калыккан, кеше яшәргә яраксыз, хәтта очар кошлар да утырмый торган шыксыз, ямьсез тау-кыяны хәтерләтә булыр. Андый утрауларнын архипелагта чуты юк. Ә менә ниндидер җинаятьчел оешманын, төркемнең сизгер капшагычлары биредәге стратегик әһәмияткә ия чималны капшаганнар.

—Без—егерменче гасыр уртасы каторжаннары. Барча гамәлләре баштан алып ахыргача җинаятькә корылган мафияне без баетабыз,—ди геолог Пьер. Ул бик укымышлы кеше. Анын әсирлеккә төшүенә инде биш еллап узган.

Әлеге, бер карасан—кызгылт, икенче караганда соры-зәнгәрсу төстәге, җемелдәп торган тау токымын әсирләр вагонеткаларга төяп, кое авызына китерәләр. Биредә барысы да бик төгәл автоматикага корылган. Вагонетка келәткә керү белән астагы тирән коенын авызы ачыла, электромотор вагонетканы ян-ягына аудара. Әсирләр чапкан тау токымы аста чайкалган паром өстенә коела. Чимал коелып бетү белән кое авызы ябыла. Барысы да план белән алдан уйлап, инженерларча төгәл исәп-хисап белән эшләнгән.

Бу бичаралар мең ел ятса да, аларны моннан беркем дә эзләп табачак түгел. Кичләрен йокы блогына җыйналгач, бу турыда алар төннәр буена сөйләшеп чыгалар. Адәм баласы күңелендә барыбер өмет чаткысы сүнми икән. Өмет ул—озын гомерле бит!

Шкипер, мәлгунь, дөрес әйткән: аларны монда яхшы ашаталар. Эштән соң һәр кичне—кайнар душ. Атнасына бер саф, чиста урын-җир кертеп торалар. Әмма алар—мәңгелек әсирләр, каторжаннар, куллары-аяклары богаулы коллар. Алар кәйлә белән руда чапканда, материктагы ирекләләр рестораннарда утыралар, кино-театрларга йөриләр, сөяләр-сөешәләр, бала үстереп, аларны үчти-үчти өскә чөяләр булыр. Кайчакларны чиксез иркен дөньяны да тарсынып талашалар, хәтта сугышып та китәләр булыр. Ә Таһирлар шушыларнын барысыннан мәхрүм. Биредән шул үлеп котылсалар гына... Башка килгән уй-фикергә богау сала алмыйсын. Ара-тирә күнелләрен өметсез уйлар да баса.

Геолог Пьерны егетләр аеруча ихтирам итәләр. Шырпы кебек ябык, чал чәчле француз ул, иптәшләренә карата эче тулы—рәхимлелек, ихтирам. Бик әдәпле, тыйнак холыклы адәм. Гаиләсен өзелеп сагыну кайчакларны аны тәмам чыгырыннан чыгара. Чәчен йолкый-йолкый елап ала, «бетсәм-бетим инде»—дип, анын югалтканчы эчеп куя. Депрессиягә бирелә. Псих авыруга әйләнеп бара.

—Франциянең Алжирга экономик ярдәм йөзеннән җибәргән илле кешелек махсус Геологик Экспедициясенә мин җитәкчелек иттем. Нибары ике ел эчендә без бу илнең Геологик картасын төзеп өлгерттек. Бер очтан биредә бик бай нефть, ташкүмер, руда ятмаларын да ачтык,—дип сөйләгәне бар. Ул бик бай кеше булса кирәк. Тулон каласында бик зур җир биләмәм бар, йөзем үстерәм, үз обсерваториям, өч катлы йортым бар, ди.

—Гаиләмә, ике кызым һәм улым Шарльгә исәнлегемне генә белгертү

өчен дә, җанымны бирер идем!—дип, вакыт-вакыт холыксызланып-гасабиланып та ала.

Эчәргә теләүчеләргә, шулай ук, ни теләсән, шул бар. Хуҗалар анысын кызганмыйлар. Беләләр, эчкәч кеше күндәм була. Син ана эчәргә генә бир, чатнаган чагында аның башын гына төзәттер. Ул синең бар кушканыңны карусыз-нисез башкарачак. Аларга ай саен медицина тикшерүләре уздырып торалар. Тешең-мазар бозыла башласа да, бавыр-бөерен кайларда гомер итүләрен сиздерсәләр дә, шундук дәвалау билгелиләр. Фәлсәфәсе бик гади—хуҗаларга сау-сәламәт коллар кирәк.

Таһир беренче күрүдә ук «Горилла» дип атаган ямьсез адәмне, як-якка тырпаеп торган шыксыз мыеклары өчен Соры Күсе дип йөртәләр икән. Кулыннан резин таягын беркайчан төшерми, мәлгунь. Аны теләсә кайчан синең җилкәңдә уйнатырга гына тора. Зиндан тоткыннары кулында да бик үткен кәйләләр бар, югыйсә. Бу хайванны алай кыландырмаска булыр иде. Әмма аның артыннан җанлы шәүлә булып, икесе дә дөм чукрак җан сакчылары йөри. Алары әллә акылга да бераз сыеграклармы? Бигрәк кансызлар. Өстергәнне генә көтеп торалар.

Менә шундый хәлдә Таһир. Күз алдында Данәгөле, колагында аның тавышы. Исеннән дә чыкмый, күз алдыннан да китми. Таһир үзен портка китергән машинадан төшеп, Шәһрәт ага белән саубуллашып, катерга утырырга җыена. Бу катер аны крейсерына илтәчәк. Аның күзләре хәтта шушы пирстан да бераз төсмерләнгән, Данәгөл аны озатып калган кыяга төбәлгән. Данәгөл шуннан Таһир бүләк иткән бескозырканы изи, бер кулы күкрәгендә, күзләре тулы яшь. Таһир аны ап-ачык итеп күрде.

Ә йөгерек җилләр Данәгөлнең:

—Таһир! Таһир! Син минем бергенәм!—дигән сүзләрен ишеттерделәр. Ә башка өзелеп-өзелеп әйткән сөю сүзләрен диңгез кинлекләренә алып киттеләр ахры.

Вәгъдәсенә тугры калып, Данәгөл һәр иртәне аны шулай көтә булыр. Соңгы сулышына кадәр. Шулай вәгъдәләштеләр бит. Тик менә Таһир гына аны бүтән күрә, кочакларына алып, иркәләп тирбәтә алмас микәнни? Монысы аның башына сыймый. Тәнендә җаны барындамы? Беләк юанлыгы чылбырларны да ул теше белән чәйнәп өзәчәк! Данәгөлгә булган мәхәббәте хакына!

Хөрмәтле укучым, әсәр барышында, дөньяда кешеләр, тере җаннар арасында була торган иң бөек хискә, яратуга, мәхәббәткә һәр адымында җанын фида кылырга әзер торган Таһирны, тумас борын йонын кыркыткан бер аңгыра бәрәнгә саный булырсыз. Юкса соң? Диңгезләр, давыллар кичкән моряк, үзен шушы зинданга ябып кол иткән мәлгунь шкиперның ичмаса бер сугып, ярты «взвод» тешен дә коймады дип, аны орышасыздыр. Коймаган кая! Татар егете Таһир Туктамышевның, тимер юл рельсларын ныгытканда тимер чөй кага торган авыр кувалдадай йодрыкларының «кадерле» генә сыйпап алуын бер тапкыр, әмма бик берәгәйле татыды җирән сакал. Берчак ул штольняга нindидер эш белән бик ашыгып-әтәләнеп килеп чыкты. Гориллага да җикеренеп алды. Ике биленә таянып, Таһир янына килде. Мыскыллап күз кыса, күптәнге танышымы? Йә, ничек, дускай, минем белән кайнар грог эчкән чакларың исеңдәме, имеш...

—Хәтердә булмыйча! Бик хәтердә!—дип, Таһир ана кулын сузды. Күрешмәкче булды, янәсе. Шунда ана, җан ачуы белән: «Бетсен, яшәмәсен бу хәшәрәт!»—дип берне китереп сылады. Бу ударга бокс буенча дөнья чемпионы Мөхәммәт Али дә ауган булыр иде. Җирән сакал да җиргә сузылды. Аны аңсыз хәлдә өстерәп алып киттеләр.

Таһирның үз өстенә очынып килгәннәре булды. Ләкин ул бармак белән дә чирттермәде. Кагылып карасыннар, аның кулында—тимер ыргак!

Ялчыларның атарга, утлы корал кулланырга хаклары юк. Чөнки Таһир аларга иң кирәкле колларның берсе, шартлатучы. Таһирдан башка алар кыл да кыймылдата алмыйлар. Шурфларга зарядны бит математик төгәллек белән хисаплап салырга кирәк.

Шул очрактан соң Таһир шкиперны протез тешләр белән күрде.

Штректа шартлаткыч патроннар тутыру өчен шпурлар, шурфлар тишкәндә, кин күкрәкле, алыптай гәүдәле төрек егете Мостафа белән дуслашты Таһир. Бу зинданга эләгүенә аның бишенче ел киткән. Шушы вакыт эчендә, тәүлекләргә әйләндерсәң—1825 тәүлек, түз генә! Ул берәү белән дә якынаймаган, дуслашмаган. Беркемгә ачылмас, сөйләшмәс, елмаймас, үтә дә кырыс йөзле егет Мостафа. Күзләрендә генә беркайчан сүнмәс ут дөрли. Алардан буйсынмау, тез чүкмәү, бу коллыктан ничек тә котылу өчен теләсә нинди, хәтта башка сыймаслык тәвәккәллекләргә барырга әзер ут чаткылары чәчри сыман.

Шушы теләген тормышка ашыру юлында, кайчакларны башка сыймастай хаталар да эшләп куюдан үзен-үзе тыеп, Мостафа борын эченнән гел бер озын көй көйли. Бу көй аны иң кызган чакларында: «Мостафа, ашыкма, ашыгып, ахмаклыкларга юлыкма, сәгатең сукканны көт!»—дип, кисәтеп килә иде бугай...

Вәләкин Мостафа белән Таһир, бер-берсенә күптән дустанә караса да, күңел ишекләрен төбенәчә ачып куярга гына ашыкмадылар. Аңлашыла да, зинданда яшәү шартлары шулай куша бит! Һәр адымда: «Сак бул!»—дип кисәтеп тора.

Таһирның бирегә эләгүенә өченче ел китте. Ятак башындагы фанера кисәгенә 760нчы сызыкны сызды...

—Сыз, әйдә, сыза бир. Монда акбур кисәкләре житәрлек. Сызар тактаң тулгач, ташларсың,—дип мыскыллы елмая Соры Күсе. Геолог Пьер, бик нечкә күңелле француз, гаиләсен, инде житеп килгән кызлары Мэри белән Жаннаны, улы Шарльне өзелеп сагынудан бөтенләй эчүгә сабышты. «Кайда булуымны, ни эш башкаруымны беркемгә дә әйтмәм. Зинһар мине берәр атнага гына жибәрегез. Балаларымны күрим. Аннары тагын килеп алырсыз. Мин сезгә чын француз сүзе бирәм!»—дип, ялкынланып-ялкынланып ялвара бичаракай.

Кытай Ли сукырайды. Атлет гәүдәле грек егете Астакидис рудалы кәржин белән коега ташланды. Ә хужалар руда чыгаруны киметергә жыенмыйлар. Ике яңа бичараны—Джек белән Томны тотып китерделәр. Икесе дә Шотландия моряклары, алар да нык салган, төшергән баштан эләккәннәр. Ярады әле, зиндандагылар алар аша дөнья яңалыкларын белештеләр. Юкса, алар монда үтергеч изоляция шартларында яшиләр. Радио юк, газета бирмиләр. Диңгез уртасындагы әлеге исемсез кечкенә утрауда яшерен шахта-штольня барын, аларның монда стратегик чимал чыгарып ятуларын берәү дә белми шул. Аларны кол иткән яшерен синдикатның эшләре көйле булса кирәк. Кемнәр икән соң алар? Сенатларда сенатор булып, парламентларда депутатлар булып, ак күлмәкләрдән, кара фраклардан утыра булырлар әле. Ялларын Атлантик океан ярларында, Ямайка атауларында эре комда кызынып уздыралардыр. Бу зинданнан котыласы да, алар койган бомбаларның иң көчле эквивалентлысын менә аларның штаб-квартираларына ташлыйсы иде дә бит!

Бу араларда жирән сакаллы шкипер штольняга нигәдер еш килә башлады. Иш янына куш булыр дипме, бу юлы, кабырга сөякләре тәртеп торган, күзгә чебештәй ябык, чем-кара негр егетен әләктергән. Хужаларның нияте—руда чыгаруның күләмен тагын да арттыру.

Хәрби флотта да минер булып хезмәт иткәнлектән, шартлату эшләрен Таһир үз жаваплыгына алды. Шартлаткычлар белән бик сак һәм төгәл эш итәргә кирәк. Рассчетларны төгәл ясамасаң, чаманы белмәсәң, штрекның үз өстеңә ишелүе дә ихтимал. Соры күсе шартлаткыч патроннарны

Таһирга үзенчә бик төгәл исәп белән бирә. Әлеге стратегик әһәмияткә ия тау токымын кәйлә белән чабарга керешкәнче, ишәсе стенада метр-метр ярымнар эчкә шурф тишәләр. Таһир шул шуфрларга һәркайсы бишәр йөз граммлы, эчләре ак дары белән тутырылган гильзалар салып чыга, юнәлеш биреп шартлата. Тоткыннарга руда чабу җиңеләя. Хезмәт җитештерүчәнлеге үсә, хуҗалар моңа бик канәгать.

Соры Күсе Таһирга күпме аммонал шашка бирүен махсус кенәгәгә теркәп бара. Әмма дә ике-өч шашканы шурфка салмыйча, яшереп калдыру Таһирга берни тормый. Аның ничә шурф бораулатуын, аларга ничә данә шашка салуын санап тормый бит ул. Тора да алмый. Өстенә штрек ишелүеннән курка. Андый хәтәр эшләрдән ерак булырга тырыша. Шартлату алдыннан еракка качып, будкасына кереп бикләнә.

Шашкаларны яшереп алып калып була. Ләкин алар белән бередә нинәрсә генә кыла аласың? Әгәр шуларның берсен генә булса да Соры Күсенең йомшак урындыгы астына куеп булса икән! Менә ул чын мәгънәсендә тулы фейерверк булыр иде. Куярсың, бар! Аның тән сакчылары, сукыр күп күрер, аксак күп йөрер, ди, дөм чукраклар булсалар да, үзеннән болайрак сизгерләр. Соры Күсенең янына якын да җибәрмиләр.

Әмма көннәрнең берсендә Таһир шуны сизде: ул яшереп алып калган шашкалар яшергән җирдән берәмләп югала башладылар. Таһир моны тиз абайлап алды. Әмма сизмәгәнгә салышты. Белергә кирәк, кем эше бу? Шашкалар үзләреннән-үзләре генә аякланмыйлар бит инде. Аннан башка араларында минер, шартлату һөнәрен белүче дә юк шикелле.

Узган атнаны аңа шашкаларны бер тартма итеп бирделәр. Тартмада бишәр рәт белән, илле данә. Хуҗаларның, Шотландия егетләре Джек һәм Том, әлеге чем-кара негр егете хисабына, руда чыгаруны тагын да арттырасылары килә. Нәфес бит ул баеган саен үсә. Ә боларныкы—чүпрә салгандай күперә булыр.

Бу шашкалар—биш тапкыр шартлату өчен. Аларны хәзер кем чәлдерсә дә, иң унай момент. Ике-өч патронның юкка чыгуын сизми калырга да мөмкин. Таһир аларны берәмләп санап тормас ич инде. Чөнки монда, җиде кат җир астында, алар кемгә хаҗәт? Шартлаткычларны саклый торган шкафын Таһир юри ачык калдыра башлады. Урлаучыга җиңелрәк булсын. Сәер, бик сәер. Аларны кем чәлдерә, нинди максат белән?

Бер кичне Таһир, шкафын ачып куйды да, үзе аның артына посты. Байтак көтте. Ишетә, инде төн житкәч, штольняда утларны сүндергәч, кемдер, кыштыр-кыштыр атлап, аның алачыгына таба килә. Аяк очларына гына басып эчкә керде. Шкаф алдына килде. Капшана. Таһир аны күрмәсә дә, барын сизеп тора. Мышный бит. Тын алуын ишетә. Угры, шылт иткән аваз чыгармый, патроннар салган тартманы алды. Шунда Таһир кинәт кенә кесә фонарен кабызды. Кабызса, күзләренә ышанмый торды. Мостафа ич бу! Ул да Таһирны күреп алды. Куеныннан шундук пычак чыгарып, Таһир өстенә ташланды. Шунда Таһир каушап калсамы? Мостафа аны чебеш урынына чалып ташлаган булыр иде. Югыйсә икесе дә мөселманнар. Күп сүзләре дә уртак. Штольнядагы әсирләр, вата-сыта булса да французча геолог Пьер телендә аралашсалар, Таһир белән Мостафа исә берсе татарча дәшеп, икенчесе төрекчә җавап биреп аралаштылар...

Көч-хәл белән Мостафаның кулыннан хәнҗәрен каерды Таһир, үзен стенага терәде. Биш-алты катлы итеп сүгенәсе дә, ярамый. Стеналарның да колагы бар. Соры Күсенең ишетүе бар. Икесе дә мыш-мыш киләләр. Бар булмыш көче белән төрек егетен стенага бик нык терәде. Гырылдый бичара. «Дилбегә»не бераз бушата төште. Бармагын иренәнә куеп:

—Тысс, кызма! Патроннарны кирәгенчә ал! Бу турыда берәүгә дә әйтмә!

Тысс!—дип пышылдады.—Тысс! Юкса, кых үзенне!..

Биредәге егетләрнең качарга җыенуларын, шул турыда план коруларын Таһир күптән белә иде. Ләкин, аларны электрон-радио аппаратура белән саклыйлар. Башыңа да китермә, качырсың моннан, бар! Әлеге җинаятьчел синдикатны мәми авыздыр, дип уйлау—тирән ялгышлык.

—Монда эләккәннәр—шушында үләргә дә тиешләр!—дигән принципка корылган системаны хуҗалар бар ягын камилләштереп корганнар.

Бу төркем-группага кемнәр керә соң? Төркемнең башлыгы сумала төсле чем-кара чәчле, какча йөзле, куе кара кашлары астында тәвәккәллек хисләре уйнап торган, очлы күзле испан егете Жорес булмагае. Иң күңелсез минутларда да төшенкелеккә бирелгәнен күрмәссең. Кулына җиде кыллы гитарасын да алса, күңеленне бөтенләй күтәреп җибәрә. Һәркемгә җылы сүзен кызганмаса да, кырыс сынаулы карашлы! Әгәр егетләр качарга җыена икән, алар бу эшкә Жорестан башка алынмаслар.

## 10

Яңа елга каршы кич дип тормады, Урта диңгез актарылып-актарылып дуларга кереште. Аның ни дәрҗәдә котырынуын, холыксызлануын тоткыннар җир астыннан торып та сизәләр.

Үзара:

—Ай-яй, котырына, әллә утравыбызны ук урыныннан кузгатмак буламы? Ишеп үк ташламасын тагын...—диделәр.

—Ярап куяр иде ул! Без дә бу зинданнан котылыр, ирекккә чыгар идек!—дип сөйләштеләр.

Мондый кичтә бар җан ияләре өчен күптән расланган бер теләк, сыеныр куышың булса, шунда сыен! Борыныңны төрт, тынынны чыгарма.

Берөзлексез гашиш-анаша суыра-суыра йөзе йомырка сарысыдай саргая барган Соры Күсе, әсирләргә: «ятыгыз шушында, черегез» дигән караш ташлап, аларны тышкы яктан өч йозакка бикләде дә, мулатка сөяркәсен алып, каядыр Яңа ел каршыларга китеп барды. Монарчы да шулай бикләп киткән чаклары булды. Нигә китмәскә? Башкалар бәйрәм иткәндә, нигә аңа да иркенләп кәеф-сафа кормаска? Әллә мөмкинлеге юкмы? Кочагында сөяркәсе... Тоткыннарга аларга нәрсә булсын? Тоз түгел—җебемиләр, боз түгел—эремиләр. Нарасыйлар да түгел, имезлек каптырасы юк. Соры Күсе бу юлы да бер дә шикләнми китеп барды. Өч кат ишекне каерып карасыннар! Син аны танк белән дә аудара алмыйсың.

Әмма бу сәгатьне егетләр дә өзелеп көткәннәр иде шул!

—Тәвәккәлләсәк, менә бүген! Мондый ипле очрак бүтән мәңге булмаячак!—дип җилтерәтте барысын да Жорес.—Монда кол булып, юеш зинданда черегәнче, Урта диңгезнең талымсыз балыкларына азык булуың мең өлеш артык!

Бар булган шартлаткыч аммонал шашкаларын тимер ишекләр астына куйдылар. Металл һәм бетон баганаларны аудару өчен күпме заряд салырга икәнен исәпләп торыр чакмы? Икесенең берсе: йә штольня белән һавага очачаклар, ә инде исән калсалар, коллыктан котылачаклар.

Таһир—югары класслы минер. Биредә дә байтак тәҗрибә туплады. Аларның болай кабалануы—ажгырып килгән поездга каршы чыгып, рельсларга башыңны салу белән бер. Тәвәккәлләр акылсыз була. Әллә аларның акыллары гамәлләреннән алдарак чабамы? «О, безумстве храбрых песню мы поем!»—дип юкка гына җырламыйлардыр ул.

... Бөтен утрауны дер селкетеп, хәтта бераз чайкалдырып, гөрс итеп шартлау яңгырады. Егетләр иң ышанычлы штрекка кереп яшеренгәннәр иде—йөгерешеп чыктылар. Карасалар, заряд штольняның ишекләрен тупсалары-ниләре белән диңгезгә үк каерып ташлаган. Бушлыктан ачы җил

өрә. Юл ачык! Әмма егетләр бер мәлгә тораташ булып катып калдылар. Күзләре күргәнгә ышанмадылар. Бу минутлар монарчы аларның татлы хыялларында гына яшәде бит.

Диңгездән искән салкын җил, битләреннән сыйпап, аларны тораташ хәленнән тиз чыгарды. Жорес белән Мостафа руда коя торган улактан аска шудылар. Алардан күреп, Таһир да аска сикерде. Аста—ят күзләрдән бик оста яшереп ясалган ангар. Алар өстән койган руданы алырга килгән катер менә шушы ангар ышыгында ышыклана торган булгандыр. Ә бер читтәрәк тиз йөрешле, җилкәнле көймә тора. Аңа сикерештеләр. Ун-унике кеше сыешлы бер дигән моторлы баркас. Йөз литрлы канистрда запас бензин да бар. Күтәрәм дисәң, ике җилкәне әзер. Соры Күсенең диңгезгә чыгып кәеф-сафа кора торган көймәсе булса кирәк. Пакетларда ризыклар, хәтта берничә шешә ром да бар.

—Беркемне дә калдырмыйбыз! Сыешырбыз!—диде Жорес.

—Ниһаять!—дип, Мостафа ике кулын күккә күтәрде.—Гомерем буе—кара бәхетем, карбыз алгач кына кызыл булып чыкты!

Качаклар, баркасның көчле моторын кабызып, диңгезгә ыргылдылар. Бу кичтә чыгырыннан чыгып дулаган диңгез аларны куркытмый. Таһир, Мостафа, Джек белән Том да диңгезләрне күп кичкән егетләр.

Тагын бер киңәшкәч, бик ерак булса да, Алжирга таба китәргә булдылар. Бу курс белән барганда, юлда берәр сәүдә карабына юлыгу мөмкинлеге дә зур. Юлга чыксаң, юлдашларың синнән уңганрак булсын, ди бит. Сары чәчле, зур зәңгәр күзле инглиз егете Джек та үз гомерендә күпне күргән диңгез бүресе булып чыкты.

—Марсельдән Алжирга, бик ачык хәтерлим, алты йөз илле мильләр чамасы. Ә Балеар архипелагыннан Алжирга байтак якынрак. Шулай да биш йөз мильләр булыр,—дип саргылт йон баскан юан бармакларын бөгеп, бик тиз исәпләп чыгарды ул.—Бензин җитмәс. Анысы зур кайгы түгел. Кайда җилкән куеп, кайда дрейфка ятып, без анда ун-унике көннәрдә барып җитәрбез. Курсны Алжирга алабыз. Башкасына түзәргә булыр, безгә суны сакларга кирәк. Бүгеннән, шушы минуттан һәркемгә—көненә өч тапкыр өчәр кашык. Түзәрбез. Аны саклауны үз өстемә алам,—дип, су канистрасын үз янына куйды.

Джек, чыннан да, ун көн буена суны иптәшләренә марляга манып, иреннәрен чылатырга гына бирде.

—Курыкмагыз! Берегез дә авыз кипкәннән үлмәс. Мондый ситуацияләргә эләккән булды инде,—дип, суны күбрәк, һич югында ярты стакан сораучыларны тынычландырып барды.

Тиз йөрешле, суны җиңел ярып баручы баркасны юлдаш җил Алжир ярларына таба куды. Давыл да басылды. Көндезләрен чалт иткән кояш астында, төннәрен салкынча диңгездә, кысынкы баркаста йөзү берсенә дә җиңел бирелмәде. Егетләр үзләре турында түгел, геолог Пьер турында күбрәк кайгырттылар, аны сакладылар. Хәтта Джек та аңа суны башкаларга караганда бермә-бер күбрәк бирде. Чөнки Пьерны Тулон каласында хатыны, ике кызы һәм улы Шарль сигезенче елын көтә булырлар. Гаиләсе кочагына ул исән-имин кайтып керергә тиеш!

Алжир дәүләте территориясенә килеп житкәч, коллыктан котылдык, менә-менә материк җиренә аяк басабыз дигәндә генә, аларны артларыннан тиз йөрешле, биш җилкәнле шхуна куып җитте. Туктарга, кире борылырга кушып, ут ачты. Беттек, бәхетебез тагын көпчәккә чорналамы, дип торганда гына... Ярый әле шулчак тиз йөрешле өч катер белән Алжир яр буе чик сакчылары килеп чыктылар, качакларны үз канатлары астына алдылар. Эре калибрлы пулеметлардан ут ачып, әлеге шхунаны диңгез эченә чигенергә мәҗбүр иттеләр.

## 11

Алжир ярларына аяк басу белән, качакларны резервациягә урнаштырдылар. Геолог Пьерның гына хәле үтә начар иде. Аны хәрби госпитальгә салдылар. Качакларның, бичараларның, кемнәр булуы йөзләреннән, аяк атлауларыннан күренеп тора. Ничек әле оеша, шушы хәлдә кача алганнар?

Резервациядә ашау-эчү шартлары түзәрлек, мохтаҗларга медицина ярдәме дә күрсәтәләр. Атна-ун көннәр узгач, Алжирның контрразведка органнары, берәм-берәмләп кенә аларның кемнен-кем, каян булуларын ачыклый башладылар. Аларга сизгерлекләрен бер генә минутка да югалтырга ярамый. Алжир озак еллар Франциянең колониясе булып торганлыктан, ике дәүләт арасында киеренке дипломатик мөнәсәбәтләр бүген дә сизелә, туып тора. Алжирның патриотлары, икенче бөтендөнья сугышы тәмамлангач, азатлык яулап, Франциянең элекке колониясен Алжир халык демократик республикасы, дип игълан иттеләр. Франциянең житәкче даирәләре «итле», «симез калҗалы» колонияләрен кулдан ычкындыруларын бүген дә оныта алмыйлар. Җае чыкса, чеметеп алырга, умырып тешләргә, провокация ясарга гына торалар. Шунлыктан, Алжир контрразведкасы әлеге качакларга да бик шикләнеп карады. Бу актның бик оста сюжетка корылган, әмма чепчи легенда булуы да бик мөмкин. Бер дә харап: качканнар икән!? Аларның ата бандитлар, битлек кигән террористлар булулары да бик ихтимал лабаса... Геолог Пьер белән мәсьәлә тиз ачыкланды. Аның исеме хәтта Алжирның үзенә дә күпләргә мәгълүм булып чыкты. Чөнки ул Франция хөкүмәтенең кушуы буенча Алжир территориясендәге жир асты казылма байлыкларын тикшергән, запасларын билгеләгән экспедициядә катнашкан. Шушы мәсьәләгә кагылышлы күп документларга кул куйган. Ул эшләгән департаментка хәбәр салу белән, аның бүгенге хуҗалары геолог Пьерның исән булуына чиксез шат булуларын әйттеләр. Тиз арада Парижлан махсус самолет белән килеп, аны алып та киттеләр.

Алжир контрразведкасы берәр ай чамасы качакларның һәркайсыннан аерым-аерым сораулар алганнан соң, бу бәхетсезләрнең чыннан да әлеге хәлгә юлыккан, мафия кулында иза чиккән бичаралар икәнлегенә ышанды бугай. Бугай гына. Контрразведканың бернигә, бернәрсәгә дә, хәтта кулындагы саф алтын бөртегенә дә—бу саф алтын бөртеге, дип, алдына утыртып сөйгән бердәнбер улына да, бу минем улым, дип ышанырга хакы юк. Ул шундый орган. Аның җилкәсендә илнең, дәүләтнең куркынычсызлыгы, халыкның иминлеге. Ул бернәрсәгә дә ышанмаска, бар нәрсәдән шикләнә белергә, һәрчак уяу булырга тиеш.

Бик вак күзәнәкле «иләк» аша уздыргач, Мостафаны төрекләргә бирделәр. Таһирны Алжирдагы совет илчелегеннән кара «Джип» белән килгән егеткә утыртып җибәрделәр. «Ниһаять, котылдым бугай!»,—дип Таһир башта бик сөенде. Әмма монарчы күрмәгәннәре әле алда булган икән. Илчелектә ике атна тотканнан соң, тагын нәрсәләрнедер кат-кат ачыклагач, аны самолет белән Мәскәүгә озаттылар. Бу самолетта Джельфа-Алжир нефтьүткәргечен салуда кайсы бер ел, кайсылары ярты гына ел катнашкан шат күнелле совет тракторчылары, бульдозеристлары, электриклары кайттылар. Таһирның алар белән рәхәтләнеп бер сөйләшеп кайтасы килгән иде. Озата кайтучы егет аның авызын да ачтырмады. Чөнки аларның икесенең кулында да богау. Йозакның бер биге Таһирның сул кулында, икенчесе—әлеге егетнең уң кулында. Алар белән кайтучы пассажирлар богауларга игътибар итмәсеннәр, гомумән, күрмәсеннәр өчен, әлеге егет аларның ике кулы арасына бик оста итеп соры җиләнен салган. Самолетка да иң соңгы пассажирлар булып кереп, иң арттагы ике урындыкка утырдылар. Таһир күңелендә әллә нинди каршылыклы уйлар уйнаклый. Ни генә булса да, ул туган илгә кайта. Бу

богауны ни дип кидерделәр соң инде аның кулына? Кая да булса качу планы аның башына да килгәне юк. Ни булса, шул булыр инде... Туган иле, Ватаны үз баласының башын уйламый-нитми, сораштырмый гына чапмас әле. Әйе... Кылган гөнаһысы да җинаять дип санарлык микән әле? Әйе, законсыз, рөхсәтсез СССР чикләрен бозды. Рәхмәт әйтешле гамәл түгел. Алай да? Шуннан кемгә зыян? Күрәсен үзе күрде...

Самолеттан төшә торган трап төбендә аны кап-кара костюмнар, ап-ак күлмәкләренә буй-буй галстуклар таккан, озын буйлы, кырыс йөзле ике егет каршы алдылар. Аэропорт бинасына кереп тә тормыйча, самолет канаты астында ук торган кара «Волга»га утырттылар. «Волга»ның бар тәрәзәләре дә—тонык-карадан... Таһир—Мәскәүдә беренче тапкыр. Башкала урамнарын карап барасы килгән иде дә, әмма тәрәзә аша алар бик тонык күренәләр.

—Егетләр, сез мине кая алып барасыз?—дип сорады ул әлеге егетләрнең аның белән янәшә утырганыннан. Һәрхәлдә, башкаланың иң атаклы ресторannарыннан берәрсенә—«Берлин», «Пекин», «Останкино»га, иртәнге чәйгә, йә берәр тантаналы очрашуга түгел инде. Анысын үзе дә сизә. Әлеге егет, бер сүз белән генә:

—Баргач, күрерсез...—диде.

Юлда беркая да туктап тормыйча, Таһирны, күп очракта сәяси тоткыннарны, хәрби җинаятьчеләрне яба торган «Матросская тишина» төрмәсенә китереп яптылар. Аны каршы алган егетләр—профессионал чекистлар иде булса кирәк.

***

Икенче көнне үк күрше камерадан аңа «тук»-«тук» итеп шакый башладылар. Өч елдан артык диңгез флотында хезмәт итсен дә, Таһир Морзе әлифбасын ничек белмәсен инде? Яхшы ишетелсен өчен, стенага тимер кружкасын терәде, колагын куйды. «Син кем? Каян? Нәрсә өчен эләктең? Кайсы статьялар белән гаеплиләр? Нык тор! Бирешмә!»—дип «так»-«ток» шакыды күршесе. Таһир, юкса, аның барча сорауларын да аңлады. Шайтанның белсенме, провокатор-мазар түгелме? Махсус провокация булмагае, дип шиккә калды. Бу шакуга җавап бирми дә, берни ишетмәгәнгә салышып та булмый. Таһир Морзе әлифбасын бөтенләй белмәүче сыман, күрше як стенага мәгънәсез «шак»-«шок» сугу белән генә чикләнде. Итәгеңне җыеп йөрү бер дә зыян итмәс...

Надзиратель агай беркөнне камера ишеген киң итеп ачты.

—Принимай гостя, молодой человек!—диде. Ишектә киң җилкәле, күзлекле, ярым пләш башлы, күрер күзгә килбәтле генә йөзле, кырыклар тирәсендәге ир уртасы күренде. Кулында—бераз таушала төшкән калын папка. Өстендә гражданский кием булса да, хәрби икәне сизелә. Таһирны күптән белгәндәй:

—Гражданин Туктамышев, ничек, камера шартларына бераз күнектегезме?—диде.—Безнең монда тыныч, рәхәт. Иртәнге якта майлы ботка, кайнар чәй. Төшкә кәбестә ашы. Икенчегә ит белән бәрәңге, компот. Курортның үзе! Шайтан алгыры, чираттагы ялымны алып, әллә үземә дә берәр ай утырып чыгасы инде? Диссертациямне тәки тәмамлый гына алмыйм бит. Эш тә эш! Очы-кырые юк.

Бу кешенең кем, аның янына нинди максатлар белән керүен белмәсә дә, Таһир:

—Ә нигә икеләнеп торасыз? Керәсез дә утырасыз!—дип түргә чакырды.

Ир, ике кулын кесәләренә тыккан хәлдә, әле үкчәләренә, әле аяк очларына күчеп, тирбәлеп, берара сүзсез торды.

—Булмый шул,—диде ул.—Мина сезнең «дело»ны алып баруны йөкләделәр. «Волэнс—нолэнс» була латинча, теләсән дә, теләмәсән дә

алынырга туры килде.

Әлеге ир уртасы өстәлгә бер кап сигарет чыгарып куйды.

—Тартасызмы? Силь ву плэ! Рәхим итеп. Көйрәтеп җибәрегез.

Таһир башын чайкады:

—Тартмыйм.

—Кызык! Бик кызык. Хәтта сәер. Шул кадәр күпне күреп, күп илләрдә булып, тартмыйсыз. Ә менә үзем көненә бер капны «ашыйм» да куям. Сезнең характерны ачуда—тартмавыгыз минем өчен бик әһәмиятле деталь!

Таһир чамалады, аның янына камерага кергән бу кеше, аның эше буенча тикшерүче, ягъни, следователь булырга тиеш. Таһир алай да:

—Ә мин сезне кем дип белим?—диде.

—Мин... э-э-э, КГБның өлкән тикшерүчесе, майор Туктаров. Зуфар Хакимович. Сезнең эшне мина йөкләделәр. Бөтенләй очраклы рәвештә. Чөнки безнең тәҗрибәле күп следовательләребез икенче бер бик җитди процесста мөеннан эштә.—Туктаров коллегаларының муеннан чумып эштә булуларын бармагы белән муенына сызып күрсәтте. Хәтта берникадәр көлке дә чыкты. Таһир авыз чите белән елмаеп алды.

—Әйе, әйе, мин татар,—дип дәвам итте ул.—Мин—Курган татары. Урта мәктәпне алтын медальгә тәмамладым. МГУның юридик факультетына имтихан тоттым. Аны Кызыл диплом белән тәмамлагач, мине Дәүләт куркынычсызлыгы органнарына дәштеләр. Бу өлкәдә уналтынчы елымны эшлим. Бик кызык язмышлы контингент белән очрашырга туры килә. Менә сезнең дә тормыш юлыгыз—ой-ей-ей! Ләкин алдан ук шуны кисәтеп куям, татар милләтеннән булуым биредә берниндә дә роль уйнамый. Моны сез дә исегездә тотыгыз!

Аннары ул кинәттән генә:

—Гражданин Туктамышев, РСФСР Җинаятьләр Кодексының «64 «а»» маддәсе сезгә таныштыр?—дип сорап куйды.

Бу зрә дә укымышлы тикшерүче алдында Таһирның да дөм-томана булып күренәсе килмәде. Ул әлләни исе китмәгәндәй:

—Әллә инде...—дип кенә уздырды.

—Әле монда, сезнең камерага кергәнче,—дип сөйләп китте тикшерүче Туктаров,—сезнең биографиягезне, тормыш юлыгызны ачыклау буенча мин колоссаль эш башкардым. Алар барысы да шушы папкада.

Салкын Алан авылында урта мәктәпне тәмамлагансыз. Авылда алдынгы комбайнер булгансыз. Комсомол путевкасы белән Чистай авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагансыз, һәрчак уку алдынгысы булып, аннан техник-механик дипломы алып чыккансыз.

Следователь Туктаров, кесәсеннән мамык чыгарып, аны шырпы очына чорнап озак кына сул колагын казып торды. Бу нәрсә? Тоткынга психологик тәэсир итү алымымы?

—Сезне, физик һәм рухи яктан тап-таза татар егетен, хәрби хезмәткә Кара диңгез флотына алганнар. Флотның флагман карабына—«Сергей Киров» крейсерына эләккәнсез. Бөтендөнья киң җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә торган дуслык визиты белән, «Тимер Чаршау» пәрдәсен ертып, Франциянең иң көчле хәрби порты Марсельгә баргансыз. Бу каләресе мина аңлашыла. Ә менә шуннан соңгылары томан эчендә.

—Нәрсәсе томан эчендә?—дип кисәктән бүлдерде аны Таһир.—Әле илчелектә язган аңлатмамда ук мин бар булганны, бер детальне дә төшереп калдырмый яздым.

—Шулаймы-ы?—дип суздьі следователь нык гаҗәпкә калган сыман. Аяк очларыннан үкчәсенә күчеп тирбәнеп алды.—Ул чакта без конкрет эшкә күчик. Шөхрәт Нугайбәк әфәнде кайсы илнең, кайсы разведканың агенты? Аның кызы Данәгөл кем?—дип, бармакларын бөгеп, сорауларын тезә башлады.

—Данәгөл—минем никахлы хатыным. Менә хәзер дә, нәкъ менә шушы минутларда да, аны өзелеп сагынам. Канатларым булса, хәзер очар идем!—дип бүлдерде аны Таһир.

—Аңлыйм, аңлыйм! О-о, мәхәббәт—дөньяда иң бөек хисләрнең берсе! Монысы бәхәссез! Ләкин безне менә нәрсә шикләндерә, гражданин Туктамышев, бу вакыйгалар чылбыры алдан ук ныклап уйланылган, расланган сценарий буенча бармыймы?

—Нугайбәк ага әхлакый яктан энже бөртегедәй саф кеше. Минем бабам, ягъни өзелеп сөйгән хатыным Данәгөлнең әтисе. Марсель Сәүдә портының тирән ихтирамга лаек, ун-унике телдә сөйләшә белгән, бирегә кергән барча чит ил карабы капитаннарының якын дусты, тәрҗемәчеләре! Әлеге портка кереп якорь салган караб капитаннары беренче эшләре итеп аңа мөрәҗәгать итәләр. Аны эзләп тапсалар, эшләре уңачак, йөкләре тиз бушатылачак.

Тикшерүче Туктаров шап итеп учын учка сугып алды.

—Беренче класслы агент булу өчен иң ипле эш урыны инде бу! Моннан да яхшы конспирациянең булуы да мөмкин түгел. Ә күп телләр белүе! Әгәр миңа берәр агентымны берәр илгә внедрять итәргә туры килсә, мин шулай күп тел белүчене һәм шундый ипле урын сайлаган булыр идем,—дип куйды.—Сезнең биографиягездә ак таплар нәкъ менә шушы моментлардан соң башлана. Бу турыда без үзебезнең коллегалар белән байтак баш ваттык. Шөһрәт Нугайбәк әфәнде сезне ничек эзләп тапты? 1нче ранг капитаны Соболь, юкса, бик җитди кеше, сезне кунакка ничек җибәрде? Үз өстенә нинди җаваплылык алуын аңлап бетермәгән булса кирәк. Юкса, нинди авторитетлы капитан.

—Беренчедән, без Марсельгә дуслык визиты белән килдек. Безнең крейсерда көн саен уннарча делегацияләр, аерым французлар булып торды. Икенчедән, Нугайбәк аганың гаиләсе, әти-әниләре 1921 елны Идел буе халкын кырган ачлыктан качып, Финляндиягә киткәннәр. Ачлык-хәерчелекне балачактан ук татып, ахырда Марсельгә килеп төпләнгән. Үз халкын, үз телен сагыну һәркем өчен бик табигый хәл. Франция газеталары безнең дуслык визиты белән киләчәгебез турында яза башлагач, аның башына: СССРдан, бөек Россиядән килгән хәрби карабта бер генә татар егете бардыр әле, дигән уй килгән. Ул егет менә мин булып чыктым. Аның кызы Данәгөл туташка бер күрүдә күзем төште. Без башларыбызны бер мендәргә салдык. Никах укыттык.

—Гражданин Туктамышев, болар барысы да дөреслеккә шул кадәр якын...—диде Туктаров аны бүлдереп.—Сезне бит калырга кыстаганнар... Безгә барысы да билгеле...

—Данәгөлнең әтисе Ногайбәк ага ничек кенә кыстады әле!

—Ник калмадыгыз?

—Ничек калыйм? Илемә, халкыма биргән антыма-присягама хыянәт итә алмадым.

—Слишком высокопарные слова, гражданин Туктамышев. Я не верю ни одному вашему слову! «Караганда» теплоходыннан качып, өч еллар кайда югалып тордыгыз? Монысына нинди аңлатма бирәсез? Менә шушы соравыма бик дәлилле җавап көтәм мин сездән. Ә сез аны әйтергә, ягъни тирән серне чишәргә теләмисез. Бу килеш сезне җаваплылыктан да азат итеп булмый. Ирекка җибәрә алмыйбыз. Алай гынамы?! «64 «а»» маддәсе—бик коры статья ул. Ә мин сезне нәкъ шул статья белән гаепләргә җыенам.

—Сез үзегезнең күп сорауларыгызга җавапны минем капитаным Роман Сергеевич Собольдан сорап таба алыр идегез. Франция ярларыннан кайткач, аңа контр-адмирал дәрәҗәсе бирделәр.

—Хәзер инде тулы дәрәҗәле адмирал Соболь бүген Ангола, Вьетнам

ярларында халыкара тынычлыкны ныгытуга юнәлдерелгән бик җаваплы эшләр башкара. Без аны мондый вак мәсьәләләр белән борчырга җөрьәт итмәдек. Киресенчә, борчырбыз да. Хокуклар—безнең кулда!

Бераздан Туктаров үзе дә, янә бер сигаретын суырып бетереп, берни булмагандай:

—Чирәм җирләргә «Сергей Киров»тан ике йөз егерме егет килгәнсез,—дип сүзен дәвам итте.—Аларның ике йөздән күбрәге «Коммунизм»га совхозында гаиләләр корып, өчәр-дүртәр бала үстереп, мәңгегә төпләнеп калганнар. Ә сезнең үз-үзегезне тотышыгыз сәер. Нинди чибәр ханымны ташлап, Архангельскига чыгып киткәнсез. Франциядә сезне вербовайт иткән хуҗаларыгыз кушуы буенчамы? Анда профессионал рецидивист Владимир Шубин белән дә дуслашкансыз. Шулай ук сәер һәм серле. Нинди максат белән? Кара диңгез хәрби флоты матросы, мичман дәрәҗәсе алган Таһир Туктамышев өчен аның дәрәҗәсен, тормышта тоткан урынын нәкъ бер башка күтәрә торган, ачуым да бер килмәгәе, пар инде сезгә Владимир Шубин, ачуым да килмәгәе! Бигрәк тә безнең органнар өчен. Җитмәсә, Шубинны сез Бомбейда калдыргансыз. Махсус задание беләнме? Без, орган кешеләре, шулай уйлыйбыз. Ярга чыгып эзләп йөргән булып та кылангансыз бит әле. Боларына акланырдай нинди аргументларыгыз бар?

—Володя Шубинмы? Ул эчкерсез, әмма бераз хыялыйрак егетне мин бертуган энем кебек яраттым. Бомбейда мин аны тапсаммы? Тапсам, колагын борып, теплоходыбызга алып кайтырмын дип чыктым,—диде Таһир, сезгә соң сөйләдең ни дә, сөйләмәдең ни, дип кулын гына селекте.

—Минем папкада үзебезнең разведка органнары офицеры, ул чакта «Сергей Киров»та хезмәт иткән өченче ранг капитаны Штанько рапорты бар. Сез аны яхшы беләсез. Капитан Штанько сезне эзләп Казакъстанга, «Коммунизмга» совхозына килеп чыккан. Ул бит сезгә үзе үк әзерләгән бер дигән легенда буенча, шул ук Марсель портына безнең разведка резиденты булып барырга тәкъдим иткән. Ә сез баш тарткансыз. Бүген подполковник дәрәҗәсен йөрткән разведчик офицерга ишеккә ымлагансыз. Башка сыймаслык гамәл! Бу кирелегегезне, дуамаллыгыгызны коллегиябезнең махсус утырышында берничек тә аңлый алмадык. Кулыннан килгәндәме!? Кычкырып торган мөмкинлекләр булганда, илеңнең, Ватаныңның шундый дәрәҗәле заданиесен үтәүдән ничек баш тартырга мөмкин? Моның өчен кем булырга кирәк? Антипатриот, кара эчле дошманмы?

Таһир тикшерүчегә туп-туры карап:

—Өзелеп сөйгән ярың иленә, сөйгәнең каршына, ул яшәгән илнең кара дошманы булып бару—минемчә, чын егет башына аннан да түбән мәсхәрә нәрсә юк дөньяда! Аның өчен иң җирәнгеч хәшәрәт булырга кирәк!—диде. Пычрак эштән җирәнгәндәй йөзен җыерды.

—Ә без мәсьәләгә башкарак аспектта карадык. Чөнки бу периодка сез инде дошман разведкасы капкынына ычкына алмаслык булып кабарга өлгергәнсез. Алай да-а,—дип сузды майор Туктаров.—Миндә сезнең өчен шактый информация бар. Күңелегезгә авыр алмагыз, әниегез моннан өч ел элек мәрхүмә. Сеңлегезне Кемерово шахталарында күмер чабучы бер егетегез кайтып алып киткән. Хәзер ике кыз үстерәләр. Өегезнең тәрәзәләренә такта кадаклаганнар. Күрәсез, сезне югалттык, дип без тик ятмадык. Сезнең өчен, между прочим, шатлыклы хәбәрләрем дә бар,—дип дәвам итте КГБ тикшерүчесе.—Моннан ике ел элек, сезне эзләп, Франциядән хатыныгыз мадам Данәгөл Ногайбәк-Туктамышева килгән иде. Биш-алты яшьләр тирәсендәге улын ияртеп. Улыгызның исеме Жан. Әлбәттә, белә булырсыз. Белмәскә соң?

Боларны ишетеп, Таһир чак авып китмәде. Тыңлаган җиреннән торып

басты. Колакларына ышанмый торды.

Каян белсен? Марсель портында аерылышкан сәгатьтән бирле, ни алар турында ишетмәде, ни үзе турында хәбәр сала алмады. Туктаровның бу сүзләрен ишетүгә башы әйләнеп киткәндәй булды. Шунда кинәттән генә аның тәненә, бөтен әгъзаларына ниндидер көч, энергия керең тулгандай булды. Димәк, аның улы үсә! Жан исемле ди бит. Ә Данәгөл, жан яраткан, сөйгән кошы, аны эзләп «Коммунизмга» совхозына чаклы килгән. Шушы матур хәбәрләр өчен генә дә дөньяда яшәвеңнең максаты бар!

—Мадам Данәгөл Ногайбәк-Туктамышева чыннан да бик чибәр ханым. Бик үткен дә булса кирәк,—дип сүзен дәвам итте майор.—Биш көнгә килгән визасын, безгә билгесез каналлар аша бер айга озынайтып, «Коммунизмга» совхозына да барып чыкты. Ул килүгә, без аның койрыгына үзебезнең яшь кенә оперативнигыбызны утырткан идек. Ул аны сизеп алып, позор белән куган. Нишлисең, безнең эштә дә проваллар була,—дип көрсенеп куйды Туктаров.—Совхозда сезнең андагы хатыныгыз Оксана белән күрешеп, озак кына сөйләшкәннән соң:

«Минем Таһирым Марсельдә! Анда ул! Минем янга дип киткән!»—ди дә, визасын өзеп, беренче самолет белән Парижга оча. Кыскасы-ы,—дип сузды майор Туктаров.—Бик борынгы философларның берсе Аристотель: «Амикус Плато, сэд мачис амика эст вэритас»—«Платон минем дустым, әмма миңа хакыйкать кадерлерәк»,—дип әйтергә яраткан. Син дә, гражданин Туктамышев, болай карап торырга чибәр генә егет. Житмәсә, без кардәшләр, икебез дә татарлар. Ләкин мин сезне бик житди ике статья белән җавапка тартам. Беренчесе—законсыз рәвештә чикне бозу. Монысы бәхәссез расланган факт. СССР чикләрен законсыз бозуыгызны үзегез дә инкарь итмисездер. Бу жинаять өчен биш елдан—сигез елга төрмә каралган. Икенчесе, ягъни РСФСР Жинаятьләр Кодексының «64а» маддәсе—чит ил разведкасы белән бәйләнеп, алар файдасына шпионажны күздә тота. Монысына хөкем егерме елдан алып, үлем җәзасына, расстрелга чаклы. Дөрес, бу жинаятегезне без әлегә бернинди документлар белән дә раслый алмадык. Чөнки сез—бик тирән конспирацияләнгән агент. «Өч елга якын мафия кулында әсирлектә булдым»,—дип сөйләгән легендагыз балаларны гына ышандыра. Аклану өчен суд кабул итәрдәй дәлил түгел бу!

***

Законсыз рәвештә СССР чикләрен бозган һәм чит ил разведкасы белән бәйләнештә торган Таһир Туктамышев эшен караган Ябык Суд Утырышы нәкъ өлкән тикшерүче Зөфәр Туктаров әйткәнчә барды. Дәүләт тарафыннан гаепләүче, Юстиция Министрлыгының беренче класслы киңәшчесе подполковник Суворов гаепләнүче Туктамышевка беренче жинаяте өчен биш ел сорады. Суд дүрт ел раслады. Шпионаж өчен егерме ел сораган иде. Шпионлык өчен бернинди дәлилләр китермәгәч, суд сигез ел гына калдырды. Әлеге статьялар белән гаепләнүчене кырыс режимдагы төрмәгә унике елга ябарга хөкем иттеләр.

Шунысы гажәп, суд барышында Таһир үзен искитмәле тыныч тотты. Аңа хәзер дингез тубыктан. Аның Данәгөле исән. Улы Жан үсә. «Будет день, будет и пища!»—дияргә ярата иде аның «Академик Белов» та бергә йөзгән старпомы Рюкзак. Әйе, нәкъ шулай, «Будет день, будет и пища!».

Суд залыннан алып чыкканда, Таһир ишек катында майор Туктаровны күрде. «Очень жаль, очень жаль!»—дигән сыман инбашларын жыерды. Аннары үзен аклагандай: «Дура лэкс, сэд лэкс!», «закон суров,—но это закон!»—диде.

—Кырыс булуы хак...—диде Таһир. Унике елга каты режимлы төрмәгә хөкем иткәнгә рәхмәт әйтеп тормас ич инде.

## 12

«Хәсрәт—хәсрәткә ошамый, баш хәсрәттән бушамый»,—дигән әлеге мәкаль, йомры акыл, шаян тел белән матур гына олыгаеп барган Шөһрәт агайның ара-тирә булса да әйтеп куя торган, хәтта яраткан әйтеме. Хәер, төбендә шундый тирән фикер, саф алтын гыйбрәтләр яткан әйтемнәрне, мәкальләрне, борынгы җырлар, бәетләрне ул хәттин күп белә. Табигать аны ошбу җиһанга тумыштан ук үткен зиһенле, бәс кунмас, тутыкмас хәтерле, төрчә җан итеп яраткан. Күп телләр белүе дә шуннан. «Баш хәсрәттән бушамый»,—дигәндә ул, көндәлек тормыш үзе тудырып торган бетмәс-текәнмәс мәшәкатьләрне, вак-төяк борчуларны күз алдында тота. Бер карасаң, искитмәле бит! Туган иленнән, туган теленнән бик яшьли аерылса да, Тәнре аңа һәрчак мәрхәмәтле булды. Кайларда, кемнәр арасында яшәсә дә, татар өммәтеннән булуын тутыктырмый саклады. Арасын, җаен табып, букинистлар салонында казыну—аның күптәннән ин яраткан шөгыле. Франция калаларында алар искитмәле бай. Бер керсән, тиз генә чыгышлы түгел. Йомышы төшеп, чит калаларда булганда да, ул беренче эше итеп, букинистлар кибетен эзләп таба. Алардан, башы күккә тиярлек шатлык-сөенечләр кичереп, аңа яхшы таныш гарәп һәм латин имляларында татарча дини һәм дөньяви китаплар табып куя.

1917 нче елгы революциядән качып, ул елларда Германиягә, Франциягә, Төркиягә, Кытайга, Япониягә китеп, Казанның үзеннән, Сембердән, Әстерхан, Нижгар калаларыннан, хәтта Мәскәү, Петербургтан бик күп татар гаиләләре ризык тапкан. Алар, әлбәттә, аякларына юкә чабата кигән татарлар булмаганнар. Чабата өстерәп әллә кая бара алмассын. Анысы рас, дип уйлап куя Ногайбәк ага. Эмиграциягә киткән татар аягына читек-кәвеш кигән, ә вакытны, күкрәк кесәләреннән алтын-көмеш чылбырлары асылынып торган Швейцария сәгатьләренә карап билгеләүче затлардан булган. Телләрне дә яхшы белгәннәрдер. Чит-ят җирләргә аяк баскач та югалып калмаганнар. Табышлы, файда китерешле үз эшләрен башлап җибәргәннәр. Германиягә килеп тупланган «Бертуган Гәрәйләр» фасонлы матур, фетр эшләпәләр белән Германияне генә түгел, ә бөтен Европаны тәэмин итеп торганнар.

Туган-үскән илләреннән мәңгегә, кем белә, бәлкем вакытлыча гына аерылган бу төр татарлар югалып калмаганнар. «Оча торган кошкайның да канаты каерылган. Бер без генә түгел бит ул иленнән аерылган»,—дип җырлый-җырлый, күнел төшенкелегенә бирелми, ныклы тормыш корып яшәп киткәннәр.

Моның нәкъ шулай булуына Ногайбәк ага күп тапкырлар үз күзе белән күреп ышанды. Кай тарафларга таба кузгалсалар да, әлеге гаиләләр, чиста тастымалга төреп, Коръән-Кәримне һәм татар китапларын алганнар. Китап-Галиҗәнап алдында безнең татар бик борынгы заманнардан ук тез чүгеп, баш игән. «Бар гыйлем китапта»—дигән төшенчәне татар үзенең баласына әвәл-әвәлтеннән бишектә, күкрәк сөте имеп яткан чагында ук сеңдерә килгән. Ногайбәк ага үзе дә, «китап сүзе», «китап әйтә», «китап сүзе хак булыр», «башыңдагы сорауларга акыллы җавапларны китаптан эзлә!»—дигән сүзләрне Финляндиядә малай чакларында күп ишетте. Ишетеп кенә калмады. Китап белән һәрчак янәшә булу, аны куеныңда йөртү аның яшәү рәвешенә әверелде.

Яшеллеккә, кәстәнә, йөзем куакларына күмелгән бик матур һәм төзек Буживаль каласы Парижга терәлеп кенә тора. Ул чорларда әле Петербургта Эчке эшләр Министрлыгында дәрәҗәле чиновник булып торган танылган язучы Иван Сергеевич Тургенев дәүләт йомышлары белән Франциягә еш килеп йөргән. Шулай бер килүендә Франциянен

танылган җырчысы меццо-сопрано П.Виардо белән таныша. Аңа гашыйк була. Ике арадагы мөнәсәбәтләр озак еллар буена хат язышу белән генә тәгәлләнми. И.С.Тургенев ахырда Франциягә бөтенләйгә күченеп килә. Буживаль каласында зур утар сатып ала. Соңыннан, 1883 елда, шушында мәрхүм дә була. Русның бөек язучысы торган йортны соңыннан музей итәләр. Аны карарга Ногайбәк ага кызы Данәгөл белән килгән иде. Ул чакны йөзенә философ Сократ уйчанлыгы чыгарып: «Кызым, мәхәббәт дигән нәрсә өермә, цунами, әнә нинди көч-кодрәткә ия! Нинди кешене, яшәгән җиреннән тамырлары белән каерып алып, кая китереп куйган бит!»—диде. Бу минутта ул, әлбәттә, кызы Данәгөлнең татар егете Таһирга сүнмәс, шиңмәс, тутыкмас мәхәббәтен күз алдында тотты. Әтисе аны аңлаганга мең-мең рәхмәтен белдереп, Данәгөл аңарак сыенды, үрелеп, сүзсез генә әп итеп алды. Заманында, хуҗасы исән чакта, язучы, артист, композитор, рәссам халкы өзелмәгән утар бүген бераз ташландык хәлдә. Аны чүкеч сугып сатмакчы да булганнар, алучы табылмаган. Язучының үзеннән калган архивы исемлегендә Ногайбәк ага «Сак-Сок» бәете барлыгын да күреп исе китте. Тургеневның ерак бабалары татар булуын укып белә иде ул. Бу турыда аның музейда эленгән биографиясендә дә язылган. Андый чакта Ногайбәк ага югалып калмый инде. Үзенең кем булуы турындагы таныклыгын күрсәтеп, сораучы, кызыксынучы булса, кайтарып бирергә сүз биреп, музейны карап торучы ханымнан «Сак-Сок» китабын шактый кыйбат бәягә сатып та алды.

Ногайбәк ага, калтыранган куллары белән, җылысын сизгәндәй, сыпырып торды.

—Оныгым Галимҗанга бүләк!—диде.—Бөтен Китапханәм аңа булачак!—дип өстәде аның бу гамәлен чак кына елмаеп, әмма хуплап торган кызына.

Күп телләрдәге китаплардан, гомер буена дисәң дә ялгыш булмас, Ногайбәк ага бик бай китапханә туплады.

Данәгөл «түтәлдәге кәбестәләр арасыннан» улы Жанны алып кайткач, ата белән кызының аралары сөйләп бирә алмастай тагын да якынайды. Оныгы тугач, Шөһрәт агай үзен бу дөньяда бер хәсрәте дә калмагандай хис итте. Маңгай тире белән җыйган мал-мөлкәтен васыять итәргә варисы бар. Үзе ун елларга яшәреп киткәндәй булды. Галстугын гына түгел, костюмын да көн аралаш алыштыра. Иртән эшкә киткәндә, аяк очларына гына басып, оныгы йоклаган бүлмәгә керә. Аны аркасыннан сөеп, дога да укып чыга. Эштә дә бер минут та артык тоткарланмаска тырыша. Хатыны Фәйрүзә апа да:

—Һәй-й-й, кызым! Әтиебезгә йомры бәхетле булу өчен шушы малай, йомры башыбыз гына җитмәгән икән!—дип бот чабып туймый.

Ногайбәк ага үзе дә сизә, әйе, ул бөтенләй башка Ногайбәк. Холкы үзгәрде, каз мамыгыдай йомшакланды. Ә уенчыкларны ташый гына. Алар белән бөтен ишегаллары тулып килә.

—Минем өчен бик татлы оныгым Галимҗан, зур үскәч, кем булырга теләсә, шул булсын. Әмма нәкъ үзем төсле эш сөюче, нигә алынса, шуны очлап чыгарлык, кулыннан эш килешле уңган-булган егет булып үссен!—дип шушы сүзләрен мең-мең тапкырлар кабатлый-кабатлый, аны үзе белән күп төрле һөнәрләргә өйрәтергә тырышты.

Марсель порты администрациясе махсус килешүләр нигезендә даими сәүдә, алыш-биреш алып барган эре фирмалар, йә концерннар белән дебитлар-кредитка бик үк туры килеп бетмичә, аңлашылмаучылыклар килеп чыкканда, Ногайбәк аганы чит шәһәрләргә, хәтта чит илләргә командировкаларга да җибәрә. Күп телләр белгәнлектән, ул мондый

мәсьәләләрне бик җинел, унай хәл итеп кайта.

Бер елны аны балачагы, егетлек чоры кичергән Суоми иленә, ягъни Финляндиягә җибәрделәр. Андагы кан-кардәшләр арасында да урам себерүчеләр юк. Барысы да укымышлылар, зыялылар. Ана теленнән башка тагын дүрт-биш тел беләләр. Бай-мул тормышта яшиләр. Телләрен дә, милли гореф-гадәтләрен дә бик кадерләп саклыйлар. Ногайбәк ага аннан күтәрә алганча татар җырлары язылган тәлинкәләр, китаплар алып кайтты. Бирәм дисәме колына?..

Берсендәме?! Кым-кырыс эш арасында ана, әле яна гына суга төшерелгән караб—контейнерлар ташучы япон теплоходы капитаны мөрәҗәгать итте. Күп булса, утыз биш-кырык тирәләрендәге, җыйнак, какча гәүдәле, бик чибәр егет. Йөзенә йомшак елмаю кунган. Өстендә кыска җинле ак күлмәк. Башында фуражкасы. Кулында сәгать.

—Сай-фут-дин!—дип, башта ике кулын күкрәк өстенә куеп торып, аннары гына сузды ул кулын Ногайбәк агага. Нәкъ япончa чыкты инде. Кошлар да шулай бит: әйтик, кыр казлары, торналар, челәннәр, үрдәкләр, хәтта сыерчыклар да җылы якларга киткәндә аларнын көтүләре Марсель өстеннән дә узалар. Кошкайларнын монсу гына «кыйгак-кыйгак»—дип саубуллашуларын Ногайбәк ага күзендәге яшьләрен сөртә-сөртә озата. Язын кайтуларын күрү үзенә бер шатлык. Әллә кайдагы Африка, Австралия җирләрендә кышлаган төбәкләреннән, туган-үскән илләренә, балалар чыгарган ватаннарына, меңнәрчә чакрым араларны узып, бернинди ориентирсыз-нисез кайталар бит бичаракайлар. Җанашларым, димәссенме?! Юлда күп газаплар, югалтулар кичереп...

Галимнәр: кошлар алар юлда йолдызларны ориентирлары итеп кайталар, диләр. Галим булгач, нидер әйтергә кирәктер инде. Ярый да һәр кичне йолдызлар калкып торса. Күк йөзен болытлар баскан кичләр дә күп була бит...

Әлеге чибәр егет, япон карабы капитаны, йөзендә елмаю саклап:

—Сай-Фут-Дин!—дип кабатлады. Аннары саф татар телендә:

—Ногай-бәк ага! Сезне күрүемә бик шатмын,—диде. Япон теплоходы капитаны саф татар егете булып чыкты.

—Атакаебыз Арифулланың, анакаебыз Зөһрәнең алты улы булып үстек,—дип сөйләп китте ул.—Атакайларыбыз-анакайларыбыз вафат. Ә без, аларнын балакайлары—барыбыз да исән. Агаларыбызның дүртесе—сәүдәгәрләр. Токионың үзендә зур кибетләр тоталар. Кече туганыбыз Айнетдин—теш докторы. Үзенең клиникасы бар.

Татар да, берсен-берсе, әллә нинди шартларга эләксә дә, әлеге очар кошлар төсле, беркемгә билгесез ориентирлар, сыйфатлар буенча бик тиз эзләп таба.

—Мин узган килүемдә үк сезгә сүз катарга теләдем. Ләкин базмадым,—дип, ап-ак тешләре, юка иреннәре аша сүзләрен сайлап кына чыгарып, әмма кан-кардәш якынлыгын раслап сөйли күрер күзгә дә бик мөлаем егет Сәйфетдин. Агайны үз теплоходы бортына менәргә, япон чәе эчәргә кунакка дәште. Ногайбәк ага, әлбәттә, бик теләп риза булды. Өстәлдәге татлы ризыклар белән сыйланып, шапырма тиргә төшеп чәй эчкәннән соң, Сәйфетдин Куба портында «Муса Җәлил» исемле совет теплоходының икенче штурманы Рафаэль атлы шаян холыклы бер татар егете белән танышуын да сөйләп алды. Аннары каютасындагы электрон бикле сейфны ачты, бик кадерләп кенә, ак тастымалга ураган бер төргәк чыгарды. Аны кунагына сузды. Ногайбәк ага тастымалны үзенә бер тирән дулкынлану хисе белән сүтеп, анын эчендәге әйберне күргәч, чүт кенә һушын җуймады. Тастымал эчендәме!? Япониянең башкаласы Токионың үзендә, әле 1908 нче елда ук нәшер ителгән Габдулла Тукаебызның «Халкыбызның тел

гәүһәрләре»[1] дип исемләнгән калын гына китабын күрде. 1908 нче елда ук нәшер ителгән бит!

—Бу чакта сөйгән шагыйребез әле исән. Ул бит 1913 нче елда мәрхүм була,—диде Ногайбәк ага кулындагы чын реликвия китапның битләрен саклык белән генә ача-ача.

—1908 нче елда аңа әле нибары егерме ике генә яшь.

—Иҗатының чәчрәп чәчәк аткан еллары булса кирәк!—дип куәтләде аның сүзләрен Сәйфетдин.

Ногайбәк ага япон татары Сәйфетдин бүләк иткән китапның беренче битен ачты. Анда аңа балачагыннан ук таныш—«Туган тел».

—Безнең Казаныбыздан егерме мең чакрымнар ерактагы японнар башкаласына Тукаебызның бу әсәрләре ничек барып чыкты икән?—дип гаҗәпкә калды.—Мөгаен, ул чакларда ук ике арада сәүдә бәйләнешләре нык булгандыр.

— Кызыктырырлык товарың булганда, сәүдә өчен чикләр юк,—дип җөпләде аны Сәйфетдин.—Ногайбәк ага, мин сезне үз каютама менә шушы бүләгемне бирү өчен чакырдым. Узган килүемдә үк сезнең укымышлы адәм булуыгызны күреп киттем. Бик теләп бүләк итәм. Без, Токиода яшәгән япон татарлары, балаларыбызны мәчетләребезгә йөртеп, телебезне үрәтәбез. Алар Тукайны да яхшы беләләр. Күңелдән ятлыйлар.

—Куш йодрык хәтле алтын кисәге бирсәң, белмим, алган булыр идемме әле, улым?—диде, үзе дә сизмәстән «улым» дип куйды Ногайбәк ага.—Ә бу зур бүләгеңне үзенә мең-мең рәхмәтләр укып алам. Җилкәннәреңә һәрчак шәфкатьле җилләр генә өреп торсын. Амин!

—Амин! Амин!—дип җөпләде аны капитан Сәйфетдин.

***

«Хәсрәт хәсрәткә ошамый»ны Данәгөл дә әйткәли шул. Кирәк бит, диген. Үткән атнаны гына Жан велосипедтан егылып сул янбашын тайдырды. Сөякне урынына наркоз астында утырттылар. Олы яшьләрдәге, тәҗрибәле хирург калын итеп гипс салды. Бу көннәрдә тиктормас Галимҗанның әнисе дә, әби-бабасы да ут йоттылар.

—Улым, балакаем, менә шушы көннәрдә кинәттән генә әтиебез килеп чыкса!? Ник минем улымны карамагансыз, ни кисәткәнием, дияр. Ә мин ни диеп җавап бирермен?—дип сөйде улын әнисе бу көннәрдә.—Кичә дә, иртәнге якта, монарчы синең белән барып йөргән Көтү, Сагыну, Өмет Кыясына басып, гаваньга кергән карабларны карап тордым. Корпуслары ап-ак итеп буялган океан лайнерлары да, теплоходлар да, җилкәнле караблар да Марсель портына күп керделәр. Менә шуларның берсендә әтиебез барыбер килеп чыгачак. Барыбер!

Данәгөл ханымга бәлкем өзелеп сагыну хисе шундый иҗат дәрте бирәдер? Шушы арада гына ул тагын бер картинасын тәмамлады. Дөрес, үзе дә сизде, бу әсәрен ул елдан артыкка сузып, моңа чаклы мыскал да татымаган иҗади газаплар кичереп, әмма дә әлеге газаплардан үзенә бер татлы канәгатьләнү, күңел күтәренкелеге хисләре татып иҗат итте. Чын иҗат, талант иясе

[1] Әлеге китапның бер данәсен бу юлларның авторы үзе дә күрде. Ул Дәүләт Куркынычсызлыгы Комитетының Татарстан бүлеге китапханәсендә саклана иде. Аны шушы юлларның авторы күз алдында, Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлангач, Токиога барып урнашып, анда, япон контрразведкасының борын төбендә совет разведкасы резиденты булып унөч ел яшәгән Шамил аганың тормыш иптәше Ирина апа тапшырды. Мәрхүмнең үләр алдыннан әйткән васыятен үтәп. Чөнки Шамил ага – чыгышы белән Буа мишәре. Ирина апа әлеге китапны Шамил аганың чекистлык таныклыгы һәм табельле пистолеты белән бергә тапшырды. Кызыксынучыларга 2002 елда Татарстан китап нәшриятында басылган «Кан үче» исемле китабымда легендар совет разведчигы Шамил ага Хәмзинның Токиода эшчәнлеге турында язылган «Кабаланмый чара юк» дигән повестемны укырга тәкъдим итәм.

кешеләрендә була торган хәләттер инде ул. Карл Брюллов, рәссамнар башкаласы Римгә укырга, профессионал осталыгын үстерергә килә. Байтак вакытлар, тегендә сугылып, монда буталып, үзен-үзе таба алмый йөри. Рим аны кабул итми сыман тоела ана. Аннары үзен Олимп тавынын иң биек баскычларына күтәргән «Помпейнын сонгы көнен» нибары унбер ай эчендә язып куя. Айлар буена беркая чыкмыйча баш күтәрми эшләп. Әлбәттә, әсәрне язарга керешкәнче, кулына мольберт, пумалалар алганчы, ике еллар чамасы бик көчле әзерлек алып бара, материал туплый...

Огюст Ренуа премиясенә лаек рәссамга, башкача булуы да мөмкин түгел дипме, Данәгөл үзенә планканы тагын да югарырак куйдымы? «Шомлы бәхет»не ул, еш кына бер урында таптаныбрак, мольбертындагы буяуларның кайсын кая салырга урын тапмыйча, хәтта бераз каушау хисе дә кичереп язды. Күрер күзгә, чиертсәң, уалып, кочакка салсаң, эреп китәрдәй җыйнак гәүдәле мадам Данәгөл Ногайбәк-Туктамышева көчле рухлы затлардан иде. Аны аяк чалып кына аударырмын, егармын, димә. Үзе сайлаган юлдан да—шулай ук! Әлеге картинасын язганда туган каршылыкларны да, болар барысы да вак хәсрәт, вакыты житкәч, бар буяулар да полотнода үз урыннарын табарлар, дип кенә карады. Хәер, ул шунысын да яхшы белә, олы сәнгатьтә бер генә әсәр дә, булсын Виктор Гюгонын «Парижнын Богоматерь соборы» романы, вальслар гение Иоһан Штрауснын «Вена урманы әкиятләре», Карл Брюлловнын «Помпейнын сонгы көне» картинасы, Илья Репиннын «Иделдә бурлаклар»ы да, авторлары тарафыннан тик үзләре генә татыган иҗат газаплары кичерми кат-кат яна вариантлар эзләп, искеләрен ертып ташламый гына язылмый. Һичшиксез шулай!

Әйе, Данәгөл ханым әлеге әсәрен «Шомлы бәхет» дип атады, һич икеләнүсез. Бәхетнең кайсы да, олысы да, хәтта кечкенәсе дә, аны татучы күнелендә борчу, шом тудыра. Бәхеткә юлыккан һәр зат, «бу татлы алманы», язмыш хәзрәтләренең миңа усал ният белән бирүе түгелме, монын ахыры начар булмасмы, дип куркып, шикләнеп, шом белән кабул итә.

Автор һаман да импрессионизм, иҗатына баш игән остазы Ренуар таләпләренә тугры калып, полотносында кечерәк кенә урман яланы бирде. Кулына пумаласын алса, Данәгөлнең исенә остазы әйткән сүзләр төшә. Огюст Ренуар тәмам олы яшьләргә житкәнче яшәгән. Житмеш яшьләрендә аның бармакларын раматиз сара. Аларны берсе өстенә берсе атланган тавык тәпиләре хәленә китерә. Ренуар хәтта шул хәлдә дә кулына һәр көн мольберт ала. Сул кулы белән уң кулына ярдәм итә.

—Э-э...юк, юк! Бер генә көнем дә эшсез узмаска тиеш!—ди ул үзенә-үзе.

Зур, танылган мастерның хәлен белергә аның мастерскоена кергән берәү:

—Кадерле маэстро, нигә соң шул кадәр үҗәтләнәсез? Сезне бөтен дөнья таный. Картиналарны да аз язмагансыз. Алар иң танылган музейларның байлыгы, горурлыгы,—ди.

Чираттагы картинасын ясау белән мәшгуль маэстро:

—Кадерлем, минем өчен шушыннан да зур ләззәт юк бит!—дип җавап бирә. Бераздан:

—Аннары... Мин үземнең шушы хәләтемне зур бурычымны үтәүгә охшатам,—дип өсти.

Сиксән яшьләрен тутырып килгән маэстро әлеге сорауларны бирүчегә елмаеп текәлә.

—Кеше дигәнеңнең татырдай, кичерердәй ләззәте, кичекмичә түләргә тиешле бурычы да калмаса, ул чакта ни дип кенә яшәргә?—ди.

Рамга тарттырылган киндер тукыма битенә төшерелгән һәр тамчы буяу маэстро күнелендә канәгать калу, ләззәт хисе кичерү тудыра бит. Монысы

инде маэстро Ногайбәк-Туктамышеваның үз-үзенә таләбе. Ул ясаган урман яланы читендә—сихри тын күл. Алан читендә, куаклар арасында, һәр чыбыгын томшыгына ташып, хуҗасы тарафыннан бик хасиятләп ясалган оя. Оя читендә—хуҗалары дөньяга чыкканлыктан бушап калган йомырка кабыклары. Тамашачы аларны күрү белән санаячак. Алар сигезәү. Димәк, алардан сигез бәбкә чыккан.

Алгы планда—Ана үрдәк үзе. Аның шатлыгы, сөенече тышына чыккан. Ничек сөенмәсен! Көнен дә, төннәрен дә күз керфегенне какмый сигез бәбкә басып чыгар да, сөенмә, шатланма, имеш. Бу бәхет күпләргә татымый. Ул ике канатын як-якка җәйгән. Ана үрдәк, хәер-фатихасын биреп, балалары-бәбкәләре аларның моннан соң даими, судан чыкмый яшәү, көн итү урыннары булачак мохиткә алып килгән. Бу минутларда Ана үрдәк кичергән хисләрне аңлавы кыен түгел. Ана балаларына иминлек, бәхет тели. Ә балалар—кемдә дә балалар. Аларга шаянлык хас. Әнә бәбкәләрнең суга кергәннәре, әниләренең киңәшләрен тыңлап та бетерми, уйнап-шаярып алмакчылар. Су бик рәхәт урын икән ул. Теләсәң, йөз, теләсәң, чумып кит. Ә икесе, Ана үрдәкнең төпчекләре, йомыркадан соңрак борнаганнары булса кирәк, монарчы аяк басмаган, бераз серлерәк тоелган су стихиясенә кереп китәргә базмыйчарак, бераз чытаеп торалар төсле.

Бер күз салу белән «Шомлы бәхет» күңелдә нечкә хисләр уята. Нәкъ импрессионистларча. Автор үзе сайлаган кыйблага тугры калган. Әмма бу мизгелләрдә эче тулы шатлык кичергән Ана үрдәк бәхетенең шомлы булмавы мөмкин түгел. Әнә аулак, тын урман яланы өстеннән ак эзләр калдырып, колак тондырган авазлар чыгарып, самолетлар, һава лайнерлары очып торалар. Аланның аргы башына бер сунарчы инде килеп тә җиткән түгелме соң? Әйберләрен бушата. Агачка ау мылтыгын чыгарып сөягән. Хуҗасының машина бушатып бетергәнен көтеп, үрдәк ауларга өйрәтелгән спаниель ятып тора...

Бер карасаң, хөрмәтле авторның бу картинасында алай искитәрлек берни дә юк. Әмма тимер-бетон-пыяладан бастырган шыксыз йортларда яшәп, бар төшенә асфальт түшәгән урамнарны, мәйданнарны таптарга күнеккән тамашачылар күңелендә шундук җылы хисләр уята. Су читенә баскан Ана үрдәкнең шомлы бәхетен тамашачы үзенеке дәрәҗәсендә кабул итә.

Мадам Данәгөл Ногайбәк-Туктамышева бу әсәрен Марсель рәссамнарының һәр елны була торган күргәзмәсенә куйды. Әлбәттә, мине дөрес аңларлармы, дигән шикләнү хисе белән. Ул хисне аны бар иҗат кешесе кичерә. Шунсыз иҗат юк. Шунсыз бер урында таптану, яңадан велосипед уйлап табу гына башлана...

Шушы, беренче карашка гап-гади сюжетка корылган картина алдына баскан һәр кеше, Ана үрдәк күңелен биләгән шөбхәле проблемалардан ераккарак атлап, үзенә шундый сорау куярга мәҗбүр. Үзебез дә шушы табигатьнең, шушы мохитнең балалары. Ә безне алда нәрсә көтә? Елдан-ел шәһәрләр үсә, киңәя, яңа мәйданнарны билиләр. Кичә генә ал, кызыл, зәңгәр чәчәкләр үсеп утырган, берсеннән-берсе матур күбәләкләр очкан, бал кортлары бал җыйган болыннарда очы-кырые чиксез аэродромнар калка. «Моңарчы кеше аяк басмаган» дип тәртелгән тау сыртларын, төпсез сазлыкларны, кара урманнарны ерып юллар уза. Туган як кырларыбызны, урман-суларыбызны бизәгән кош-кортларыбызга, кыргый җанварларыбызга гына түгел, үзебезгә яшәргә, иркенләп бер сулыш алырга тын почмак каламы соң?

Марсель—илле миллионнан өстә халкы булган Франция дәүләтенең Париждан кала иң зур шәһәрләре. Анда дистәләрчә чиркәүләр, костеллар, мәчетләр, синагогалар бар. Урманнарны, скверларны истәлек һәйкәлләре бизи, чат саен музейлар, антиквар салоннары. Бик югары дәрәҗәле уку йортлары күп. Марсель—Урта диңгез бассейнында иң зур сәүдә порты

булганлыктан, алыш-биреш, ике як өчен дә отышлы сәүдә проблемаларын хәл итү белән мәшгуль дистәләрчә илләрнең консуллыклары белән тулы. Марсель портына көн аралаш кереп торган сәүдә корабларыннан тыш, бирегә—тулы мәгънәсендә зур культура үзәгенә, планетаның барча почмакларыннан сәяхәтчеләрне, дөнья гизүчеләрне, туристларны төягән океан лайнерлары да килеп торалар.

Марсель публикасы—бик нечкә зәвыклы публика. Зур сәнгатьтә шулай бит ул. Бәлкем син шедевр тудыргансыңдыр? Әмма ул тамашачының кабул итүе белән бәйле. Анысы инде публиканың зәвык дәрәҗәсеннән тора. Көндәлек тормышта сәер хәлләр дә очрап куя. Соныннан вальслар короле дәрәҗәсе алган, бар музыкасы тормышны сөю, кешеләрне шатландыру ноталары белән тулы Иоһан Штраусның бүген исә иң-иң тантаналы кичәләрне бизәгән искиткеч әсәрләрен, Вена публикасы беренче чорларда танымаган, бөтенләй кабул итмәгән. Аның үлемсез «Вена урманы әкиятләрен», «Зәңгәр Дунай» вальсларын балаганнар, исереклəр тулы төнге таверналар, кабаклар өчен генә яраклы пүчтәк нәрсәләр, дип кенә санаганнар.

Марсель публикасы да шулай: операмы, симфонияме, яңа романмы, яисә танылган рәссамның яңа картинасымы, кабул итсә—итә, итмәсә—барыны да белми.

Данәгөл дә «Шомлы бәхет»не күргәзмәгә кыяр-кыймас, хәтта бераз шикләнү хисе белән тапшырган иде. Берәр атнадан күргәзмәгә керсә, фикер теркәү өчен куелган кызыл бәрхет тышлы альбом битләре «Шомлы бәхет» кә карата әйтелгән иң җылы хисләр белән тулы мин синайтим! Жюри әгъзалары да газеталарда аны күтәреп мактап язып чыктылар.

Шундый шатлыклы мизгелләр кичереп яшәп ятканда, Ногайбәк агаларга Париждан шалтыраттылар. Совет илчелегеннән. Телефонга мадам Данәгөлнең килүен сорадылар.

—Мадам Данәгөл, Сезме? Онытмаган булсагыз, Игорь Наумович бу. Ни хәлләрдә яшәп ятасыз?—диде тегесе һәр сүзгә житди кешеләрчә генә хас басым ясап.

—Тавышыгызны ишетүемә бик шат, хөрмәтле Игорь Наумович!

—Башкалабыз Мәскәүдәге Третьяков галереясенең йөз еллыгы якынлаша... Сезне шунда чакырабыз!

## 13

...Мордовиянең Зубово-Поляна районындагы шәһәр тибындагы Потьма поселогында Таһир Туктамышев «Политик тоткыннар төрмәсе»ндә инде бишенче елын утыра. Таһирны бирегә, бер вагонда, Габбас Чанышев исемле татар егете белән бергә китерделәр. Габбас—кырык-кырык бишләр тирәсендәге, озын буйлы, какча гәүдәле, сөйкемле йөзле ир уртасы. Тормыш сукмакларында очрашкан кешеләренә Таһир бер карау белән тиешле бәясен бирергә өйрәнде. Габбас кайчакларны татарча матур итеп җырлап җибәргәли. Коммунист булган. Лубьян урман техникумын тәмамлаган. Чаллы районында өлкән механик булып эшләгән. Күр күнелле, тормыштан гел яхшылыкны гына көтеп яшәве белән дә Габбас искитмәле матур кеше.

—Габбас, дөресен генә әйт әле, син атаклы совет генералы Якуб ага Чанышевлар нәсел-нәсәбеннән түгелме сон? Үзең минә «Особо опасный государственный преступниклар» йөртүче поездның пассажиры идең...—дип ике-өч сорады аннан Таһир.

—Каян киле-е-еп...—дип суза Габбас җавабын.

«Дәүләтне аеручы зур күләмнәрдә урлашып, төп башына утырткан өчен» дигән статья белән аңа «назлап-кадерләп» кенә, армый-талмый урман

кисәргә «путевка»ны ундүрт елга биргәннәр.

—Әле дә шуңа сөенәм, ундүрт ел гына бирделәр. Прокурор, комсыз баш, мине «экономик диверсия» маддәсе белән гаепләмәкче иде. Булдыра гына алмады. Ул маддә белән япсалар—егерме биш ел!—дип сөенеп сөйли Габбас.

Түбән Кама су саклагычы төзелә башлагач, су басасы җирләрдәге урманны кисү эшләрен производство алдынгысы, КПСС әгъзасы, коммунистик хезмәт ударнигы Габбас Чанышевка йөкләделәр. Очлары белән күккә төбәлеп утырган калын урманны су төбендә калдырып булмый бит инде. Кисәргә кирәк.

—Һәркайсыннан җилкәнле кораблар өчен бер дигән мачталар ясарлык чат чәерле, шәм кебек төз наратларны кистереп, малай, штабельләргә салдырам. Үзебез әлегә хатынның әниләрендә, иске генә бер йортта яшәп ятланабез. И-их, шушы «шәмнәр»дән тугыз метрга тугыз метрлы итеп, үземә дә бер бура буратасы иде!—дип әйткән чакларым күп булды. Толстойның Ясная Полянадагы йортыннан ким чыкмас иде ул. Намус саклыйм, сорамыйм. Сорасам да, бирмәсләр, дим. Ә Казаннан, тугыз-унбер метр озынлыктагы прицеплар тагып килгән «МАЗ»лар бу «мачталар»ны каядыр ташып кына торалар. Миңа өстән, үзебезнең Урман хуҗалыгы Министрлыгыннан, шулай куштылар. Синең эш—аларны тоткарламый озатып тору, диделәр. Карыйм, накладнойлары да болай дөрес төсле. Штамп-печатьләре дә сугылган. Житмәсә, ашыктыралар. Су баса башлаганчы, булачак «диңгез» урыны чип-чиста булырга тиеш, диделәр.

Чынында исә алар ялган бер оешмадан булганнар. Накладнойлары да фиктив икән. Кыңгыр эш кырык елдан да беленә, диме? Көннәрнең берендә боларның эзләренә төшкәннәр. Эләктергәннәр. Накладнойларда—минем кул. Үз башыңа килмәсә, белмисең икән. Безнең суд системасында—бардак! Тикшерүләрнең дә очы-очка ялганмый. Барыбызны да бер тарак белән тарап, мине дә утыртып куйдылар,—дип өстәде Габбас.—Прокурорның да миңа бигрәк комсызы, тук мәче төсле ваемсыз чырайлысы эләкте. Суд эскәмиясенә утыртучыларга «елларны» сибә генә. Үземә каламы соң дип тә уйламый. Сәдака өләшәм дип уйлыймы? Тыңкыш борын, муенын кыскан яңа күлмәк якасын симез бармаклары белән бушайта-бушайта, миңа егерме биш ел сорап маташты бит, бурсык. Ә өйдә—өч балам. Дүртенчесе—әнисе карынында. Үзебез кыз көткәниек тә, тагын малай алып кайткан. Ярар, бәхете белән туган бала булсын! Хат белән фотосын салганнар. Әнисе итәгендә түтәлдән генә казып алган шалкан кебек тәгәрәп ята. Таһир, син ничек уйлыйсың? Нужәли мине монда ундүрт ел тотарлар икән? Нужәли берәр ниндиерәк амнистия-мазар булмас икән? Минем бит, ныклап торып тикшереп карасаң, мыскал да гаебем юк. Бүрәнә озаткан кешеләрнең берсен дә белмим. Алар белән аралашмадым. Йөзләрчә гектар мәйданда кистергән урманнан өемә бер генә чыбык та күтәреп кайтмадым. Ә Гөлнәзирәм ул дүрт малайны берүзе ничек аякка бастырыр?

***

Төрмә башлыклары Таһирлар барагыннан бер почмакны аерым бүлеп алдылар. Чаршаулар элеп, яңа карават-өстәл, суыткыч куйдылар. Кемне китерәләр, бик важный персонадыр, мөгаен, дип көтсәләр, кулына җинелчә генә дипломат тотып, чал чәчле, авызы тулы алтын тешле бер агайны китерделәр. Үзенә тәкъдим ителгән почмакны килештереп:

—Нәрсә?! Претензиям юк. Монда яшәргә була. Алдан ук әйтәм, приговорда күрсәткәнчә, егерме ел түгел,—диде ул аны озата килгән прапорщикка. Мәскәүнең «Прага» ресторанының элекке директоры булып чыкты ул. Үзен: «Моисей Львович Ромм!»—дип таныштырды.

—Егетләр, таныш булыйк әле, сез барыгыз да минем кебек: «Особо опасный государственный преступниклармы» сон? Мине, бөтенләй авторитетымны төшереп, вак-төяк кесә караклары, стоянкалардан машина урлап китүче малай-шалайлар арасына китереп тыкмадылармы?—шул булды аның баракка кереп, караватына утыргач әйткән беренче сүзе.

—Болары тагын ниемә хаҗәт!—дип, аны башкалардан аерган чаршауларны да йолкып алды. Моисей Львовичның да статьясы—«Совет дәүләтен аеруча зур күләмнәрдә урлашып төп башына утырту, илдә экономик хаос тудырырга тырышу» икән.

—Бот арасына утлы күмер сибәсе нәрсә, мине хөкем иткән судьяның күзендә мыскал миһербан әсәре юк. Юкса, күкрәгендә ике вуз бетергәнлеккә «поплавок»лар балкый. Андый юрист йөрәгендә миһербанлык хисе икеләтә артык булырга тиеш иде. Ә ул миңа, алтмышын тутырып килгән агасына, совет сәүдәсе алдынгысына, күзен дә йоммый, егерме ел чәпәде дә куйды. Әйе, минем «Прага» ресторанны, Мәскәүнең клиентлар иң күп йөри торган җәмәгать туклану объектларының берсе иде. Булмаска, клиентларыбызны да по высшему разряду каршы алдык, сыйладык. Конечно, үзебез дә сыйландык. Нәрсә ул кызыл, кара уылдыклар!? Политбюро әгъзаләре өчен генә мәллә?

Моисей Львович шаян телле, кыю фикерле, беркемнән куркып-нитеп тормыйча үз сүзен сөйләүче, дөньяны күп күргән агай булып чыкты. «Особо опасный җинаятьчеләр» утырган төрмәгә ул Мәскәүдәге соңгы яңалыкларны, яшәү дәрте, алдагы көннәргә тик өмет белән карау хисе алып килде.

—Совет хөкүмәте алдында мыскал да әҗәтемне калдырмыйм дисәм, миңа бит сиксәнгә кадәр яшәргә туры киләчәк. Иртәрәк чыгу юлын карыйсы булыр,—дип сөйли ул, әле бер, әле икенче күзен хәйлә белән кысып алып.—Әле бит балаларымның назын татып, үзем исә оныкларымны иркәләп тә яшисе бар!

Аның килүенә атна-ун көннәр уздымы икән, лагерьдан йөз метрлар гына уйсу җиргә, пыр-пыр килеп, вертолет төшеп утырды. Иректә калган дуслары Моисей Львовичның хәлен белергә килгәннәр икән. «Прага» ресторанының элекке директоры, зонадан читкә чыгып, дуслары янында чәй эчеп, кәеф-сафа корып, алты-җиде сәгатьләр булып керде. Аны озата йөргән прапорщик Ковтун, баракка бер зур кәрҗин белән бик тәмле пироглар, кызыл уылдык консервлары, кофе-чәй, кыйммәтле дарулар күтәреп кертте.

Әлеге вертолет, Ромм агайның хәлен белергә, таш яуса да, аена бер утыра башлады.

Баракта төннәр ай-һай озын. Декабрьнең бер төне бер елга тиңдәй озын тоела. Тоткыннар арасында: «никадәр аз сөйләсәң, шул кадәр гомерле булырсың» дигән акыллы кисәтү яшәсә дә, йокысыз төннәрне телең үзең дә сизмәстән ачыла. Баштан узган хәлләр, иректә калган сөйгән ярлар турында сөйләп кую ни дип гаепкә саналсын? Көтмәгәндә генә эчеңне бушатып куясың да, соңыннан сиңа гына түгел, сине тыңлаучыларга да рәхәт булып китә. Үзенең башыннан үткәннәрне Таһир да сөйләми калмады.

Кем ни-нәрсә турында сөйли, искә төшерә башласа да, сүз бит чәнечкеле чыбыклар белән әйләндереп алынган зонаның тышында, иректә бара. Төннәрен ачылып сөйләп китүләр барысы өчен дә шул ягы белән кадерле.

Моисей Львович ничектер беренче көннәрдән үк Габбас Чанышевны якын күрде. Габбас үзе дә бик ипле, йомшак, саф күңелле, итәгатьле кеше. Һәркемгә ярдәмчел. Габбас та аңа үз биографиясен сөйләп бирде. Аны дикъкать белән тыңлаганнан соң, Моисей Львович кулындагы сигаретын сүндереп:

—Э-э, сынок, с тобой жестоко поступили. Пусть сидят те, кто воровал. А ты здесь причем? Справедливость должна восторжествовать! Я на волю своим адвокатам передам, чтобы твое дело подняли, вновь пересмотрели.

А сам, сынок, готовься, через месяц будешь дома!—диде. Габбас исә:

—Что вы говорите, дорогой Моисей Львович! Хоть бы срок малость сократили...—дип, үз колакларына ышанмады. Ул гына түгел. Барактагыларның барысы да!

***

...Таһир белән Габбас пилорамнан чыккан такталарны өеп маташалар иде. Моисей Львович белән теге сөйләшүдән соң ай ярымнар чамасы узган иде. Баш очларындагы репродуктор телгә килде:

—Габбас Чанышев, срочно с вещами на выход!—дип кабат әйттеләр. Чөнки бу мәсьәләдә зона-лагерьларда «тимер» закон яши. Төрмә администрациясенең ирекле кешене бер генә сәгать тә тоткарларга хакы юк. Моның өчен аерым статья каралган. Зонада Габбас барысы белән дә саубуллашып, баракларына таба атлады. Аннары:

—Моисей Львович, мин мәңге рәхмәтлемен. Менә бит... Нинди мәрхәмәтле кеше булып чыктың. Мәңге исән-сау бул, мәңге яшә, хөрмәтле агай,—диде.

Габбас Чанышев Таһир белән аеруча җылы саубуллашты.

—Алла бирсәме, Таһир! Тормышның бу үтә әче шулпаларын туйганчы, тәмам гарык булганчы татып карадык. Аның татлы шулпаларын да татырга хакыбыз бардыр бит!? Алдагы көннәрдә яшәп тә карарбыз әле, боерса. Менә күрерсең!—дип, аңа өй адресын бирде, бернигә карамыйча, хат язышып торырга булдылар.

—«Туктамышев, с вещами немедленно на выход!»—дигән сүзләрне тиз көннәрдә сиңа да ишетергә язсын, әйбәт егет! Сиңа кулымны шундый теләкләр белән бирәм, Таһир,—диде янә Габбас.—Менә иреккә чыгып, балаларымны күреп, бераз баш-күз генә алыйм. Синең эшеңне яңадан карату артыннан үзем йөри башлыйм. Гаделлек дигән нәрсә бар икән бит бу гөнаһка баткан дөньяда! Шулай булгач, нигә аны үзебез җиң сызганып эзләмәскә, тапмаска?

Чанышевтан соң, Ромм агай үзе дә озак утырмады. Ул Бөек Ватан сугышы ветераны икән. Орден-медальләре дә бар. Фронтта ике тапкыр контузия алган. Йөрәгендә аритмия. Яше дә олы. Кылган җинаяте дә «особо опасный государственный преступник» дәрәҗәсендә үк түгел икән. Әз-мәз урлаштырган, дус-ишләре белән кәеф-сафа корып яшәгән, иртәнге чәен дә, ак ипи өстенә кара уылдыкны башка совет кешеләренә караганда калынрак ягып, эчкән-ашаган. Ашаса инде, кулында булгач. Ул бит ресторан директоры!

Киткән чакта Таһирга да:

—Сынок, синең «Эш»еңдә дә ак җепләр белән теккән җирләр бик күп. Теге кичтә мин сине дикъкать белән, исем китеп тыңладым. Сине бит, улым, бөтенләй кылмаган җинаятьләрдә гаепләп утыртканнар. Алар кулында раслардай бер материал да юк. Үзеңне дә әйтер идем. Шуңа риза булгансың,—диде.

—Шуның өчен дә бит судья, прокурор сораган егерме биш елны тулысы белән түгел, ә унике ел гына бирде,—диде Таһир, хәтта бераз елмая төшеп.

—Ә унике елы нәрсә өчен? Биш елыңны нәрсә өчен утырдың? Үзең болай киң кругозорлы, укымышлы гына егет. Һәрхәлдә, күнелдә шундый фикер тупланды. Суд хөкемен көтеп одиночный камерада биш ай утыргансың, обвинение кулында булган. Шунда соң, сине гаепләүче прокурорның бар сүзен юкка чыгарырлык чыгыш хәзерләгән булсаң! Үзеңне үзең якламасаң, бу кансыз дөньяда сине кем якласын!?—Моисей агай гайрәте чигеп, өметсезлеккә ымлап кулын селкеп куйды:

—Без дә яшибез инде дөньяда! Бойняга куган сарык көтүеннән мыскал да аермабыз юк, шайтан алгыры! Озын сүзнең кыскасы шул, Таһир улым. Кешеләргә, иптәшләренә карата яхшы, йомшак мөгамәләдә булуын, әдәпле яшәү рәвешең белән кереп каласың Моисей агаң күңеленә. Янында синдәй егетләр булу—үзе үк күңелдә якты өметләр уята. Без, фронтовикларның, яраткан сүзе бар: «Синең белән дошман тылына разведкага, «тел» алырга икеләнми барырга була!»—дип бәялибез кешеләрне. Син ышанычлы егет, дустыңны иң авыр хәлендә дә юлда ташламаячаксың. Безнең, фронтовикларның, кешеләргә карата бирә торган иң югары бәясе бу. Син дә аны, миннән, ихтирамыңны саклап, кабул ит. Бер баракта яшәгән, озын төннәрне уздырган көннәребездә сиңа карата туган хисләремнең нәтиҗәсе шул: синең белән «тел» алырга барырга хәтта бүген дә икеләнми китәр идем!

Үзара мөнәсәбәтләрең никадәр якын булса да, төрмә шартларында ул кадәр «күңел йомшаклыгы», яисә күз яше күрсәтү юк. Бу—тыелган гамәл. Ә Моисей Львович:

—Кил, сынок, бер кочыйм үзеңне!—дип колачын җәйде, Таһирны кочып та алды. Һәркемгә ярдәм кулы сузарга әзер бу мөлаем агайның әлеге гамәлен аны озатырга чыккан тоткыннарның барысы да килештерделәр.

—Эшеңне яңадан карат. СССР Верховный Советына апелляция яз. Чыгыйм гына әле, бу эш белән үзем дә мәшгуль булырмын. Таһир, улым, бу дөньяда Моисей агаң барын беркайчан онытма! Ул сине яратты, ихтирам итә... Иректә, бәхет чаткылары тулы йөз белән... Очрашырбыз әле!

## 14

—Кадерле Игорь Наумович, күңелгә якын тавышыгызны ишетүемә бик шатмын. Ничә тапкырлар шалтыратырга, хәлегезне белергә ниятләнеп тә, килешмәгән эш булмагае, дидем, ул уемны алга калдыра киллем,—дип, шатлыклы тембр белән Данәгөл сүз барышын үзе «иярләде».—Без, Франция рәссамнары, агалы-энеле Павел һәм Сергей Третьяковлар нигез салган Мәскәү сәнгать Музее турында шактый тирәннән хәбәрдар. Ленинградтагы «Эрмитаж»ны да яхшы беләбез. Третьяков залларын, Леонардо до Винчи, Рафаэль, Микеланджело, Тициан, Эль-Греко, Рембрандт кебек генийлар тудырган шедеврларның төп нөсхәләре белән бергә, бүгенге бик күп сәнгать осталарының әсәрләре дә бизи. Сездә, әле 1917 елда булган революциягә кадәр үк, аның тупланмаларында дүрт меңнән артык рәсем сәнгате, скульптура, фарфор, бронза, керамика, икона төрләре тупланган була. Әле менә соңгы елларда гына Халыкара рәссамнәр ассоциациясе «Белешмә»сендә: «Третьяков галереясе» залларында илле биш меңнән артык шедевр тупланган, дип күрсәтелә.

Телефон трубкасында Игорь Наумовичның:

—Мадам Данәгөл, алдыма куйган бурычымны үтәүне Сез бермә-бер җиңеләйттегез!—дигән тавышы ишетелде.—Тасвирлау сәнгатенең Бөтендөнья күренекле осталары катнашы белән безнең илдә узачак тантанага Франциянең танылган җиде рәссамын чакырдык. Әлеге исемлеккә, үзегездән рөхсәт тә сорап тормыйча, Сезне дә теркәдем. Каршы түгелсездер бит?

—Кадерле Игорь Наумович! Бик теләп, бик теләп!.. СССРда, аның башкаласы Мәскәүдә булу—минем күптәннән башымда булып та, тормышка ашыра алмый йөргән якты хыялым. Сезгә булган хөрмәтемне, мең-мең рәхмәтемне ирештерергә әлегә юлларын тапмыйм... Минем Сезне кочып-кочып үбәсем килә, мәрхәмәтле Кеше!

—Мадам Ногайбәк-Туктамышева?! Сездәй чибәр ханымның кочагына эләгеп, мин шунда ук инфаркт алмаммы соң?—Игорь Наумовичның

җинелчә генә көлүен ишетте Данәгөл.

—Хөрмәтле кунакларыбыз Мәскәүгә атна башында очачаклар,—дип дәвам итте СССРның Франция республикасындагы илчелегенең мәдәният-музыка-сәнгать бүлеге башлыгы И.Н.Базилевский—Сезгә юлга җыенырга тагын өч көн кала. Шәт, өлгерерсез бит? Мин аңлыйм, срок зур түгел. Чөнки кайбер ханымнарга театрга җыену өчен дә—өч көн бик тар... Аннары ул күп мәгънәле итеп:

—Калганын безгә килгәч, күрешкәч сөйләшербез. Берүк соңара күрмәгез!—диде.

—Улым Жанны да алсам буламы?

—Теге чакта минем белән ирләрчә кул биреп күрешкән матур малаймы? Аңа хәзер ничә яшь?

—Җидене тутыра.

—Мөмкин. Бу кинәшне сезгә үзем дә бирмәкче идем. Ул чакта—безнең илчелектә күрешкәнгә кадәр—сау булыгыз!

Көтмәгәндә өстенә ишелгән бик сөенечле хәбәрдән Данәгөл шатлыгын тыя алмыйча: «Бик теләп! Бик теләп!»—дип ышандырса да, офисыннан өйләренә кайтса, җидене тутырып сигезенче яшенә чыгып барган улы Галимҗан «ут эчендә» ята. Дәү әнисе белән шәһәргә чыккан җирләреннән, иң тәмле ризыкларның әле тегесен, әле монысын татып йөреп, берьюлы өч туңдырма ашаган. Оныгы ни сораса, бер карусыз шуны эшләргә әзер дәү әнисе кечкенәдән ук туңдырмалар яраткан Жанны тыя алмаган күрәсең.

Хәзер менә тамагы ялкынсынган—«ут эчендә» ята. Мондый хәлдә кайсы ана шундый ерак сәфәргә чыга алсын? Данәгөл мең-мең кат гафу үтенеп, илчелеккә шалтыратты. Бу юлы аның белән, бераз карлыкканрак тавыш белән, әмма һәр сүзендә теләктәшлек интонациясе сиздереп, бер ханым сөйләште:

—Мадам Данәгөл, борчылмагыз. Барыбызда да була торган хәл. Игорь Наумович делегация белән Мәскәүгә очты. Документларыгыз менә алдымда. Барысы да тәртиптә. Улыгыз терелгәч, килерсез. Чакыру үз көчендә кала,—диде.

Өч-дүрт көннән Жанның хәле рәтләнде. Дәү әтисе аңа җәя белән ук ясап биргән иде. Җәяне үз бакчаларындагы чия агачыннан ясады. Әйбәт чыкты, укны бик еракларга очыра. Ногайбәк ага, бер фанера кисәгенә акбур белән түгәрәкләр сызып, оныгына мишень ясап бирде. Әнә, бабалы-оныклы ике сабый ишек алдында шул мишеньга ук атып уйныйлар.

Данәгөл, Жанны да ияртеп, СССР илчелегенә бер атнага соңарып килде. Бәхетләреннән, бүген төштән соң, «Лиссабон-Париж-Берлин—Мәскәү» маршруты белән атнасына бер регуляр рейслар ясаучы Германиянең «Люфтвоффс» компаниясе очкычлары Мәскәүгә оча икән. Илчелекнең Курьер егете аларны Бурже халыкара аэропортына машина белән озатып куйды. Башына саламнан үргән сомбрерро—эшләпә кигән, өс-башын да нәкъ аларча киенгән Жан, үзен Америка индеецларының иң көчле кабиләсе-апачилар башлыгы итеп сизә. Аркасына дәү әтисе ясап биргән җәясен аскан. Кынында ике-өч угы да бар. Янына килеп, авыр сүз әйтмә! Кыныннан угын алып, җәясен шунда ук йөрәгенә төбәр. Курьер егет Жанның бу килеш-килбәтен килештереп:

—Минем дә, нәкъ Жан яшендә булыр, кызым бар. Алсу исемле. Ул безнең курчаклар белән җенләнә. Бөтен квартирабызны курчаклар басты инде!—диде.

Моңа кадәр француз телендә сөйләшеп килгән җирләреннән кинәттән татарчага күчеп, Данәгөл ханым әлеге егеттән:

—Сез әллә татар егетеме?—дип сорады.

—Мине илчелектә Самоэль дип йөртәләр. Чын исемем Исмәгыйль минем. Татар гына түгел, Татарстанның башкаласы Казанның үзеннән мин. Хәрби хезмәттә дингез флотына эләгеп, биш ел рәттән «Ленин» бозваткычында Котып дингезендә йөздем. Бозваткычта вахтадан буш вакыт күп була. Үзлегемнән Виктор Гюго, Бомарше телен өйрәндем. Имтихан тоттым. «Бишкә» тапшырдым. Бозваткычның китапханәсе искиткеч бай. Тел өйрәнәм дигән матроска лингофон бүлмәләренә хәтле бар. Магнитофонга үзең өйрәнергә теләгән тел язылган кассетаны куй да, колакларыңа наушниклар киеп, рәхәтләнеп тыңлап утыр. Сиңа берәү дә комачаулык итми. Безнең арада бер дигән итеп немец, испан, хәтта япон телләрен өйрәнүчеләр дә булды. «Ленин» атомоходында хезмәт срогым тулгач, комсомол путевкасы белән Тышкы Эшләр Министрлыгына юллама бирделәр. Французча яхшы белгәч, бирегә Курьер итеп билгеләделәр. Әлегә дипКурьер булып йөрсәм дә, бу эш бик ошый миңа. МГИМОның Дипломатия тарихы факультетында читтән торып дүртенче курста укыйм.

Курьер егет Исмәгыйль, тагын да ачыла төшеп, болай диде:

—Данәгөл ханым, канкардәш затлардан булгач, шуны да әйтәсем килә. Институт программасы буенча дипломатия тарихын без бик тирәннән өйрәнәбез. Мәскәү кнәзе Иван Грозный 1552нче елда Казан ханлыгын басып алгач, кызганычка каршы, безнең дәүләтчелегебез бетә.

—Әтиебез Ногайбәк ага бик укымышлы зат. Мин бу турыда берникадәр хәбәрдар,—диде Данәгөл ханым.

—Рус чиркәве, хансыз, дәүләтчелексез калган халыкны көчләп, кыйнап, каравыл кычкыртып талап руслаштыру-чукындыру сәясәтен алып бара башлый. Хәтта бөтенләй юк итү чараларын да күрә.

Әмма азатлык сөйгән халыкның кол булып яшисе килмәгән. Еш кына баш күтәргәннәр, дәүләтчелекне торгызырга тырышканнар. Менә шул хәлләр булмасын өчен, рус колонизаторлары иң эффектлы чараларны күргәннәр. Коралсыз, кылычсыз баш күтәрә алмыйсың. Халыкка һәр гаиләдә тимер затыннан нибары бер пычак кына тотарга рөхсәт ителгән. Пычкы-балтаны урәтниктән вакытлыча гына алып торганнар. Чөнки алар баш күтәрүчеләр кулына эләксә, баш чабардай коралга әвереләләр. Сынык пычак белән яшәүне күз алдына китереп карагыз инде. Бу законның тайпылышсыз үтәлүен көн саен диярлек тикшереп торганнар. Бер гаиләдә ике пычак тапсалар, хуҗасын салып сuктырганнар. Ә яшәргә кирәк! Бер-берең белән аралашмый, кулдан килгәнчә үзара сәүдә итми дә яшәп булмый. Энә, тегәрҗеп, сәдәф-төймә, каптырма ише вак-төяк белән алыш-биреш, сәүдә итү, ягъни «кырык тартмачылык» белән кәсеп итүчеләр пәйда булган. Мин исә шушы кадәресен дә бик житди китаплардан укып белдем: Мәскәү кенәзлегең ил итүдә күп гасырлар буе рәттән татар өммәтеннән булган илчеләр, бер дигән тылмачлар, зирәк акыллы дипломатлар гаять зур көч куйганнар. Безнең халыкның әвәл-әвәлтеннән килгән төп һөнәре тылмачлык, илчелек вә дипломатия булган.

Курьер егет салмак кына сөйләп килгән жиреннән:

—Ә менә боларына ни әйтерсез?—дип куйды.—Иң эре филләрне, кобра еланнарын үз кубызларына биетүче факирлар иле Һинстанга рус сәяхәтчесе Афанасий Никитиннан ике гасыр алда татар сәүдәгәре Ибраһим Хәлфин барып чыккан. Әхмәдабад һәм Дәһли калаларында аның кибетләре булган.

—Бу кадәресе миңа да яңалык,—диде Данәгөл.

—Тарих битләрен жентекләп актарсаң, рус патшасының Һиндстандагы, Әфганстандагы, Иран-Гыйрак, Төркия, Италия, Германия, Франция, Литва-Латвиядәге илчеләре татар булган. Болар—тарихи факт. Кирәксә, бик күп исем-фамилияләрне санап чыга алам.

—Исмәгыйль, сездәй укымышлы замандашыбыз белән танышуыма мин бик шат,—диде Данәгөл ханым.—Франциядә эшләп, зур тәҗрибә туплап, укуыгызны да уңышлы тәмамлап, Европаның берәр илендә Советлар Союзының Тулы вәкаләтле һәм Чираттан тыш илчесе булсагыз, без бик сөенер идек.

Исмәгыйль иңбашларын уйнатып алды.

—Безнең бозваткычта: «кайсы матрос адмирал булырга хыялланмый!»—дигән тапкыр әйтем бик популяр иде...—дип кенә куйды.

—Исмәгыйль, минем сезгә карата хөрмәтем икеләтә!—диде Данәгөл, йөзенә җитдилек алып.

—Ни өчен икеләтә?

—Беренчесе—шундый ачык күңелле, тирән укымышлы егет булган өчен.

—Икенчесе?—дип сузды Исмәгыйль.

—Анысы... матрос булганыгыз өчен!

Ул арада самолетка утырту башланды. Самолетка илтә торган микроавтобуска чыктылар. Исмәгыйль бер кулы белән Жанны җитәкләде, икенче кулында—Данәгөл ханымның юл сумкасы.

—Мәскәүгә миннән күп итеп сәлам әйтегез!—диде Исмәгыйль.—Арагыз калса, безнең Казанга да барып килегез. Поездда нибары унбер сәгать. Анда минем әти-әниләрем яши. Шәехисламовлар, дип сорасагыз, бик тиз табып күрсәтерләр.

—Кем белә, кем белә! Бәлки барып та чыгарбыз әле. Шулай бит улым, Галимҗан!?—дип саубуллашты Данәгөл ханым илчелек Курьеры мөлаем йөзле егет Исмәгыйль Шәехисламов белән.—Исән-сау булыгыз!

***

Игорь Наумович Базилевский Франция кунагы Данәгөл Ногайбәк-Туктамышеваны «Россия» кунакханәсенең Конференц-Залына каршы ял бүлмәсендә эзләп тапты. Тиктормас Жан сомбрерро эшләпәсен самолетта онытып калдырды. Мәскәү хәтле Мәскәүдә яланбаш йөрү килешми. Ул үзгә төр баш киеме кияргә теләмәде. «Военторг» кибетендәге кызыл йолдызлы пилотканы бик ошатты. Әнисе аңа шул пилотканы алып киертте.

Игорь Наумович, Жанны пилотка кигән башыннан сыпырып, хәл-әхвәл сорашканнан соң:

—Данәгөл ханым, тормыш иптәшегез Таһир Туктамышев турында туплаган информация әлегә бик сай...—дип сөйләп китте.

—Франциягә дуслык визитыннан кайткач, ул демобилизацияләнгән. Бездә Казакъстан республикасында буш яткан чирәм җирләрне үзләштерү компаниясе булып алды. Үзе белән бергә флоттан киткән ике йөздән артык егет белән алар Казакъстанга, Павлодар өлкәсенең «Коммунизмга» совхозына чыгып китәләр. Кызганычка каршы, илне телефонлаштыру буенча әлегә күп илләрдән калышабыз. Ни тырышсак та, «Коммунизмга» совхозын ала алмадык. Ләкин күңелне төшермик. Казакъстан Коммунистлар партиясенең Үзәк комитетында бер дус иптәшем—Саттар Муканов эшли. Аның белән Мәскәүдә, КПСС Үзәк Комитеты Академиясендә бер курста, бер бүлмәдә торып укыдык. Мин аның белән бәйләнешкә кердем. Саттар дустым партиянең Павлодар өлкәсе секретарена шалтыраткан. Аның беренче секретаре Павлюченков Сергей Михайлович:

—Франциянең танылган рәссамымы? Килсен, килсен! «Коммунизмга» совхозына да алып барырбыз, бик зурлап кунак та итәрбез!—дигән.

—Данәгөл ханым, мин сезнең Советлар иленә визитыгызны тагын ун көнгә озайттым. Кирәксә, казакъ дусларым тагын озынайтырлар. Менә

сезнең кулыгызга бүген сәгать дүрттә Алма-Атага оча торган самолетка билет тоттырам. Анда каршы алырлар. Павлодарга оча торган самолетка утыртырлар. Сезгә тик уңышлар гына телим, кадерлем!—дип Игорь Наумович урыныннан күтәрелде.

## 15

Ерак Франциянең үзеннән килгән танылган рәссамны каршы алырга Павлодарга «Коммунизмга» совхозы башлыгы Кирилл Куприн белән сәнгать мәктәбе директоры Жәгъфәр Калканбаев килгән иде. Әлеге хәбәргә совхоз җитәкчеләренең башта әллә ни исләре китмәде. Монарчы шәп-шәрә дала булып яткан җирләрдә яңа торак пунктлары, поселоклар калкып чыга башлагач, шул исәптән «Коммунизмга» совхозына да журналистлар, язучылар, рәссамнар, композиторлар Алма-Атадан, Мәскәү-Ленинградтан, хәтта чит илләрдән дә кунаклар еш килеп чыккаладылар. «Коммунизмга»да хәтта Мәскәү Консерваториясенең Симфоник оркестры да килеп, концерт куеп китте.

Совхоздан килгән егетләрне партиянең Павлодар Өлкә Комитетының Беренче секретаре Рыленко кабинетына дәштеләр.

—Мин Таһир Туктамышевның никахлы тормыш иптәше булам,—дип күреште алар белән чәч-толымнарын каерып артка бәйләгән, өстенә моренго, ягъни юеш асфальт төсендәге затлы костюм кигән бу мөлаем йөзле ханым—мадам Данәгөл.

Исемен атаганны, таныштырганны да көтмичә, аннары алар белән җиде яшьләр тирәсендәге, бераз кысыграк күзле, әмма терекөмештәй бер малай килеп күреште:

—Галимҗан Туктамышев!

Тәгәрә дә кит, суйган да каплаган!—Әлеге тынкыш борынлы, кысык күз, Таһирның коеп куйган үзе бит бу! Күз карашы, сул ягына бераз гына янтаеп, аяк атлауларына кадәр. Бик үзсүзле, принципиаль холыклы егет булып үсәсе йөзеннән бүген үк чагыла. Галимҗан шунда бик җитди кыяфәттә:

—Мин Американың Кентуки штатында яшәгән Апачилар кабиләсе башлыгы!—диде. Аркасындагы җәягә, кулындагы укларга ымлады.

Егетләр дә, йөзләренә тагын да җитдирәк кыяфәт биреп:

—Ул чакта без сиңа, Галимҗан, икеләтә ихтирам белән карыйбыз!—дип куйдылар.

Кирилл Куприн беркайчан да сүзгә кесәгә кермәде. Әмма, гомерендә беренче тапкыр дигәндәй, бераз югалып калды. Мондый чакта әйтелергә тиешле бик кирәкле сүзләрне озаклабрак сайлаган кыяфәттә:

—Бу очрашуны көткән булсак та, күргән күзләребезгә һаман да ышанып бетәсе килми. Бу чынлап та сезме сон?—диде.

—Мин булмыйча!—дип елмайды кунак ханым.

—Сезне исән-имин күрүебезгә без бик шат!

—Ничә еллардан соң!?—дип өстәде Жәгъфәр.

—Без бит сезне яхшы беләбез.

—Мине-е?—дип гаҗәпләнде Данәгөл.—Ничек? Каян? Бу тарафларга минем гомеремдә беренче аяк басуым.

—Ничек белмик ди инде!—дип җөпләде Кирилл сүзен Жәгъфәр.—Марсель портында сез безнең крейсер палубасына аяк басканда, ул көнне без карабның кунакларны кабул итү, озату группасында идек.

—Шулай мени-и?—дип гаҗәпләнде Данәгөл ханым.—Барысын да хәтерлисез!?

—Хәтерләмәскә! Ул кеше әтиегез булгандыр, бик күркәм төс-кыяфәтле ир уртасы белән килдегез. Сезне ярдан китергән катердан палубага

күтәрелгәндә, кулымны сузып ярдәм иттем. Ул көнне гаваньда җинелчә бриз уйнады. Трап ярыйсы гына чайкалгалап торды...—дип дәвам итте Кирилл.

—Кирилл, синең: «Бу Франциядә туташлар бигрәк чибәрләр!»—дип әйткәнең хәтеремдә әле минем,—дип өстәде Җәгъфәр.

Беренче киеренкелекне җиңеп, теле ачыла барган Кирилл:

—Ник? Әллә ялгышканмынмы? Чыннан да шулай бит. Данәгөл ханым, комплиментларымны ихлас күңелдән кабул итегез!—диде. Бераздан Данәгөл ханым, исен җыеп:

—Ә Таһир кая? Нигә үзе килмәде?—диде.

Кунакбикә ханымның бу сүзләрен егетләрнең икесе дә өсләренә бер чиләк кайнар су койгандай кабул иттеләр. Сүзсез калдылар. Бер-берләренә караштылар. Димәк, Кунакбикә ханым Таһирның совхозда юклыгын, аннан күптән киткәнен белми? Каян белсен? «Россия» кунакханәсенең холлында очрашканда Игорь Наумович аңа:

—Сезнең ирегез, Франциягә визиттан кайткач, хәрби флоттан демобилизацияләнгән ике йөздән артык иптәше белән, Казакъстанга чирәм җирләр үзләштерергә киткән. Аларны Павлодар өлкәсенә, Биш Караган районы «Коммунизмга» совхозына җибәргәннәр,—дигән иде. Данәгөл шул сүз белән, әлбәттә, Игорь Наумовичның Казакъстандагы дуслары ярдәмендә, Павлодарга ук килеп җитте. Таһирның совхозда булмавын Данәгөл белми иде. Әмма күрде, бу соравы белән әлеге егетләрне уңайсыз хәлгә куйды. Сүзне тизрәк икенчегә борырга ашыкты.

—Аэропорттан Павлодарга төшкәндә, «Волга» тәрәзәсеннән карап бардым. Нинди киңлекләр, нинди тигезлек! Аяк төртер җире аз булган Көнбатыш Европадан килгән кешегә, бу тарафлар, бу иркенлекләр яңа планетаны күз алдына китерә. Еракта горизонт читендә утлап йөргән ат, куй көтүләре күренеп китә. Машина иксез-чиксез бодай басуы буйлап килә дә, биеклеккә ике метрдан өстә булып үскән көнбагыш кырына килеп керә. Искитмәле матур пейзажлар. Ирексездән кулга мольберт аласы килә.

—Анысы инде үзебезгә, совхозга кайткач!—диде Җәгъфәр. Теманы Кирилл әләктереп алды:

—Безнең Җәгъфәр дә профессиональ рәссам. Ике ел элек Ленинградтагы Суриков исемендәге рәссамнәр академиясен тәмамлады. Үзебезнең совхозда балаларның сәнгать мәктәбен ачты. Хәзер шуның директоры.

Данәгөл ханымның: «Таһир кая соң? Безне каршы алырга ник килмәде?»—дигән соравыннан шулай җиңел котылуларына икесе дә шат иделәр. Анда, совхозга кайткач, күз күрер әле.

***

Җәгъфәр кадерле кунакларны бер генә минутка да ялгыз калдырмады. Икенче көнне үк үзе укыткан балалар сәнгать мәктәбенә, тау булып бодай көшелләре яткан ябулы ындыр табагына алып барды. Төзелеп килүче яңа пекарняны карадылар. Аннары Җәгъфәр кунакбикә ханымны «Тозлы күл» буена этюдка алып чыкты. Павлодар өлкәсендәге барча күлләр дә тозлы. Монысына бу исемне җирле казакълар аеруча тозлы булганга биргәннәрдерме? Әмма бик матур күл. Шулай тозлы булса да, күл уртасында үрдәкләр йөзә. Ә яр буенда, озын сыйраклары белән адымнарын санап-санап кына басып, торналар, челәннәр йөри. Данәгөл дә, Галимҗан да бик канәгать калып, илһамланып кайттылар. Галимҗанга барыннан да бигрәк Җәгъфәр абыйсының куй итеннән ясаган шашлыгы, чат бал карбызлары ошады.

Бирегә килүләренең өченчеме-дүртенчеме кичендә кунакларның ишеген шакыдылар.

—Керегез! Керегез!—диюгә, ишектә сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле, төз, матур гәүдәле бер ханым күренде. Ул да үзе белән ун-унике яшьләрендәге, үзе кебек сары чәчле бер кыз ияртkән. Ханымнар бер-берсенә текәлделәр. Беренче булып Данәгөл ханым:

—Түрдән узыгыз! Тынлыйм сезне?—диде.

Ишектә күренгән ханым, Данәгөлне тагын бер кат баштанаяк күздән кичергәннән соң:

—Мин Оксана булам,—диде.—Мин сезне, Чибәркәем, нәкъ шушылай итеп күз алдына китергәниием.

—Комплиментыгыз өчен рәхмәт. Шундый ук сүзләрне сезгә дә әйтәсем килә. Ә мине каян беләсез?

—Белмәскә соң!?—дип елмайды Оксана.—Беләсезме, кадерлеләрем? Зинһар баш тарта күрмәгез, сезне үзебезгә кунакка дәшәргә килдек.

Шушы сүзләрдән соң, монарчы дәшми торган кызчык, Данәгөл апасы каршына килеп, книксен ясады:

—Без сезне ихлас күңелдән кунакка алырга килдек.

Данәгөл ханым ни әйтергә дә аптырап торганда, арага Галимҗан килеп керде.

—Мин кунакка йөрергә яратам. Марсельдә дә без дәү әтием белән аның дусларына кунакка йөрибез. Мин барам кунакка!—диде.

—Вот и умница! Акыллы егет икәнсең!—диде аларны кунакка дәшкән кыз.

Без моннан ике-өч адымнарда гына торабыз, рәхим итегез!—диде Оксана.

Данәгөл ханым, бу чибәр хатынның аларны үзенә кунакка бернинди сәбәпсез дәшмәвен, Таһир турында нинди дә булса яңалык ишетәсен күңеле белән сизде. Оксаналар бер гаилә өчен генә төзелгән аерым йортта торалар икән. Ишегаллары тулы чәчәк. Чиста. Алар ишегалдына кергәч, амбар артыннан бер маэмай өреп чыкты.

—Белочка, үз кешеләребез, урыныңа кер!—дип Радмила аны кире амбар артына куды. Белочка карышмады.

—Минем исемем сезгә берни дә сөйләми,—диде Оксана кунаклары белән өйгә кергәч. Матур итеп бизәлгән өстәл артына утыргач:

—Кызым Радмилага ике яшьләр булганда, беренче ирем белән аерылыштык. Ул чакта монда кечерәк кенә медпункт. Мин шунда фельдшер. Совхозның оеша гына башлаган чорлары. Бер җәйне, уракка төшәр алдыннан, флоттан демобилизацияләнгән матрослар килеп төштеләр. Китте өйләнешүләр, язылышулар, китте туйлар. Күп егетләр үзләренә парларны моннан таптылар. Күбесе, флотта хезмәт иткәндә хатлар язышып торган кызларын чакырттылар. Әнә, безнең директор Кирилл, ул чакны берүзенә дүрт йөргән кызын чакыртып китерде. Җирәбә салып берсен үзенә алды. Калганнарын башка егетләр эләктерделәр. Мин генә ялгыз. Бер тапкыр кияүдә булган тол хатынны кем алсын? Житмәсә, прицебым да бар...

Әнисенең сүзен Радмила да ишетеп алды:

—Әнием, мин нишләп прицеп булыйм? Мин—Радмила! Мин сине прямо акылымны җуеп яратам!—диде ул.

—Рәхмәт, кызым!—диде дә, Оксана дәвам итте. Өенең ян тәрәзәсеннән каршыдагы ике катлы бинага күрсәтте.—Бу—безнең Культура Сарае. Шуның түбәсен япканда Таһир кадакка баскан. Аягы шунда ук гөбе булып шешә башлаган. Миңа китерделәр. Яраны бик нык эшкәртергә, юарга кирәк. Гангрена башлануы бар.

—Күз алдыма китерәм Таһирны,—дип куйды Данәгөл.—Ничек сызлангандыр!?

—Медпункта ике ятагыбыз бар иде. Шунда салдык. Авыруның хәле авыр. Температурасы төшми. Иртәсен дә, төшен дә, кичен дә авыруның хәлен Радмила белән белеп кенә торабыз. Таһир абыйсы бер күрүдә бик яратты аны. Радмила, Галимҗан белән китаплар карап утырган жиреннән:

—Таһир абыйны мин бүген дә бик яратам!—дип кычкырып куйды.—Ул мировой егет! Ул да мине бик ярата!

—Радмиланың туган көне иде,—дип янә сөйләп китте Оксана.—Таһир култык таягына таянып бераз йөри башлады. Шеше дә кайта төште. Радмила миннән сорамый-нитми аны туган көненә кунакка алып кайткан. Авыру кешене куып чыгара алмыйсың. Кич булгач та җибәрмәдек. «Мин Таһир абыйга гашыйк булдым. Аны кочаклап йоклыйсым килә!»,—дип аны җибәрмәде. Икәү кундылар. Таһир үзе дә балалар яратучы җан иде. Шулай итеп торып киттек. Миңа да бит тормышта терәк кирәк. Ә Таһир нык, ышанычлы терәк. Ике ел ярымнардан артык без ир белән хатын булып яшәдек. Бик тату тордык. Үзебез дә кунаклар кабул иттек, аның дусларына да кунакка йөрдек. Данәгөл ханым, сез мине нинди хисләр белән тыңлыйсыздыр... диде дә, Оксана берара сүзсез торды.—Минем турында начар фикер тупларга ашыкмагыз, зинһар. Таһир—дөньяда сирәк очрый торган кешелекле, киң күңелле, гаять әдәпле җаннарның берсе. Аның кулыннан килмәгән эше юк.

Оксана берара сөйләвеннән бөтенләй туктап, өстәлгә җәйгән шакмаклы ашъяулыкның җөйләрен сыпырып-сыпырып торды.

—Хәзер сезгә әйтергә җыенган сүземне, белмим, ничек кабул итәрсез?—диде.—Үзегез күз алдына китерегез. Төннәрен, кочакларга теләп миңа кулын сала. Ә бөтенләй икенче исемне кабатлый. «Данәгөлем! Данәгөлем!—ди. Минем тарафтан бәлкем зур мәгънәсезлек, кансызлык булгандыр. Бу турыда әйттем Таһирның үзенә. Ул яшермәде. Франциядә минем законлы хатыным калды. Мин аны өзелеп яратам. Бер генә минутка да күңелемнән чыкмый, диде. Хөрмәтле Данәгөл ханым, мине дөрес аңлый күрегез. Радмилага алты тулды, җиденче яше белән бара. Мин бит ирле хатын. Радмилага иптәшкә тагын бер бәбәй алып кайтасым килә. Бәбәй дә алып кайтсам, бала җанлы Таһир безнең гаиләгә бөтенләй берегәчәк. Ә бит ул Франциядәге Данәгөлен сөя. Төннәрен һаман да шул исемне кабатлый. Мин аннан, бик авыр булса да, безне калдыруын үтендем. Үземә дә бик авыр булды. Мин дә бит аңа гашыйк булып, аны бик нык яратырга өлгердем. Кайда гына йөрсә дә, кайда гына яшәсә дә, мин аны бүген дә өзелеп яратам. Бездән киткәч, ике-өч айлар безгә күрше генә булып яшәде. Радмила белән киноларга йөрделәр. Шул көннәрдә поселокка вербовщик килеп чыкты. Таһир шуның белән каядыр Архангельск якларына китеп барды. Радмила исеменә атап, шул яклардан бик зур суммаларда ике-өч тапкыр акча күчерде. Шуннан бирле бернинди хат-хәбәре юк...

Оксананы бүлдермичә, дикъкать белән тыңлап утырган Данәгөл хуш исле кульяулыгын күзләренә бик еш китерде. Данәгөл үз янына Радмиланы дәште. Рубин ташлы алкаларын салып, аның колагына киертте.

—Данәгөл апа, колагыма матур алкалар тагу минем күптәнге хыялым иде. Рәхмәт сезгә!—дип, Радмила аны кочып алды, ике як яңагыннан үпте.

Данәгөл бармагындагы зур ак зөбәрҗәт кашлы алтын йөзеген салып, Оксана бармагына киертте.

—Язмыш безне туганнар иткән. Туганнар булып калыйк. Язмыш безне нинди генә сынаулар алдына куйса да, туганлыкны онытмыйк, бер-беребезне ташлашмыйк!—дип пышылдады ул, күзләренә янә кульяулыгын китереп. Күңелләрдә туган киеренкелекне болай гына хәл итеп булмаслыгы икесенә дә көн кебек ачык. Бу ике ханым, үзләре дә сизмәстән, берсен-

берсе кочып алып, рәхәтләнеп бер елаштылар.

Данәгөл, кунакханәгә кайткач, Галимжанга:

—Улым, безгә кичекмичә илебезгә кайтырга кирәк. Әтиебез бәлкем күптән Марсельдәдер инде. Безне көтә булыр!—диде.

Иртәнге якта аларның ишегенә Радмила шакыды. Кулында кечкенә генә бик матур кәрҗин. Кәрҗин эчендә әле күзе ачылып кына килгән, шар кебек йомры көчек.

—Безнең Белочканың бик яраткан улы бу. Мин аны сезгә бүләккә алып килдем,—диде кызчык. Көчекне күргәч, Галимжан да «аһ» итте. Чөнки ул шундый матур. Йонлач, куе мамык йоннары арасыннан шомырт бөртеге хәтле генә ике күзе ялтырый.

—Ай-й, улым. Таможня аша алып чыга алмабыз шул...—диде Данәгөл.—Бүләге бик кыйммәтле дә.

Таможня узганда алар олы яшьләрдәге бер мөлаем генә ханым торган бүлеккә туры килделәр. Әлбәттә, тегесе кәрҗин эчендәге көчекне күреп алды.

—Ә барсикны каян алдыгыз: ветеринар врачның рөхсәте бармы? Булмаса, калдырырга туры киләчәк!—диде. Галимжан күп уйлап тормады:

—Ул чакта мин үзем дә калам!—диде.

—Әниеңнән аерылыпмы?—дип елмайды таможня инспекторы.—Бер ялгызың монда нишләрсең? Кая, күрсәт әле көчегеңне. Бигрәк матур икән шул. Ярар, улым, мин бернәрсә дә күрмәдем. Көчегеңне яшер. Самолетта да беркемгә күрсәтмә. Юкса, Париж аэропортында төшертмәүләре мөмкин. Килештекме?

—Килештек! Рәхмәт сезгә!—дип, Галимжан бу мөлаем йөзле апасына кулын сузды.

—Безгә алмашка шушындый егетләр үскәндә, дөньяда яшәве үзе зур бәхет!—дип, бераз каушау хәлендә торган Данәгөлгә дусларча күз кысты инспектор.

Шул ук «Люфтваффс» авикомпаниясе самолетында алар исән-имин Парижга кайтып җиттеләр. Шарль де-Голль аэропортына утырдылар. Аркасында җәясе, бер кулындагы җиңелчә кәрҗине булган «Апача кабиләсе башлыгы» Жан бу юлы да таможняны җиңел узды.

Ә Таһир?! Ул кая? Нәкъ шушы вакытларда ул Урта диңгез уртасында меңләгән вак утраулардан торган Балеар архипелагының бер исемсез утравында мафия кулында әсирлектә, зинданда ята, кәйлә белән тау токымнары чаба иде. Менә ничек бит язмыш дигәнең, адәм баласын сыныйм дисә, җаен чыгара инде. Түз генә...

## 16

... Лагерьга яңа начальник итеп, Иркутск-Хабаровск якларында зур төрмәләр саклаган, подполковник дәрәҗәсе алган Дмитрий Горбунны куйдылар. Тоткыннарга чәйнәргә тагын сәбәп бар.

—Ярый, ярый, безнең начальникның бер бөкресе бар икән инде, горбун, диләр. Икенчесен, исән булсак, без бүләк итәрбез!—диючеләр табылып кына тора. Дөрес, яңа себерке яңача себерер инде. Яңа начальник килә-килешкә үк, зонаны әйләндереп алган чәнечкеле чыбыкларны яңаларга алыштыртты. Каланча-вышкаларга көчле прожекторлар куйдырды. «Тревога», «сигнал» системасын яңача көйләтте. Әмма Таһир күреп тора. Качам дигән тоткынга зонадан читкә чыгу, качу хәзер берни тормый. Мона каләр күп еллардан килгән традиция буенча, МВД гаскәрләрендә, бигрәк тә төрмәләр, зона-лагерьлар саклау частьләрендә Төрекмәнстанның караңгы кышлакларыннан хәрби хезмәткә алынган төрекмән егетләре хезмәт итәләр иде. Русча—ләм-

мим болар. Моңа кадәр кышлакларыннан бер адым читкә чыкмаган яшьләрнең аңнарына, әле өйләрендә чакта ук, бер нәрсәне сеңдергәннәр:

—Мәскәү кышы, балам, ай-яй, салкын! Ул суыкларга түзә торган түгел! Берүк, аягыңны өшетә күрмә!

Шуңа күрә дә, бу егетләр аяк киемнәре өләшкәндә, моңарчы утыз алты-утыз җиденче размерлы чүәк итекләр генә кигән булсалар да, армиядә кырык өч-кырык дүртенче размерларны эләктерәләр. Аның каравы—җаны тыныч. Кат-кат һәм калын итеп аякчу чорнап кигәч, Мәскәү суыклары куркыныч түгел. Бушлатларны да өч-дүрт размерга зурракларны эләктерәләр. Эченнән җылы куфайка белән кияргә. Ул чамасыз зур кирзалар бер заманны чана табаны төсле кәкрәяләр. Җәй көне шуларны дөп-дөп өстерәп, абына-сөртенә йөриләр. Бер-берләренең итәкләренә тагылышып. Бер ялгызың йөрсәң, бу бөтенләй ят-чит илдә кем белә нәрсә буласын? Әллә кемнәр кулына барып эләгүең бар...

Төрмәдә утыручылар алар өчен—коточкыч башкисәрләр, имансыз җинаятьчеләр. Алар белән каберең якын булмасын. Командирлары да шулай өйрәтә. Шунлыктан алар белән аралашмаска тырышалар. Әгәр инде зонада, лагерь биләмәләрендә, ул-бу хәл, шиклерәк нәрсә күрсәләр, автоматтан ут ачарга да күп уйлап тормыйлар. Совет җитәкчелегенә эш йөртү өчен уңайлы, ипле контингент иде алар.

Бер араны Таһирны күңел төшенкелеге басты. Күпме түзәргә, үзеңне корыч рамнарда тотарга була? Ул ишетергә теләгән:«Туктамышев, с вещами на выход!»-ны аңа әле тагын җиде еллар көтәсе. Түзеп булырмы? Әллә чәнчелеп китсенме дөньясы, тотарга да качаргамы? Мөмкинлекләр бар. Иреккә чыкса, хәзер белер иде ул бу дөньяда нишлисен! Әле Алжирдан кайтканда ук, иреккә җибәрсәләр, Франциягә визит алдыннан аларга француз теле укыткан Мәскәү кызлары Лузанна блән Сюзаннаны күреп чыгармын, дип җыенган иде. Таһирның французчасын менә хәзер тыңласалар, исләре китәрие. Бу игезәкләр хәзер дә Патрис Лумумба исемендәге «Халыклар дуслыгы» университетында укыта булырлар. Кирәгебез чыкса, безне шуннан бик җиңел табарга була, дигәннәр иде бит. Алар янына бүген барып чыкса да, танымаган булып кыланмаслар. Андыйлардан түгел иделәр. Аннары Таһирга карата алар аеруча игътибарлы булдылар.

Таһир, шушы уйларыннан арынып, сискәнеп киткәндәй булды. Ул көннәрдән соң күпме сулар акты бит. Аннан соң флотта ярты ел хезмәт итте. Чирәм җирләрдә—«Коммунизмга» совхозында—өч елга якын. Оксана ни хәлдә яши икән? Радмила зур үскәндер инде. Архангельскида, «Озерное» поселогында Володя Шубин белән ике ел ярым урман кистеләр. Ярты ел да, өч ел, ике ел ярым—барысы алты ел буламы? Диңгездә биш еллар чамасы йөзде, бар дөньяны айкап чыкты. Ни омтылып та Марсельгә генә эләгә алмады. Алты ел да плюс биш ел—була унбер ел. Мафия кулында әсирлектә өч ел ярым булды. Барчасы ундүрт ел. Хәзер менә Потьма Политик тоткыннар төрмәсендә биш ел. У-у, унтугыз еллар узган. Үзенә соң аның ничә яшь, кырыкларны тутырып килә түгелме соң? Бу вакыт эчендә Лузанна да, Сюзанна да инде күптән тормышка чыгып, уллар, кызлар үстерәләрдер. Үстерсәләр соң? Алар каршына хәер сорарга бармый. Барса, сагынып, хәл белергә генә барыр. Бу ни хәл соң бу? Таһирда түзә алмастай сагышлы, кискен депрессиянең башлануымы әллә? Аның күңелен, күз көннәрендә туган як урман-кырларына һич ерып чыга алмаслык калын булып төшә торган куе томан төсле, төшенкелек басты. Инде хәзер нишләсе, кычкырсаң, кеше ишетәсе. Кеше ишетеп тә нишли?

Беркемне күрәсе—берни ишетәсе килмичә барагына кайтса, өстәлдә—аңа хат! Менә сөенеч! Габбас Чанышевтан.

«Гражданин Туктамышев, с вещами на выход!»ны ишетергә бүгеннән әзер тор. Безнең эшләр на мази! Санаулы көннәр генә калып бара. Дөресрәге, тагын бер авыр ташны урыныннан кузгатасы гына калды. Лев Моисевич, мировой егет. Аның дус-ише—ярты Мәскәү һәм ул бик зур эшчәнлек алып бара. Синең хакта аталарча кайгыртып ул чаба инде. Энергия дә, акыл-зиһен дә бар үзендә. Таһир, держись! Азат булу белән туп-туры үземә кайтасың. Сиңа, моряк кешегә, бик яхшы эш урыны табып куйдым. Бездә бик зур су саклагыч бар. Шунда моторлы һәм җилкәнле көймәләрнең прокат пунктын ачтылар. Нәкъ синең урын инде. Шушы базаның начальнигы постын сиңа саклыйбыз. Дусларым белән тизрәк котылган көнеңне көтәбез!»—дип язган иде Габбас.

Шундый авыр көннәреңдә мондый хат алгачмы? Берәү булса, күккә сикерер иде. Таһирның да күңеле шундук күтәрелеп китте. Кояш та җиргә сөйкемлерәк карый төсле тоелды. Габбаска мең рәхмәт. «Сиңа эш урыны да таптык. Аны саклап торабыз»,—дигән бит. Әйтерсең, ул берәр атнадан кайтып җитәргә тиеш! Димәк, аның «эше» өстә карала. Шулай булмаса, эш урыны ук табып куймасые.

Шунда Таһирның исенә, кылт итеп, следователь Туктаровның, Франциядән, сине эзләп, хатының белән улың килгән иде, дигән сүзләре төште. Ул чакта ул ничек сөенде! Менә хәзер дә күңеле шатлык белән тулды. Улың да булгач, бирешмәскә, төшенкелектән мөмкин кадәр тизрәк котылырга кирәк. Чөнки бу дөньяда сине сөючеләр, эзләүчеләр бар! Ул үзе соң бәхет түгелмени!?

Нәкъ менә шулай шул. Кайчакны менә сүнәм, менә бетәм, дип торган учакны дөрләтеп җибәрергә бер шырпы, бер очкын җитә. Кеше хисләре дә шулай. Бер җылы сүздән канатлана. «Тагын бер ташны гына кузгатасы, юлдан читкә атасы калды. Шик юк, без аны алып ташларбыз»,—дигән бит Габбас Таһир өчен бик вакытлы килеп җиткән хатында. Ул аны кат-кат укыды. Үзен кая куярга урын тапмый аптырады.

Шушы җылы хаттан соң, күңел тынычлыгы алып, янәдән татлы өметләр дөньясында гизеп, ай ярымнар чамасы узганны Таһир сизмәде дә төсле. Төрмәнең яңа начальнигы подполковник Дмитрий Горбун яңа буын кешеләренә хас эшчән холыклы булып чыкты. Әллә, чынлап торып, үзенең «икенче бөкресен» чыгарырга керешә? Административ бина белән янәшә генә икешәр катлы ике йорт салдырырга тотынды бу. Берсе уналты фатирлы булачак. Офицерлар, прапорщиклар өчен. Икенчесе—спорт залы, бассейны, бильярд бүлмәсе һәм Потьма төрмәсенә эш белән килеп йөргән следовательләр өчен кунакханә. Белмим, бәяләр көн саен күтәрелеп торганда тәвәккәлләп чыга алырмы? Яңа начальник төрмә континенгенты белән дә уртак тел тапты, һәр тоткынга түләүле эш тәкъдим итте. Төзелеш күзгә күренеп үсә. Дүрт «Камаз» тыз да быз йөреп, әле ком, әле измә, әле блоклар ташып тора. Төрмә начальнигы Таһирга прорабльк итеп тору вазыйфаларын тапшырды. Таһир теләп алынды. Төзү бит, сүтү, җимерү түгел!

***

Төш вакыты иде. Төзүчеләр барысы да ашханәдә утыралар. Шулчак администрация бинасы каршына ике иномарка килеп туктады. Төрмә начальнигы үзе дә төзүчеләр белән бергә ашап утыра иде.

—Генподрядчиклар килде бугай...—дип урыныннан торып, фуражкасын киеп, аларны каршы алырга китте.

Ун минутлар да узмагандыр, репродукторда:

—Бывший заключенный по статье «64а» уголовного Кодекса Российской

Федерации Таһир Туктамышев с вещами на выход!—дигән сүзләр яңгырады.

Таһир гына түгел, ашханәдә ашап утыручылар да сискәнеп киттеләр. Күбесенең кулларыннан идәнгә «зың» да «зың» кашыклары коелды... Бу хәбәрнең репродуктордан яңа кабатланганын көттеләр.

—Гражданин Туктамышев, с вещами на выход!—Бер зинданнан котылып, икенчесенә унике елга хөкем ителгән зэкта нинди әйбер булсын? Көзгесе, кырыну, теш чистарту әсбаплары... Таһирның өстендә эш киеме, зәңгәр комбинезон, башында капрон шлем. Ни дип дәшәләр аны? Ялгышып булмагае... Туп-турыдан, проходной аша чыгып, администрация бинасына керде. Ишек төбендә үк аны Лев Моисеевич һәм Габбас каршы алдылар. Алар исә, Таһирны аркасыннан этеп:

—Әйдә, әйдә, дорогой, түргә уз!—дип, читтән килгән кунаклар туктый торган махсус залга алып керделәр. Төрмә начальнигы подполковник Горбун да шушында. Таһир күзләренә ышанмады: каршы яктагы кәнәфидән, унҗиде-унсигез яшьләрендә булыр—коеп куйган Таһир!—Бер егет күтәрелде.

Бөтен йөзенә елмаеп:

—Әти! Шушы сәгать, ниһаять, сукты! Без сине алырга килдек!—дип аны кочып алды.—Шушы мизгелләрне минем ничек көткәнемне белсәң икән!

—Улы-ым!—диде дә, тыны кысылыпмы... Таһир... тынып калды. Күзләре белән Данәгөлне эзләде. Шулчак, өстенә зәңгәрсу җинел җилән, ә башына Кара диңгез хәрби флоты бескозыркасы кигән, урта яшьләрдәге ханымнарның бар матурлыгын, бар гүзәллеген бу минутларда үзенә җыйган бер ханым:

—Таһир! Күз алмам! Бу синме, кадерлем!—дип килеп сыенды аңа.

—Данәгөл!

Аның башында—Таһир истәлеккә биреп калдырган бескозырка! Данәгөл аны шул еллар саклаган.

Таһирны да аңларга кирәк. Шушы кадәр шатлык, шушы кадәр бәхет барысы берьюлы өстенә ишелсен әле! Моны күтәрер өчен нинди нервылар, нинди йөрәк кирәк?

—Галимҗан, улым!—дип, аны шатырдатып кысты да, кочагына Данәгөлне алды.

—Бәгърем! Бер генәм! Сине кулыма алып тирбәтимме, әллә кочагыма алып эретимме? Зинһар, аңлый күрегез, күргәнемә дә, ишеткәнемә дә ышанмыйм, гәрчә икегезнең дә йөрәк җылыгызны тоеп торсам да...

Шул рәвешчә бераз хәл алгач, Лев Моисеевич:

—Таһир, улым, менә ике җиренә печать сугылган бу Таныклык синең бүгеннән азат булуыңны раслый. Югалтма! Күз караң кебек сакла! Кирәге чыгуы бар,—диде. Аннары бераз елмаеп:—Син миңа бераз бурычлы, егетем,—диде.—Шушы Таныклыкны алу өчен миңа Гаагага, «Халыкларның хокукларын яклый торган суд»ка барырга туры килде. Әле дә ярый, картлыкны танымаган, бар җиргә тыгылып йөри торган карт еврей Лева бабагыз бар...—дип күкрәгенә сугып алды.

—Без Сезгә исәнлек-саулык, алда да бәхетле көннәр телибез!—диде Габбас.—Сез булмасагыз, без, надан татарлар, ни генә кыра алыр идек!? Торып-торып исем китә минем сезнең нинди унган-булган, һәркемгә ярдәмчел кеше булуыгызга. Таһир, беләсеңме? Гаага судының сине азат итәргә дигән карарын алгач, Данәгөл белән Жанны да Франциядән чакыртты бит.

—Жан түгел, минем тулы исемем Галимҗан!—диде Таһирның улы.-

Россия җирләренә минем инде өченче тапкыр аяк басуым. Менә шушы үзен күрмичә дә өзелеп яраткан әтиемне эзләп! Туган сәгатемнән яратам мин сине!

Галимҗан шунда кинәттән генә әтисенең беләк мускулларын капшады. Аннары күлмәк җинен күтәреп үзенекен карады.

—Минем мускулларга синеке дәрәҗәсенә җитәргә күп кирәк әле. Гәрчә, каноэда йөзү буенча Марсель чемпионы булсам да!—диде.

—Анысын гына улым, житкерербез!—диде әтисе.

—Бу яклар килгән саен миңа күбрәк ошый. Алай да, әти, башта Марсельгә кайтыйк. Анда безне дәү әтием Шөһрәт бабабыз һәм дәү әнием Фәйрүзә әби көтә калдылар. Ә мин—Сорбонна университеты Халыкара мөнәсәбәтләр факультеты студенты. Деканыбыз дәресләрне күп калдыручыларны өнәми. Исемлектән сызу ягында гына.

—Мәскәүгә кайтып, кайчандыр үзем директоры булган «Прага ресторанында бу бәхетле очрашуны тантаналы билгеләп үткәрмичә, мин сезне беркая да җибәрмим,—диде Лев Моисеевич.—Үзем чакырып китердем, үзем озатырмын да! Ә «Прага»да мине һаман да ихтирам итәләр. Өстәлләрне төрек солтаннары көнләшерлек итеп әзерлиләр. Җәмәгать, менә нәрсә! Мин кешеләрне бер генә сыныйм. Таһир кебек олы җанлы, йомшак күнелле, булган, уңган егеткә ярдәм итүем белән чиксез шатланам. Шул шатлыгымны бер кич минем белән бер өстәл артында уртаклашуыгызны үтенәм.

—Ул чакта шулай итик, Мәскәүгә, «Прага» ресторанына кайтыйк!—диде Галимҗан.—Әнием син каршы түгелдер бит?

—Янымда әтиең булганда, мин вулкан кратерына сикерергә дә әзер! Тик безне аермасыннар гына. Таһир, сине өзелеп-өзелеп сагынуымны белсәң икән! Өченче килүебез бит. Дөньялыкта күрешәчәгебезгә мин инде өметемне өзә башлаган да идем...

Таһир, бераздан зиһенен җыеп:

—Матурым, мин бу залны үзебезнең «Сергей Киров» крейсерындагы капитан Соболь каютасына охшатам. Хәтерлисеңме, ул чакта да син каюта тирәсендәрәк утырып тордың. Башта Ногайбәк ага белән таныштык. Аннары синең белән күрештек. Бер күрүдә күнелемә кергән идең, ошаткан идем үзеңне...—диде.

—Нинди изге кешеләр—Лев Моисеевич, Габбас Чанышев ярдәме белән, күпме еллардан соң кавыштык!—дип куәтләде аны Данәгөл. Аннары борылып:—Зинһар минем тарафтан әдәпсезлек саный күрмәгез. Мин никахлы ирем белән озак еллар күрешмәдем...—диде.

Лев Моисеевич барысын да үзенә каратып:

—Французларда борынгыдан килгән матур традиция бар. Мондый чакны алар стрессны бер сүз белән җиңәләр. Алар: «Ачы! Ачы!»—диләр. Мин хуплыйм бу традицияне: «Ачы! Ачы!»—диде.

—Очрашу, күрешү, сезне кавыштыру шатлыгыннан без бу турыда онытып та җибәрә язганбыз бит, әнием!—диде Галимҗан.

Беренче булып, калын тавышы белән:

—Ачы! Ачы!—диде.

Данәгөл Таһирны ике кулы белән кочып алып, аның иреннәренә сузылды. Бу бәхетле кич эчендә алар әлеге татлы, тылсымлы сүзне күп кабатладылар әле. Таһир аны кочагыннан чыгармады. Чыгарсам, тагын югалтмагаем, дигән шик белән...



Илдус
Фазлетдинов

# ТӨНГЕ КҮКТӘН БАГА... АТ КҮЗЛӘРЕ

***

**Язмыш белән язу бер тамырдан—**
**Кайчак бер сүз елга тормалы...**
**Язуым да язмыш кебек шуңа**
**Әле киртләч, әле бормалы.**

**Язуымда хата күп түгелдер,**
**Язмышымда шактый хаталар.**
**Барыр юлны бикләп, ташлар кебек**
**Тәгәрәшеп алар яталар.**

**Язудагы хата кебек түгел,**
**Үлчәнмиләр алар сан белән.**
**Үлчәнәләр тик каләмнән саркып,**
**Шигырьләргә күчкән кан белән.**

**Ә шулай да үзгәртәсе килми**
**Күкләр язган шушы язмышны—**
**Һәрбер хатам туганымдай газиз,**
**Балам кебек һәрбер ялгышым.**

**Язмыш белән язу бер тамырдан...**

## Кылган моңы

**Мин—бер кылган...**
**Җанда дала моңы—**
**Чал гасырлар бирә тавышын.**
**Алпамшалар анда иген игә,**
**Ярсу атлар үтә чабышып.**

Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ (1975)—*шагыйрь, галим; «Соңгы шүрәле» исемле китап авторы. Уфада яши.*

Мин—бер кылган...
Багам чиксез Күккә—
Ашкыналар болыт-җайдаклар.
Төрки каһан, гүя, гаскәр әйди,
Юртак каны чыга кайнаплар.

Бу вакытлар, белмим, кайда калган?
Төрки даны кая югалган?
Халкым рухын нинди чоңгыл йоткан?
Алпамшалар кая юл алган?

Мин—бер кылган...
Үткәннәрдә яшим.
Зарым сөйлим, җанны актарып.
Күз яшьләре кебек чык тамчысы,
Сагышлардан күңел сап-сары.

Мин—бер кылган...
Инде мең ел торам—
Чал Тарихның телсез шаһиты.
Оранымны Аждаһалар йотты—
Төркиләрнең телсез вакыты.

Мин—бер кылган...
Җанны кайгы сарган,
Күзләремә яшьләр төелгән.
Халкым мескенлеген күрмәс өчен,
Горур башым аска иелгән.

Мин—бер кылган...
Гасырлардан калган
Күңелемдә күпме байлык бар!
...Җанны таптап, өсләремнән бүген
Көтү-көтү үтә сарыклар.

Мин—бер кылган...

## Хәбәрсез югалганнар

Хәбәрсез югала кеше—
Бала, хатын, ирләр дә.
Ирләр генә түгел, хәтта
Югалалар илләр дә.

Болгар, Алтын Урда кайда?
Кемнәрдә һуннар каны?
Гамьсезлеккә чыдый алмый,
Югала халкым җаны.
Хәбәрсез югала милләт,
Җыр-моңнары югала.
Үзен аңлар күңел эзләп,
Чал тарихка юл ала.

Континентлар юкка чыга...
(Санасаң, юктыр саны!)
Инде ничә гасыр Кеше
Эзли Атлантиданы.

Хәбәрсез яналар еллар
Мәңгелек учагында.
Хәбәрсез киселә юллар
Карурман кочагында.

Сөю югала хәбәрсез—
Күңелдән китә очып.
Парсыз очкан сөю кошын
Бүтәннәр ала кочып.

Күк-тәрәз аша сикереп,
Юкка чыга йолдызлар.
...Йолдыз арасында күпме
Минем кебек ялгызлар...

Дөньялыкта югалсам да,
Беләм, эзләп табарсыз.
...Шигърияттә булмасамчы
Югалучы хәбәрсез...

## Атлар

Авылымда атлар юкка чыкты—
Кар туздырып узмый чаналар.
Тимер «ат»лар тимер җыр үкереп,
Асфальт юлдан тыз-быз чабалар.

Ат җаннары күптән Күккә ашкан,
Дага төшеп калган Ай булып...
...Атлар көткән тугайлыкны эзләп,
Бер ялгызым йөрим каңгырып.

Авылымның чирәмнәре кайда?
Эз калдырган кайда чаналар?

...Ташка сеңгән тояк тавышлары
Йөрәгемне килеп кагалар...

Бу тавышта уклар сызгыруы,
Бу тавышта кылыч чыңлавы,
Бу тавышта чал кылганнар моңы—
Бу тавышны рәхәт тыңлавы...

...Далаларны сары сагыш сарган:
Атлар күрми кибә далалар.
...Төнге Күктән гүя йолдыз түгел,
Ат күзләре миңа багалар...

## Аклык

Ак биләүдә килдем бу дөньяга:
Ак нурларын Кояш юллады,
Ак теләкләр теләп, иркәләде
Әниемнең ап-ак куллары.

Балачагым ак шикәрдәй эреде,
Татытмады кара борычын.
Яшьлегемнең ак таңнары атты,
Тормыш куйды яңа бурычын...

Ак калага озатканда әни
Ак ипекәй бирде кулыма.
Ак яулыгы белән яшен сөртеп,
Ак юл теләп калды улына.

Ак күгәрчен кебек хыялларым
Йолдызларга мине илттеләр.
Ак сөюем язган ак шигырьне
Ак кәгазьгә теркәп киттеләр.

Күңел һаман да ак...
Уйларым да...
Бүтән төскә миндә урын юк.
Ап-ак күңелләрне каралтырлык
Сүзләремдә минем корым юк.

Киләчәк—ак томан...
Ә артымда
Дөрләп яна еллар учагы.
...Кара җиргә тапшырыйм дип, көтеп
Ак кәфенлек ачкан кочагын...



Булат
Ибраһим

# ӨЙ АРТЫНА... ЯҢА ЗАМАН КИЛГӘН

***

Яшьтәш,
Иртәгәгә кабат яңгыр диделәр,
Кабат җилле, кабат давыл ди.
Бүген менә дөнья рәхәт булса,
Иртәгәгә кабат авыр ди.

Яшьтәш,
Бүлмәдәге соңгы икмәкне дә
Яшердем мин, ул тәмлерәк булыр.
Күз яшендә җебетербез аны?
Бераз гына күңеллерәк булыр,
Бераз гына җиңелрәк булыр.

Яшьтәш,
Ишек өстендәге шәмаилне
Мин түргәрәк кертеп элеп куйдым.
Шайтан керсә үзем каршы алам,
Коръән тотып антны биреп куйдым.

Ә син намазлыктан торма, яшьтәш,
Аллаһыдан үтенеп ярдәм сора...
Өй артына яңа заман килгән,
Яман җилләр бусагада тора...

## Кулларыңны күкләргә күтәр

Һәр югалган көннең матурлыгын
Биләүләргә төреп тибрәткәндә,
Бирәчәккә алынган бәхетең
Китәм-китмим диеп тибрәлгәндә.

Әллә каян күкрәү арасыннан
Фәрештәләр тав(ы)шы сузылгач,
Һәм томанлы көннең һавасыннан
Аңны җуеп, тының буылгач,

Булат ИБРАҺИМ (1990) – *яшь шагыйрь; КДФУ студенты. Казанда яши.*

**Колларыңны күкләргә күтәр дә**
**Ярлыка, дип сора Ходайдан:**
**Зинһар өчен мине гафу ит Син,**
**Туры юлга басам бу айдан.**

**Туры юлга басам бу айдан мин...**
**Һәм ярдәмен сора Аңардан,**
**Ә тетенгә баткан заманада**
**Караңгы таң ата яңадан.**

**Караңгы таң ата калтыранып,**
**Мәче кебек ялт-йолт каранып,**
**Һәм кирәкми: әнкәй белән, диеп,**
**Икмәк тотып, юкка каргану,**
**Гөнаһ салып, болай да гөнаһлы**
**Бу Җир шарын төреп карага...**
**Колларыңны күкләргә күтәр дә,**
**Сәҗдәгә төш, зинһар, Аңарга.**

***

**Бу ялгызлык түгел,**
**Бу хисләрнең җаннан китеп**
**Далаларга сибелгән чагы.**
**Күңеле тулган чакта,**
**Сулагандыр шагыйрь балачагы.**

**Сәер халәт...**
**Җиргә ятып күз яшьләрен**
**Коткарасы иде бу күзләрдән.**
**Җитми калган язгы халәт матурлыгын**
**Кайтарасы иде сөрген-көзләрдән.**

**Туйдырды бу түшәмле күк,**
**Һаман су үткәрә,**
**Тамчы күңелләрне юешләтте.**
**Әҗәткә алынган иртәгәләр,**
**Чынбарлыкны ватты, бүгенне үзгәртте.**

**Җир астында яткан, үлмәс күзәнәктән**
**Ахырзаман үсә, тамыр җибәргән.**
**Бакчадагы ауган алмагачны**
**Яшен суккан,**
**Мин күрмәдем аны,**
**Җил күргән дә сөйләгән.**

**Түшәмнәргә сыланган күкләрдән,**
**Болытлар агыла, киеп кара күлмәкләрен.**
**Берәр якын кешеләре үлгән ахры,**
**Җирдән күрәм өзгәләнгән йөрәкләрен.**

**Сәер халәт,**
**Бу ялгызлык түгел,**
**Бу—каргалган көннәр язмышы.**
**Сәер халәт,**
**Бу—каралган җанның**
**Чираттагы моңсу сагышы...**

## «Ахырзаман»

Көнбатыштан кояш чыгып килә,
Ахырзаман?
Бу заманның ахры?
Юл читендә калган ятим
Елый акрып.
Заман хәзер шундый тупас, ахры.
Егылган ир кылычына сузылырга
Уңай вакыт эзли.
Җирне ертып, ватып,
Җәсәденә кергән җаннар
Күктән яктылыгын эзли.
Күктән.
Ахырзаман.
Исрафил хан
Сур өрәме Каф тавыннан?
Ә вәзире—Җәбраиле,
Соңгы тамчы ышанычка
Корьән төреп,
Күккә менеп бара...

Җәннәт белән Тәмугъ арасында
Вәхшәт бара.
Вәхшәт,
Мәхшәр бара.
Газазил ут яга,
Шәһәр ватыклары
Кабер ташы кебек
Салкын...
Ләкин якын...
Салкын, салкын, салкын.
Җир ананы үзен
Баскан ялкын,
Ләкин салкын...
Күктән кара болыт
Җан авазы белән:
—Качыгыз бу җирдән,
Яшен яңгыр белән кочаклашып,
Чистартырга килә Җир анаы
Яман чирдән...

## Телсез заман

Курка-курка бүген ике телсез
Куллар болгый-болгый дөньясына,
Каһәр төшкән диләр әллә шунда,
Әллә инде тәгәрәгән шунда дөньясы да.

Калтыранып кына җилне коча күптән,
Зинданнарда атмый калган таңнар.
Ярсып-ярсып канаган күңелне,
Белмим инде хәзер кемнәр аңлар.

Кайтаваз да хәзер өзек-өзек,
Сызык-сызык булып сибелә.
Телсез заман яңа дәүләт төзи,
Миңа никтер шулай сизелә.

Телсез заман яңа дәүләт төзи,
Диварларны ватып-җимереп.
Үз яманын ямаулыкка төреп,
Манарадан аска төкереп,

Телсез заман яңа дәүләт төзи
Артык теллеләрен үтереп.
Әнә анда минем яшьти ауный,
Караңгыдан туеп, исереп.

Алар анда яңа дәүләт төзи,
Яңа кояш элеп буш күккә.
Без үзебез акылдан шашканнар,
Һәм шашканнар никтер бик күпкә.

Нинди дәва язар безгә язлар,
Бу ясалма чирдән ни бирер.
Ике телсез куллар болгый-болгый
Үз эшләрен эзләп йөгерер.
Йөгерер дә алар сикерерләр,
Диңгез диеп чиксез упкынга...
Телсез дөнья илсез дәүләт төзи,
Кәгазь дәүләт—яңа буынга.



Рахман Шәфигуллин

# ТАУИЛЕ ГАРАСАТЫ

КЫЙССА

Боргаланып аккан бәләкәй генә инеш буендагы Тауиленә еш кайтып йөрибез. Монда минем хатынымның туганнары көн күрә. Бик кунакчыл һәм эчкерсез алар. Кайтып җитү белән, кырык эшләрен кырык якка ташлап, хәл белергә килеп тә җитәләр. Беренче булып җингинең дәдәйләре керә. Ул аларны укымышлы итеп күрсәтергә тели. Авылдашлары аларны Питер, Фидер, Паул дип йөртсәләр дә, 4-5 класслы өч бертуган абыйларын Петр Иванович, Федор Иванович, Павел Иванович дип культуралаштырып әйтә. Дөнья хәлләре турында бераз гәпләшкәч, өстәл янындагы әңгәмә җирле яссылыкка күчә. Кем үлгән, мал-туарлар, печән, пенсия һәм башкалар. Беренче партия кунаклар озатылгач, нәселнең иң абруйлы кешесе—Бөрчә Микулае, ягъни минем хатынның дәдәсе килә. Гомер буе мал карап, Сандра җинги белән 5 бала тәрбияләп кеше иткән туганнар алар безнең. Икесе дә берәр чәркә аракыдан баш тартмасалар да, артыгын өмет итмиләр. Кичкә яки иртәгәгә кунакка чакыралар. Йорт-куралары нык, абзар тулы мал. Җиләк-җимеш, яшелчәләре дә бик мул булып үсә аларның. Дәдәй эшчән, күндәм булса, Сандра җинги бик үткен һәм уңган хатын. Сөйләгәндә тартынып-нитеп тормый, ничек уйлый—фикерен шулай җиткерә. Тозлап-борычлап сүгәргә дә күп сорамый. Әйтик, бүген тагын бирәненне тыктыңмы, аша, эч, авызыңа аркылы килмәс. Күнеле күтәрелеп китсә, частушкага да ерак калмый. Азактан: «Чубарина баба, зад есть, груди есть, что тебе надо!»—дип бәйрәмне йомгаклап та куя.

Ике-өч сәгать узгач, калын тавышлы Владимир җизни килеп җитә. Ул әбинең сеңлесенең ире. Тормышта күп кыйналган. Сугыш ветераны. Пленда булган. Тауиленә Америкалар аша 1947 елны гына кайта. Хәбәрсез югалган дигән язу алгач, хатыны Үренә пурмы өчен ике ай көтә дә, Түбән авыл фронтовигына тормышка чыга. Владимир да иясез калмый, билгеле. Фрося түтигә өйләнә. Бер кызлары туа. Валя татар егете Роберт белән тормыш көтәләр. Үрнәк гаилә. Владимир кызы белән дә, кияве белән дә нык горурлана. Ике сүзнең берендә: безнекеләр болай эшләгән, безнекеләр матур яши һәм башкалар, һәм башкалар...

Владимир җизни бик гадел һәм акыллы зат. Хәтта чебенне дә рәнҗетмәс.

---

Рахман ШӘФИГУЛЛИН (1949)—*журналист, публицист; әсәрләре республика матбугатында даими басыла. Чаллыда яши.*

—Кияү, тормышлар ничек? Эшләр барамы?—дип сүзне башлый ул. Букәнгә утыра да янчыктан тәмәкесен алып төрә, ашыкмыйча ут тергезеп, бер-ике мәртәбә суырып ала. Тирә-якка тәмле ис тарала.

—Мин хәтта негрларның сигараларын да тарттым. Тик туган авылдагы тәмәкемне үз итәм. Суырган саен кан тамырлары киңәйгәндәй була, миләр эшли башлый.

Туган кеше булгач, өстәл көйләнә. Алмагач төбенә вак-төяк кабымлыклар килә, күчтәнәчкә алып кайткан аракы чыгарыла... Гомер буе мәктәптә немец теле һәм тарих укыткан Владимир җизни һәр очрашуда үзе ишеткәнне, күргәнне сөйли. Тулаем алганда, аның сүзләреннән чыгып, мин инде авыл, анда яшәүчеләр, аның пленда вакыты, немецларның тормышы хакында азмы-күпме беләм. Ә менә аларның фамилияләре ни өчен Аппаков, кушаматлары Шәкерт? Әле монда барып җиткән юк иде. Әңгәмәгә үзем үк юнәлеш бирәм.

—Фамилияң татарча, өстәвенә, Шәкерт кушаматлы. Кайдан килгән ул сезгә?

—Кайдан? Кайдан? Кияү, беләсең килсә, аның үз тарихы бар... Әйдә, сал әле чәркәне тутырып, сал әле...

Иван Грозный гаскәрләре безнең якка Казанны алуга килеп җиткәннәр. Чукынган татар исән калган, теләмәгәннәре качып котылган. Янбирде авылына килеп җитә болар. Шул чакта хәбәр китерәләр: Мамадыш ягында урыс гаскәрләренә һөҗүм булган, хәзер патшага каршы төшкән татарларны акылга утыртырга кирәк. Отряд җыела да Мамадышка китеп бара. Чукындырылган авыллар янәшәсендә Янбирде белән Алмалы гына мөселман динендә кала. Илбасарлар тегендә барып җитә алмый, Үри Чаллысы тирәсендә татарлар һөҗүм итеп, аларын да үтереп бетерә. Тирә-якта очсыз-кырыйсыз урманнар, сазлык, күлләр татарны саклап кала. Мәскәү, татар милләтен аеру максатында, керәшеннәргә кием-салымнарын үзгәртергә ярдәм итә. Олы көн, тагын әллә нинди христиан бәйрәмнәре кертә. Салымнарны киметүгә карамастан, керәшене дә, икеләтә изелүгә дучар булган татары да ярлы яши. Ләкин диннәр бер—ата-ана баласын аера алмый. Исемнәре аеры булса да, алар элеккечә дустанә яши бирә. Власть яки башка максатларда динен алыштырган керәшен барыбер телен югалтмаган. Урыс йөзәрләгән мең татарны кырса да, халык иманын сатмый. Тырышлыгы, акылы, фидакарьлеге белән яши бирә. Мәскәү яулап алынган халыкны бетерә алмаячагына төшенә. Шуннан соң 200 еллык тынлык урнаша. Петр I тәхеткә килгәч, Россия чит җирләрне яулап ала, халыкларны кыра. Иноверецларга каршы сәясәт тагын да көчәя. Татарлар күпләп Санкт-Петербургка иң авыр эшләргә озатыла. Кораб төзү өчен йөзьеллык имәннәр кисү дә алар җилкәсенә төшә.

Петр I үлгәннән соң да (1725 ел) татарны юк итү планлы рәвештә дәвам итә. Көч җитмәслек салымнар билгеләнә. Егетләрне 25 еллык солдат хезмәтенә җибәрәләр. Чукынсаң, син болардан азат ителәсең. Минем ерак бабам Аппакның биш кызы, бер улы була. Күршедә генә Солтан исемле кешенең—биш малае. Солтан да, Аппак та улларын укымышлы итәргә омтыла. Алар мәдрәсәдә шәкерт булырлык белем ала. Мамадышта 1-2 ел русча да укыйлар. Егетләргә армия хезмәтенә барыр вакыт җитә. Аппак бердәнбер улы Зөбәерне югалтасы килми—динен алыштырырга була. Бер селтәүдә Аппак—Александрга, Зөбәер—Захарга, Зөләйха—Зояга, Нәфисә Агрофенага әйләнә дә куя. Авылда тагын берничә гаилә керәшенгә әйләнә. Соңрак аларны Тауиленә күчерәләр...

Владимир җизни тагын бер чәркәне салып куя да, тәмәкесен суыра-суыра, башлаган сүзен дәвам итә.

Фамилиясен саклап, Аппаков булып калган Зөбәер-Захарга Шәкерт кушаматы тагылып кала. Менә безнең тарих шундыйрак.

...Захар яна керәшен кызына өйләнә. Зоя, Агрофена, Анастасияне рус егетләренә көчләп кияүгә бирәләр. 14-15 яшьлек Галина белән Аннаны да киләчәктә шундый язмыш көтә. Солтан балалары исә башкачарак юл сайлый. Ата кеше биш малаеның берсе Дәүләтьярны элеккеге күршесе Зөбәер-Захар урынына 25 еллык гаскәри хезмәткә озата. Иң матуры, иң батыры һәм уку буенча тиңе булмаган Сабиры исә барлык Урмановлар өчен армиягә китә. Солтан картның фикере болайрак була: «Талантлы кеше беркайда да югалмас, үз урынын табар»,—ди ул.

Дәүләтьяр флотта хезмәт итә. Бик күп батырлыклар күрсәтә. Яралана. Махсус пособие һәм җир бирелеп, отставкага чыга. Сабирга да бәхет елмая. Ул 29 яшьлек подполковник Михаил Кутузов командалыгындагы батальонга эләгә. Үзенең канында татарлыгы булган командир Сабирны ярдәмче итеп ала. Бу денщик түгел, ә ярдәмче! Сабир рус-төрек сугышында Кутузовның уң кулына әйләнә. Русчаны яхшы белә, буй-сыны коеп куйган, төрекчәне аңлый. Өстәвенә, гаярь егет тә була. 5 еллык солдат шулпасы эчкән Сабир 1774нең җәендә Кырымда үзенең чын батыр икәнен күрсәтә.

Кырымның төньягында русларның өстенлегенә табигый шартлар ярдәм итә. Кая карама, тигез дала. Дошманның ничек урнашуы уч төбендәгедәй күренә: ат та ат. Ә менә көньяктарак хәлләр нык үзгәрә. Төрекләр, кырым татарлары булышлыгы белән, тау араларында үзләрен иркен тота. Теләсә кайдан чыгып, көтмәгәндә һөҗүм итәләр. Фәкать зур югалтулар бәрабәренә генә руслар алга баруларын дәвам итә. Бөеклек чиренә бирелгән руслар хәрбиләрне генә түгел, җирле татар халкын да кызганмый. Карт-корымы, бала-чагамы, син барыбер дошман, ә дошманны фәкать юк итәргә генә кирәк! Руслар шулай эшли дә. Сабирның моңа йөрәге телгәләнә. Ни әйтсәң дә, без бит бер каннан яратылган. Ләкин рус гаскәре ягында булып, кырымлыларга ничек ярдәм итәргә соң?

Кырым ханлыгы башкаласы Бахчасарайга җиткәндә, Сабир хезмәт иткән полк чолганышта кала. Төп частьләр белән элемтә өзелә. Төрекләр һәм кырым татарлары тау башыннан, саклану чарасыннан мәхрүм ителгән рус гаскәрләрен кыра. Сабир Кутузовка мөрәҗәгать итеп, үзен илче итеп җибәрергә һәм атышны туктатырга кирәклеген әйтә. Командир моның файдасы булачагына ышанмаса да, вакытны отып булыр, бәлки ярдәм килеп өлгерер дип фикер йөртә.

Атыш бер мәлгә туктагач, Сабир, ике офицер белән ак флаг күтәреп, төрекләр ягына атлый.

Кырмыскадай мәш килгән төрекләр илчеләрне нәфрәт белән каршы ала. Күзләре янып торган, бөркет борынлы төрек полковнигы тылмач аркылы кичекмәстән русларга бирелергә куша. «Каршылык күрсәтү—ул җүләрлек»,—ди.

Сабир, сүз алып, үзенең татар булуын әйтә. Ышанычлырак булсын өчен Фатыйха сүрәсен дә укып күрсәтә. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим...

Төрек полковнигы Сабирга үзләре ягына күчәргә тәкъдим итә. Кире җавап алгач:

—«Без барыбер кяферләрне юк итәчәкбез. Исән вакытта йә биреләсез, йә үләчәксез,—дип сүзен тәмамлый.

Сабир кабат телгә килеп:

—Сугышның язмышы хәл ителгән инде. Руслар Кырымны алачак. Ә сез качып киткәннән соң кяферлар бер гөнаһсыз татар халкын кырачак, авылларны яндырачак. Аларның исән-сау калуларын теләсәгез, сез бәрелешне туктатырга тиеш,—ди.

—Каян килгән мондый акыл иясе? Алай булгач, ник Казаныгызны

русларга саттыгыз?

—Без сатылсак, йөзәрләгән мең корбан бирмәгән булыр идек. Нигә Кырым, нигә төрекләр ярдәм итмәде? Сез безне саттыгыз да инде...

Монысын ук көтмәгән полковник аптыраштa кала. Чыннан да, руслар көчле. Әлеге фаҗига өчен Кырым халкы кан коячак түгелме?

Төрекләр 10-15 минут кинәшкәннән соң, кичкә кадәр ике якка да атышудан тыелып торырга тәкъдим итәләр. Шулай итеп, Сабирның тапкырлыгы русларны кырылып бетүдән саклап кала. Төнлә полк, яралыларны алып, чолганыштан исән-имин чыгып китә.

Бер айдан соң Кара диңгез буендагы Алушта шәһәре өчен барган сугышта Сабир командирын үлемнән саклап кала. Дошман пулясы үзен дә ялый, ә Михаил Кутузов күзен югалта. «Әгәр Сабир булмаса, гомереӊ киселгән булыр иде»,—диләр врачлар.

—Сабир, сиңа ни кирәк?—ди Кутузов.

—Ваше высокоблагородие, миңа сезнең рәхмәт сүзегез дә бик житкән. Бер үтенечем бар, тизрәк терелегез... Әгәр, мөмкин булса, дәваланырга туган якка җибәрсәгез иде...

—Ярар,—ди Кутузов. Сиңа унтер-офицер званиесе бирергә ходатайство яздым, хәзергә Георгий кресты белән бүләкләп торам, командованиега 6 айлык ялны туган җиреңдә үткәрергә рөхсәт сорап та рапорт юлладым. Акчасын бирерләр. Терелү белән хезмәткә килерсен.

Китүенә биш ел дигәндә, инәдән җебенә кадәр киенгән унтер-офицер Сабир Урманов бүләкләр тәяп туган авылына кайта.

Русларга да тәтемәгән мондый дәрәҗә чиновникларны битараф калдырмый, билгеле. Унтер-офицер дәрәҗәсен һәм Георгий крестын бит теләсә кемгә бирмиләр. Моңа фәкать сирәкләр генә лаек була. Әнә шуңа моңарчы җәберләнеп килгән татарлар күнелендә очкын кабына. Сабирны күрергә тирә-юнь авыллардан да халык килә. Туган-тумачасы барын-югын җыйнаштырып кунак итә.

...Владимир җизни әкренләп кенә тәмәкедән фильтрлы сигаретка күчә. Дәрәҗәсен белеп, чәркә артыннан чәркә күтәреп, кыйссасын дәвам итә.

Көннәрдән бер көнне әфисәрне күрергә дип элекке күршеләре Аппак-Сандр малае Зөбәер-Захар (кушаматы Шәкерт) төшәләр. Күренеп тора, икесе дә бушап калган, күзләрендә нур сүнгән. Татары сатлык дип, урысы басурман дип мәсхәрә итә. Иң аянычы, Галия-Галинаны урыска кияүгә чыкмаганы өчен Никифоровка хатын-кызлар монастырена алып киткәннәр.

—Мин мөселман, минем исемем Галия,—дия-дия елады кызым. Түзәрлегем калмады. Болай булса, үз-үземә кул салам!—ди Сандр-Аппак бабай, гарәп хәрефләре белән язылган хатны Сабирга биреп. Зөбәерне солдат хезмәтеннән саклыйсы калмаган икән... Ялгыштым, Солтан, ялгыштым. Хәзер Галияне коткарасы иде. Ни кылырга? Башым эшләми...

Гозер белән килгән кунакларны озаткач, Солтан Сабирына кинәш бирә:

—Улым, синнән калмасын, бар монастырь нәчәлнигенә. Галия минем туганым, аның белән сөйләшергә рөхсәт бирегез, диген.

Иртәгәсен, кучтәнәчләр алып, Сабир Никифоровкага китә. Аңлата кемлеген монастырь настоятеленә. Алтын-көмеш күргәч, фәрештәләрнең дә күзләре ялтырый дигәндәй, 45 яшьләр чамасындагы анакай Галина белән күрешергә рөхсәт бирә. Аларның сөйләшүләрен монастырьдагылар күзәтеп, тыңлап тора.

Патша хезмәтенә киткәндә яшүсмер булган кыз бала, әкияттәге гүзәл кызга әйләнгән. Сабирны күргәч:

—Абый, мине моннан ал, зинһар,—дип әйтә дә аңын югалтып егыла.

—Хәзер үк Мамадышка! Земский врачка алып барырга кирәк,—ди унтер-офицер кырт кисеп. Монастырьдагылар ни эшләсен, буйсыналар, биреп җибәрәләр Галияне Сабирга.

Аягы яраланган отставкадагы хәрби врач авыруны карый да:

—Нервысы какшаган, аңа фәкать ял кирәк,—ди.

Галиягә бер күрүдә гашыйк булган Сабир көн саен монастырь тоткыны янына бара. Атка утыртып, табигатькә алып чыга. Ике арадагы аралашу яратышу, мәхәббәткә әйләнә. Бер айдан соң уездный урядник белән монастырь рухание Галияне кабат Никифоровкага алып китәләр. Моңарчы мулла никах укып, аларны ир белән хатын итеп игълан иткән була. Документлар алу мәсьәләсен хәл итәргә вакыт җитми.

—Конфликт сиңа кирәк түгел, аек акыл белән фикерләшик,—ди земский врач Станислав Жигульский. Руслардан без, поляклар да, зур зыян күрдек. Монда хәйлә, дипломатия кирәк. Аннан соң, синең карьерага да зыян килүе мөмкин.

Көн артыннан көн уза. Галиянең карынындагы бала үсә тора. Бер заман монастырьда Галиянең гөнаһы фаш ителә. Җәзасын, чишендереп 30 мәртәбә тал чыбыгы белән сугуны, билгелиләр.

Сөйгәнен ничек саклап калырга? Сабир шул хакта баш вата һәм тапкыр Станислав Жигульский белән җаен да табалар. Хөкем карарын гамәлгә ашырасы төндә, Галиянең тәненә дини образлардан сурәтләр ясарга булалар...

Билгеләнгән көнне монастырьга тирә-як авыллардан керәшеннәр, урыслар җыела. Менә ике яктан кулларыннан тотып гөнаһлы Галияне алып чыгалар. Җиде кат йозакка бикләнгән тоткын җәза урынына китерелә. Яшелле-зәңгәрле тавыш белән атакай сирәк сакалларын селки-селки: «Галина, новокрещенная татарка, приняв христианство изменила канонам святой религии. Встала на путь предательства. Обратного хода нет и не будет. Отрекись от своих злых намерений, отрекись. Вернись на путь истинный»,—ди. Уңай җавап алынмагач, зәһәрлегеннән чыдый алмаган рухани Галиянең өстендәге киемен салдыра. Анадан тума калган йөкле хатынны күреп, халык гаҗәпкә кала. Бары да: «Фәрештә килгән, фәрештә!»—дия-дия тезләнеп чукынырга керешә. Галиянең тәненә Иисус Христос, Мәрьям ана рәсемнәре зур осталык белән ясалган була. Галия шул килеш җәза урыныннан бер тоткарлыксыз Сабир белән сөйләшкән урынга килә...

—Владимир жизни, син әкияттәге вакыйгаларны сөйлисең бугай. Чыннан да, булган хәлме соң бу?

—Фронтовикны не обижай, кияү. Ышанмасаң, икмәк белән, туган җир белән ант итәм.

—Азагы ни белән бетте соң?

—Әйткәнемчә, без Аппаков булып калдык, кушаматыбыз—Шәкерт. Сабирга килгәндә, Галиясен алып китә ул хезмәт урынына. Кутузовка барын да сөйләп бирә. Бер күзен кара ситсы тасма белән япкан булачак полководец Сабирның тапкырлыгына шаккатып тора да, аңа Санкт-Петербургка укырга барырга тәкъдим итә. Әйтүләренчә, Сабир Урманов генерал дәрәҗәсенә ирешеп, 1812 елда татар-башкорт кавалериясе белән Парижны алуда катнашкан.

Милләтнең горур балалары буларак, риваять булып халык күңеленә кереп калалар Сабир белән Галия. Алар үрнәгендә яңадан-яңа буын тәрбияләнә.

...Шәкертләр нәселенең дәвамчысы Владимир жизни, аягүрә басып, әби-бабалар хөрмәтенә бер чәркәне йотып куя, ә мин эчемнән белгән догаларымны укып: «Татар милләте нык сыегайды... Ичмасам, бер генә Сабир Урмановны бирсәнә, Ходаем»,—дип ялварам.

# ЮАШ МИРЗАХАН

ХИКӘЯ

Мирзахан туып-үскән авыл Утткуз дип атала. Сөн буенда урнашкан гадәти авылга нәмәгә шундый исем биргәннәр, аны Мирзахан да, шайтан да белми. Хәтта кешеләрендә дә берни аерма юк. Барысы да эшчән, үткен, жырга-монга әвәс. Тик менә Мирзаханны гына Ходай кимсеткән: бик юаш ул. Гомергә кешегә начар сүз әйтмәде, беркемне рәнжетмәде. Урта мәктәпне тәмамлагач, ДТ-75 тракторына утырды. Яшьтәшләре кызлар озатып, таннарын чишмә буйларында каршылаганда, трактор кабинасында йоклады. Солярка исе, мотор гөрелдәве аның өчен иң татлы ләззәт иде.

Армиядән бераз үзгәреп, шомарып кайтырмы дисәләр, кайтты да кабат тракторга утырды, холкы үзгәрмәде. Юаш кешегә үткен хатын менә дигән инде дип, сары чәчле, зәңгәр күзле, зәһәр телле Сажидәгә димләп өйләндерделәр үзен. Яшь хатын тегеләй итте, болай итте, әмма Мирзаханның кылы селкенмәде.

—Кеше ирләре кебек, хет бер тапкыр булса да кыйнап кара инде,—дип, тәнкәсенә тиде аның Сажидә. Ләкин юаштан юан чыкмады. Мирзахан армый-талмый колхозда эшләвен белде. Машина-машина ашлыгын алды, йорт-каралты җиткерде. Сажидә дә җавапсыз калмады: ел саен иренә бала тапты.

Юаш иренә үч итеп исемнәрнең дә модныйларын куштырды: Робсон, Фикус, Графит, Диксон, Фрисә...

Мирзаханның тормышы ерак арага чабучы спортчыныкын хәтерләтә иде: кышын—техника ремонтлау, язын—чәчү, җәен—урып-җыю, анысы беткәч—тунга сөрү. Такы-токы ашау, Сажидәнең төче теле эзсез калмады. Кырык яшен тутырганда унике илле эчәгендә язва таптылар. Ике айлап район булнисендә дәвалангач, берәр санаторийга барып ял итәргә кинәш иттеләр.

Ирен эш аты итеп кенә күрергә күнеккән Сажидә Мирзаханны «Шифалы су» курортына иске-москыны кидереп озатты. «Юаш алашага ярамаган тагы»,—дип калды ул зәһәрлеген яшермичә.

Үзенең йортын—дәүләт, ә авылын—зур ил, районын материк дип күзалларга күнеккән Мирзахан Чаллының матурлыгына сокланып туя алмады, бөек химик Менделеев исемен йөртүче шәһәрнең барлыгын белеп тә гаҗәпләнде.

Хәзер генә часть командиры подполковник Дышлюкның «учись себя любить» дигән сүзен аңлый башлады кебек. Эшләп тә, ял итеп тә яшәргә була икән, ләбаса! Мирзахан мазут ашап бетергән кытыршы кулларына, курткасының төрле төстәге җепләр белән тегелгән төймәләренә карап оялып куйды.

«Шифалы су» курорты мәһабәт бинада урнашкан икән. Сары чәчле, мөлаем йөзле врач ханым Мирзаханны бик дикъкать белән тыңлады, пульсын тикшерде, яткырып эченә баскалады. Мускуллары уйнап торган ир уртасының гәүдәсенә хәйран калып:

—Язвагыз төзәлер. Киләчәктә ачы, тозлы әйберләрдән генә бераз сак булырга туры килер,—диде.

Бүлмәдәше Чистай мишәре булып чыкты. Күзләре мут, гәүдәсе ут. Аракы заводында механик икән.

—Беләсеңме, брат, ир кешенең өч әйбере булырга тиеш: чигәсендә ак чәч, ирлек көче һәм кесәсендә акча. Иначе, син—алаша!—диде ул турыдан

бәреп.—Менә мин шулай яшим, кызлар кочам, акчам да бар. Гаиләм дә түгәрәк. Хатын мин кайтмыйча табынга утырмый, балалар да ашамый. Син, Мирзахан, юаш булма, андый атны печәләр.

Чистай егете Исмай юаш Мирзаханны яңа тормышка өйрәтә башлады. Беренче көнне үк кич белән күршедәге ике хатынны кунакка дәште.

Алар кер юудан, ашарга пешерүдән арып килүләрен яшермәделәр.

—Знаешь, Мирза,—диде калку күкрәкле Нинасы,—во мне кипит кровь с молоком. Люби, не пожалеешь!

Исмай тост тәкъдим итте. Мәҗлестә катнашучылар салганны эчеп куйдылар. Мирзахан, күпме генә кыстасалар да, авызына аракы алмады. Нина белән бергә калгач та, сыер сөте, силос исе килгән хатынын сагынды.

Көннәрдән бер көнне Нина Мирзаханны урамда йөреп керергә дәште. Сәләмә киемле ирне күргәч, Нинаның йөзе бөтенләй үзгәрде. Ык-мык итте дә башка төркемгә ияреп китеп барды.

Исмай белән шифалы ләм алырга баргач, Мирзахан тагын көлкегә калды. Бүлектә эшләүче ханым брезент өстенә сары-кара сыекча җәйде дә: «Кай җирең авырта?»—дип кызыксынды. Мирзахан, эче җәфалагач, шулай кирәктер дип, җылы ләмгә йөзтүбән капланып ятты.

Ханым бармагын чигә тирәсендә боргалап, «әллә житеп бетмиме моңа?»,—дигән сыман ишарә ясады.

Мирзаханнан кеше ясарга җыенган Исмай башка компанияне сайлады.

Бер атна ыгы-зыгы белән үтте. Менә бүген ул кичке аштан соң язгы ташуны карарга төште. Берсе өстенә берсе менә-менә, бозлар, бата-чума бүрәнәләр ага. Ул, күңеле белән шуларга утырып, яшьлегенә кайтып киткәндәй булды. Бераздан яр кырыйларындагы коры агачларны җыеп учак кабызды. Үзе җыр сузды: Су буенда учак яна...

Кадер-хөрмәтсез яшәүнең нәтиҗәсе аяныч шул. Гомер буе хатыны сүзеннән чыкмый ат урынына эшләү юаш Мирзаханны тагын да басты. Өстендә зәңгәр төстәге иске болонья куртка, аягында малаеның ботинкасы. Әнә бит Нина да: «Какой ты сильный мужчина, тебе цены нет,—ди.—Только смелее будь. Не давай над собой смеяться».

Мирзахан тагын уйлар кочагына чумды. «Авылдашлар хөрмәт итә итүен, балалар да ярата. Ну хатынга килгәндә, бер юашка—бер зәһәр, бер ялкауга бер унган тиешледер инде ул...»

—Бик матур күренеш бит, ә!—дигән тавышка ул сискәнеп китте. Аның каршында бер ханым тора иде.

Бераздан тагын өстәп куйды:

—Гомерләр үтә икән ул, ә без һаман эш дигән булабыз.

Туташ Тәслимә икән. Казан кызы, төскә-биткә әллә ни дан булмаса да, гәүдәсе әле нәфислеген югалтмаган, тавышы бик матур, чишмә агышы кебек, һәр сүзе күңелгә үтеп керә. Математика буенча фән кандидаты, ди. Яшьлегенең иң матур чагы китапханәләрдә, институт аудиторияләрендә үткән. Яшьтәшләре ир кочагында балалар үстереп, шатланып яшәгәндә, үзенең киләчәк тормышын күзаллап, бер мәлгә аптырап калган. Аның да яратырга, сөеклесе куенында иркәләнергә хакы юкмыни? Тәслимә кырыкка якынайганда гына гомеренең заяга узганын аңлаган.

Тәслимә фән өлкәсендә балыктай йөзсә дә, тормышта йомшаклык күрсәткән. Артык йомшаклык күрсәткән.

Турысын әйткәндә, Мирзаханнан артык җире юк. Алдаша белми, тиз ышанучан. Беренче көннән үк аларны менә шушы сыйфатлар берләштерде дә, мөгаен. Көн саен кичләрен елга буенда очраша торган

булып киттеләр.

Башлыклы яшел плащ, биек үкчәле итальян итекләре кигән хатын болонья курткалы Мирзахан белән кеше арасына чыгарга да тартынмады. Ул сафлыгын саклап калган танышында төз, матур гәүдәле, ирлек көче ташып торган шәхес чалымнарын тоеп алды. Ә шәһәрдәге ирләрнең күпчелеге аракы чөмерә, көчен унга-сулга өләшә. Мирзахан моңа өйрәнмәгән, ул—тормышта үз бәясен алалмаган зат. Шәпләп киендереп тә җибәрсәң, менә дигән егет булыр иде, валлаһи.

Бу хакта Мирзаханга ничек әйтергә? Җае табылды тагын. Тәслимә аны ял көнне Чаллыга барырга күндерде.

—Шәһәрне бик матур диләр, анда бер дә булганым юк,—дип хәйләләде.

Тегесе тиз күнде. Барырга булгач, барырга. Шактый гына искерә төшкән автобус аларны яшьлек каласына китерде. Беренче эш итеп киемнәр кибетенә сугылдылар. Тәслимә башта үзенә күлмәк сайларга булды. Аннан соң Мирзаханга кара төстәге плащ кидертеп карады.

—Нәкъ үзенә атап тегелгән,—диде Тәслимә чын күңелдән куанып. Чыннан да, иске куртка кигән Мирзахан күзгә күренеп үзгәрде. Ул тагын да гаярь булып китте.

—Үзенә киеп туздырырга насыйп булсын,—дия-дия, Тәслимә акча саный башлады.

«Тузга язмаганны, мин, районның алдынгы механизаторы, чит хатын-кыз исәбеннән киениммени?» Ул Тәслимәгә бер төргәк акча сузды. Хатын тимерне кызуында сугарга теләде бугай. Бер булгач булсын дип, арзан гына бәягә кара йон свитер, куе көрән төстәге костюм-чалбар алдылар. Иң соңыннан үкчәсе ашалып беткән ботинкага да чират житте.

Юаш Мирзахан кибеттән шәһәр кешесенә әйләнеп чыкты. Аннары алар көлешә-көлешә паркта йөрделәр. Тәслимә Мирзаханның иске киемнәрен биек нарат ышыгында үбешкән җирдә «онытып» калдырды.

Кеше авырлыкка да, җиңеллеккә дә бик тиз ияләшә, диләр. Хатыныннан яхшы сүз ишетмәгән, наз күрмәгән ир Тәслимә янында үзен бөтенләй башкача хис итте. Әйтерсең, аңа канат куйдылар. Ул сөйгәнендә таяну ноктасы, терәк тойды. Иң мөһиме—ул үзен аңлардай кеше белән табышты. Ә бит күпме гаиләләр уртак балалар үстереп тә, хатын үзенчә, ир үзенчә яши. Андый бәхетсезләр саны аз түгелдер бу дөньяда. Курортка кире кайтканда, әлеге фикер Мирзаханның башын игәүләде, йөрәген телгәләде. Ирне бар иткән дә хатын, юк иткән дә хатын дип белми әйтмиләр икән шул... Ничек кенә булса да, Тәслимәнең назыннан башы әйләнгән Мирзахан иң бәхетле кеше иде бу минутларда. Бу тәүлек аның өчен тагын бер ачыш төне булды. Мирзахан гомерендә беренче тапкыр кыз кеше белән йоклады. Ике йөрәкнең бер-беренә омтылуы шулкадәр көчле иде, сәгатьләр-минутлар буталды. Сөю һәм сөелү моңарчы татышмаган хисләр дөньясында гиздерде. Бу бәхетле көннәр тагын күпме генә дәвам итсә дә, аның очы да, кырые да күренмәс кебек иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, санаулы көннәр бик тиз узды. Аерылу мизгелләре дә килеп җитте.

Алар курорттан икесе бергә китәргә булдылар. Башта—Чаллыга, аннан икесе ике якка. Тик алар монда бер-берсеннән аерылып китә алмадылар. Ни әйтсәң дә, Мирзахан да, Тәслимә дә кабат очрашуларына ышанмый иделәр. «Мәхәббәт ничек кенә көчле булмасын, Мирзахан гаиләсен, балаларын ташламаячак. Бөек затлар моңа бара алмый. Аның күңеле чиста, намусы пакь»—Тәслимә шулай уйлады. Әмма... әмма... Мирзахан элекке юаш, мескен Мирзахан түгел иде инде. Ул, ни булса шул булыр дип, Тәслимәне

Казанга кадәр озатырга булды. Чехов базары янындагы уңайлы фатирда ике йөрәк кабат бергә типте. Казан белән, Тәслимә белән ул тагын бер атнадан соң гына саубуллашты.

Мирзаханның үзгәреп кайтуына бөтен авыл шаккатты. Бары да: «Күптән кирәк иде инде»,—диештеләр. Зәһәр Сажидә дә иренең тормышында зур үзгәрешләр булуын күңеле белән сизде. Унсигез ел яшәү дәверендә Мирзахан хатынына беренче мәртәбә арты белән борылып ятты. Төннәрен дә Тәслимәне күреп саташып чыкты. Сажидә исә ире белән ике арадагы упкынның тирәнәюенә һәм ярларның ерагая баруына сызланды. Үткәннәрне кире кайтарып булмаса да, киләчәк, балалар өчен яшәргә кирәк. Шуңа күрә, көннәрнең берендә икәүдән-икәү генә калгач, Сажидә иреннән гафу үтенде. Хәер, эш гафу үтенүдәмени? Мирзахан дөньяга мескеннәр күзлегеннән түгел, ә аягында нык басып торган кеше буларак карый иде инде. Димәк, калган гомерен Сажидә дә яңача яшәргә тиеш булып чыкты. Кыскасы, санаторий галәмәтләре Уткүз авылында тагын бер ирне гаилә башлыгы итеп өскә чыгарды.

Яз артыннан җәй, аннан соң көз, кыш килде. Мөмкинлеге булган саен, Мирзахан Тәслимәгә туган көне, Сигезенче март бәйрәмнәре белән котлап открыткалар сала торды. Тик ни ял йортына, ни башкалага барырга җае чыкмады. Вакыт узса да, ул «Шифалы су»да үткән минутларны беркайчан да хәтереннән чыгармады. Тәслимәсе күңел түрендә якты йолдыз булып януын дәвам иттерде. Үз-үзен хөрмәт итәргә өйрәткән фән кандидатына һәрдаим рәхмәтләрен укыды ул.

Дүрт елдан соң Мирзахан Җәүдәтовка хезмәттәге уңышлары өчен «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исемен бирделәр. Олы бүләкне алырга Илбашы янына Казанга чакырдылар. Авыл кучтәнәчләрен төяп, башкалага юл тотты Мирзахан.

Автобустан төшүгә, таныш фатир ишек төбенә барып басты. Шакыды. Эчтән саф татарча: «Кем анда?»—дигән балалар тавышы ишетелде. Бу мизгелдә Мирзаханның миеннән меңләгән сораулар сызылып узды. «Нәрсә булган?.. Ни хәлдә яшиләр?.. Кем белән?..»

Ниһаять, ишек ачылды. Мирзахан алдында ике тамчы су кебек үзенә охшаган, кылыч борынлы, йөзе бераз сипкелле малай елмаеп тора иде. Бала кунакка кулын сузып:

—Мин Гыйлемхан Мирзаханович булам, ә сез кем?—дип сорады.

Мирзаханның күзләренә яшь килде, тезләре йомшарды. Бермәл аптырап торгач, көчле куллары белән Гыйлемханны күтәреп алды да күкрәгенә кысты.

—Беләсеңме, мин кем?.. Мин бит Мирзахан, синең әтиең булам,—дип кенә әйтә алды.

Ничә еллар буе күрешү минутларын зарыгып көткән Тәслимә дә алар янына атлады...

# Печән Базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Зөлфәт
Хәким

## БАРМЫ РИШВӘТКӘ ДӘВА?..

САТИРИК КОМЕДИЯ

**Катнашалар:**

Гарипов Сәйфи Мингалим улы—химия укытучысы

Руфия—Сәйфинең хатыны, культура сараенда китапханәче булып эшли

Әбүзәр Шактыев—район гәжитенең мөхәррире

Әхмәдиев Фоат Абзалович—районның администрация башлыгы

Гөлчирә—районның иң чибәр кызы, мисс-район, Әхмәдиевнең секретаре

Мутиева Нурия Шәмсиевна—РОНО (районның мәгариф бүлеге) житәкчесе

Ханнанов Вил Нилович—прокурор

Бакеев Вәдүт Юнусович—баш врач

Мусин Мөхтәр Әхәтович—военком

Казан кешесе

Мәскәү кешесе

Курьер

Пожарник

Ак халатлы кеше

Район чиновниклары

Корреспондент кыз, телевидениегә төшерү группасы

Снайпер һ. б., һ. б.

*Вакыйга Татарстанның бер районында бара.*

# 1

*Район хакимияте башлыгының кабинеты. Әхмәдиев өстәлендәге гәҗитне каткат укып карый.*

Әхмәдиев *(кычкыра).* Гөлчирә!

*Гөлчирә керә.*

Гөлчирә. Тыңлыйм, Фоат Абзалович!

Әхмәдиев. Син район гәҗитенең баш мөхәррирен чакырдыңмы?

Гөлчирә. Әбүзәр Шактыевнымы? Чакырдым. Сез әйтү белән үк.

Әхмәдиев. Нишләп килми соң инде ул? Бар, тагын шалтырат, хәзер үк килсен.

Гөлчирә. Ярар, Фоат Абзалович.

*Гөлчирә чыгып китә.*

Әхмәдиев *(телефон кнопкасына баса).* Алло! Нурия Шәмсиевна! Исәннәрмесез. Бүгенге район гәҗитен укыдыгызмы? Житешә алмадыгызмы әле? Сез, РОНО житәкчесе, барысыннан да алданрак укырга тиеш гәҗитләрне. Миңа килеп китегез. Көтәм.

*(Икенче кнопкага баса.)* Алло! Районның баш табибы Бакеев нихәлләрдә? Район гәҗитен укыйсыңмы, юкмы? Вакыт юкмы? Алай икән. Миңа килеп китәргә вакыт табарсыңмы? Ярый, көтәм.

*(Өченче кнопкага баса.)* Алло! Здравия желаю, товарищ военком Мусин! Син гәҗит укымыйсың инде. Хатының укый?.. Хатының укыган белән генә дөньядан артта калмагаең. Миңа килеп киталмассың микән. Хәзер үк.

*(Дүртенче кнопкага баса.)* Алло! Прокурор Ханнанов әфәнде, исәнмесез. Сез бүген район гәҗитен укыдыгызмы? Ничек инде юк?! Районның прокуроры иң беренчеләрдән булып укырга тиеш түгелмени ул гәҗитне? Ничек инде укырлык гәҗит түгел?! Менә бүгенге сан укырлык. Миңа килеп китегез әле, яме. Көтәм.

*Әбүзәр Шактыев керә.*

Әбүзәр *(кыюсыз гына).* Исәнмесез!

Әхмәдиев. Исәнме. Кил, утыр. *(Әбүзәр Әхмәдиевтан күзен алмыйча әкрен генә урындыкка килеп утыра.)* Син, Әбүзәр, «Бармы ришвәткә дәва?..» дигән мәкаләнне чыгарыр алдыннан берәр акыллы кеше белән киңәштеңме?

Әбүзәр *(калтыравыклы тавыш белән).* Юк... Сенсация бит...

Әхмәдиев *(кырыс).* Сенсация булгач, бигрәк тә, минем рөхсәттән башка моны чыгарырга ярамый иде. Район башлыгы буларак, райондагы сенсацияләрне иң беренче нәүбәттә мин белергә тиеш! Халык түгел! *(Гәҗитне кулына ала.)* Химия укытучысы коррупциягә каршы дару уйлап чыгарганмы?

Әбүзәр. Әйе. Бер таблетканы капкач, ярты сәгатьтән соң кешедә взятка алу теләге юкка чыга икән.

Әхмәдиев. Кем ул, нинди укытучы ул?

Әбүзәр. Гарипов Сәйфи Мингалим улы. Химия укытучысы. Редакциягә үзе шалтыратты.

Әхмәдиев. Бәлки, ул шарлатандыр. Кем, кайда һәм ничек тикшергән соң ул чыгарган препаратны?

Әбүзәр. Ваннасын рәтләргә килгән сантехник су эчәсе килә дигәч, ул аның суына шул даруны салган. Эшен тәмамлагач, сантехник тиешле хакын гына алган, өстәмә акча да, аракы да сорамаган. Үзенең хатынына да эчерткән, хатыны хәзер акча дауламый икән. Кыскасы, нәфсене кайтара торган дару уйлап тапкан ул химик.

Әхмәдиев *(тагын гәҗиткә күз сала, укый).* «Районыбызда ришвәтчелек хөкем сөрә... Әмма тиздән взятка алулар бетәчәк, коррупциянең тамыры корыячак», дигәнсең. *(Башын калкыта, усал итеп Әбүзәргә карап тора.)* Төтенең бик югары күтәрелә түгелме?!

Әбүзәр *(маңгаендагы тирне пинжәк җиңе белән сөртеп ала).* Үзегез бит коррупциягә каршы көрәш турында гел сөйлисез.

Әхмәдиев. Аны башкачарак та язып була иде. Безнең район коррупциягә баткан дигән фикер алга сөрелә түгелме?

Әбүзәр. Мин, киресенчә, безнең район иң беренче булып ришвәтчелеккә

каршы дару уйлап тапты дип мактанырга теләдем.

Әхмәдиев. Адресы нинди ул химикның?

Шактыев. Менделеев урамы, 14нче йорт.

Әхмәдиев *(язып ала)*. Менделеев урамы, 14нче йорт. Гарипов...

Шактыев. Сәйфи Мингалим улы.

Әхмәдиев *(яза)*. Сәйфи Мингалим улы.

*Мутиева керә.*

Нурия *(авызын ерып елмая)*. Исәнмесез!

Әхмәдиев. Узыгыз әйдә, Нурия Шәмсиевна. Син, Шактыев, бар, үзеңдә бул. Редакцияннән беркая чыкма, кичекмәстән бу мәкаләгә опровержение язарга туры килер, мөгаен.

*Әбүзәр вак-вак адымнар белән атлап чыгып китә.*

Әхмәдиев. Бер мәкалә чыккан гәҗиттә. *(Өстәлдәге гәҗиткә төртеп күрсәтә.)*

Мутиева *(йөзеннән елмаю югала)*. Мин аны сез шалтырату белән үк укып чыктым.

Әхмәдиев. Йә, алайса тизрәк фикереңне әйт.

Мутиева. Мин ни дип әйтергә дә белмим. *(Үпкәле тавыш белән.)* Бу мәкалә аркасында мине чакыруыгыз сәер. РОНОны һәм мине төп ришвәтчеләр дип санаган шикелле килеп чыга.

Әхмәдиев *(торып кабинеты буйлап атлый)*. Гарипов Сәйфи Мингалим улы, химия укытучысы, сезнең система кешесе. Ул чынлап та шундый дару уйлап чыгара алды микән?

Мутиева. Шәхсән үзем мин моңа ышанмыйм. Андый начар укытучы зур ачышлар ясарга сәләтле түгел дип саныйм.

Әхмәдиев. Ничек сез, РОНО җитәкчесе, үзегезнең укытучыгыз хакында начар укытучы дигән фикердә? Сездә начар педагоглар бармыни?

Мутиева. Ул инде безнеке түгел. Без аны мәктәптән куып чыгардык.

Әхмәдиев. Ул мәктәптә эшләмимени?

Мутиева. Юк. Директор белән тыныша алмады. Гел конфликт та конфликт. Барысы да гаепле, ул гына чиста, ул гына гадел...

Әхмәдиев. Ул бит инде препаратын кулланып караган, нәтиҗәләре дә бар ди.

Мутиева *(паузадан соң)*. Әй, белмим инде...

Әхмәдиев *(Мутиева каршысына килеп)*. Бәлки, аны мәктәптән куарга ашыккансыздыр, бәлки, калдырырга кирәк булгандыр?

Мутиева. Директор белән даими рәвештә талашучы укытучыны ничек мәктәптә калдырасың инде...

Әхмәдиев. РОНО системасындагы кеше бит ул барыбер. Мәктәптән куылса да, сезнең кеше ул. Химия укытучысы нәфсене корыта торган дару ясаган! Ничек уйлыйсың, без ничек кабул итәргә тиеш бу вакыйганы?

Мутиева. Аның үзе белән сөйләшмәдегезме әле?

Әхмәдиев. Юк.

Мутиева. Үзе белән сөйләшергә кирәк. Нинди дару икәнен, составын тикшертү зарур. Чынмы-юкмы—ачыклау мәслихәт. Чынлап та андый препарат ясалса, ул даруны кайда, ничек, кемгә эчертергә...

Әхмәдиев *(урынына барып утыра)*. Анысы инде алга таба хәл ителер. Ярый, Нурия Шәмсиевна, элемтәдә торыйк, тиз арада тагын кирәк булырсыз, мөгаен.

*Мутиева чыраен ясалма елмаю белән «бизәп» чыгып китә.*

Әхмәдиев *(кычкыра)*. Гөлчирә!

*Гөлчирә керә.*

Гөлчирә. Тыңлыйм, Фоат Абзалович.

Әхмәдиев. Срочно минем машинаны Менделеев урамы, 14нче йортка җибәр. Гарипов Сәйфи Мингалимовичны районның хакимият башлыгы көтеп утыра дип әйтегез.

Гөлчирә. Аңладым.

*Гөлчирә чыгып китә. Бакеев керә.*

Бакеев *(якын туганына эндәшкәндәй җылы тавыш белән)*. Исәнмесез, Фоат Абзалович.

Әхмәдиев. Сәлам. Утыр, Вәдүт Юнусович, утыр. Сәламәтлек ничек?

Бакеев *(өстәл янындагы урындыкка утыра).* Ярыйсы болай. *(Караңгыланып.)* Бил генә беraз борчып тора.

Әхмәдиев *(коры гына).* Мин сиңа, районның баш врачына, район халкының сәламәтлеге ничек дигән мәгънәдә сорау бирдем.

Бакеев *(шат тавыш белән).* Халыкның сәламәтлеге аның беркайчан да начар булмады, Фоат Абзалович. Халык ул чыдам.

Әхмәдиев. Ярар. Бу темага башка вакытта сөйләшербез. Вәдүт Юнусович, бүгенге район гәҗитендә бер мәкалә чыкты.

Бакеев. Сез шалтыраткач, шундук укып чыктым, Фоат Абзалович.

Әхмәдиев. Ничек тәэсир итте?

Бакеев *(үтә җитди кыяфәт белән).* Аптырашта калдым. Аннары сез миңа шалтыратып чакыргач, бөтенләй кәефем кырылды. Коррупция медицинада гынамыни?

Әхмәдиев *(графиннан су салып эчә).* Миңа киңәш кирәк. Гарипов Сәйфи Мингалим улы исемле химия укытучысының психотерапевтка, невропатологка мөрәҗәгать иткәне юкмы, хәтерләмисеңме?

Бакеев *(беравык уйланып утырганнан соң).* Ул кешенең баш белән мөрәҗәгать иткәне юк... әлегә. Ул даруны, кичекмәстән, анардан үрнәк өчен бер-икене алырга кирәк.

Әхмәдиев. Мин аның белән үзем очрашачакмын. Син әзер тор—аны бәлки берәр санаторийга җибәрергә кирәктер, йә психик чалышлыгы турында справка кирәк булыр.

Бакеев *(шөбһәле тавыш белән).* Аны районнан беркая да чыгармаска кирәк, менә шул минем беренче киңәшем.

Әхмәдиев. Мин дә шулай уйлыйм. Россиядә коррупцияне җиңгән бердәнбер район булсак—тарихка кереп калачакбыз. Барлык чиновникларыбызга шул даруны каптырабыз да...

Бакеев *(кискен).* Мин үземнең врачларыма андый дару каптыруга каршы. Чөнки алар шул дару тәэсирендә пациентлардан вак-төяк взятка алмый башласалар, хезмәт хакына гына яши алмаячаклар.

Әхмәдиев *(бармак янап).* Ә-ә-ә, димәк, син баш врач буларак, бүлнистәге ришвәтчелеккә каршы түгел?

Бакеев. Дөньяга мин аек акыл белән карыйм. Без ул даруны ашап хезмәт хакына гына яши алырбызмы соң?

Әхмәдиев. Нечкәлекләрен соңрак уйларбыз. Элемтәдә торыйк, Вәдүт Юнусович.

Бакеев. Ул даруны кулга тотып, тикшереп, анализ ясап карарга кирәк.

Әхмәдиев. Тикшербез, тикшербез.

*Бакеев борчулы кыяфәт белән чыгып китә. Мусин керә.*

Мусин *(шат күңелле).* Здравия желаю!

Әхмәдиев. Исәнмесез, иптәш полковник. Утырыгыз.

Мусин *(килеп урындыкка утыра).* Сез шалтыраткач мин мәкаләне укып чыктым.

Әхмәдиев. Фикерегез нинди?

Мусин *(бер дә исе китмичә).* Мин, военком, при чем монда? Мине чакыруыгыз аңлашылмый. Взятканы военкоматта гына алалармыни!

Әхмәдиев. Мөхтәр Әхәтович, мин сезне генә түгел, күп кешене чакырдым. Сезнең бик кирәк булып чыгуыгыз бар. Ришвәтчелеккә каршы көрәшергә кирәк, барыбер шунсыз булмый.

Мусин. Аны монда гына көрәшеп... Ил бик зур бит. Мәкаләдә ул химикның бер улы бар дип язылган. Хәзерге вакытта ул армиядә хезмәт итә—Уральский военный округта. Малаенны армиягә алабыз дип куркытып булмый инде аны. *(Уйга кала.)*

Әхмәдиев. Ул химикны әлегә район үзәгеннән беркая да чыгарырга ярамый. Военкоматтан аның үзенә повестка җибәреп, ике ай беркая китмичә өйдә генә булырга кушарга мөмкинме?

Мусин. Әлбәттә, мөмкин. Чакыртам да, переподготовкага җибәрәчәкбез, бер ай эчендә беркая да китмә, дип боерам.

Әхмәдиев. Бу вакытлыча, аның даруын тикшергәнче, үзенең максатларын белгәнчегә кадәр.

Мусин. Аңлыйм инде, аңлыйм.

Әхмәдиев. Бу арада үзегездә буласызмы?

Мусин. Алай тегендә-монда барасым юк бугай.

Әхмәдиев. Элемтәдә торыйк.

Мусин. Ярый.

*Мусин чыгып китә. Ханнанов керә.*

Ханнанов *(таш чырайлы, бернинди хис сизелми).* Районның прокуроры ник кирәк булды?

Әхмәдиев. Утыр әле, Вил Нилович. Менә бу мәкаләне укып чык әле тиз генә. *(Гәҗитне суза.)*

Ханнанов. Мин аны сез шалтыратканнан соң алдым да монда килгәндә машинада укыдым.

Әхмәдиев *(сагаеп).* Ошадымы соң мәкалә?

Ханнанов *(салкын тавыш белән).* Мәкаләдә бернинди криминал да күренми. Мине чакыруыгызны аңламыйм. Миңа һәм прокуратура хезмәткәрләренә ашатмакчы буласызмы әллә ул даруны?

Әхмәдиев *(аптырабрак).* Синең шаяруыңмы бу?..

Ханнанов. Мин шаярмыйм. Хокук саклау органнарын, прокуратураларны сүгү, ришвәтлектә гаепләү модада бит хәзер.

Әхмәдиев. Мин сине киңәшләшергә чакырдым. Минем үземне нык куркытты әле бу мәкалә.

Ханнанов *(күзләрен челәйтеп).* Нишләп икән?

Әхмәдиев *(өстәлдә яткан каптан сигарет алып каба, кесәсеннән зажигалка алып кабыза, сигаретын тирән итеп суыра).* Башымда уйлар өере кайный, болай сүз белән генә дә аңлатырлык түгел. Ул химикны күзәтү астына алырга кирәк. Повестка белән следовательгә чакырт, сәбәбен шул мәкаләгә бәйләсән дә ярый. Сиңа хәзер чиновниклар бик ачулы, покушение булмагае дип куркыт. Милиция нәчәлниге белән сөйләш тә, сакларга дигән булып бер-ике сержантны аның йорты янына дежурга куярга кирәк.

Ханнанов. Аңладым, Фоат Абзалович. Законсыз рәвештә дару ясаганы өчен аны җавапка тартыйк. Даруларын конфисковать итәргә кирәк.

Әхмәдиев. Ашыкмыйк әле. Әлбәттә, анализ өчен бер-икесен кулга төшерү кирәк. Саклык белән генә эш итик. Мин аның үзе белән очрашып сөйләшәм әле башта.

Ханнанов. Гәҗитнең редакторын...

Әхмәдиев *(прокурорның сүзен бүлеп).* Аның белән нишләргә икәнне алга таба үзем хәл итәрмен. Элемтәдә торыйк.

Ханнанов. Ярар!

*Ханнанов чыгып китә. Гөлчирә керә.*

Гөлчирә. Фоат Абзалович, Гарипов монда.

Әхмәдиев *(кашларын җыерып уйланып тора).* Кем соң ул?

Гөлчирә. Машинагызны шуны алып килергә җибәрдегез бит.

Әхмәдиев *(исенә төшереп).* Ә-ә-ә, теге химик. *(Гасабиланып.)* Керсен тизрәк, чакыр тизрәк! Нәрсә катып торасың! Тизрәк керт аны монда!

*Гөлчирә йөгереп чыгып китә. Сәйфи керә.*

Сәйфи. Исәнмесез.

Әхмәдиев *(сигаретын көл савытында сыта).* Исәнмесез, исәнмесез, Сәйфи Мингалимович. *(Өстәле артыннан чыгып Сәйфинең каршысына килә, ягымлырак елмаерга тырышып кул биреп күрешә.)* Мин сезне башкачарак күзаллаган идем. Сез бик мөлаем кеше икәнсез. Узыгыз, утырыгыз. *(Кычкырып.)* Гөлчирә!

*Гөлчирә керә.*

Әхмәдиев. Бер чәйгүн чәй яса. Өрек, кара җимеш, бал, йөзем, чәкчәк.

*Гөлчирә тыз-быз килеп, кер-чыга чәй әзерләп йөри. Сәйфи урындыкка утыргач, Әхмәдиев үзенең урынына түгел, аның каршысына утыра.*

Сәйфи *(көлемсерәп).* Бигрәк кызык килеп чыкты. Мин сезгә приемга керә алмыйча ике ел йөрдем. Ә бүген, көтмәгәндә, үзегезнең машинагыз мине монда алып килде. Мин башта ышанмадым...

Әхмәдиев *(урыныннан кузгала, күп төрле шешәләр торган шкафны барып ача).* Нинди телисез—ак аракы, коньяк, виски, ром?

Сәйфи. Рәхмәт. Мин андый каты эчемлекләр эчмим.

Әхмәдиев. Ярар, чәй эчик алайса. *(Янә Сәйфинең каршысына утыра. Чәй йотып куя. Елмаеп Сәйфине күзәтә.)*

Сәйфи. Инде күптән приемга язылган идем, шуңа чакырдыгызмы?.. Әллә?..

Әхмәдиев. Ә сез үзегез ничек уйлыйсыз?

Сәйфи. Хакимият башлыгы машинасын җибәреп үзе чакыргач ниләр уйларга да белмим.

Әхмәдиев *(житдиләнеп)*. Миңа приемга эләгә алмау ул табигый хәл инде. Эшләр бик тыгыз бит. Бүген дә мин Казанга барырга тиеш идем. Район гәҗитендә сезнең ачышыгыз турында укыгач, барлык эшләремне читкә куйдым да, Казанга шалтыратып гафу үтендем һәм кичекмәстән сезнең белән очрашырга булдым.

Сәйфи. Мин үзем дә Казанга барырга җыенып йөри идем.

Әхмәдиев *(куркып)*. Ник?

Сәйфи. Эшләрем бар Казанда. *(Чәй эчә.)*

Әхмәдиев. Казанга берәр көнне бергә барырбыз, минем машинада. Әлегә без сезнең белән монда булырга тиеш. Без башта сез уйлап чыгарган дару мәсьәләсен монда үзебездә хәл итәргә тиеш.

Сәйфи *(гаҗәпләнеп)*. Аның нәрсәсен хәл итәсен? Ул даруны кичекмәстән ил күләмендә куллана башларга кирәк.

Әхмәдиев. Башта үзебездә генә кулланып карыйк.

Сәйфи *(катгый итеп)*. Юк, Казанга барам! Аннан Мәскәүгә китәм!

Әхмәдиев *(чак кына ишетелерлек итеп)*. Сине Казанда дөрес анламаулары ихтимал. Мәскәүдә бөтенләй җүләр дип психушкага салачаклар үзеңне.

Сәйфи *(аптырап)*. Ник мине психушкага салсыннар? Коррупциягә каршы көрәшне инде кайчаннан бирле игълан итеп киләләр түгелме?

Әхмәдиев *(ясалма ягымлылык белән)*. Әй бигрәкләр дә сабый күнелле икән үзегез дә. Күренеп тора—сез табигать баласы, кешеләр дөньясын аңлап бетермисез икән. *(Сәйфинең чынаягына чәйгүннән чәй өсти.)* Мин сезнең өчен хәзер бик борчылам. Уголовный эш башламагайлары үзегезгә.

Сәйфи *(Әхмәдиевкә карап тора)*. Ни өчен?..

Әхмәдиев. Президент коррупциягә каршы көрәш игълан итте итүен, әмма көрәшне дарулар, препаратлар ярдәмендә алып бару мәслихәт дип аның әйткәне юк. Комсызлыкка каршы дару уйлап чыгаруыгызны хокук саклау органнары ничек бәяләрләр икән?

Сәйфи *(тыныч)*. Сез минем өчен борчылмагыз. Бу илдә мин гомерем буе куркып, борчылып яшәдем. Гаделсезлекне җиңүгә өлеш кертә алмавым да минем җанымны гомер буе ашады.

Әхмәдиев *(алга таба иеленкерәп)*. Нинди дару ясадың соң син, ничек составын уйлап таптың, нинди матдәләрдән тора ул? Бәлки, кеше организмына зарарлы нәрсәдер ул?

Сәйфи. Препаратымның составын патент алганчыга кадәр сер итеп тотачакмын. *(Горур тавыш белән.)* Шәп дару ясадым мин. Бер төймә препаратны йоткач, тәкъдим ителгән взяткадан кешенең күнеле болгана. Взятканы алса косарга тотына. Ике төймә эчсә яшисе килми башлый.

Әхмәдиев *(түрдәге урынына барып утыра)*. Куркам! Сез, мөгаен, монда кире кайтмассыз. Сезне хәтта Казаннан Мәскәүгә дә җибәрмәсләр. Сез коррупциянең масштабын аңлап бетермисез. Минем сезгә тәкъдимем бар—үзебездә генә, тып-тын гына кулланыйк. Район масштабында гына взяточникларны җиңсәк тә зур эш була бит. Районыбызда ришвәтчелекнең тамырын корыттык дип мактана алачакбыз. *(Пауза.)* Сезнең нинди проблемаларыгыз бар?

Сәйфи *(иннәрен сикертеп)*. Нинди проблемалар дип...

Әхмәдиев *(тагын Сәйфинен каршысына килеп утыра)*. Эшегездә восстановить итәбез... Мәктәп директоры итеп куярбыз... Коттедж салып бирербез... Ял йортына җибәрербез... Чит илгә сәяхәт оештырырбыз... *(Ишек ягына карап пышылдый.)* Бик шәп кызларыбыз бар...

Сәйфи. Миңа бернәрсә дә кирәкми. *(Көлемсери.)* Мине, шундый даруны уйлап чыгарган кешене, сатып алырга мөмкин дип уйлыйсызмы?

Әхмәдиев *(артка каерылып)*. Ул даруны син үзең дә ашадыңмыни инде?

Сәйфи *(кузгала).* Ярый, киттем мин.

Әхмәдиев. Юк, юк, ашыкмагыз. Утырыгыз әле. Мин аннары машина бирермен, кая телисез шунда илтеп куярбыз. Миңа бернечә дару бирә алмассыз микән?

Сәйфи *(урынына утыра).* Шәхсән үзегез өченме?

Әхмәдиев. Минем үземә кирәкме... Мин взятка алмыйм бит.

Сәйфи *(көлә).* Ничек инде—барлык чиновникларыгыз ала, ә сез бирүзегез генә алмыйсыз?

Әхмәдиев. Сәйфи Мингалимович, һәрбер кешене ришвәтчелектә гаепләргә хакыгыз юк. *(Басынкы тавыш белән.)* Күрсәтегез әле, төсе нинди ул препаратның.

Сәйфи. Үзем белән алмадым.

Әхмәдиев. Ышанычлы урында саклыйсызмы ул даруларны?

Сәйфи. Әлбәттә.

Әхмәдиев *(шомлы тавыш белән).* Өйдә саклыйсызмы?

Сәйфи. Борчылмагыз, ышанычлы урында.

Әхмәдиев. Без монда барыбыз да ул даруны ашасак, башка районнарда барыбер ришвәтчелек шул килеш калачак. Без бит аерым ил түгел, без бит бер илнең аерым бер районы гына.

Сәйфи. Шуна күрә бит мин ил күләменә чыгарга телим. Иң элек Татарстан Президентына барам.

Әхмәдиев. Ике Президент бит хәзер бездә. Кайсысына барасың?

Сәйфи. Россия Президентына барырмын.

Әхмәдиев. Россиядә дә икәү бит хәзер президент.

Сәйфи. Башта Миннехановка барам. Аннары Медведевка.

Әхмәдиев *(күңел тынгысызлыгын яшерә алмый).* Юк, ашыкмыйк! Куркам! Районыбыз өчен куркам! Монын өчен безне хупламаячаклар. *(Торып әрле-бирле йөри башлый.)* Сез влач вертикаленең нечкәлекләрен аңламыйсыз. Сезнең аркада бөтен районга тап төшәчәк. Сезнең даруыгыз аркасында барыбызны да гаепләячәкләр, каргаячаклар.

Сәйфи *(кузгала).* Кайгырмагыз, гаепле калсалар, бөтен гаепне үз өстемә алырмын. *(Ишек катына таба юнәлә.)*

Әхмәдиев *(Сәйфигә ияреп бара).* Кайчан юлга кузгалырга уйлыйсыз?

Сәйфи. Иртәгә.

*Сәйфи чыгып китә.*

Әхмәдиев *(түрдәге креслосына барып утыра, кычкыра).* Гөлчирә!

*Гөлчирә йөгереп керә.*

Гөлчирә. Әү, Фоат Абзалович?

Әхмәдиев *(тагы да катырак кычкыра).* Гөлчирә!!!

Гөлчирә *(котсыз калып).* Тыңлыйм, Фоат Абзалович?

Әхмәдиев *(бер ноктага текәлгән килеш).* Совещание!!! Жый барысын да!!!

*Гөлчирә йөгереп чыгып китә.*

## 2

*Сәйфинең йорт-жире. Ишегалды, бакча. Бакча түрендә зур агач. Әле яна гына таң атткан. Сәйфи юлга әзерләнгән. Хатыны Руфия аны озатырга чыккан.*

Руфия *(моңсу).* Бәлки, шушы атнада кайтып та житәрсең.

Сәйфи *(үзен тотышында күтәренкелек сизелә).* Бу атнада кайтып булмас, мөгаен. Казаннан Мәскәүгә үк китәргә туры килер, ахрысы.

Руфия. Бигрәк озакка китәсең икән.

Сәйфи. Улыбыздан хат килсә, мин кайтмыйча жавап язмый тор.

Руфия. Ярар.

*Капкадан ишегалдына Курьер йөгереп керә.*

Курьер. Хәерле иртә!

Сәйфи *(шомланып).* Хәерле иртә.

Курьер. Сез каядыр жыендыгыз бугай?

Сәйфи. Казанга. *(Руфия Курьерга куркып карап тора.)*

Курьер. Сәфәрегезне кичектерергә туры килер. Сезгә повестка бар. Сез

следователь Мукшиевка барырга тиеш, 16нчы кабинет. *(Сәйфигә повестка тоттыра.)*

Сәйфи *(әле Курьерга, әле повесткага карап)*. Мин Казанга барырга җыендым, аннан Мәскәүгә юл тотарга исәбем бар.

Курьер *(кырт кисеп)*. Иртәгә сәгать унберддә сез следователь Мукшиев бүлмәсендә булырга тиеш!

Сәйфи *(аптырап)*. Мин иртәгә инде Казанда булам.

Курьер. Повестканы инкарь иткән өчен кулга алынуыгыз ихтимал.

*Курьер чыгып китә.*

Руфия *(котсыз калып)*. Ник чакыралар икән?

Сәйфи. Ник икәнен аңламыйсыңмыни? Минем Казанга баруымны теләмиләр. *(Повестканы бөкләп чалбар кесәсенә тыга.)*

Руфия *(йөзе яктыра)*. Болай булгач, бармыйсың инде Казанга.

Сәйфи *(каушавын җиңеп)*. Юк, юк, берникгә дә карамый барам. Повесткам буенча син бар следовательгә.

Руфия. Нәрсә дим мин аңа, ничек сөйләшермен?

Сәйфи. Берни белмим дип, башыңны җүләргә сал да утыр.

Руфия. Берни белмәгән килеш следователь янына ник килдең, дисә?

*Капкадан Пожарник формасы кигән кеше керә.*

Пожарник. Мин янгын куркынычсызлыгы инспекторы. Иртәгә өйдә булыгыз, йортыгызны, каралты-курагызны тикшерәчәкбез.

Руфия. Безнең нәрсәбезне тикшерәсез?

Пожарник. Янгын куркынычсызлыгы линиясе буенча.

Сәйфи *(ачулы тавыш белән)*. Бездә янгын чыгарырдай сыекчалар юк, электр чыбыклары төзек...

Пожарник *(ишегалдына, каралты-курага күз йөгертә)*. Иртәгә өйдә булыгыз. Тикшерү комиссиясе киләчәк.

*Пожарник чыгып китә.*

Сәйфи *(җикереп)*. Барыбер барам Казанга!

Руфия *(тыныч кына)*. Сиңа хәзер өйдә булырга кирәк.

Сәйфи. Алар юри, мин чыгып китмәсен өчен, тикшергән булып кыланачаклар. Безнең закон бозганыбыз юк, каралты-курабыз да тәртиптә. *(Кузгала.)* Мин киттем. Син курыкма. Тагын берәрсе килсә, прокурорга барам дип үзләренә яна. *(Хатынын кочаклап битеннән үбә.)* Курыкма.

*Сәйфи капкадан чыгып китәм дигәндә генә кулына саквояж тотып ак халатлы һәм ап-ак чырайлы кеше керә.*

Ак халатлы кеше. Исәнмесез. Гарипов Сәйфи Миңгали улымы?

Сәйфи. Әйе.

Ак халатлы кеше. Прививка ясамадылармы әле?

Сәйфи. Нинди прививка?

Ак халатлы кеше. Ишетмәдегезмени, карантин игълан ителде. Поселоктан берничә көн чыгарга ярамый, прививка ясыйбыз.

Руфия. Нинди карантин? Ишетмәдек!

Ак халатлы кеше *(саквояжын ачып)*. Бик куркыныч грипп килде безнең тарафларга.

Руфия *(кыюланып)*. Ул птичий грипплар, свиной грипплар китеп барды бит инде, бетте бит инде алар.

Ак халатлы кеше. Тагы да куркынычрагы килде. «Козлиный грипп» дип атала. Сез, ханым, борчылмагыз, хатын-кызга йокмый ул. Ир кешеләргә генә кадыйбыз.

Сәйфи *(кыза башлый)*. Ә башкаларга кададыгызмы соң әле? Күршем Габделбәргә кададыгызмы?

Ак халатлы кеше. Ул ничәнче елгы?

Сәйфи. Илле җиденче елгы, миннән ике яшькә кечерәк.

Ак халатлы кеше. Әлеге дә баягы грипп илле бишенче елгыларны гына парализовать итә. Илле бишенче елгыларга гына кадыйбыз. Күтәгезне әзерләгез.

Сәйфи *(усал тавыш белән)*. Бернинди укол да кадатмыйм!

*Капкадан Әбүзәр керә.*

Әбүзәр *(тартынып кына)*. Саумысез!

Сәйфи. Әбүзәр, син ничәнче елгы?

Әбүзәр. Без бит синең белән бер елгы.

Сәйфи. Әбүзәргә кадыйсызмы сон?

Ак халатлы кеше. Сез район гәҗитенең баш мөхәррире бит әле?

Әбүзәр. Әйе.

Ак халатлы кеше. Илле бишенче елның кайсы аенда тудыгыз?

Әбүзәр. 21 нче апрельдә. *(Елмаеп.)* Гитлер 20 нче апрельдә, Ленин 22нчедә, мин 21есендә. Хе-хе-хе, мин гел шулай шаярам.

Ак халатлы кеше *(Сәйфигә)*. Сез кайсы айда тудыгыз?

Сәйфи. Августта.

Ак халатлы кеше. Без менә нәкъ илле бишенче елның августында туган кешеләргә укол ясарга фәрман алдык.

Сәйфи *(кычкырып диярлек)*. Әбүзәр, илленче елның августында туганнарны гына парализовать итә торган козлиный грипп дигән чирнең барлыгына ышанасыңмы син?

Әбүзәр *(югалып кала)*. Дөньяда ни булмас. *(Ак халатлы кешене беләгеннән тота.)* Туктагыз әле, прививка ясамый торыгыз.

Ак халатлы кеше. Ул бит карантинны бозып районнан чыгып китмәкче була.

Әбүзәр. Юк, юк, китми. Безнең монда кичектермәслек эшебез бар. Беркая да китми. Сез башка вакытта килегез. Мин район гәҗитенең баш мөхәррире, миңа ышаныгыз, ул беркая да китми, уколыгызны кадамый торыгыз аңа. Бик кирәк булса, иртәгә килерсез.

*Ак халатлы кеше беравык Әбүзәргә, аннары Сәйфигә карап тора да чыгып китә.*

Сәйфи *(ишегалды буйлап йөренә)*. Мине өйдән чыгармас өчен әллә ниләр уйлап табалар.

Әбүзәр *(Сәйфигә ияреп йөри)*. Опровержение языйк, Сәйфи! Бетерәләр башны. Улымны военкоматка чакырдылар. Армиягә алып китәчәкләр. Үзең беләсең, малайны армиядән алып калыр өчен ким дигәндә йөз мең сум акча түләргә кирәк, ә минем андый акчам юк.

Сәйфи. Шул военкоматларда акча сорамасыннар өчен дару уйлап таптым бит инде мин.

Әбүзәр. Юк, юк, юк, андый даруны военкомнар эчәргә тиеш түгел! *(Мескенләнеп.)* Минем улымның сәламәтлеге начар.

Сәйфи. Алайса, ник куркасың?

Әбүзәр. Аны хәзер чирле килеш армиягә алачаклар—мина ачу итеп. Языйк опровержение!

Сәйфи. Менә шундый илдә, шушындый кешеләр белән яшибез инде без.

Әбүзәр *(еламсырап)*. «Земельный комитет»тан килеп йорт-җиремне үлчәделәр. Уң як күршеләргә ике метр, сул як күршеләргә өч метр кергәнсең, диделәр. Гаражыңны сүтәргә, сараеңны күчерергә туры киләчәк дип куркыттылар. Имештер, хәзер җирне спутниктан фотога төшереп үлчиләр. *(Ялварып.)* Языйк опровержение, Сәйфи!

Сәйфи *(Әбүзәргә җирәнеп карап тора)*. Беркайчан ришвәтчелекне җиңеп булмаячак монда.

## 3

*Хакимият башлыгы кабинеты. Әхмәдиев кәгазьләр актарып утыра. Мутиева керә, йөзендә шатлык балкый.*

Мутиева. Фоат Абзалович! Гәҗиттә опровержение чыкты!

Әхмәдиев *(чәнчүле тавыш белән)*. Нурия Шәмсиевна, бәгърем, гәҗит укый башладыгызмы?

Мутиева *(үпкәләп)*. Ник алай дисез... *(Килеп өстәл янына утыра.)* РОНО җитәкчесе гәҗит укырга тиеш. Коррупциягә каршы уйлап чыгарылган даруның ялган икәнен, теге химикның шарлатан икәнен ачыклаган мәкаләне укыгач, сез дә сөенгәнсездер дип уйлаган идем.

Әхмәдиев. Бу опровержениене басым ясап, көчләп чыгарттык без. Мин хәзер шуны укып сөенеп утырырга тиешме?

Мутиева. Фоат Абзалович, мин ул химикның кем икәнен, нинди кеше

икәнен яхшы беләм.

Әхмәдиев *(тавышын күтәреп).* Ташлагыз, Нурия Шәмсиевна! Сәйфи эшләгән мәктәпнең директоры—сезнең туганыгыз. Сәйфи мәктәптәге тәртипсезлекләргә каршы еш кына баш күтәргән, шуңа күрә директор белән тыныша алмаган. Ата-аналардан акча җыюга каршы да чыгыш ясаган ул. Ул бит сезне судка биреп, сезгә каршы көрәшеп йөрмәгән. Ул бит глобаль рәвештә уйлап ниндидер химик препарат уйлап чыгарган.

Мутиева *(кәефе кырыла).* Ата-аналардан акча җыймасак, без мәктәптә ремонт та ясый алмас идек. Без, акылдан язып, әллә нинди глобаль нәрсәләр турында уйлап утыра алмыйбыз... Сез бит әле бөтен нечкәлекләрен белеп бетермисез... Баш врач Бакеев Вәдүт Юнусовичның хатынының энесен мәктәпкә эшкә урнаштырырга кирәк иде. Ул да химия укытучысы.

Әхмәдиев. Сәйфидән дә яхшырак укытучымы?

Мутиева. Фоат Абзалович, без сезнең белән яшь чактан ук якын кешеләр, шуңа күрә, рөхсәт итегез, ачыктан-ачык сөйләшергә. *(Кайнарланып.)* Барлык справкаларны, больничныйларны барыбыз да Вәдүт Юнусович аша ясыйбыз—без, бу районның чиновниклары, һәммәбез аңа мөрәҗәгать итәбез. Уларыбызны армиягә җибәрмәс өчен дә башта Вәдүт Юнусовичка барырга туры килә...

Әхмәдиев. Тынычланыгыз әле, зинһар. Мин аңлыйм, сез шәхсән бу вакыйгада үзегезнең гаебегезне таныйсыз, ләкин берни эшли алмыйсыз. Барыгыз, ял итегез. Тынычланыгыз, борчылмагыз, бу эшне озакка сузмабыз. Монда сезнең гаебегез алай бигүк зур түгел.

*Мутиева карангыланып чыгып китә. Мусин керә.*

Мусин *(көр тавыш белән).* Здравия желаю! *(Килеп урындыкка утыра.)*

Әхмәдиев. Мөхтәр Әхәтович, әйтегез әле, безнең районда теге яки бу чиновник үзенең улын армиягә җибәрмәс өчен иң элек бүлнискә барып үзенә кирәкле справкалар ясатамы?

Мусин *(гаҗәпләнеп).* Сез бу турыда белми идегезмени?

Әхмәдиев *(авыр сулап).* Белә идем. Әмма элек миңа ачыктан-ачык бу турыда әйткәннәре юк иде.

Мусин. Медицина заключениесеннән башка без беркемне дә армиядән коткара алмыйбыз.

Әхмәдиев *(военкомга шаккатып карап тора).* Сез шул кадәре тыныч кына бу турыда миңа сөйләп утырасыз. *(Гасабиланып.)* Бу бит җинаять! Яшьләр армиядә хезмәт итәргә тиеш! Илне кемдер сакларга тиеш! Армия булырга тиеш!

Мусин *(тыныч).* Сез дөрес сүзләр сөйлисез. Мин дә шулай дип уйлыйм. Ләкин чынбарлыктан кая китәсең? Мәсәлән, беркөнне милициядән берәү килде дә, улын армиядән алып калуыбызны үтенде. Ә мин нишләргә тиеш? Мин әйтәм: «не годен» дигән заключение кирәк, ә аны безнең районда баш врач хәл итә.

Әхмәдиев. Ник соң син ул милиция вәкилен күтенә тибеп чыгарып җибәрмәдең?

Мусин *(елмаеп).* Гафу итегез, әйтәм инде... ул сезнең хатыныгызның абыйсы.

Әхмәдиев *(чыраен сытып).* Әй, бу дөнья!

Мусин *(шатлык белән).* Гәҗиттәге опровержениегә мин бик сөендем. Бу эш зурга киткән очракта башлар харап булыр иде.

Әхмәдиев. Нишләп харап булыр иде башлар?..

Мусин. Чыннан да ул даруны күпләп чыгарып, аны барлык чиновникларга эчертергә тотынсалар, нәрсәләр булып бетәр иде—х... его знает!

*Бакеев Вәдүт Юнусович керә.*

Бакеев *(ягымлы).* Исәнмесез, Фоат Абзалович! *(Тиз генә өстәл янына килеп утыра.)*

Әхмәдиев. Исәнме. *(Күкрәген угалап куя.)* Вәдүт Юнусович, торымнан-торымга күкрәкне каты иттереп кыса. Нәрсәдән икән ул?

Бакеев. Төрле сәбәп булырга мөмкин. Бәлки, стенокардиядер. Әйдәгез, тикшерелегез—кардиограмма ясыйк, анализларыгызны карыйк.

Әхмәдиев. Әлегә вакыт юк. Теге химик белән баш катты.

Бакеев. Опровержение булды бит инде.

Әхмәдиев. Булса ни... Ә химик исән-сау! Даруын да кулга төшерә алганыбыз юк. Инде ике тапкыр тентеделәр—табалмадылар. Нык яшергән!

Бакеев. Опровержение булгач, нигә тентеп торырга?

Әхмәдиев *(газаплы тавыш белән)*. Опровержениене мәҗбүри рәвештә яздырдык бит без! *(Пауза)*. Коррупциягә каршы көрәшне кайчан башларбыз соң? Бәлки, бу химикның препараты ришвәтчелекне бетерергә бирдәнбер шанс булгандыр.

Бакеев. Мин ышанмыйм андый дару барлыгына. Булган сурәттә дә аны табып юк итәргә кирәк. Ришвәтчелек дип... Рәхмәт йөзеннән бирелгән бүләкләрне ришвәт дип атап булмый инде. Кемдер бүләк урынына акчалата ала, ансы да җинаять дип саналырга тиеш түгел. Мин врачларыма бүләк яки акча алмагыз дип әйтә алмыйм. Ә зуррак масштабта алганда, без яши торган системаны сез үзегез миңа караганда да яхшырак аңлыйсыз. *(Мусинга.)* Яшерен-батырын түгел, гафу итегез, Мусин әфәнде, сезнең наркоман малаегызны төрмәгә утыртмыйлар, чөнки прокурорның малаен армиядән коткарып киләсез... Шулай бит инде? Мин прокурор малаена ялган заключение бирми булдыра алмыйм, чөнки бүлнисебезне, поликлиникабызны күпме комиссияләрдән, тикшерүләрдән саклап килә ул. Бу бәйләнешләрдә, бу бәйләнешләрдә акчасыз, ришвәтсез нишләмәк кирәк! Ничек инде бер-береңә ярдәм итмисең?! Ә сез ниндидер пүчтәк ришвәтләр өчен кайгырып утырасыз. Сез, Мусин әфәнде, миңа ачуланмагыз, мисалга сезне телгә алганым өчен. Без сезнең белән чит-ят кешеләр түгел...

Мусин. Дөрес, дөрес. Шуңа күрә чын күңелдән котлыйм сезне гәҗиттә чыккан опровержение белән!

Әхмәдиев. Сөенерлек бернәрсә дә юк әле. Ни гаҗәп: барыгыз да гәҗиттә чыккан опровержениегә куанасыз!

Мусин. Ана гади халык та куана. Гади кеше дә адым саен кемгә дә булса акча төртә.

Бакеев. Улыгызның хәле бу арада ничек соң?

Мусин *(йөзе караңгылана)*. Ярый, ярый. Рәхмәт инде сезгә.

Бакеев. Карагыз аны, упкын өстендәге кыя кырында йөри улыгыз.

Мусин *(тирән сулап куя)*. Заманы шундый аның. Илнең астын өскә китерделәр дә...

Әхмәдиев *(сигарет кабыза)*. Ә сез үзегез читтә идегезме илнең асты өскә килгәндә?

Мусин *(паузадан соң)*. Мин күптән түгел астына сия торган бер малайны армиягә җибәрдем. Призывниклар җитми. Кем гаепле? Военкоматмы? Беләсезме, уларын армиягә җибәрмәс өчен күпме кеше тырыша? Военкоматны гаеплләргә генә торалар... Иң беренче чиратта зур чиновниклар йөри малайларын армиядән коткарып. Илгә хезмәт итү почетлы дип санамагач, ул чиновникларның патриотизмына ышанасызмы? Җаваплы урыннарда утыручылар илгә шундый мөнәсәбәттә булгач, аларда ватан хисе булмагач, бу ил нишләсен?! Ничек ришвәтчелек чәчәк атмасын?!

Бакеев. Соңгы вакытта зур чиновниклар гына түгел, аз гына мөмкинлеге булган кешеләр дә уларын армиягә бирмәү артыннан йөриләр. Иң ярлы, иң мескен кешеләрнең генә уллары бара армиягә.

Әхмәдиев. Акчасы булмаган, блаты булмаган мескен кешеләрнең генә малайларын армиягә алгач, аның армиясе дә мескен инде.

Бакеев. Сезгә, иптәш господин Әхмәдиев, сөйләве рәхәт, сезнең малаегыз юк, сезнең—ике кыз.

*Ханнанов керә.*

Әхмәдиев. Ну, нәрсә анда?

Ханнанов *(килеп утыра)*. Тапмадык бернинди препарат та.

Бакеев. Юктыр ул. Юри әйткәндер.

Ханнанов. Следователь янына бармаган. Барлык тикшерүчеләрне, комиссияләрне инкарь иткән, берсенә дә взятка тәкъдим итмәгән.

Әхмәдиев. Димәк, ул үзе уйлап чыгарган даруларны эчкән.

Бакеев. Юк ла, ышанмыйм. Үзе шундый кире, принципиаль кешедер. Була бит шундый халәт кайвакыт—кем әйтмешли, ике дөнҗа бер моржа. Химик та шул халәттәдер.

Мусин *(тешен кысып)*. Переподготовкага армиягә җибәрәм мин аны.

Әхмәдиев. Ә син, Ханнанов,

гәҗиттә чыккан опровержениедән соң химикны мәҗбүри рәвештә милициягәме, прокуратурагамы алып бара аласынмы? Эш ачарга кирәктер бит.

Ханнанов. Бик сәер кеше булып чыкты ул. Беләсезме ул нишләгән?

Әхмәдиев. Нишләгән?

Ханнанов. Протест йөзеннән бакчаларындагы зур агач башына менеп киткән. *(Барысы да көләләр.)*

Әхмәдиев. Аны агач башыннан төшерү генә милициянең хәленнән киләдер әле.

Ханнанов. Ул үзе белән бау алган, элмәк ясаган. Берәрсе менә башласа, асылынам дип куркыта.

Мусин. Асылынсын!

Әхмәдиев *(авызыннан бер бөрек төтен чыгарып)*. Юк, юк, алай ярамый. Җайлап-майлап кына, әйбәтлек белән кирәк... Йорты сак астындамы?

Ханнанов. Үзегезнең куркынычсызлыгыгыз өчен диган булып, йортын, йорт тирәсен сак астына куйдык. Беркая да кача алмаячак.

Мусин. Тамагы ачкач үзе төшәр әле.

Бакеев *(көрсенеп)*. Бу яшәештән агач башына менеп кенә качып булса икән ул!

## 4

*Сәйфиләр пуҗумы. Агачның иң югары юан ботагында Сәйфи утыра. Руфия килә, кулына пакет тоткан.*

Руфия *(сагышлы тавыш белән)*. Ник куптардың мондый ыгы-зыгыны? Хәзер башыңны ашыйлар бит.

Сәйфи *(кырыс)*. Бар әле, кит, шыңшып торма монда!

Руфия. Мин сиңа ашарга алып килдем.

Сәйфи. Нәрсә анда?

Руфия. Ике йомырка, бер шешә сөт, ипи.

*Сәйфи бауны төшерә. Руфия ашамлыклар салынган пакетны бауга эләктерә. Сәйфи бауны тартып пакетны күтәрә. Машина килеп туктаган тавыш ишетелә.*

Руфия *(сискәнеп)*. Кемдер килә.

*Ишегалдына Әхмәдиев керә. Руфия аның каршысына таба атлый.*

Әхмәдиев *(мөлаем кыяфәт белән)*. Исәнмесез.

Руфия *(каушанкырап)*. Исәнмесез.

Әхмәдиев. Хәлләрегез ничек?

Руфия. Хәлләрне үзегез беләсез бит инде.

Әхмәдиев. Сез культура сараенда китапханәче булып эшлисез, шулаймы?

Руфия. Әйе. Теге директорны куганнан соң, вакытлыча директор вазифасын да башкарам.

Әхмәдиев. Аны ник кудылар әле?

Руфия. Бик каты эчте ул. Уен коралларын, инвентарьны сатып эчте. Бер караганда кызганыч аны, ә икенче караганда... Саксофонны бер литр усадский аракыга сатып инде! Шул хәтле зур инструментны...

Әхмәдиев. Телисезме, мин сезне бөтенләйгә директор итеп урнаштырам.

Руфия. Юк, юк, кирәкми! Рәхмәт! Яшьләр бик әшәке, мин аларны тыя алмаячакмын.

Әхмәдиев. Тыярбыз. Яшьләрне генә тыя алырлык көч юкмыни бездә?

Руфия. Бина бик иске—әле теге төше, әле бу төше ишелеп, кителеп тора.

Әхмәдиев. Ремонт ясарбыз.

Руфия. Китапханәгә дә ярдәм итсәгез иде. Яна китаплар кирәк, киштәләрне янартасы бар.

Әхмәдиев. Казанга шалтыратып китап нәшриятлары белән сөйләшермен. Ике йөз өр-яңа китап кайтартырмын.

Руфия *(куанып)*. Чын әйтәсезме?

Әхмәдиев. Мин алдый торган кеше түгел. Ни... Мин дә сезнең ярдәмегезгә мохтаҗ, Руфия ханым.

Руфия. Ничек ярдәм итә алам икән мин мондый зур кешегә?

Әхмәдиев *(әкрен генә)*. Ирегез чынлап та нәфсене бетерә торган дару

уйлап таптымы?

Руфия. Үзе әйтүенчә, шулай.

Әхмәдиев. Ничә штук ясаганын белмисезме?

Руфия. Белмим.

Әхмәдиев. Кайда яшергәнен дә белмисездер инде?

Руфия. Әйтмәде.

Әхмәдиев. Ул даруны сезнен чәегезгә салган булган, имеш. Аны да сизмәдегезме?

Руфия *(гаҗәпләнеп)*. Сизмәдем. Кем әйтте сезгә минем чәемә андый дару салганын?

Әхмәдиев. Гәжит редакторы әйткән иде. Ярар. *(Сынаулы караш белән.)* Бәлки, шул дару тәэсирендә генә директор вазифасыннан баш тартасыздыр?

Руфия *(пошаманга калып)*. Белмим. Минем башым каткан.

Әхмәдиев. Ике йөз китапны шушы көннәрдә алып кайтырлар.

Руфия *(шатланып)*. Рәхмәт яусын!

Әхмәдиев. Шунын өчен иренне агачтан төшәргә күндер.

Руфия *(агач төбенә йөгереп бара)*. Сәйфи! Фоат Абзалович китапханәгә ике йөз өр-яңа китап кайтарттырам диде. Төш инде, төш! Шундый шатлык бар чагында утырма анда! *(Тиз генә агач янынннан китә.)*

Әхмәдиев *(агач янына килә)*. Нихәл, Сәйфи Мингалимович!

Сәйфи *(агач башыннан)*. Аллага шөкер! Үзегез ни хәлдә?

Әхмәдиев. Ярыйсы. Нервыны гына бераз какшаттын бу арада. *(Шат күнелле булырга тырышып.)* Син ясаган дару слабыйрак булып чыккан бугай...

Сәйфи. Ник алай дисез, сезнең бит ул даруны кабып караганыгыз юк.

Әхмәдиев. Хатынын ике йөз китап бәрабәренә сине агачтан төшәргә өнди түгелме? Син бит аңа ул даруны яшертен генә эчерткән булгансын. Әллә хатынкызга тәэсир итмиме препаратын?

Сәйфи. Хатыныма берничә көн элек салган идем мин ул даруны. Аны көн саен берәр төймә эчеп торырга кирәк бит. Шунда гына эффект була.

Әхмәдиев *(үтә житди кыяфәт белән)*. Анлашылды. Мин үзем дә ришвәтчелекне бетерер идем, тамырын корытыр идем мин анын. Әмма мин теләп кенә, син теләп кенә, әгәренки башкалар теләмәсә—ни мәгънә?! Барыбыз да берьюлы теләсәк кенә жинеп булачак коррупцияне.

Сәйфи. Шуна күрә ясадым да мин ул даруны.

Әхмәдиев *(паузадан сон)*. Аны көненә бер тапкыр эчәргә кирәкме?

Сәйфи. Әйе. Иртәнге якта.

Әхмәдиев. Ашаганнан сонмы, ашаганчымы?

Сәйфи. Ашаганда.

Әхмәдиев. Син анда хәзер ашап утырасын. Каптынмы ул даруынны?

Сәйфи. Иртүк каптым.

Әхмәдиев. Син үзенне намуслы кеше дип санагач, нигә ул даруынны эчәсен?

Сәйфи. Сез мине сатып алмасын өчен, алай-болай взятка биреп дару серен ачтырмасыннар өчен.

Әхмәдиев. Димәк, хәзер синен белән сөйләшүдән мәгънә юк. Алайса сау булып торыгыз! Егылып төшә күрмәгез!

Руфия. Сау булыгыз.

*Әхмәдиев китә. Руфия агач төбенә йөгереп килә.*

Руфия *(канатланып)*. Сәйфи! Ике йөз яна китап кайтачак! Төш! Влач белән болай конфликтка керергә ярамый.

Сәйфи. Яна китаплар кайтса, аны монда укучы бармы сон? Син, Руфия, безнен халыкнын бер аерым конкрет мисалы—юк кына нәрсәгә алданасын, пүчтәк кенә нәрсәгә сатыласын.

Руфия *(сөмсере коела)*. Күпме бергә гомер кичергән хатынына андый нәрсәләр сөйләп утырма инде. Син чынлап та мина даруынны салган иденме?

Сәйфи *(елмаеп)*. Курыкма, бердәнбер сөекле хатыныма начар нәрсә салмам мин.

Руфия *(ягымлы итеп)*. Кичкә нәрсә пешерим?

Сәйфи. Дучмак.

*Руфия өйгә кереп китә. Әбүзәр килә, як-ягына карана, башын күтәреп агачларны күзәтә.*

Сәйфи *(кинәт өстән эндәшә)*. Һәй!

Әбүзәр *(сискәнеп китә һәм, ниһаять, Сәйфине күреп ала)*. Сәйфи!

Сәйфи. Нишләп йөрисен?

Әбүзәр *(моңсу тавыш белән)*. Сәйфи, ник минем син агачка?

Сәйфи. Минем башка чарам юк иде. Протестны фәкать шулай гына белдерә алам. Мине беркая чыгармыйлар. Мин тоткын хәлендә. Шуңа күрә мендем.

Әбүзәр. Агачка менеп кенә котыла алмыйсың.

Сәйфи. Ә син—ихтыярсыз бөҗәк. Мине яклап үзең Казанга барасы яки хәбәр итәсе урынга, опровержение яздың.

Әбүзәр. Ә бит минем ул даруны күргәнем дә юк әле.

Сәйфи. Күргәнең булмагач, нишләп башта сенсация, фәлән-фәсмәтән дип минем препаратым турында мәкалә язган идең?

Әбүзәр. Кем белгән аның болай килеп чыгасын. Мәкалә чыгу белән үк редакциягә шалтырата башладылар—чиновниклар да, гади кешеләр дә. Гади халык сине дә, мине дә каргады. Мин опровержение язмый булдыра алмадым инде.

Сәйфи *(җикереп)*. Бар, күземә күренмә! Үзеңне журналист дип йөргән буласың! Мескен!

Әбүзәр *(урамда ишетелгән тавышларга колак салып)*. Әнә монда да халык килә башлады.

*Бакча рәшәткәсен сикереп чыгып кача. Чиновниклар делегациясе килә. Эзли торгач, Сәйфинең кайсы ботакта утырганын абайлыйлар.*

Мутиева *(яман усал тавыш белән)*. Агачка менеп качтыңмы? Ха-ха! Опровержение булды инде! Син—шарлатан! Сине әле хөкемгә тартачаклар!

Сәйфи *(исе китми)*. Хөкемгә тартсалар да, дару уйлап табылган бит инде. Мин аны теләсә кайчан ясый алам.

Мутиева *(таләпчән тавыш белән)*. Төшеп барыбыз алдында гафу үтен!

Сәйфи. Синеңише ришвәтчеләр алдында гафу үтенешле булса мин бу дөньяда яшәмим дә.

Ханнанов *(вәкарьле кыяфәт белән)*. Син үзеңне үзең агач башына куып менгергән кеше. Сиңа бит закон алдында җавап бирергә туры киләчәк.

Сәйфи. Минем закон бозганым юк.

Ханнанов. Син наркотиклы препарат ясап безнең барыбызның да башын бутарга маташтың.

Бакеев. Теге син даруыңны эчерткән сантехникның анализларын алдылар—канында наркотик матдәләр табылды.

Сәйфи. Ышанмыйм. Минем препаратта наркотик матдәләр кулланылмады.

Мусин *(хәрбиләрчә боерып)*. Син агачтан төшәргә тиеш!

Сәйфи *(үҗәтләнеп)*. Юк! Мине эзәрлекләүдән туктасагыз гына, миңа районнан чыгып китәргә мөмкинлек бирсәгез генә төшәчәкмен.

Мусин. Сиңа военкоматка повестка бар—переподготовкага җибәрәбез. *(Ярдәмчеләренә.)* Барыгыз, менеп алып төшегез әле шуны!

*Берничә яшь кеше агачка менмәкче булалар.*

Сәйфи *(алар менә башлау белән үк бауның элмәген башына кия һәм кычкыра)*. Асылынам!

Бакеев *(куркып)*. Әй, менмәгез, кирәкми! Чынлап та асылынуы ихтимал.

*Тавышларны ишетеп Руфия йөгереп чыга.*

Руфия *(ачыргаланып кычкыра)*. Китегез! Менмәгез! Ике дә уйлап тормый, асылына!

*Барысы да агачтан читкәрәк тайпылалар.*

## 5

*Әхмәдиев кабинеты. Төрле вазифалардагы чиновниклар киңәшмәгә җыелганнар.*

Әхмәдиев. Аның янына менү мөмкин түгел, шундук асылына башлый.

Ханнанов. Асылынсын! Опровержение булды бит. Хәзер хатынын ныгытып эшкәртеп, иренә каршы котыртырга кирәк.

Әхмәдиев *(кычкыра).* Гөлчирә!

*Гөлчирә керә.*

Гөлчирә. Әү, Фоат Абзалович.

Әхмәдиев. Сәйфинең хатынын алырга машина җибәрдеңме?

Гөлчирә. Әйе.

Әхмәдиев. Килү белән монда керсен.

Гөлчирә. Ярар. *(Чыгып китә.)*

Әбүзәр. Аның асылынуын теләргә ярамый. Сез укымагансыздыр әле... *(Портфеленнән ике гәҗит ала.)* Казанда ике гәҗиттә чыккан—«...Учитель химии придумал чудо-лекарство против взяточничества»,—диелгән. Коррупциягә каршы көрәшкәне өчен асып куйганнар дип уйлаулары бар. *(Барысы да өнсез калалар.)*

Мусин *(шаккатып).* Инде Казанда беләләр икән!

Әбүзәр. Ник, сез республика гәҗитләрен укымыйсызмыни?

Бакеев *(ачу белән).* Нинди гәҗит! Монда күт кашырга ара юк.

*Курка-курка гына Руфия керә.*

Руфия. Исәнмесез.

Әхмәдиев. Исәнмесез, Руфия ханым. Узыгыз, утырыгыз. Сезнең ирегез бик принципиаль шәхес, компромисларга бармый торган кеше, шуна күрә аның белән сөйләшүе безгә гаять авыр. Зинһар өчен, ирегезне җиргә төшәргә күндерегез! Һәм безнең белән, шулай ук хокук саклау органнары белән дә, хезмәттәшлек итсәгез бик рәхмәтле булыр идек.

Руфия *(өстәл янындагы буш урындыкның кырыена гына утырып).* Мин ни әйтергә дә белмим инде.

Ханнанов. Ясаган дарулары кайда икәнен әйтегез ичмаса.

Руфия. Билләһи, белмим!

Ханнанов. Ул аларны кайда ясады соң? Лабораториясе кайда?

Руфия. Белмим. Миңа әйткәне булмады.

Мутиева. Ничек инде сез, аның хатыны, берни белмисез?

Руфия. Берни белмим түгел! *(Күзләрендә усаллык чагыла.)* Мин бик күп нәрсәне беләм! *(Калтырана башлый.)* Минем ирем яхшы педагог икәнне дә беләм, мәктәптән аны ник куганыгызны да беләм, мәктәптә калыр өчен аннан күпме акча сораганыгызны да беләм! *(Мутиевага нәфрәт белән карап тора.)* Сезнең кем икәнегезне дә беләм! *(Ярсып.)* Казаннан килгән инспектор белән ресторанда утырганнан соң кунакханәгә менеп йоклаганыгызны да беләм! *(Елап җибәрә.)*

Мутиева *(сикереп тора).* Ялган! Мин сезне судка бирәм!

Әхмәдиев *(торып Руфия янына килә).* Тынычланыгыз, тынычланыгыз. *(Графиннан стаканга су салып Руфиягә бирә. Руфия тончыга-тончыга эчә. Кул ишарәсе белән Мутиевага утырырга куша. Мутиева урынына утыра.)*

*Гөлчирә керә.*

Гөлчирә. Фоат Абзалович, Казаннан корреспондент белән төшерү группасы килде.

Әхмәдиев. Нинди группа?

Гөлчирә. Казаннан, «Эфир» телекомпаниясеннән, «Город» программасыннан.

Әхмәдиев *(каушый).* Бетте баш! Барыгыз да тизрәк чыгып китегез! Гөлчирә! Корреспондент үзе генә керсен!

*Барысы да ашыга-ашыга чыгып китәләр. Корреспондент кыз керә.*

Корреспондент *(сагыз чәйничәйни).* Исәнмесез.

Әхмәдиев *(ясалма елмаю белән).* Исәнмесез.

Корреспондент. Сездә Сәйфи исемле химия укытучысы взяточничествога каршы дару уйлап тапкан һәм агач башына менеп киткән. Без аның турында материал эшләп эфирдан бирмәкче идек. Сәйфине камерага төшерергә рөхсәт итмәделәр. Сез анда сакчылар куйгансыз икән.

Әхмәдиев. Әйе, сакчылар куйдык. Коррупциягә каршы көрәш игълан иткән кешене сакламыйча булмый.

Корреспондент. Нишләп агач башына менгән соң ул?

Әхмәдиев. Соң, андый талантлы кешеләр, галимнәр чудагырак булалар бит инде алар.

Корреспондент. Мин аның белән интервью эшләргә телим.

Әхмәдиев. Ә ул үзе янына беркемне дә менгерми, асылынам дип куркыта.

Корреспондент. Аның янына менмичә генә дә сөйләшеп була бит.

Әхмәдиев *(ык-мык килеп)*. Ни... Әйе шул... Ярар. *(Кычкыра.)* Гөлчирә!

*Гөлчирә керә.*

Гөлчирә. Әйе, Фоат Абзалович.

Әхмәдиев. Гөлчирә, кунакларны ашатыгыз-эчертегез.

Корреспондент. Рәхмәт. Без юлда туктап ашадык.

Әхмәдиев. И, юлда ашау инде ул... Татарстан халкының ашказаны, бавыры, үт куыгы Чаллы трассасындагы тукталышта тамак ялгап эштән чыкты. Әнә безнең баш врач Бакеев не даст соврать. Гөлчирә, әйбәтләп сыйла кунакларны. Аннары микроавтобус аларны Сәйфиләр йорты янына алып килсен. *(Гөлчирәнең колагына пышылдый.)* Озаккарак тоткарларга тырыш боларны.

*Әхмәдиев йөгереп чыгып китә.*

## 6

*Сәйфиләр ишегалды. Сәйфи кунаклаган агач төбенә Әхмәдиев килә.*

Әхмәдиев. Сәйфи Мингалимович! Әйдә, әйбәтләп тыныч кына сөйләшик әле.

Сәйфи. Мине кысрыклаудан туктасагыз гына сөйләшәчәкмен.

Әхмәдиев. Сине кысрыклаучы юк ла.

Сәйфи. Мине районнан чыгармыйсыз. Мин протест белдерәм!

Әхмәдиев. Районнан чыксаң, нәрсәгә дучар буласыңны күз алдына китерүе дә кыен. Синең ул даруыңны системага каршы баш күтәрү дип кабул итәчәкләр, шуны аңламыйсыңмыни, укымышлы башың белән?!

Сәйфи. Сез минем өчен кайгырмагыз. Хәер, сез үзегез өчен борчыласыз.

Әхмәдиев. Әйдә, шартларыңны куй. Нинди таләпләрең бар? Миңа, главага, гозерләрең бардыр?

Сәйфи. Районнагы яшәешне үзгәртик.

Әхмәдиев. Кулдан килгәнчә, булдыра алганча үзгәрешләр ясарбыз. Сине мәктәп директоры итеп куярбыз, бәлки РОНО белән җитәкчелек итәрсең. Хатыныңның китапханәсенә мең китап кайтартырмын, икегезнең дә хезмәт хакы зур булыр.

Сәйфи. Сез шәхси мәнфәгатьләрем өчен тырышам дип уйлыйсызмыни?

Әхмәдиев. Ә нәрсә өчен тагын?

Сәйфи. Ә поселок? Ә район? Ә халык?

Әхмәдиев. Иртәгә үк халык таләпләрен үти башлаячакбыз. Кайнар линия ясыйбыз, контрольдә тотарбыз. Минем бер үтенечем бар—анда «Эфир»дан, «Город» программасыннан төшерү группасы килгән. Авызыңны чамалап ач инде, яме. Безнең мондагы хәлләрне Казанда белмәсеннәр иде.

*Төшерү группасы килә.*

Корреспондент. Исәнмесез!

Сәйфи *(Корреспондентка күренер өчен кычкыра)*. Исәнмесез!

Корреспондент *(Сәйфине күреп ала)*. Без Казаннан, «Эфир» телекомпаниясеннән.

Сәйфи. Бик әйбәт. Тыңлыйм сезне.

Корреспондент. Сез химия укытучысы...

Сәйфи. Идем. Кыскарттылар.

Корреспондент. Сез ришвәтчелеккә каршы дару уйлап тапкансыз икән.

Сәйфи. Әйе. Иртән бер төймә дару капканнан соң, кешенең «Время» программасына хәтле взятка аласы килми. Должностьларда утыручы барлык чиновникларга эчертсәк, илдә коррупция бетәчәк.

Әхмәдиев *(кыбырсып)*. Ләкин аны әле киң чыгарылышка куярга кирәкмидер.

Корреспондент. Ә ул даруны ничек барлык чиновникларга эчертү мөмкин булыр икән?

Әхмәдиев. Мин дә шулай дим—бирсенә даруны эчертеп, икенчесе эчми калса? Кемгәдер эчерткән арада, инде

эчкәненең организмыннан дару шаукымы чыгып бетсә?

Корреспондент. Ничек ул даруны менләгән-менләгән кешегә берьюлы эчертмәк кирәк, бәлки, үзегез әйтерсез?

Сәйфи. Үзәк водоснабжениегә салачакбыз. Һәр фатирга краннан су белән киләчәк ул препарат. Бөтен халык эчсен ул даруны.

Корреспондент *(көлә)*. Взятка алучылар «Олероли» эчә бит, краннан түгел! Агачтан жиргә төшәргә вакыт сезгә.

Сәйфи. Сез ришвәтчелеккә каршы көрәштә катнашырга телисезме?

Корреспондент. Теләмәсәк, без монда килер идекмени?

Сәйфи. Алайса, мине «Эфир»дан күрсәтегез. Мине районнан чыгармыйлар, кысрыклыйлар, җавапка тартырга уйлыйлар. Фәкать комсызлыкны бетерә торган дару уйлап чыгарганым өчен генә.

Корреспондент. Озак утырачаксызмы агач башында?

Сәйфи. Сез мине телевизордан күрсәтеп, халыкка, дәүләт җитәкчеләренә минем турында сөйләсәгез һәм дә сезнең ярдәм белән мине эзәрлекләүдән туктасалар, мин агачтан җиргә төшәчәкмен.

Корреспондент. Гафу итегез, ә хажәтләрегезне сез ничек башкарасыз?

Сәйфи. Төнлә, кеше күрмәгәндә. Кече хажәтне болай гына. Ә зурысын башкарырга хатыным чиләк менгерә, аннары чиләкне бау белән төшерәм, хатын илтеп түгә.

Корреспондент. Ә юыну?

Сәйфи. Юыну шулай ук чиләк ярдәмендә. Хатын чиләккә су тутыра, мин аны бау белән тартып алам, шушында коенам.

Корреспондент. Гафу итегез, суны да шул ук бер чиләктә, ягъни хажәт башкарган чиләктә бирәме?

Сәйфи. Нишләп алай булсын инде! Сезнең башка сорауларыгыз юкмыни? Нишләп сез, «Эфир» каналы, коррупциягә каршы көрәш турында сөйләшәсе урынга, һәрвакыт пычрак, тузга язмаган сораулар белән халык башын катырасыз?!

Корреспондент *(кызып китә)*. Сезнең ни хакыгыз бар безнең телеканал турында андый фикер әйтергә?!

Сәйфи. Китегез! Минем печ итәсем килә!

*Барысы да читкә тайпылалар, аннары бакчаның ерак почмагына китәләр.*

Әхмәдиев *(Корреспондентка ялагайланып)*. Үпкәләмәгез, зинһар. Акылга зәгыйфь кешегә үпкәләргә ярамый.

Корреспондент *(Сәйфигә ямьсез итеп карый)*. Фу, дурак какой-то!

Әхмәдиев *(Корреспондент ишетерлек кенә итеп)*. Дурак ул, дурак! Тиле булмаса стенага башы белән бәрелергә маташмас иде ул. Сезгә минем үтенечем бар: аның турында бөтенләй сөйләмәгез телевизордан, дурак икәнен дә әйтмәгез, бөтенләй күрсәтмәгез. Акылдан язган кешеләр дөньяда бихисап, аларга игътибар итәргә кирәкми.

Корреспондент. Хам! Нәрсә дип утыра бит. Эфир турында нәрсә ди, наха-а-ал! Аны мыскыл итеп, җүләр дип күрсәтик мәллә?

Әхмәдиев. Юк, юк! Минемчә, бөтенләй күрсәтергә ярамый. Андый тилене күрсәтсән, әбизәтелне аны яклаучылар табылачак, коррупциягә каршы көрәшүчене агач башына куып менгергәннәр, диючеләр булачак.

Корреспондент. Әйе шул.

Әхмәдиев *(Корреспондентны читкәрәк алып китә)*. Сезнең эш тә бик авыр инде... Гел юлда, хезмәт хакыгыз да аздыр инде...

Корреспондент. Шулайрак шул.

Әхмәдиев. Мин сезгә бераз матди ярдәм күрсәтә алам... Спонсор буларак инде...

Корреспондент. Безгә бер яхшы камера кирәк иде. *(Төшерүче тоткан камерага ымлап.)* Менә бит нинди иске камера белән йөрибез.

Әхмәдиев *(кычкыра)*. Әбүзәр!

*Каяндыр Әбүзәр килеп чыга.*

Әхмәдиев. Район гәҗитенең сиксән еллыгына бүләк ителгән камераны, эт сигәнче монда алып килеп, менә бу «Эфир» группасына тапшыр.

Әбүзәр *(күзләрен акайтып)*. Ник?

Әхмәдиев. Сиңа нигә ул? Ә боларга ул бик кирәк.

*Әбүзәр шалперәеп китеп бара.*

Корреспондент. Сезгә тагын бер үтенечем бар. Минем энем медицина академиясен тәмамлады, лечебный факультетны. Направление буенча ул сезнең поселок хастаханәсенә эшкә килде. Аңа монда берәр ничек ярдәм итсәгез иде.

Әхмәдиев *(кычкыра)*. Бакеев!

*Каяндыр Бакеев килеп чыга.*

Бакеев. Тыңлыйм, Фоат Абзалович.

Әхмәдиев. Энегезнең исем-фамилиясе ничек?

Бакеев. Бакеев Гәрәй... Сез аны беләсез бит, баш ветврач булып эшли.

Әхмәдиев. Синекен сорамыйм мин. *(Корреспондентка.)* Исем-фамилиясе ничек энегезнең?

Корреспондент. Шуруев Пафнутий Лютикович.

Әхмәдиев *(Бакеевка)*. Андый кеше эшлиме синдә?

Бакеев. Әйе, эшли, терапевт булып.

Әхмәдиев. Менә бу хөрмәтле журналист кызның энесе икән ул. Аңа җил-яңгыр тигезмә, яме.

Бакеев *(Корреспондентка елмаеп)*. Бик сәләтле, уйлый белүче, акыллы табиб сезнең энегез. Мин аны шушы арада терапия бүлегенең җитәкчесе итеп куячакмын.

Корреспондент. Рәхмәт сезгә.

Әхмәдиев. Ә хәзер, әйдәгез, миңа киттек.

Бакеев *(Корреспондент ишетмәслек итеп)*. Шул хәтле надан аның энесе. Акча түләп укыган кешедән нинди табиб чыксын.

Әхмәдиев *(пышылдап)*. Тс-с-с, әлегә ярдәм иткән булырсың да, аннары теләсә нишләтерсең үзен. *(Барысы да ишетелерлек итеп.)* Әйдәгез, миңа киттек!

*Барысы да китәләр.*

## 7

*Шул ук күренеш. Күпмедер вакыт үткән. Сәйфи янына Руфия килә.*

Руфия *(хәлсез)*. Сәйфи, мин арыдым.

Сәйфи *(битараф)*. Ятып тор.

Руфия *(ялына)*. Төш агачтан. Синең таләпләреңнең күбесен үтәделәр бит. Инде культура сараенда ремонт ясадылар. Китапханәгә китаплар кайтартылды. Хезмәт хакым хәзер уникe мең. Унике мең, аңлыйсыңмы? Өч мең ала идем бит. Төш! Күрсәт препаратларыңны. Бөтен дөньяга каршы көрәшмәкче буласыңмыни соң син?

Сәйфи. Син нишләп миңа, үз иренә теләктәшлек белдерәсе урынга, мине көрәшемнән баш тартырга өндисең?!

Руфия. Ахыры фаҗигале тәмамланмагае. Инде урамыбызда юлны төзекләндерделәр.

Сәйфи. Безнең барыбер машинабыз юк.

Руфия. Мәктәпләрне ремонтларга РОНОга акча күчергәннәр.

Сәйфи. Ул акчаның яртысын барыбер урлап бетерәчәкләр.

Руфия. Мин шуңа тагы да ныграк борчыла башладым—бүген иртән «Эхо Москвы»дан синең турыда әйттеләр. Инде Мәскәүдә дә беләләр хәзер синең хакта.

Сәйфи *(сөенә)*. Бик яхшы.

Руфия *(еламсырап)*. Куркам!

*Әхмәдиев, аның ярдәмчеләре килеп җитәләр.*

Әхмәдиев *(ярдәмчеләренә)*. Без шул бер химикны агачтан төшерә алмыйбыз. Влач бармы бездә, юкмы? Инде Мәскәүдә беләләр! Әле аларга мәгълүмат имеш-мимешләр формасында гына барып җиткән. Путин белән Медведев кызыксына башласалар, нишләрбез?

Ханнанов. Алар үзләре коррупциягә каршы көрәш игълан иттеләр. Шуңа күрә безгә моны ничек тә агачтан төшерергә кирәк тә, ничек тә булса юмалап игә китерергә кирәк.

Әхмәдиев. Нишләп соң моңарчы һаман җаен таба алмыйсыз?! *(Кычкырып.)* Кая подъемник?

*Шул арада төзүчеләр һәм малярлар куллана торган подъемникны китерәләр.*

Әхмәдиев *(Сәйфигә эндәшә).* Сәйфи Мингалимович! Рас инде үзең төшәргә теләмисең икән, рөхсәт ит, мин үзем синең янына менәм. Беркемгә ишеттермичә генә әңгәмә корып алыйк әле синең белән.

Сәйфи *(кыланып).* Минем приемный көн түгел!

Мусин. Үзегезне түбәнсетеп менеп йөрмәгез инде, Фоат Абзалович.

Әхмәдиев *(бармагын өскә күтәреп).* Без үзебез халыкка таба барырга тиешбез.

*Подъемник Әхмәдиевне өскә күтәрә. Сәйфи белән тигезләшкәч, Әхмәдиевне тагын чак кына югарырак күтәрәләр.*

Әхмәдиев. РОНОда кадрлар арасында үзгәрешләр ясадык. Син эшләгән мәктәп директорын кудык. Сине мәктәп директоры итеп куябыз. РОНО белән житәкчелек итә алсаң, РОНО башлыгы итеп куярмын.

Сәйфи *(көлемсерәп).* Ришвәтчелеккә каршы дару уйлап чыгарган кешене сатып алмакчы буласызмы?

Әхмәдиев. Ил күләмендә ришвәтчелеккә каршы көрәшү мөмкин түгел, шуны аңламыйсыңмыни? Инде синең ала карга сыман агач ботагында утыруыңны Мәскәүдә беләләр.

Сәйфи. Бик яхшы.

Әхмәдиев. Яхшыдырмы, юкмы—әле билгеле түгел. Снайпер жибәрмәгәйләре. Бир даруыңны, үзем эчәм, калганнарын иң зур чиновникларга өләшәм.

Сәйфи. Бирмим.

Әхмәдиев. Нишләп мине дошман итәсең соң син? Сине тынычландырыр өчен, агачтан төшерер өчен, препаратларыңны тикшереп карар өчен районда нинди төзелешләр башладык, күпме эшләр эшләдек! Район үзең танырлык түгел. Син монда агач башында утырганга гына күрмисең.

Сәйфи. Акча урлау, ришвәтчелек, кода-кодагыйлык—болары да беттеме?

Әхмәдиев. Ничек бетсен ул! Взяткасыз булмый. Без бит аерым стакандагы су түгел. Без зур бер бассейндагы болганчык су! Россиянең бер башыннан икенче башына барыр өчен дә ничә көн кирәк бит. Ничек ришвәтчелекне бетереп булсын ди!

Сәйфи. Мин Мәскәүгә барырга тиеш.

Әхмәдиев. Ә мин кире кайтмассың дип куркам. Башыңны харап итәрләр дә, бәддогасы миңа булыр. «Нишләп коррупциягә каршы дару тапкан кеше юкка чыкты?!»—дип миннән сораячаклар. Син минем белән бергәлектә хәрәкәт итәргә тиеш хәзер. Төш жиргә!

Сәйфи *(катгый итеп).* Төшмим!

Әхмәдиев *(аска карап кычкыра).* Төшерегез мине!

*Әхмәдиевне подъемник белән төшерәләр.*

Бакеев *(башын калкытып Сәйфигә акыра).* Нинди кеше соң син?!

Сәйфи *(көлә).* Туктагыз әле! Нишләп сез шул хәтле ыгы-зыгы куптардыгыз?! Минем бит сезне ришвәтчелектә гаепләгәнем юк әле. Безнең район коррупциягә батты дигәнем булмады. Мин бит дару ясадым дип кенә әйттем. Сез бит үзегезне үзегез рисвай иттегез. Мин бит хәтта монда кулланырга тәкъдим итмәдем препаратларымны. Мин бит Казанга, аннан Мәскәүгә барырга гына жыенган идем. Ник болай котсыз калдыгыз соң сез?

Ханнанов. Бәлки, синең даруың да юктыр?

Сәйфи. Бар! Әле мин яңа төрлесен чыгарачакмын. Акчага аллергия ясый торганын. Мәсәлән, акчаны күргәч, яки кулга алгач, бөтен тәнең кутырлана, лихорадка башлана, авызыңнан күбек килә, астыңа сиясең...

Бакеев *(кул селти).* Моның белән сөйләшеп булмый.

Әхмәдиев *(йодрыкларын төйнәп өскә карап ала).* Киттек!

*Барысы да китәләр. Караңгы төшә. Сәхнә яктырганда агач төбенә халык жыела. Барысы да Сәйфине тиргәргә тотыналар.*

—Нигә син дөньяның астын өскә китерәсең?

—Берүк кулланма ул даруны, ташла, бетер, юк ит!

—Малайларыбыз үсеп житеп килә.

Армия яшенә житкәч, военкоматта взятка бирә алмасак нишләрбез?

—Болай булса, сине уголовниклар үтерәчәкләр. Прокурорлар синең дару аркасында ришвәт алмый башласалар братвага бик читен булачак.

—Адым саен акча төртсәң генә кешеләрчә яшәп була!

—ГИБДД взятка алмый башласа барыбыз да машина йөртү правасыннан колак кагачакбыз бит!

—Синең даруны куллансалар, балаларыбызны укырга да кертә алмый җәфаланачакбыз!

—«Регистрационная палата»да, «земельный комитет»та, БТИларда, налог инспекциясендә, машинаны учетка куйганда чират торып шунда егылып үләчәкбез бит!

—Взятка бирми ничек яшәмәк кирәк?!

—Акча төртмәсәң, врач та юньләп карамый бит!

—Син бөтен илгә каршы барып нишләмәкче буласың!

—Харап итәләр сине!

—Җиргә төш, сволочь!

Сәйфи. Мин сезне әнә шул акча төртүдән, взятка бирүдән, чиратлардан азат итәр өчен дару уйлап чыгардым. Моның өчен сездә миңа карата нәфрәт уяныр дип уйламаган идем.

—Ничек азат итеп булсын! Бөтен тормышыбыз шуңа корылган!

—Төш!

Сәйфи. Төшмим! Куркам мин сездән.

—Хәзер үзебез йолкып төшерәбез!

—Асылынам дип куркыткан була! Асылынсын!

*Халык кызганнан-кыза бара.*

—Агачны кисеп аударырга кирәк!

—Снайпер кирәк монда!

*Бакча читендә маска кигән кара киемле кеше күренә. Кулында снайпер винтовкасы. Ул иелә-иелә читтән күзәтеп йөри.*

—Без монда юк чакта атып төшерсеннәр.

—Бензопила алып киләбез дигәннәр иде бит.

*Иске «Дружба-4» бензопычкысы тотып бирәү пәйда була. Стартер тросын тартып кабыза. Инде агачны кисәм дигәндә генә Ханнанов, милиционерларны ияртеп, килеп чыга.*

Ханнанов *(кычкыра).* Стоп! Минем рөхсәттән башка кыймылдамагыз да!

*Снайпер кача.*

Ханнанов *(халыкка).* Самосуд ясарга ярамый. Аның турында хәбәр бөтен илгә таралды. Казаннан бер вәкаләтле кеше килде. Таралыгыз! Кирәк булса, сезне үзебез җыярбыз. Таралыгыз, таралыгыз! Әнә Казан кешесе килеп тә җитте.

*Халык тарала. Казан кешесе, Әхмәдиев, тагын берничә кеше киләләр.*

Казан кешесе. Кайда ул?

Ханнанов *(агач ботагына күрсәтеп).* Әнә ул.

Казан кешесе *(Сәйфигә).* Исәнмесез!

Сәйфи *(аска карап).* Исәнмесез! Сез кем буласыз?

Казан кешесе. Мине Казаннан монда сезнең белән бәйле вакыйганы ачыкларга дип җибәрделәр. Район үзеге бик нык үзгәргән. Төзелешләр, чистарыну эшләре дәвам итә. Моны сез коррупциягә каршы уйлап чыгарган дару ярдәме дип аңларгамы?

Сәйфи. Моны район житәкчеләреннән сорагыз. Мине Мәскәүгә җибәрмәделәр. Агачтан төшсәм, мине бүген үк Мәскәүгә озатырга ярдәм итәрсезме?

Казан кешесе. Юк, сезгә башта Татарстанның врачлары карамагында реабилитация үтәргә кирәк, аннары берәр санаторийда ял иттерү мәслихәт.

Сәйфи. Мин беркемгә дә ышанмыйм. Миңа шушында вертолет китерегез, мине Мәскәүгә озатыгыз.

Казан кешесе. Мөмкин түгел. Мәскәү тирәсендә урманнар яна, анда бу арада вертолет түгел, каргалар да очмый. Ясаган препаратлар үзегез беләнме?

Сәйфи. Әйтмим! Гафу итегез, печ итәр вакытым житте. Агач астында тормавыгызны үтенәм.

*Барысы да тиз генә читкә китәләр.*

Казан кешесе *(ачуланып)*. Нүҗәли берничек тә җайга китереп булмый моны? Нүҗәли аның бу дөньяда кызыккан бернәрсәсе дә юк? Нүҗәли сатып алу мөмкин түгел моны?

Әхмәдиев. Миллион сумны да алмады. Район үзәген янартканга сөенеп тик утыра. Ясаган даруы белән бөтен Россиядә тәртип урнаштырам дип хыяллана.

Казан кешесе. Сатылмый торган кеше юк бу дөньяда, сөйләшә белмисездер.

Әхмәдиев. Инде әллә нинләр тәкъдим итеп карадык. Ясаган препаратларын үзе эчеп утыра бугай ул анда.

Казан кешесе *(Әхмәдиевкә)*. Даруын үзегезнең кабып караганыгыз булмадымы?

Әхмәдиев. Юк. Бирми бит. Бер таблетка капкач, взяткадан косасы килә ди.

Казан кешесе. Шуннан соң взятка тәкъдим итсәләр гел косасы килә диме?

Әхмәдиев. Көн саен берне эчәргә кирәк ди.

Казан кешесе. Даруының берсен булса да кулга төшерә алмадыгызмыни?

Әхмәдиев. Аның белән сөйләшеп тә булмый бит.

Казан кешесе *(Сәйфигә)*. Мина, Казаннан килгән вәкилгә, берәр төймә дару бирмәссезме икән?

Әхмәдиев. Юк, башта Россия Президенты белән очрашам, аннары даруны иң зур галимнәр комиссиясенә тапшырам.

Казан кешесе *(Әхмәдиевкә)*. Моны Мәскәүгә җибәрергә ярамый.

Әхмәдиев. Шуңа блокировать иттек бит без аны.

Казан кешесе. Мәскәүдән тикшерүчеләр килеп җиткәнче моның белән бу кәнитилне бетерергә кирәк.

Әхмәдиев. Нишлик соң? Инде күпме түбәнсендек. Аның кушуы буенча район үзәген ялтыраттык, юллар салдык. Базардагы бәяләрне халык өчен төшердек. Убытокка батып беттек. Тагын ничек ярарга соң бу химикка? Үзем атып төшерердәй булам инде мин аны.

Казан кешесе. Тынычлан, тынычлан. Мин сиңа шуны тәкъдим итәм: Мәскәүдән тикшерүчеләр килеп җиткәнче, аның бу иске йортын сүтеп, дүрт катлы коттедж салып куярга кирәк! Срочно! Ишегалдына затлы машина китереп куярга кирәк! Үзен компрометировать итәр өчен. Инспекция килгәч, күрсен—нинди шартларда яшәп ята. Шантаж белән таләп итте дибез. Кичектермичә эшләргә кирәк моны. Коттеджы тирәсендә проституткалар чуалсын. Гел музыка акырып торсын. Кешеләр алдында да яман атын чыгарырга, уңайсыз хәлдә калдырырга кирәк. Хатыны ничек?

Әхмәдиев. Соңгы вакытта хатыны да туйды аның бу сәерлегеннән. Хатынын авызлыкладык инде без аның.

Казан кешесе. Хатынына күп итеп акча бирегез, янында бай, затлы ирләр бөтерелсен. Боларның барысын да мәскәүләр килеп җиткәнче эшләргә кирәк. Без бу химикны йөгәнләргә тиеш һәм дә аның таланты, дарулары безнең мәнфәгатьләргә хезмәт итәргә тиеш!

## 8

*Шактый вакыт узган. Сәйфинең иске йорты кырыена дүрт катлы коттедж салынган. Коттедж каршында тулы приводлы затлы машина тора. Бакча, йорт-җир тирәсе европача баетылган, фонтан бәреп тора, экзотик үсемлекләр күренә. Хатыны Руфия супермаркеттан кайтып керә. Аны танырлык түгел—киеме, чәче, үз-үзен тотышы затлыланган.*

Руфия *(пакетларын күтәреп агач янына килә)*. Супермаркеттан сиңа тәмле-тәмле әйберләр алып кайттым.

Сәйфи *(өстән)*. Үзең аша!

Суфия. Киреләнмә инде. Безгә язмыш шундый мөмкинлек бирде, без үзебез мондый коттедж сала алмас идек. Мондый ризыкларны кайчан ашар идек әле! Улыбызның армиядән кайтуына нинди зур бүләк булачак бу! Төш агачтан, Сәйфи!

Сәйфи. Сине сатып алдылар. Син, шушындый зур ришвәт алып, миңа хыянәт иттең. Мин баш тартам бу кот-

теджлан, бу машинадан, син алган акчадан! Мин хәтта синнән дә баш тартырга мәҗбүр. Күпме яшәп, синең асылыңны монарчы аңламаганмын икән.

Руфия. Сиңа беркем бернинди начарлык эшләргә җыенмый. Сиңа шушындый зур бүләк ясадылар! Ә бу препаратың белән гомереңкайда ничек тәмамланыр—билгесез. Төш җиргә! Рәхмәт әйт тә, кабул ит шушы күктән яуган бүләкләрне.

Сәйфи. Бу коттеджны, машинаны, тәкъдим ителгән должностьны, сиңа бирелгән акчаны, бүләкләрне кабул иткән өчен барыбер җавап тотарга тиеш булачакмын. Бушлай бернәрсә дә бирелми!

Руфия. Бушлай түгел бит. Шушы бүләкләр бәрабәренә даруыңның серен ачарга тиеш буласың, ясалганнарын Әхмәдиевкә тапшырырсың.

Сәйфи. Ә бәлки миндә ул дару юктыр, бәлки, мин алдаганмындыр, бәлки, мин андый препаратны ясамаганмындыр!

Руфия. Алай булса, бигрәк тә яхшы. Шулай дип халык алдында әйтерсең дә, вәссәләм. Бу коттеджны кире алмаячаклар бит инде.

Сәйфи. Ә-ә-ә юу-у-ук. Син китап күп укысаң да, акылга сай кеше иден, хәзер инде бөтенләй түбәнгә тәгәрәп барасың.

Руфия *(кызып)*. Минем түземлегемнең дә чиге бар! Кайчаннан бирле киеренкелектә тотасың, ә хәзер инде мине мыскыл итә башладың! Мин бит чын-чынлап үпкәли дә алам!

Сәйфи. Нинди үпкәләү—әнә дүрт катлы коттеджда яшәп ятасың хәзер. Миңа үпкәләп нишләмәкче буласың тагын?

Руфия. Минме? Мин бүген «ночной клуб»ка барам!

*Руфия тыр-тыр атлап коттеджга кереп китә. Әбүзәр килә, исерек.*

Әбүзәр *(елый)*. Сәйфи! Бетерделәр мине. Бөтенләй эшсез калдым. Хатын китте, улым минем белән сөйләшми, кызым каргый.

Сәйфи. Мин сиңа берничек тә ярдәм италмыйм.

Әбүзәр. Минем бердәнбер чарам калды—синең яныңа менү.

Сәйфи. Кирәкми, кирәкми, монда сиңа урын юк!

*Әбүзәр агачка менеп карый, булдыра алмый, егылып төшә. Шундук агач төбендә ятып йокыга тала.*

*Караңгы төшә. Руфия киенеп-ясанып, биек үкчәле туфли киеп, төнге клубка чыгып китә.*

*Бераздан, кыска итәкле юбкадан, күкрәкләренең яртысы күренерлек итеп тегелгән блузкадан Гөлчирә пәйда була. Эротик музыка яңгырый. Гөлчирә акрын музыка астында ярымшәрә калып, фонарь баганасына бот араларын ышкыйышкый стриптиз бии. Әбүзәр уяна да күзләрен акайтып аңа карап утыра.*

## 9

*Шул ук күренеш. Бакча читендә район житәкчеләре, нәрсә булып бетәр икән дип, куркып торалар. Барысы да галстуклы, арада хәрби киемлеләр бар, милиция формасы кигәннәре күренә. Уртада район мәчетенең Имамы тора—гарәп иленнән кайтарткан затлы киемнән, чалмасын зур итеп урап куйган.*

Ханнанов. Кем киләсен төгәл әйтмәделәрмени?

Әхмәдиев. Юк. Мәскәүдән шалтыраттылар. Президент аппаратыннан берәү сөйләште. Безнең кеше сезгә килеп житәчәк, диде.

Мусин. Ник куркабыз соң без?!

Әхмәдиев. Курыкканыбызны белгерттек шул инде.

Мутиева. Аны кайдадыр башка жирдә каршы алырга тиештер бит без, һичьюгы сезнең бина янында.

Әхмәдиев. Юк. «Будьте там, под деревом,—диделәр.—Прямо туда прибудут»,—диделәр.

Бакеев. «Будьте под деревом...»—бигрәк куркыныч яңгырый.

*Машина килеп туктый. Мәскәү кешесе килә. Барысы да тезелеп басалар. Әхмәдиев Мәскәү кешесенә таба атлый.*

Әхмәдиев. Район житәкчесе Әхмәдиев Фоат Абзалович.

Мәскәү кешесе *(кул биреп күрешә).* Дуев Риф Әбульмәмәтович. МЧС башлыгы Шойгуның агач башына менүчеләрне төшерү эшләре буенча урынбасары. *(Куен кесәсеннән алып таныклыгын күрсәтә.)*

*Дуев барысы белән дә күрешеп чыга. Һәрберсе күрешкәндә үзләренең фамилиясен һәм должностен әйтә:*

—Начальник милиции Тукмаков.

—Прокурор Ханнанов.

—Янгын куркынычсызлыгы бүлеге житәкчесе Шарабанов.

—Военком Мусин.

—Налог инспекциясе житәкчесенең урынбасары Свистодувка.

Мәскәү кешесе. Ә житәкче үзе кайда?

Әхмәдиев. Ул узган атнада асылынып үлде.

Мәскәү кешесе. Ник?

Әхмәдиев. Шушы химик аркасында дип уйлыйбыз. Кайчаннан бирле районда нервозлы халәт бит.

—«Земельный комитет» житәкчесе Штеккель.

—РОНО житәкчесе Мутиева.

—Баш врач Бакеев.

—Горгаз начальнигы Козявкин.

—Электросеть башлыгы Амперов.

—ГИБДД начальнигы Козлов.

—Санэпедимстанция начальнигы Маргулис.

—Роспотребнадзор житәкчесе Баһаутдинов.

—Үзәк базар директоры Ширяева.

—Район суды рәисе Фуфлов.

—Районның криминаль авторитеты «Шнырь».

Мәскәү кешесе. Мине Россия Президенты үзе жибәрде. Ни өчен Шойгу урынбасарын жибәргәннәрен аңлыйсыздыр—монда чрезвычайная ситуация, татарча әйткәндә, гадәттән тыш хәл, кеше агач башында, тегесе-монсы... Аннары, мин бит үзем Мәскәү татары. Татарлар янына татарны жибәрми кемне жибәрсеннәр инде.

Әхмәдиев *(ялагайланып).* Без бик шат.

*Мәскәү кешесе үрә катып басып торучы чиновниклар каршында кинәт усал кыяфәткә керә.*

Мәскәү кешесе. Ну, нәрсә, жәмәгать! Доигрались?! Хәзер районыгыз турында бөтен ил белә. Коррупциягә кереп баттыгызмы?

Әхмәдиев *(үзен көчкә кулга алып).* Гафу итегез, коррупция безнең районда башкалардагыннан артыграк түгел.

Мәскәү кешесе. Коррупциягә каршы көрәш игълан иткән кешене агачка куып менгергәнсез. Андый кешеләрне йә нахакка төрмәгә утырталар, йә берәр жирдә үтереп ташлыйлар, йә куркыталар, йә үзен сатып алалар—кызганычка каршы, ил буенча төрле хәлләр бар. Ә менә агач ботагына атланып көрәшеп утыручы сездә генә!

Әхмәдиев. Без куып менгермәдек аны агач башына.

Имам. Хөрмәтле Мәскәү кешесе, районыбызның житәкчеләре, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән, район үзәгебезне, юлларыбызны төзекләндерде. Яңа мәчет салдык, әлһәмделилла...

Мәскәү кешесе. Сез теге моннан биш ел элек «Фольксваген» машинагыз белән пошины бәрдереп үтергән Имаммы?

Имам. Юк, юк, әстагъфирулла, мин түгел ул. Ул Казандагы хәзрәт иде. Мин үзем үсмер вакытта мотоцикл белән бер әбинең кәжәсен бәрдергән идем, андый гөнаһым бар—гомерем буена шуңа үкенеп, тәүбә итеп яшим. Дингә дә шул кәжә аркасында кереп киттем мин.

Мәскәү кешесе. Поселогыгызны төзекләндерергә шул химик агач башына менгәч тотынгансыз бит сез. Коррупциягә кереп батмасагыз, сез химиктан куркыр идегезмени? Менә бу коттедж кемнеке?

Ханнанов. Шул химикныкы. Хатынына шәхси милек итеп билгеләнгән.

Мәскәү кешесе. Теге машина кемнеке?

Ханнанов. Машина да аныкы.

*Пауза. Мәскәү кешесе аптырабрак кала.*

Бакеев. Акылга зәгыйфьрәк кеше бугай инде ул дигәнрәк шигебез бар.

*Руфия чыга.*

Мәскәү кешесе. Ә теге хатын?

Әхмәдиев. Ул хатын да аныкы. Руфия исемле.

Мәскәү кешесе *(Руфиягә)*. Исәнмесез.

Руфия *(йөгереп килә)*. Исәнмесез.

Мәскәү кешесе *(авызын кыйшайтып)*. Шикарно живете!

Руфия *(куанычлы тавыш белән)*. Рәхмәт яусын район житәкчеләренә!

Мәскәү кешесе. Ә ирегез ришвәтчелеккә каршы көрәш игълан иткән...

Руфия. Ул акылга килер дип ышанам.

Мәскәү кешесе. Ул акыллы түгелмени?

Руфия. Соң инде, шушындый байлыклардан баш тарткач.

Мәскәү кешесе. Баш тартамы?

Руфия. Әйе.

Мәскәү кешесе. Чыннан да җүләрдер ул—шундый бүләкләрдән баш тарткач.

Барысы да. Җүләр ул, җүләр, җүләр!

Мәскәү кешесе. Ә хәзер химикның үзе белән танышыр вакыт. Кайда ул? Кайсы агач башында? *(Башын калкытып агачларны күзәтә.)*

Руфия. Әнә ул. *(Агач башында утыручы иренә ишарәли.)*

*Барысы да Сәйфи утырган агачка таба баралар. Агач төбендә бер исерек йоклый, янында берничә буш шешә ята. Мәскәү кешесе әле өскә, әле аска карый.*

Мәскәү кешесе. Кайсысы химик соң монын?

Барысы да. Өстәгесе, өстәгесе.

Мәскәү кешесе. Ә монсы кем?

Әхмәдиев. Монсы Әбүзәр, район гәҗитенең элеккеге редакторы.

Мәскәү кешесе. Хәзер монда кучтемени?

Руфия. Ирем ясаган препарат турында мәкалә язган кеше ул.

Мәскәү кешесе. Минем анын белән сөйләшәсем килә.

Руфия *(Әбүзәрне җилтерәтеп)*. Әбүзәр, синең белән сөйләшергә телиләр.

Әбүзәр *(күзен ачмыйча гына)*. Кем?

Мәскәү кешесе. Мин антикоррупция комиссиясенен әгъзасы.

Әбүзәр *(җайлабрак ята)*. Миңа димәгәе. Коррупциягә каршы көрәшеп шушы көнгә калдым инде мин. Эшсез калдым, мыскыл иттеләр.

Мәскәү кешесе. Мин Мәскәүдән килдем.

Әбүзәр *(борын төбенә мыгырдый)*. Ә мин үзем Әгерҗедән. Кировка китәсем калган... Җүләр булдым мин... *(Тагын йокыга тала.)*

Руфия. Монын белән хәзер сөйләшүдән мәгънә юк.

Мәскәү кешесе *(өскә карап)*. Сәйфи Мингалимович, исәнмесез!

Сәйфи. Исәнмесез!

Мәскәү кешесе. Бәлки, төшәрсең?

Сәйфи. Төшмим!

Мәскәү кешесе. Ничек инде төшмисен? Мине махсус Мәскәүдән җибәрделәр. Медведев та, Путин да синең хакта хәбәрдарлар. Мин сине Россиянең башкаласына алып барырга тиеш.

Сәйфи. Мин куркам, мине Мәскәүдә кулга алачаклар. Миңа бөтенесе шулай ди.

Мәскәү кешесе. Курыкма. Нишләп сине кулга алсыннар! Үзем алып барам сине Мәскәүгә, үзем китереп куярмын.

Сәйфи. Мин ышанмыйм сезгә! Мин беркемгә дә ышанмыйм!

Мәскәү кешесе. Синең янына Медведев белән Путин үзләре килә алмыйлар бит инде. Илдә корылык, быел карабодай алтын бәясе торачак. Хәтта Шойгу да үзе килә алмый. Ил буйлап күпме урман яна. Бер Шойгуга күпме пожар!

Сәйфи. Миңа аларның гарантиясе кирәк—йә язма рәвештә, йә миңа беркем дә тимәячәген телеэфирдан әйтсеннәр.

Мәскәү кешесе. Синең белән сөйләшүе авыр икән. *(Кинәт усаллана.)* Менә нәрсә, син коррупциягә каршы көрәшәм дигән булып, взятка алгансың—бик зур размерда—коттедж, машина, акча, кызлар... Хатынын балдамайда йөзә...

Сәйфи. Мин сорамадым бит...

Мәскәү кешесе. Сорамасан да, комачауламагансың бит. Ришвәт

алунын бер формасы шул—бирүләренә каршы килмәү. Коттедж сала башлагач ник төшмәдең агачтан—төзүчеләргә ник каршы тормадын?

Сәйфи. Мина салырга сорамадым ул коттеджны.

Мәскәү кешесе. Хатынына хосусый милек итеп оформить иткәннәр бит.

Сәйфи. Мин аерам хатынны—коттеджы-ние белән! Мин баш тарттым барысыннан да! Хәзер хатынымнан да баш тартам! Анладыгызмы?

Руфия *(ачынып)*. Ни сөйлисең син, Сәйфи?! Оят!

Сәйфи. Сина оят булырга тиеш!

Мәскәү кешесе *(Әхмәдиевка)*. Взяточничествога каршы препарат таптым дип әйткән кешене ничек агач башына менгердегез сез?

Әхмәдиев. Ул үзе менеп китте.

Мәскәү кешесе. Ярый әле сезнең тирәдә урман юк. Мәнге тотып булмас иде. Нинди ысуллар белән аны төшерергә маташтыгыз?

Ханнанов. Кулланмаган ысул калмады.

Мәскәү кешесе. Минем тәкъдимем шул: йоклата торган дарулы пуля белән күтенә атарга кирәк. Хайваннарны атып йоклата торган транквилизатор белән. Аста зур брезент җәеп тотып торырга кирәк.

Бакеев *(шомраеп)*. Ялгыш үтерсәк?

Мәскәү кешесе. Андый пуля белән генә коррупциягә каршы препарат тапкан химикны үтерү мөмкин түгел. Хатынын алып китегез.

Бакеев *(Руфия янына килә)*. Тынычланыгыз, Руфия ханым. Әйдәгез, өегезгә керик, мин сезгә тынычландыра торган дару бирәм.

*Бакеев Руфияне коттеджга алып кереп китә. Мәскәү кешесе кемнәргәдер кул болгый. Бакчанын бер ягыннан кулына винтовкага охшаган корал тотып берәү пәйда була. Әхмәдиев үзенең яраннарына читкә китәргә куша. Винтовкалы кеше Сәйфи күрми торган яктан килеп анын күтенә ата. Сәйфинен «Ай!» дип кычкырып куйганы ишетелә. Шундук бакчанын икенче ягыннан ак халат кигән алты санитар кин брезент җәеп агач төбенә килеп басалар. Сәйфи әкренләп мәлҗерәя башлый, күзләре йомыла, башы бер якка салына, авыр һәм тирән итеп сулый башлый. Бераздан ул җәелгән брезентка егылып төшә. Аны тиз генә күтәреп алып китәләр. Коттеджан Бакеев чыга.*

Бакеев. Тәртипме?

*Барысы да китәләр. Әбүзәр уяна.*

Әбүзәр. Сәйфи туган! Ышанма берсенә дә! Төшмә агачтан! Мин үзем дә хәзер синең янына менәм, рөхсәт итсән кәнишне. Сәйфи! Син кайда? Сәйфи!

*Руфия чыга.*

Әбүзәр. Руфия! Сәйфи юк!

Руфия *(агач тирәли әйләнеп чыккач, кычкыра)*. Аһ! Харап иттеләр иремне!

Әбүзәр. Мин анын урынын алырга тиеш! Мин анын изге эшен дәвам итәм!

*Әбүзәр агачка үрмәләп менмәкче була, ләкин булдыра алмый, егылып төшә. Руфия кычкыра-кычкыра бакча буйлап йөгереп йөри дә юкка чыга.*

Әбүзәр *(кычкырып)*. Дело Сәйфи не пропадет! Я протестую! Мин хәзер анын урынына агачка менәм! Ну бирәм кирәгегезне!!!

## 10

*Руфия элеккеге гади киеменнән иске йортлары каршындагы эскәмиядә утыра. Кайгыга баткан. Мутиева килә, кулына чәчәк бәйләме тоткан. Чәчәкне агач төбенә куя, беркавым башын аска иеп басып тора. Аннары Руфия янына бара.*

Мутиева. Исәнмесез.

Руфия *(чак кына иреннәрен кыймылдатып)*. Исән.

Мутиева. Хәбәр-хәтере юкмы?

Руфия. Юк.

Мутиева. Мин сезнең белән

кинәшләшергә килдем. Сәйфи Мингалимовичның бронза бюстын ясатырга ниятебез бар. Глава белән сөйләшенде инде. Һәйкәлгә әле иртәрәктер...

Р у ф и я. Ник, Сәйфи исән түгелдер дип уйлыйсызмыни?

М у т и е в а. Дөнья хәлен белеп булмый...

Р у ф и я *(еламсырап).* Сез харап иттегез аны.

М у т и е в а. Алай түгел. Ул һәрвакыт көче җитмәс нәрсәләргә каршы көрәшергә маташты. Зур шәхес иде, әлбәттә...

Р у ф и я. Ничек инде «иде»? Сез бербер хәбәр ишеттегезме әллә?

М у т и е в а. Кайчаннан бирле бер мәгълүмат та юк бит. *(Паузадан соң.)* Сезне мәктәпләргә укучылар белән очрашырга чакыргаларбыз.

Р у ф и я. Ник?

М у т и е в а. Сәйфи Мингалимович турында сөйләргә. Нинди кеше иде ул, нәрсә ярата иде, гаилә тормышында нинди үзенчәлекләре бар иде—балаларга, үсеп килүче буыннарга кызык бит.

Р у ф и я *(усал тавыш белән).* Барыгыз әле, чыгып китегез! Эшегез беткәнмени?

М у т и е в а *(капка янына житкәч борыла).* Харап иттегез дигән була... Иренең сәерлеге аркасында состояние ясады да үзенә.

Р у ф и я *(җан ачысы белән).* Чыгып китегез! Күземә күренмәгез бүтән!

*Мутиева чыгып китә. Руфия битен куллары белән каплап елый. Чиновниклар берәм-берәм керәләр, һәрберсенең кулында чәчәк бәйләме. Берничә венок та бар. Чәчәкләрне, венокларны бер-бер артлы агач төбенә китереп куялар һәм чыгып китәләр. Агач төбендә чәчәкләр өеме барлыкка килә.*

*Музыка.*

*Руфия агач төбенә килеп чәчәкләргә карап тора, аннары бакча буйлап атлый.*

*Шул вакытны Сәйфи кайтып керә. Тыныч. Йөзендә моңсу елмаю. Тып-тын гына хатынын күзәтеп карап тора. Руфия анын күз карашын җилкәсе белән тоеп кинәт борыла.*

Р у ф и я. Сәйфи!

С ә й ф и. Руфия!

*Бер-берсенә таба ыргылалар. Кочаклашалар.*

Р у ф и я. Исән!

С ә й ф и. Үзем дә шаккатам!

Р у ф и я. Инде әллә ниләр уйлап ут йотып яттым.

С ә й ф и *(хатынын җентекләп күзәтә).* Ябыккансың.

Р у ф и я. Син киткәннән бирле юньләп йоклаганым юк, тамагыма ризык керми.

С ә й ф и. Соңгы вакытта супермаркетка йөри башлаган идең бит.

Р у ф и я. Сине котыртып агачтан төшерер өчен генә кыланып йөрдем бит мин. Миңа андый ризык кирәкми, миңа бу коттеджның кирәге юк, миңа берни кирәкми, миңа син кирәк, Сәйфи!

С ә й ф и. Син бу коттеджда яшәмисеңмени?

Р у ф и я. Юк, синең белән өйләнешкәннән бирле яшәгән шушы иске йортыбыз минем өчен иң кадерлесе.

С ә й ф и. Их, Руфия! Мин бит инде сине югалтканмындыр дип уйлаган идем. Соңгы вакытта төнге клубларга, рестораннарга йөри башлагач...

Р у ф и я. Мине чынлап та «ночной клубларга», рестораннарга йөрде дип уйладыңмыни? Мин бит сине агачтан төшерер өчен генә нервыңда уйнап шулай дип әйтә идем.

С ә й ф и *(хатынын кочаклап үбә).* Их, Руфия, җаным, бәгърем!

Р у ф и я. Улыбыздан кичә генә хат килде.

С ә й ф и. Хәзер укырбыз. Белсәң иде сине ничек сагынганымны!

Р у ф и я. Минем сине ничек сагынганымны белсәң иде син!

*Алар тагын кочаклашалар. Бу вакытта Әхмәдиев атылып килеп керә. Аның да кулында чәчәк бәйләме.*

Ә х м ә д и е в. Сәйфи Мингалимович! Синең кайтканыңны күреп хәбәр иттеләр дә, сине күрергә ашыктым. *(Агач төбендәге чәчәкләр өеменә күз ташлый, үзенең кулындагы чәчәк бәйләмен Руфиягә тоттыра.)* Бу сезгә.

Р у ф и я *(чәчәкләрне ала).* Рәхмәт!

Ә х м ә д и е в *(Сәйфигә).* Хәлең ничек? Исән-саумы?

С ә й ф и. Күргәнегезчә. *(Кул биреп*

*курешәләр.)*

Әхмәдиев. Ничекләр, нәрсәләр булып бетте анда? Нишләттеләр? Кайларда булдың?

Сәйфи *(моңсу елмаеп).* Мәскәүдә.

Әхмәдиев. Препаратыңның язмышы ничек хәл ителде?

Сәйфи *(гел елмаебрак, тыныч кына сөйләшә).* Мин ясаган даруны кабул итмәделәр. Аны Мәскәүдәге чиновникларның ризыкларына яшертен генә салып карадылар. Минем даруны капкан чиновниклар, киресенчә, взятканы күбрәк ала башлаганнар. Бу очраклы хәлдер, әлбәттә. Әмма шулай да даруымның составын зур галимнәр комиссиясе тикшерде. Взятка тәкъдим ителгәч, дару тәэсирендә чиновникның косасы килү дөрес түгел, диделәр. Взяткага каршы препаратның көче юк, фәкать косасыны гына китерә торган дару бу, диделәр. Омтылышың хупларлык, әмма даруыңның кирәге юк, диделәр..

Әхмәдиев. Нишләп соң син тыныч һәм елмаясың? *(Бер-ике адым артка чигеп.)* Ышанмыйм! Куркыныч кеше син! Ришвәтчелеккә кизәнгән килеш, Мәскәүдән исән-сау кайттың...

Сәйфи *(көлә).* Сез үзегездән үзегез куркып яшисез. Чөнки алдауга, урлауга, ришвәтчелеккә кереп баткансыз!

Руфия *(Әхмәдиевкә).* Бу коттеджны, машинаны нишләтергә уйлыйсыз??

Әхмәдиев. Сезгә бит инде ул. Коттедж сиңа хосусый милек итеп билгеләнгән, машина да синең исемгә язылган.

Руфия. Кирәк түгел алар безгә.

Әхмәдиев. Тыныч кына яшәп ятыгыз инде шушында. Һаман кирелә-неп утырмагыз. Сәйфи Мингалимович, зинһар, бүтән мондый кәнитил куптарма! Мәктәп директоры булып урнашасыңмы?

Сәйфи. Юк, үземнең элекке урыныма—химия укытучысы булып керәм.

Руфия. Мин дә культура сараеның директоры булып түгел, гади китапханәче булып эшләячәкмен.

Әхмәдиев *(кул селти).* Үзегезгә карагыз.

Сәйфи. Минем башыма бер идея килде.

Әхмәдиев *(скәнеп).* Тагын яна препарат ясарга түгелдер бит?

Сәйфи *(көлә).* Юу-у-ук. Бу коттеджны китапханә итик. Руфия шушында яна китапханә оештырсын.

Руфия *(шатланып).* Чыннан да!

Әхмәдиев. Шулай булсын.

Сәйфи. Әбүзәрнең хәле ничек?

Әхмәдиев. Белмим.

Сәйфи. Аны район гәҗитенә баш мөхәррир итеп кире куегыз инде, яме.

Әхмәдиев. Эчүдән туктаса, восстановить итәрбез.

Сәйфи. Ә ришвәтчелеккә каршы көрәшәчәкбезме соң?

Әхмәдиев *(үтә житди кыяфәт белән).* Әлбәттә! Әмма дә ләкин аның көрәш ысулын табарга кирәк. Син ял ит башта, һаман көрәш турында уйлап утырма, иң элек хәл ал. Ярый, киттем мин. Сау булып торыгыз!

*Әхмәдиев чыгып китә.*

Руфия *(очып китәрдәй булып).* Ничек башыңа килде бу уй—коттеджны китапханә итәргә! Йортыбыз кырында гына шундый шәп китапханә булачак!

Сәйфи. Алдан ук шуны әйтәсем килә: коттеджның дүртенче катында лаборатория төзим.

Руфия *(сагаеп).* Нинди лаборатория?

Сәйфи. Мин барыбер ришвәтчелеккә каршы дару уйлап табарга тиеш. Взятка алган кешене шундук паралич суктыра торган дару ясаячакмын!

*Тәмам.*

*2010 ел.*



Рөстәм
Галиуллин

# НОМЕРЫҢ КЕМ?

ХИКӘЯ

Казансу өстендә тибрәлгән куе рәшә күзгә күренеп таралды. Ул да булмады, шул рәшә эчендә изрәгән саргылт нурлар кызгылт төскә керде һәм моңарчы үзенең җиләс-җылымса нурларында оеган кояш кинәт күтәрелгәндәй булды. Биеккәрәк менгән саен ул усалрак күренде. Күк йөзе кинәт аязды. Еракта—офыкта йоннары бүселгән зур мендәрне хәтерләтеп кабарган кара-кучкыл болытлар пәйда булды. Җәй челләсенең гадәти көне башланды.

Даң-доң! Чоңк-чыңк! Казансу буендагы төзелеш мәйданында субай кага башладылар. Тимернең тимергә бәрелүеннән колаклар тона, җаннар өши. Даң-доң, чыңк-чыңк! Бу дәһшәтле авазлар тынып торган арада, машиналарның гүләгәне ишетелә.

Казанның үзәгенә таба агылган ташкыннан бер төркем аерылып, көндәгечә, алагаем зур хәрефләр белән «Керү тыела» дигән тимер капкадан эчкә уза. Аягына күнитек кигән, биленә кара резина таяк аскан сакчы егет, дәшми генә, шик белән кызыксыну бергә укмашкан карашын керүченең түшенә ташлый:

—Номер?!

Ботинка үкчәсенең таш асфальтны тырт-тырт кыйнавыннан әлегә кадәр йокымсырап атлаган кеше дертләп китә. Аннан ашыга-ашыга түшен ача.

—Алтмыш сигез,—ди ул мескен тавыш белән.

Сакчы аның муенына калын җеп бау белән асылган катыргы кәгазьдәге санга күз сала да кирпеч, таш плитәләр һәм арматуралар өелеп торган якка таба ымлый. «Кер, рөхсәт»,—янәсе.

Ул да булмый, сакчының бурзае менә өстенә сикерәм, менә ботарлап, өзгәләп ташлыйм дип, һау-һауларга тотына. Катыргылы кәгазь асканның муенын җилкәсенә сендереп бөрешкәнен күргәч, сакчы башын артка ташлап, ләззәтләнеп көлә:

—Атла әйдә, алтмыш сигез! Әлегә бәйдә ул! Рәхмәт әйт, Сталин концлагерында этләрне сиптән ычкындырганнар да! Сез санлы сансызларны бер талатып алу ярап куяр иде...

---

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН (1987)—*язучы; «Гипнозчы малай» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Тегесе артына борыла-карый, тиз-тиз адымнар белән эчкә элдертә...

Ниһаять, эш киемнәре киелеп бетә, сонга калучылар да, тирләп-мышнап, зур әйләнә хасил итеп тезелешкән куе рәтләр артына баса. Уртада—ак каска кигән, әле утыз яше дә тулмаган, сабый карашына һич тә килешмәгән сирәк озын сакал-мыеклы Мәхмүт. Анын тирәли шулай ук «аклар» көязләнеп баскан. Аларнын мәгъруро карашлары әфлисунны урталайга ярып, шуларны башларына каплап чыккандай күренгән ирләр рәте өстеннән туктаусыз йөреп тора. Мәхмүт монда хуҗа, алай гына да түгел, ул шушы төзелеш өчен җаваплы оешманын генераль директорына якын туган тиешле дә әле. Төзелеш фирмасы—төрекләрнеке, шунлыктан бригадирларнын да күбесе төрек милләтеннән. Татар белән урыслар икешәр генә.

Мәхмүт әнә шул минутларны—иртә белән һәммәсен бергә җыеп, төрле эшләргә билгеләүне үлеп ярата. Ул, әйтерсен, эш белән шөгыльләнми, ә тантана итә. Кулында—кешеләр, төгәлрәге, «саннар» исемлеге, ул шаян кара күзенә житдилек чыгарырга тырышып, үз телендә туктаусыз сөйләнә. Ин элек, кулындагы кәгазьдән күзен аермыйча, бүген нинди эшләр булачагын укып чыга. Аннары, бик әһәмиятле эш башкаргандай, рәт арасыннан «саннарны»ны бармак белән изәп чакыра. Ләкин Мәхмүткә ярап булмый: берсенең буен ошатмый, икенчесенен—озак мыштырдавын. Күнеленә ятмаган бу күренештән анын ялтырап торган тулы битләрендә җыерчыклар барлыкка килә һәм ул түзми, тагын нәрсә кыландыра инде, сакаллы сабый, дип рәт арасыннан аерылып чыккан урыс-татар агайларына чын күнеленнән ачуланып, җилкәләренә саллы гына итеп төртеп ала яисә: «Әйди-әйди!»—дип ашыктырып, үзе теләгән урынга китереп бастыра. Мәхмүтнен уенына янындагылар да теләп кушыла: алар да бармаклары белән рәтләрдәге ир-егетләрнен әле берсенә, әле икенчесенә төртеп, аңа ярдәм итәргә тырышалар.

Ниһаять, рәтләрдәге кешеләр кечкенә төркемнәргә бүленеп бетә һәм Мәхмүт шатлыгыннан чырыйлап кычкырып җибәрә: «Әйди-әйди!». Бригадирлар да, аннан калышмыйк дигәндәй, үзләренен төркемнәрен туктаусыз әйдәкләп, төзелеш мәйданынын төрле почмакларына таралыша. Иртәнге матавыктан котылган төркемнәр җанлана: анда—монда көлешкән авазлар ишетелә башлый, тәмам салынган җилкәләр беразтурая, адымнар җиңеләя.

***

Монда тиздән Казаннын ин матур һәм затлы йорты калкып чыгачак. Казан үзәгендәге, Казансу буендагы бу йортнын өч подъездында инде эшләр тәмамланугa бара. Сонгысында—анысына бик нык лап әзерләнәләр, житәкчелек көне-төне шунда мәш килә —эш башлана гына әле, субай каккан тавышлар да шуннан килә.

—Би-ик зур түрәнеке!—дип пышылдаша ярым ачык иреннәр ул подъезд турысыннан үткәндә.—Нәселен кайгырта...

Бу сүзләрдән башлар тагын да иелә, керфекләр түбән салынып, курку йөгергән күзләрне капларга тырыша.

Тиздән башка подъездлардагы һәр фатирнын хуҗасы кем икәнлеге мәгълүм булды. Йорты бик зур булса да, фатирлар бик аз—һәммәсе дә, һич арттырусыз, ике команда туп тибәрлек мәйдан алып тора. Бу хәбәр кайсыдыр төрек бригадиры авызыннан ишетелеп, бер колактан икенчесенә күчеп, төзелештәге һәркемгә житкерелде. Иңнәренә озын арматура салып ташыган, кирпеч өеме күтәреп барган, измә болгаткан татар, урыс, чуаш һәм башкалар ишеткән яңалыкларыннан бер башка үсеп киткәндәй булды: менә нинди кешеләргә якын тора алар!

Төзелештә кемнәр генә, нинди генә милләт юк. Төрек—боерык бирә, идарә итүчеләр арасына кереп бетә алмаганнары, үз телләрендәге моңлы җырларны сузып, ашыкмый гына фиргавеннәр йортын затлы мәрмәр белән тышлый. Татар, урыс һәм чуашы аларга мәрмәр плитәләр ташып, күтәреп тора, кирпеч сала. Куе кара чәчле, саргылт эре тешле, каракучкыл тәнле көрдләр нигез эшләре белән мәш килә.

Бүген дә төшке ашка чакыру янгыраугa, олпат ирләр дә, вакытлыча эшләп йөргән студентлар да бер булып, этешә-төртешә ашханә ролен үтәгән подвалга җыелды. Яшь-җилкенчәк тиз-тиз ашап, шушы бер сәгать ял вакытында өстәмә акча эшлим дип цемент бушатырга киткәч, күптәнге дуслар—төрек Хәлил; көрдләр арасында урысча аз-маз сукалый белгән ике кешенең берсе—Дилдар; Казан арты татары, инде илленең өске ягына чыккан, кыска камыт аякларына һич килешмәгән озын гәүдәле, чәчләренә бәс кунган Камил белән аның яшьтәше, озын буен бөкрәйтеп йөргән, күк төсендәге зәңгәр күзләренең карашын еракка төбәп, әңгәмәгә сирәк кушылган шәһәр урысы Иван, ягъни Ваня күләгәле урынны сайлап, чирәмгә сузылып яттылар.

—Ник шушы төрек малайларына бил бөгеп ятабыз соң без үз җиребездә, Ваня, ә?!—Авызына капкан үләнен чәйни-чәйни, Камил һәр көнне әйтә торган сүзен кабатлады.

—Үзем дә аңламыйм.—Ваня карашын Казансудан аермый гына, тәмәкесен ләззәтләнеп суырды.

—Ә мин беләм!—Инде кырыкка якынлашса да, кыяфәте, төс-бите нәкъ егерме яшьлек егетләрнеке сыман Хәлил торып утырды. Әгәр вакытсыз агарган көмешсыман чәченә игътибар итмәсәң, Хәлилне, һичшиксез, өйләнмәгән егет дип уйларлык.—Чөнки менә бу йортның,—ул имән бармагын мәрмәр диварга төртте,—хуҗаларына безнең белән эш итү файдалы. Безнең фирма салым түләми. Акча кесәдән-кесәгә генә күчә. Өстәвенә йорт күзгә күренеп калка.

—Бик калка инде...

—Әле дә эш бара. Безнең директор көн саен казинода миллион сум оттырып кайта. Шоферы сөйләп торган: миллион сумны чыгарып салганда мыегы да селкенми ди...

—Бардак инде, бардак!—Камил гадәтенчә төкеренеп алды.—Менә быелгы җәйне чыгам да, авылыма кайтып китәм. Монда бит мине исемем белән дә атамыйлар! «Җитмеш җиде, кил, җитмеш җиде, тегене эшлә, җитмеш җиде, моны күтәр!» Коллар да мондый мәсхәрәне күрмәгән! Ә авылда мине җылы өем, хатыным, аның тәмле ризыклары, яраткан тракторым, комбайным көтә. Мин бит урып-җыю вакытларында республикада алдынгылыкны бирмәгән кеше! Казанда эшләп карыйм әле дигән булып килгән җирдән йөрим һаман да...

—Мин дә китәм!—диде Ваня, аны бүлдереп. —Боларга мескен булып бил бөккәнче, үзем эшләгән төзелеш оешмасына кире кайтам да, элеккечә кирпеч тезәм. Акча дигән булып алдандым, монда да артыгын түлим дип тормыйлар...

—Быелдан мин дә калмыйм!—Дилдар Хәлилгә күз кыры белән генә карап алды да, урысчасын вата-җимерә сөйләп китте.—Мин бит Анталиядә, диңгез буенда яшим. Үз йортым белән. Казан күрим дип кенә килгән җирдән тоткарлану...

—Әгәр сездә Наташалар булмасамы,—Хәлил аның сүзен бүлеп, гадәтенчә сикереп торды,—билләһи газыйм, шулар гына тота мине монда. Истанбулда, Босфор буенда сөйгәнем белән караблар киткәнен күзәтеп кенә утырасы кеше мин. Шунда ук безнең гаиләнең офисы урнашкан. Саф диңгез җиле, шау-шулы Истанбул!—Ул беркавым күзләрен йомган килеш тын торды.

—Марҗалар итәген капшап йөреп чир эләктерәсең инде, малай актыгы!—Камил аны күктән җиргә төшерде.

—Ә мин кичә Ләйлә исемле татар кызы белән таныштым!—Хәлилнең күзләре ялт-йолт яна башлады.

—Әйдә, йоклыйк, диденме, бозык малай?—Камилнең тавышына кырыслык бәреп чыкты.

—Юк ла, ул үзе тәкъдим итте!—Хәлил тигез тешләрен елтыратып хәйләкәр елмайды.

—Һай, мәлгунь, һай, кабахәт,—Камил Хәлилгә чын күңеленнән рәнҗеп, башын чайкады,—инде татар кызларына күчтеңмени? Синең кай җиреңә кызыкты икән инде ул татарның бичара баласы?

—Кесәмдәге акчама!—Үз сүзеннән Хәлил кычкырып көлеп җибәрде.

Камилнең йодрык янавыннан шүрләпме, ашыга-ашыга, аклана да башлады:

—Син, Камил бәй, ачуланма. Ул кызны мин бозмадым. Беләсең бит инде: без акча алган көнне барыбыз да Көньяк трассага юл тотабыз. Бу юлы кызы чибәр иде, шуңа гына таныштым. Татар кызы икәнен каян белим, аның түшенә язып куелмаган бит? Ялгышмасам, аларны да номерлары белән атыйлар бугай...

—Һай, тел бистәсе!—Камил йомарланган йодрыкларын таратты.

Хәлил, тагын сикереп торып, куллары белән һавада Ләйләнең гәүдәсен сурәтли башлады:

—Аның күзе—ут! Аның чәчләре, кабарып торган түшләре, нечкә билләре, тыгыз ботлары...

—Һай, Мәҗнүн дә үзең!—дип сукранды Камил.

—Әле мин аңа багышлап җыр да чыгардым. Хәлил төрек акценты белән татарча такмак көйли башлады:

Кызлар, кызлар, киләмен:
Иренегездән үбәмен!
Сез әнкәгез куенында—
Тилмерүдән үләм мин!..

—Җыелырга! Тиз!—Хәлил, «әфлисун башлы»ларның кычкыра-кычкыра тыз-быз йөгерешә башлауларын күреп, бүленергә мәҗбүр булды.

—Әйди-әйди!—Мәхмүтнең күзләре яна, маңгаеннан тир бөртекләре тама. Ул иртән җыела торган урында ары-бире йөренә.

—Ни булды?—дип аптырашты төшке ялларыннан вакытсыз бүленгән ирләр.

—Сөйләшмәскә!—бригадирлар берьюлы кычкырып җибәрде. Мәхмүт урыс бригадирының берсенә тиз генә нидер аңлатты да, калганнарны ияртеп, ашыга-ашыга тимер капкага таба атлады.

Зур төркем алдында ялгызы калган урыс бригадиры авызыннан кырыс фәрман яңгырады:

—Минем арттан!

Ул төзелеш эшләре иң артта сөйрәлгән подъездга кереп китте. Шөбһәле, куркулы карашларын бер-берсенә күчерә-күчерә, ана муеннарына катыргылы кәгазьгә язылган санны таккан ирләр иярде. Бригадир иң соңгы катка кадәр күтәрелде дә:

—Барыгыз да шушы фатирга керегез!—дип боерды.

Йөздән артык ир тиздән зур түрәнең назлы сөяркәсе ялгызы гына яшәячәк фатирга кереп тулды. Мондый күндәмлектән үзен уңайсызрак хис иткән бригадир аңлатуны кирәк тапты:

—Егетләр, йорт белән танышырга иң зур түрәбез үзе килгән. Ул тулаем үзенеке булган подъездның планы белән таныша. Минем аңлавымча, ул безнең төзелеш фирмасыннан бер дә канәгать түгел. «Икенче фирманы

китертәм, мондагыларның бөтенесен дә куам»,—дип әйтә ди. Ул киткәнче көтегез. Тәрәзәдән карамаска! Штраф! Атабыз!

Ирләр бердәм ухылдап куйды. Шулчак бригадирның түш кесәсендәге рация аваз бирде:

—Алтынчы! Алтынчы! Бу мин—беренче! Ун секундтан икенче подъездда бул!

Артына ут капкандай ашыгып, бригадир тыштан ишекне бикләде дә аска атылды.

—Без төрмәдә түгел бит?! Ник бикләден?—Халык бераз шаулады да тынды.

Хәлил, Дилдар һәм Камил белән Ваня бер почмакта урын табып, чүгәләделәр.

Тынлыкны Камил бозды:

—Егетләр, эштән кумасыннар иде инде,—аның тавышы шундый зәгыйфь, беркайчан ишетелмәгәнчә нечкә иде,—эшләп ватыла торган булса да, ачтан үлмәслек акчасы килеп тора иде. —Ул башларын аска игән ирләргә күз йөгерткәннән соң, сүзен дәвам итте.—Безнең авылда колхоз таралды бит. Инвестор безне—тракторчы-комбайнчыларны типкәләп чыгарды. Хатын өйдә эшсез утыра. Пенсиягә ун ел чамасы бар әле—акча юк. Малай университетта түләүле бүлектә укый, кыз—мәктәптә. Бу эш ярап торадыр иде әле...

Ваня үзенең саллы кулын аның җилкәсенә салды.

—Син әйтәсеңме, Камил, минме? Мин эшләгән фирма да янды бит—банкротлыкка чыкты. Барыр җир күренеп тормый...

—Шулай...

Хәлил ишетелер-ишетелмәс кенә моңлы төрек җырын көйли башлады.

—Мин дә Анталиядә яшәмим,—диде Дилдар, тынлыкны бүлеп.—Ничек анда яшим инде? Шәһәрен дә, дингезен дә күргәнем юк минем! Без тауларда көн күрәбез. Анда электр да, кибетләр дә юк. Казанга сарык көтеп йөргән җиремнән урлап дигәндәй, алдап алып килделәр. Бераз акчасын җибәреп торгач, хатын да канәгать, балалар да ач ятмый иде. Инде нишләрмен? Үзебезнең мөстәкыйль дәүләтебез дә юк ичмасам кайтып егылырга...

Хәлил башларын игән дусларына карап, көлеп җибәрде:

—Шайтан алгыры, миңа да дөресен сөйләргә туры килә бит. Яраткан кызымны әтисе кияүгә бирмәде, калым өчен дип акча сорады. Мин ярлы малае, көне-төне бил бөксәм дә, мантый алмадым. Хәзер инде ул кияүдә, баласы бар. Йөрәк януларын басар өчен, дөньясына үч итеп чыгып киттем Казанга. Төркиягә кайтсам, тагын йокыдан калачакмын мин!

—Ә бу йортта түрә абзыкай үзе торыр микән соң?—Камил, җавап көтеп, иптәшләренә текәлде.

—Ахмак син!—диде аңа Иван.—Авызыңнан авыл бәрәңгесе күренеп тора. Нигә дип сасы, тынчу шәһәргә килсен ул? Хәзер шәһәргә урнашу турында синең кебек дураклар гына хыяллана. Әле күбегез бер бүлмәле фатир да алмыйча үлеп китә...

Гөжләп торган фатирда авыр тынлык урнашты. Һәркем катыргылы кәгазьгә язылган номерларына текәлеп, үз уена чумды. Тынчу һавадан, уйларының авырлыгыннан уфтанып утырганда, кинәт йортның зур тимер капкасы ачылган тавыш ишетелде. Аның шыгырдавын сирена авазы күмеп китте. Түрә җансакчылары, иярченнәре белән Казан урамына атылды. Ул барасы юлның һәр чатына таралып урнашкан тәртип сакчылары, кайчаннан бирле светофорның яшел утына чыга алмый интеккән автомобиль хуҗаларына, күзләреннән усал чаткылар бөркеп, өстенлекле бер караш ташлап алдылар да түрә абзый кортежына иелә-бөгелә сәлам биреп калдылар...

... Шау-шу авазлары басылуга, ишек ачылды һәм «тоткыннар» этешә-төртешә урамга атылды.

—Әйди-әйди, эшкә!—дип кычкырды Мәхмүт туктаусыз. Аның кинәт кырысланган күзләрендә кабат шаян чаткылар кабынган.

«Санлы»лар арасында, түрә үзенең булачак подъездын ошаткан, дигән хәбәр таралды. Бу иясез яңалыктан ирләрнең маңгайларына бөрчек-бөрчек салкын тир бәреп чыкты. Шулай да алар кичерешләрен тышка чыгармыйча, үзләренә көлемсерәп караган кояшка күз ташлап, сүзсез генә эш урыннарына таба атладылар.

—Шайтан алгыры!—тынлыкны Хәлилнең яңгыравык тавышы бозды.—Түрә абзыкайның хушбуй исе борынны ярып керә. Ничә йөз меңлектер бу, ә?

—Мин дә шуны уйлап тора идем әле. Ат бәясе генә түгелдер!—Дилдар ватандашы әңгәмәсенә кушылды. —Безнең эшне ошатачагы билгеле иде инде. Хан сарае төзибез бит!

—Молодец ул безнең,—Ваня да уйлаганын дусларына җиткерергә тырышты. —Бөтенебезгә дә якты чырай күрсәтә менә. Киләчәктә дә шулай булсын иде...

—Булыр, булыр, Ходай аны ярдәменнән генә ташламасын!—Камил милләттәше белән горурланып калырга ашыкты. Авылына кайткач, зур түрә белән күрешүе турында сөйләп, күрше-тирә халкын шаккатырачак әле ул!— Ул шулкадәр яхшы кеше. Барысы белән дә үз итеп сөйләшә. Гади булмаса безгә килер идемени? Үзебезнеке шул ул! Шәп хуҗа!

—Шулай-шулай...

Түрәнең кыйммәтле хушбуй исе эленеп калган һаваны эчләренә йотып, барысы да тынсыз калдылар.

Бу вакытта юл йөрү кагыйдәләрен чүпкә дә санамый куган чит ил машиналары кортежында кукраеп барган түрәнең дә күңеле төзелеш мәйданында иде. Үзе тирәли маймыл сыман сикеренеп йөгерешүләрен ул гадәттәгечә, бик ошатты. Бигрәк тә карасөякләр—кара эшчеләр белән очраштырмаска башлары җиткәнгә куанды. Монда барыбер телевидениегә төшермиләр, гәҗит-журналларның беренче бите өчен мәкалә язарга журналистлар да юк. Алар өчен ул иртәгә—дәүләтнең төзелеш планы үтәлмәвенең сәбәпләрен ачыклаячак киңәшмәдә борчылып, кемнәрнедер сүгеп утлы табага бастырачак, боерган булса! Аның җөмләләре тагын канатлы сүзләргә әйләнер, ялагайлар, куштаннары чыгышларын шул сүзләр белән башлап җибәрер! И-их! Мангаена төзелеш мәйданыннан куныпкалган тузан бөртеген сыпырып төшерде дә, эре тешләрен балкытып, киң итеп елмайды. Бүгенге сәфәр ошады аңа! Ул үз-үзеннән канәгать булып, тәмләп киерелде. Шулчак күкрәгенә каты әйбер төртелгән сыман булды. Түрәнең күз аллары караңгыланып китте, ашыга-ашыга кармаланып, күлмәк кесәсеннән көмеш металлга уеп язылган номерын тартып чыгарды. Шулчак түш кесәләрендә алтын номер йөртүчеләрнең чырае күз алдында пәйда булып, ул калтырана башлады.

—Бәхетле мәхлуклар!—дип мыгырданды ул чиләдә тирләп-пешеп йорт төзегән катыргы кәгазьлеләрне күз алдына китереп.

Түрәнең калтыравы көчәйгәннән-көчәйде.

—Их, шулар урынында булып, алтын номер йөртүчеләрнең чыраен мәңге күрмәсәңче икән!—ул көмеш номерын тирләгән бармаклары белән туктаусыз сыпырып, һичьюгы бер генә мизгелгә булса да түшенә катыргы кәгазьгә сугылган сан тагу турында хыяллана башлады...

ШАНЛЫ 90нчы ЕЛЛАРДАН
МИЗГЕЛЛӘР



*Халык ташкыны.*



*Милли-азатлык хәрәкәте җитәкчеләренең берсе— Марат Мөлеков.*



*Гавәм халык яклауга мохтаҗ.*



*Ирек (Азатлык) мәйданында чираттагы митинг. Трибунада Зәки Зәйнуллин.*



*Фәүзия Бәйрәмованың ачлык тоткан көннәре.*




*Изге максат өчен көрәшнең дәвамнары булыр әле.*

# ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ— БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

*Шушы елның 20 маенда Казан милли-мәдәни үзәгендә Татарстан язучыларының гомуми җыелышы—әдәби ел йомгаклары кысаларында «Балалар әдәбиятының торышы һәм үсеш перспективалары» дигән темага фәнни-гамәли конференция—булып узды. Анда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И.Ибраһимов һәм Р.Зәйдулла, Л.Газизова, Г.Гыйльманов, Р.Рахмани, Л.Минһаҗева, Р.Корбан докладлары тыңланды.*

*Фикер алышуда Татарстан Мәдәният министры А.М.Сибагатуллин, Мәгариф һәм фән министрлыгының бүлек җитәкчесе Җ.Н.Мотыйгуллин һәм язучылар Р.Бәшәр, Н.Орешина, З.Хәсньяр, Б.Вайнер, Н.Сафина, Й.Миңнуллина һ.б. катнашты.*

*Журнал укучыларыбызга әлеге конференциядә яңгыраган докладларны бераз кыскартып тәкъдим итәбез.*

***

**Илфак ИБРАҺИМОВ,**

*Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе:*

Хөрмәтле каләмдәшләр!

2010 елда үткәрелгән гомуми җыелыштан соң нәкъ бер ел вакыт узып китте. Бу чорда Язучылар берлеге идарәсенең башкарган эшләре айдан-айга матбугат битләрендә даими рәвештә яктыртып килендe. Шуңа күрә аларның һәрберсе турында бүген кабат бәйнә-бәйнә сөйләп торуның хаҗәте юктыр. Узган әдәби елыбызның төп нәтиҗәләре хакында, ягъни әдәби процессның, әдәби хәрәкәтнең торышы турында, Язучылар берлегенең әдәби киңәшчеләре—каләмдәшләребез Ркаил Зәйдулла һәм Лилия Газизоваларның чыгышлары тәкъдим ителгәнлектән, һәм шулай ук бүгенге фәнни-гамәли конференциянең докладлары да әдәби ел йомгаклары белән бәйле рәвештә тәкъдим ителгәнлектән, мин үз чыгышымны Язучылар берлегенең XVI съездында күтәрелгән берничә мөһим мәсьәләгә багышларга уйлыйм.

Иҗат берлекләренең, һәр каләм иясенең иҗтимагый тормыштагы активлыгы, илкөндә, җәмгыятьтә бара торган вакыйгаларга мөнәсәбәтендә чагыла. Узган әдәбият елында андый вакыйгалар бик күп булды. Халкыбызның Бөек Ватан сугышында җиңүенә 65 ел тулу, ил күләмендә үткәрелгән җан исәбе алу, Бөек Тукаебызның тууына 125 ел тулуга әзерлек һәм үткәрү мәсьәләләре һәр идарә утырышында анализлап барылды.

Бөек Җиңүнең 65 еллыгына багышланган чараларның барысына тукталып тормастан, сугышта һәлак булган каләмдәшләребезне барлау максатында, 34 яугир язучының биографиясе һәм иҗат үрнәкләрен туплаган «Каһарман каләме» исемле җыентыкны Татарстан китап нәшриятында бастырып чыгаруыбыз бик тә иҗтимагый

әһәмияткә ия чара булды дип уйлыйбыз.

Ил күләмендә җан исәп алуга мөнәсәбәтле рәвештә барлык татар халкына Татарстан Язучыларының мөрәҗәгатен кабул итү идеясе дә идарәдә туды. Аның текстын әзерләүдә әдипләребез Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Рафикъ Юныс, Зиннур Мансуров, Искәндәр Гыйләҗев, Гәрәй Рәхим, Равил Рахмани, Вакыйф Нуриев актив катнаштылар.

Җан исәбен алуга багышлап Россиянең 46 төбәгендә оештырылган очрашуларда Язучылар берлеге идарәсе тулы составында һәм барлыгы 64 язучыбыз катнашты.

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуын билгеләп үтү турында Республика Президентының Указы кабул ителүгә үк, бу мәсьәлә идарә утырышында тикшерелде. Идарә тарафыннан Республикабызның чаралар планына кертү өчен 19 мөһим мәсьәләне эченә алган тәкъдимнәр әзерләнде. Республика хөкүмәтенең 2010 елның 13 сентябрендә кабул иткән чаралар планында безнең тәкъдимнәрнең күбесе кертелде, һәм аларның күбесе, төрле кыенлыклар булуга карамастан, бүген тормышка ашырылып килә.

Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышлап Казаныбызда юбилей чараларының ничек узуына без барыбыз да шаһитлар. Аның колачлыгы, халыкара иҗтимагый әһәмияте унаеннан ул җәмәгатьчелек тарафыннан шагыйрьнең тууына 100 ел тулуга багышланган дәрәҗәдә үтте дип бәяләнде. Бигрәк тә халыкара фәнни-гамәли конференция, Габдулла Тукайның әдәби мирасының бик күп телләргә яңа тәрҗемәләрен бастырып чыгару, Рәсәйнең башкаласы Мәскәүдә Г.Тукайга һәйкәл ачылу, быелгы Сабантуйлар программасының Г.Тукай юбилеена багышлануы—болар барысы да безнең милли мәдәниятебез һәм әдәбиятыбызның тантанасы.

Габдулла Тукайның юбилеена багышланган чаралар Мәскәү һәм Петербургта, Марий Эл, Удмуртия, Владимир, Самара, Оренбург өлкәләрендә, Башкортостанда, Төркиядә, Азәрбайҗанда, Казакъстанда, Украинада, Польшада һәм башка төбәкләрдә үткәрелде һәм үткәреләчәк.

Шулай ук Татарстан Язучылар берлеге бинасын яңарту, Габдулла Тукайның каберлегендәге таш һәйкәленә реконструкция үткәрү, Тукайның биографиясенә бәйле урыннарда истәлек такталары кую, шагыйрьнең туган ягы Арча районында, Яңа Кырлайда, Кушлавычтагы истәлекле урыннарында төзү-төзекләндерү эшләре дәвам иттерелә.

Шагыйрьнең **олуг юбилее мөнәсәбәте илә** үткәрелгән чаралар, әлбәттә, мактауга лаек. Әмма Г.Тукай мирасын өйрәнү, Г.Тукайның әманәте-васыяте булган Ана телебезне саклау, Ана телебезнең төп яшәү формасы һәм рәвеше булган милли әдәбиятыбызны үстерү буенча рәсми план-программаларга кертеп тә, кертмичә дә без барысын да эшләдек дип әйтә алабызмы?

«Г.Тукайның юбилеена 10 пьеса, 16 роман, 14 киносценарий, 20 поэма, 100 шигырь язарга» дигән йөкләмә-план кабул итеп булмый, әлбәттә. Әмма **олуг юбилей мөнәсәбәте илә** безнең иҗат берлеге, Г.Тукайның **милли Әдәби каһарман буларак образын** тудыруда житлеккәнлек күрсәтте дип әйтә алмыйбыз әле.

Шөкер—романы да, киносценариесе дә, пьесасы да язылды. Мин әдипләребез Р.Батулла, З.Мансуров, Р.Зәйдулла һ.б. авторларга бүген Тукайның әдәби образларын тудырудагы иҗади эшчәнлекләре өчен идарә исеменнән рәхмәтемне җиткерәм.

Әдәби иҗат—ирекле хезмәт. Хәзерге демократия шартларында хәтта дәүләт заказлары да бик-бик сирәк кулланыла. Ә менә иҗатка Тукайча олы вазыйфа-миссия буларак карау ул күп еллар буена тәрбияләнәдер. Өлкән буын әдипләребездәге иҗади җаваплылыкны урта һәм яшь буын язучыларга йоктыру буенча уйлыйсыбыз бар әле.

Узган ел яшьләребезнең иҗатына багышланган әдәбият елы йомгаклары җыенында без бу мәсьәләне күтәреп яшьләребезне иҗатка кыю алынырга өндәгән идек тә бит. Әйе, Язучылар берлегенә кабул ителгән яшь иҗатчыларыбыз үзләренең киләчәген әдәбият фәне белән дә бәйләргә уйлап аспирантураларда укыйлар, диссертацияләр язалар. Без моны бик тә хуплыйбыз. Әмма милли язучының һәрчак иҗатта булуы—ул аның Миссиясе, Вазыйфасы. Тукайның иҗади үрнәге, әманәте, васыяте шул иде бит!

Бүгенге әдәби-гамәли конференциябезнең балалар әдәбиятына багышлануы да очраклы түгел... Чор-дәверләр алышынганда язучы-шагыйрьләр буыны гына түгел, ә китап укучылар буыны да алышына. Һәр яңа китап укучы буынын язучыларның яңа буыны тудыра, яңа буыны тәрбияләп үстерә.

Без укучыларның яңа буынын үзебезнең мәңгелек әдәбиятыбыз үрнәгендә, милли әдәбиятыбызның күркәм иҗади традицияләре үрнәгендә тәрбияләргә тиешбез.

Бүген иҗади бәйләнешләр, әдәби тәрҗемәләр мәсьәләсенең әһәмияте турында бер-беребезне үгетләп торуның хаҗәте юк. Г.Тукай юбилее уңаеннан җәелдерергән әдәби тәрҗемә эше, Мәскәү тәрҗемәчеләре белән татар шигърияте антологиясен бастыру, Г.Тукайның өр-яңа 45 шигырен русчага тәрҗемә итү һәм Идел буе халыклары телләренә тәрҗемә кылуны оештыру—безнең бу өлкәдә олы мөмкинлекләргә ия булуыбызны һәм киләчәктә билгеле бер стратегик план белән эшләвебезне таләп итә.

Мин, идарә рәисе буларак, 2009, 2010, 2011 нче ел бюджетлары каралганда Хөкүмәтебез һәм Дәүләт Советына «Дәүләт телләрен үстерү» программасы буенча акча бүлеп бирүләрен сорап хатлар белән мөрәҗәгать итеп, чыгышлар ясап та бу максатка ирешә алмадык. Балалар әдәбиятын үстерү мәсьәләсен күтәргән бүгенге форумда әдәби тәрҗемәнең зарурлыгын хөкүмәтебез җитәкчеләренең дә, Мәдәният, мәгариф, яшьләр белән эшләү министрлыкларының да игътибарына җиткерәсебез килә.

Алдагы елларда безнең иҗат берлеге рәссамнар берлеге һәм мультипликаторлар белән бергәләп балаларыбыз өчен чын сәнгать әсәрләре тудыра алыр идек. Бу максатта мәгариф министрлыгының дәүләт заказларын үти алыр идек.

2010 елда Язучылар берлеге, беренче тапкыр буларак, Хөкүмәтебезнең кече яшьтәге балалар өчен татарча, русча, инглизчә Г.Тукай шигыре буенча «Сөткә төшкән тычкан» исемендәге мультфильм эшләү өчен грант откан иде. Без алдагы елларда да Грантларны балалар әдәбияты, әдәби тәрҗемәләр һәм яшьләр иҗатын стимуллаштыруга файдалана алыр идек.

Мөхтәрәм каләмдәшләр!

Иҗат берлекләре, иҗат хезмәткәрләре турында Бөтенроссия күләмендә безне канәгатьләндерә торган законнар әлегәчә кабул ителмәде.

Бөтен ил күләмендә әдәби иҗатка каләм хакы түләүнең бердәм тариф үрнәге дә юк. Иҗатка түләү—тулысынча базар кануннары ихтыярына күчә бара.

Мондый кырыс базар шартларының милли әдәбиятчылар өчен һәлакәткә тиң булуын без күрше республикаларыбыз мисалында гына түгел, үзебездә дә тоя башлаячакбыз!

Язучылар берлеге идарәсенең тәкъдиме белән, Язучылар берлеге рәисе тарафыннан республикабыз Президентына язучыларның китапларын бастырып тарату, язучыларның Әдәби басмаларда басылган әдәби әсәрләре өчен гонорарлар түләүдә Республикабызда яңа стандартларны эшләү, гонорарларның күләмен күтәрү буенча хат әзерләнде. Республикабыз Президенты мине 2011 елның 11 ноябрендә кабул итте һәм бу мәсьәләне һичшиксез уңай якка хәл кылачагын белдерде.

Ноябрь-апрель айлары дәвамында Мәдәният министрлыгы, Финанс министрлыгы һәм «Татмедиа» оешмалары белән барган катлаулы бәхәсләрдән соң, ниһаять, Габдулла Тукайның юбилей көннәрендә без Хөкүмәтебезнең яңа карары басылып чыгар дип өметләнгән идек. Ул карарның проектын әзерләгәндә үзебезгә дә фикерләребезне әйтү мөмкинлеге тудырылды бит. Мәгълүм булганча, Тукаебыз юбилеен гонорарсыз гына каршыладык. Әмма «Тукаебыз елы» әле үзенең экваторына гына җитеп килә. Президентыбызның үз сүзеннән кайта торган гадәте юк.

Инде ишеткәнегезчә, Президентыбыз, Язучылар берлегенең Мөштәри урамындагы бинасын төзекләндерү, анда язучыларның Г.Тукай исемендәге клубын төзеп бирүне дә август аена төгәлләүне үз контроленә алачагына ышандырды. Дөрес, Г.Тукай исемендәге клубны планнан төшереп калдырырга тырышучылар да бар. Әмма, без барыбыз да татарның : «Әйткән сүз—аткан ук» дигән мәкалең, урысның «Уговор дороже денег» дигән әйтеме җиңеп чыгар! дигән ышанычлы

өметтә калабыз!

Язучыларыбыз иҗатына хәерхаһлы булганы өчен, әйдәгез, Президентыбызга үзебезнең рәхмәтләребезне һәм ихтирамыбызны җиткерик! Күпмилләтле республикабызның киләчәген, халыкларыбызның мәдәни алгарышын без иң беренче чиратта Аның исеме белән бәйлибез! Аңа авыр һәм җаваплы хезмәтендә уңышлар, саулык, иминлек телик!

Узган әдәбият елында язучыларыбызның социаль көнкүрешенә ярдәм итү буенча да берникадәр эш алып бара алдык. Моның өчен Россия әдәби фонды белән элемтәләр урнаштыру кирәк иде. Россия әдәби фонды, Халыкара әдәби фондның барлык милкен үзенә күчергәч, безгә дә әдәби фондның структурасына керү котылгысыз булып килеп басты. Бу мәсьәләне идарәдә тикшергәннән соң без Россия әдәби фондына керергә дигән бердәнбер дөрес карарга килдек. Шулай итмәсәк, ягъни 70 ел буе тупланган, әлегәчә таланып бетмәгән әдәби фонд мөмкинлекләреннән баш тартсак, бу акыллылык булмас иде.

В течение года Правлением, совместно с Литфондом РТ и России проводились меры социальной поддержки наших писателей, особенно, инвалидов, неработающих пенсионеров.

Войдя в состав Российского Литфонда мы не оказались и, надеюсь, не окажемся в какой-то жесткой вертикальной подчиненности. Мы ищем и находим новые формы сотрудничества. Благодаря руководству Литфонда России и исполкома Межрегионального сообщества писательских союзов, нам удалось повысить статус Державинского фестиваля поэзии. 14 июля 2011 года мы во второй раз соберемся в Лаишево для проведения Всероссийского фестиваля поэзии им. Г.Р.Державина. Будущее этого фестиваля очень большое.

Из средств Литфонда России оказана финансовая поддержка в сумме 90 тысяч рублей, в том числе материальная помощь в виде продуктовых пакетов инвалидам, участникам ВОВ и ветеранам тыла, ко Дню Великой победы (9 чел), а также инвалидам I группы в связи с декадой инвалидов (12 чел.)—26 600 рублей;

—в НКЦ «Казань» был проведен вечер отдыха с чаепитием ко Дню пожилых людей (130 чел.)—36 000 тысяч рублей;

—проведена подписка на журнал «Казан утлары» для неработающих пенсионеров (55 чел)—27 400 тысяч рублей.

Оказана материальная помощь из Фонда поддержки развития культуры при Президенте РТ в сумме 55 тыс. руб 11 писателям, Министерством культуры РТ в сумме 209 тыс. руб.

В прошлом году, благодаря действенной помощи Министерства культуры были расширены возможности санаторного лечения членов творческих союзов Республики. В льготных условиях 52 писателя РТ укрепили свое здоровье в санаториях «Ливадия», «Жемчужина», «Ижминводы», «Бакирово», «Васильево».

Хөрмәтле каләмдәшләр! Әдәбиятыбызны пропагандалау Язучылар берлеге идарәсенең төп юнәлеше булды һәм шулай булып кала да. Язучыларыбызның юбилей кичәләрен үткәрү дә, телевидение аша даими тапшырулар, радио әңгәмәләр, Республикабыз районнары һәм Россия төбәкләрендә татар әдәбияты көннәрен үткәрү—болар барысы да Идарә тарафыннан расланган план буенча тормышка ашырылды.

Яшьләрне әдәби иҗат эшенә җәлеп итү Язучылар берлегенең актуаль бурычларының берсе булып тора. Бу уңайдан Буада яшьләр өчен зона семинары булып узды. Анда Буа, Тәтеш, Апас, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы районыннан килгән яшь иҗатчылар катнашты.

Россиянең Пермь өлкәсе Барда районында, Удмуртиядә, Татарстанның Арча, Питрәч, Теләче, Спасс, Сарман, Кукмара, Мөслим, Тукай, Балтач районнарында Татар әдәбияты көннәре булып узды.

Язучыларыбызны дәүләт бүләкләренә тәкъдим итү буенча да идарә эзлекле эш алып барды.

Узган әдәби ел инде тарихка кереп калды. Әдәбиятыбыз үсешенә ни дәрәҗәдә тәэсирле, йогынтылы булды ул—анысын вакыт билгеләр. Безнең Вакыт сынавына

тапшырылган иҗатыбыз—әдәби журналларыбыз, газеталарыбызда һәм Татарстан китап нәшрияты, «Рухият» фонды бастырып чыгарган китапларда. Алар бигрәк тә республикабызның китапханәләре аша укучыларыбызга барып ирештe, сәхнәләрдә, экраннарда җанланды. Без бүген нәшриятларга, «Казан утлары», «Идел», «Мәйдан», «Сөембикә», «Аргамак», «Мәдәни җомга» газета-журнал коллективларына, Республика китапханәләре коллективларына олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

Алда—2012 ел. Ул безнең өчен олы сынау елы, иҗат берлегебезнең чираттагы XVII съездын үткәрү елы булачак!

## Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,

*Татарстан республикасы Министрлар Советы аппаратының мәдәният һәм Татарстан республикасы халыклары телләрен үстерү бүлегенең баш белгече:*

Балалар әдәбиятының торышы һәм язмышы хакында тагын бер мәртәбә сөйләшергә вакыт җитте. Шулай булырга тиеш иде, чөнки тагын бер яшь буын аякка басты. Елдан-ел, көннән-көн катлаулана барган яңа заман күзлегеннән карап, бу яңа буынга әлеге катлаулы тормышның гамен, яшәүнең мәгънәсен аңлатырга, күрсәтергә кирәк.

Бүгенге яшь буын узган гасырның 80- 90 елларында, хәтта XXI гасыр башында формалашкан буыннан нык кына аерыла. Аның тормышы-яшәеше генә түгел, фикерләве башка, ул башка хыяллар белән хыяллана, башка максатлар белән яши... Ул хөрлек, ирек хакында хыялланмый, ул инде ирекле, хөр рухлы, аның яшәеш офыгы гына түгел, күңел офыклары киңәйгән, ул озын-озак уйларны, фикерләрне, әсәрләрне яратмый, аның өчен тиз булсын, төгәл булсын, аңлаешлы булсын, күз алдында булсын... Күз алдында—димәк, экранда, мониторда, Интернетта, социаль сайтларда...

Яңа буын баласын аңлау, аның яшәешенә, күңел даирәсенә үтеп керү буенча кызыклы гына эзләнүләр бара. Бер төрле юнәлешне күбрәк шәһәр балаларына адресланган «Ялкын» журналы һәм республика күләмендә елдан-ел көч ала барган, янача, заманча фикерләүгә һәм иҗатка корылган «Сәләт» иҗтимагый хәрәкәте белән бәйләп карасак, икенчесен, үткәндәге традицияләргә тугры калган юнәлешне, «Иделем акчарлагы», «Дулкыннар» кебек традицион семинар-бәйгеләр, ТАТНЕФТЬнең «Рухият» фонды тарафыннан оештырыла торган традицион «Сайрар сандугач иле» конкурс-фестивале, «Салават күпере», «Сабантуй», «Көмеш кыңгырау» кебек матбугат органнары белән бәйләп карарга мөмкиндер.

Балалар әдәбияты, балалар матбугаты хакында сөйләшү өчен вакыт җитүгә турында беренче булып журналистлар чаң сукты. Март-апрель айларында «Татмедиа» агентлыгы, аннары «Татарстан—«Яңа Гасыр» телевидениесе балалар иҗаты хакында «түгәрәк өстәл»ләр, әңгәмәләр, «ток-шоу»лар оештырды. Агентлыкның 2010 елның декабрь аеннан 2011 елның мартына кадәр эшләгән «Яшь журналист мәктәбе» дә игътибарга лаек. Ниһаять, язучыларга чират җитте...

**Иң элек шул мәгълүм булды: баланы, яшүсмерне компьютер мониторыннан аерып алу өчен, әсәр тукымасында искиткеч дәрәҗәдә әдәби интрига тудырырга кирәк. Ягъни—СЕР.** Шушы сер, интрига җәлеп итәргә тиеш яшь күңелне, аны монитордан аерып, китаплы, хыялый дөньяга, әдәби образлар яшәешенә, бу образ-геройларның бәхетле дә, сагышлы да язмышына кушарга, шул рәвешле кичерешләргә, хис-тойгыларга дучар итәргә, димәк ки, аның күңелен сыгылмалы, тоемчан, кешелекле, миһербанлы итеп тәрбияләргә тиеш...

**Икенчедән, яңа буынга яңа образлар кирәк.** Яңа геройлар, каһарманнар. Аларның күбесен рухи мирасыбыздан табып кайтарырга кирәк булачак. Милли рухият, милли тойгы, милли идея—бүген дә әдәбият өчен төп максат булып кала ласа. Моңа милли патриотизмны да өстәргә кирәк. Балаларыбызга бүген үк милли каһарманнарыбыз

хакында яна әсәрләр, әдәби цикллар бирә алмасак, аларның язмышы аша милли рух, милли тойгы индермәсәк, тагын бер яисә ике буыннан космополит һәм Интернет буыны алачакбыз.

**Өченчедән, синтетик фикер, синтетик иҗат, синтетик әдәбият чорында яшәвебезне онытмыйк.** Бөтен дөнья әдәбияты һәм сәнгате хәзер синтетик иҗат формалары белән эш итә. Хәзерге иҗатта еш кына әдәби төрнең, жанрның саф, төгәл булуы мөһим түгел, ул бары тик үтемле булсын, укылсын, каралсын, тәэсир итсен, тетрәндерсен, шул гына! Безгә дә шушы әдәби принцип белән яшь башларга вакыт җитте, ахры. Матбугатта берәр гадәттән тыш, стандарт булмаган әсәр басылып чыкса, кайбер каләмдәшләрем: «Бу бит реализм да, хыялый әдәбият та түгел, дөресме сон бу?»—дип аптырашалар, конкрет әдәби төр, жанр, иҗат методы билгеләмәсенә яраштыра алмагач, еш кына тәнкыйтьләргә, кире кагарга тотыналар. Эш бит бу образга салынган хыялый мотивта, легенда-мифта яисә чынбарлыкта, реаль фактта түгел, эш монда чын, ихлас һәм, иң мөһиме, серле язмыш тудыруда... Яшәеш интригасында... Әдәби, образлы сернең ничек бер үк вакытта мәгънәле һәм талантлы итеп ачылуында...

Тагын шул: компьютер артында утырган баланы без язма әдәбиятта, китаби әдәбиятта информатизация казанышларын, заманча технология алымнарын органик кулланып та әдәбиятка җәлеп итә алачакбыз.

Бүгенге бала, яшүсмер бик акыллы, яңалыкка сизгер, аның каравы ул—хистойгыга тыйнаграк, хыялга конкрет, максатка үтә дә сак, сәясәткә, киләчәккә, хәтта язмышка ирония белән караучан... Менә шушы укучыга йөз белән борылырга тиешбез. Әдәби иҗатыбызны шушы яңа буын мәнфәгатьләренә тәңгәл итеп оештырырга тиешбез.

***

Язучы җәмгыятьтән аерым яши алмаган кебек, әдәби, иҗади процесс та хакимият ихтыярыннан һәм сәяси вәзгыятьтән башка үсә-үзгәрә алмый. Һәр чорның үз җәмгыяви казанышлары һәм югалтулары була. Бүгенге чор җәмгыятебезнең дә үз үсеш юлы бар. Максатым—бүгенге җәмгыятькә, хакимият алып барган бүгенге сәясәткә бәя бирү түгел, бу сәясәтнең конкрет балалар әдәбиятына һәм балалар матбугатына мөнәсәбәте, йогынтысы... Һәркем аңлыйдыр: бу йогынтының мәгънәсе—балалар әдәбияты үсешенә тиешле шартларның тудырылган яисә тудырылмаган булуында... Шул ноктадан карап, бүген республикабызда балалар һәм яшүсмерләр рухияте, иҗаты өчен башкарылган кайбер дәүләти һәм иҗтимагый эшләргә игътибарыгызны юнәлтмәкче булам.

Мәгълүм булганча, дәүләт сәясәте,гадәттә, тулысынча финансланган Дәүләт программалары нигезендә алып барыла. Балалар һәм яшүсмерләр тормышына, аларның рухи үсешенә кагылышлы, дәүләт карарлары белән кабул ителгән берничә гуманитар программаны телгә алып үтик.

**1. Иң элек «2004-2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы» хакында берничә сүз.** Мәгълүм булганча, бу программа телләр хакында гына түгел. Газиз телебез, рухи мирасыбыз, уку-укыту торышы, мәдәни, фәнни, иҗтимагый мәнфәгатьләр хакында да күп кайгырта бу документ. Балалар рухияте, балалар иҗаты һәм балаларның, яшьләрнең рухи үсеше өчен кирәк булган чаралар һәм шартлар хакында да дистәләгән пункт бар бу программада.

Мәсәлән, Программаның 3 нче бүлегендәге 17 пункт турыдан-туры балалар иҗатын стимуллаштыруны максат итеп куя. **«Яшь иҗатчылар конкурс-семинары үткәрүдә ярдәм итәргә»** диелгән анда. Тиешле акча да билгеләнгән. Һәрберебезгә мәгълүм «Иделем акчарлагы» конкурсы үз эшчәнлегендә нәкъ менә шушы пункт нигезендә гамәлгә куелды да инде.

Шул ук бүлекнең 18 нче пунктында **«Республика телеканалларында җиңүче проектларны тормышка ашырып, балалар өчен татар телендә кыска метражлы видеофильмнарның, телефильмнарның иң яхшы сценарийларына ел саен конкурс**

**үткәрергә»** диелгән. Бу эш тә даими рәвештә гамәлгә ашырыла;шушы уңайдан әлеге катлаулы эшкә алынган талантлы дустыбыз Нурания Жамалиевага олы рәхмәтебезне белдерәбез.

2.5 нче бүлекчәдәге 23 пунктта акка кара белән: **«Балалар һәм яшүсмерләр өчен фәнни танып белү, иҗат һәм әхлак-этика радиопрограммалары челтәрен киңәйтергә. Балалар өчен «Мин татарча сөйләшәм», «Мин татарча иҗат итәм» тапшырулар циклы оештырырга. Программалар эшләүгә грантлар булдырырга.»** «Татмедиа» агентлыгына нисбәт ителгән бу эш-гамәл берникадәр тормышка ашырылып килә. Әмма бу юнәлештә активлашасы бар әле. Бигрәк тә балалар һәм яшүсмерләр өчен иҗат программаларына яңа грантлар булдыру бүгенге көнгә кадәр зарур эшләрнең берсе булып кала.

Телләр программасының «Мәгълүмати чаралар» дигән бүлекчәсендә да балалар, яшүсмерләр әдәбиятын, иҗатын стимуллаштыруга корылган пунктлар бар. Аларда яңа сайтлар ачу, электрон версияләрдә әдәби һәм иҗади потенциалны барлау буенча шактый киң мөмкинлекләр хакында сүз бара. Барыбызга да мәгълүм **«Татар электрон китапханәсе»**нең гамәлгә куелуында «Телләр программасы»ның ярдәме хәлиткеч булды. Инде балалар, яшүсмерләр, яшьләр өчен махсус әдәби һәм иҗади сайтлар ачу вакыты да килеп җиткәндер. Җиң сызганып бу эшкә алынучылар гына кирәк.

Телләр программасының тагын бер файдалы эше булды. Нәшриятларның бик авыр вакытларында бу программа **балалар, яшүсмерләр өчен билгеләнгән хәтсез китапларны, ярдәмлек-дәреслекләрне, матур әдәбият җыентыкларын турыдан-туры да финанслады.** Татарстан Министрлар Кабинеты Аппаратының телләр секторы карамагындагы әлеге программа бүген дә дәүләт нәшриятларын үз ярдәменнән ташламый.

**2. Барыбызга да мәгълүм: соңгы вакытта Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы инициативасы белән бик мөһим программалар кабул ителде.**

**«Киләчәк—Будущее»** дип аталган, 2010-2015 елларны үз эченә алган программа, нигездә, гомуми белем бирү мәктәпләренә кагыла. Бу документның XXI гасыр башында уку-укыту процессына никадәр әһәмиятле булуы хакында сүз куертып тормастан, бүгенге сөйләшүнең темасы булган балалар әдәбияты, балалар матбугаты, балалар рухияте хакындагы программ пунктларны эзлибез.

**«Балаларның фәнни-техник иҗатын үстерү»** бүлеге бар. Шулай ук балаларны электрон технологияләргә тарту хакында да күп әйтелә... Ә менә иҗади процесс, иҗади фикерләү, рухи үсеш, ярыш хакында берни дә юк... Әһә, бар икән. Анысы да заманча технологияләргә бәйләп кенә бирелә: **«Яңа технологияләр аша туган тел»** дигән бүлек ул. Максаты: «Бала өчен туган тел һәм мәдәният өлкәсендә гармоник үсеш һәм базовый белем тәэмин итәрдәй унайлы (комфортлы) уку-укыту мохите булдыру».

Укучы балада иҗади фикер тәрбияләү буенча ни дә булса бардыр дип, тагын эзләнәм. Программаның иң ахыргы бүлегенә игътибар итәм: **«Сәләтле балалар өчен үзәкләр»**. Сәләтле балаларны эзләп табу механизмнары хакында сүз бара монда. Ләкин бу ахыргы бүлектә дә әдәби иҗат, мәдәни һәм сәнгати иҗат хакында конкрет юнәлешләр һәм чаралар билгеләнмәгән булып чыкты.

Быел Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы рамкаларында тагын бер программа эшләнде һәм кабул ителде. **«Бәләкәч—Малыш»** дип аталган бу программа мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләренә йөз тотып башкарылган һәм гамәлгә куелган. Балаларда кечкенәдән иҗади, әдәби фикер тәрбияләү буенча нинди ниятләр билгеләнгән соң бу архимөһим документта? Берни дә билгеләнмәгән. Бу программа да тулаем балаларның матди мәнфәгатьләренә генә кагыла һәм аларның рухи, әдәби, хыялый тормышыннан читләштерелә. Кирәкле күләмдә балалар бакчалары булдырып, аларны тиешле дәрәҗәдә җиһаз һәм ризык белән канәгатьләндереп кенә дә яшь буынның гармоник үсешен тәэмин итеп була, дип фикер йөрткән авторлар «иҗат иткән» бу документны.

Шулай да, Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгында балаларның иҗади фикер үсешенә уңай йогынты ясардай кайбер эшләр эшләнә. Мин монда иң элек **«Электрон балалар бакчасы»** дигән концепция проекты хакында әйтмәкче

булам. Дөнья илләрендә мондыйрак типтагы программалар күптән гамәлдә инде. Бу проектның иң кызык җире шунда: ул тәрбиячеләргә һәм администраторларга гына түгел, бәлки балаларның үзләренә дә турыдан-туры адресланган. Бигрәк тә балаларның Интернет системасына керә алулары, электрон медиатека белән турыдан-туры эш итүләре уңай күренеш. Ә бу инде әдәби, мәдәни, мультиресурсларга чыгу, әдәби тоемны, иҗади фикерләүне үстерә торган виртуаль дәресләргә, интерактив уеннарга катнашу дигән сүз.

Иң мөһиме, «Электрон балалар бакчасы» проект булып кына калмыйча, тиз арада көндәлек эш процессына әверелсен иде.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы шулай ук үзенең быелгы 657 номерлы 5 нче март приказы белән татар телен һәм мәдәниятен укытуны яңа заман мультимедиа ресурсларына нигезләнеп гамәлгә куярга тиешле иҗат группасы төзеде. Анда яңа заман татар балалар әдәбияты әсәрләре—төп чыганакларның берсе булачак.

Шулай ук быел, 15 мартта, Мәгариф һәм фән министрлыгы хезмәткәрләре «Татармультфильм» җитәкчеләре белән берлектә эшлекле киңәшмә уздырдылар, шунда ук **«Мультсадик»** проектын тәкъдир итү булды.

Тагын бер яхшы хәбәр: Мәгариф һәм фән министрлыгы инициативасы белән, яңа уку-укыту технологияләре нигезендә, моңа кадәр дөнья күргән мультипликацион фильмнарны, аудио-видеоматериалларны файдаланып, балалар өчен «Әкият илендә» дигән зур телевизион проект гамәлгә куелу алдында тора.

3. Республика җитәкчелеге, бигрәк тә Татарстан мәдәният министрлыгы ярдәме белән гамәлгә куелган, татар балалар әдәбиятын стимуллаштырырга тиешле тагын берматур проект хакында әйтергә кирәктер. **Татарстанда, ниһаять, «Татармультфильм» берләшмәсе эшли башлады.** 27 тәҗрибәле профессионалдан торган бу коллектив бүген Татарстанда мультимедиа өлкәсендә чын лидер булып җитеште. Уйлап карагыз: 2010 ел эчендә генә дә «Татармультфильм» студиясендә 17 аннимацион проект гамәлгә ашырылган.Алар арасында күпчелеге Г.Тукай әсәрләре буенча эшләнгән «Туган тел», «Бала белән күбәләк», «Эш беткәч уйнарга ярый», «Гали белән кәҗә», «Яңгыр илә Кояш», «Шаян песи», «Ялкау маэмай», «Кырлай» һәм башка фильмнар бар. Аларга татар, рус, инглиз телләрендә башкарыла торган «Кисекбаш» аннимацион мюзиклын да өстәргә мөмкин.

Бүгенге көндә «Татармультфильм» берләшмәсе балалар әдәбиятында актив эшләүче татар әдипләре белән уртак иҗади проектларга чыгарга тели.

Аерым алганда, бу оешманың агымдагы еллар планында тулы метражлы милли аннимацион фильмнар төшерү нияте бар.

Алдарак әйтелеп үтелгәнчә, соңгы вакытта әлеге иҗади берләшмә Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы белән актив сөйләшүләр алып бара. Мәгълүм булганча, бу сөйләшүләр **татар телен һәм әдәбиятын Татарстан мәктәпләрендә интерактив мультимедиа ысуллары ярдәме белән өйрәтүне төп максат итеп куя.** Бу очракта «Татармультфильм» студиясенә татар әдипләре, бигрәк тә балалар өчен язучы драматурглар, сценаристлар, шулай ук шагыйрьләр, язучылар хезмәттәшлек итә алыр иде.Үз чиратында әлеге эш-гамәл татар балалар драматургиясенә, гомумән татар балалар әдәбиятына яңа сулыш өрер иде.

4. Соңгы елларның иң мөһим казанышы—**2007 елда Татарстан китап нәшриятында балалар һәм яшүсмерләр редакциясенең кабат оешуы, шуның нәтиҗәсендә татар балалар китабының күзгә күренерлек үсеш-үзгәреш кичерүе.**

**Беренчедән,** китапларның саны һәм тиражы артты: 2008 елда 110 исемдәге китапның **20се балалар өчен** булса, 2010 елда 156 исемдәге китапның **32се балаларга атап** чыгарылган.

**Икенчедән,** күзгә күренеп, китапларның сыйфаты яхшырды: бизәлештә якты һәм җылы төсләрне куллану, яхшы кәгазь, укучының игътибарын җәлеп итәрлек тышлык, профессиональ рәссамнәргә мөрәҗәгать итү, иң мөһиме, эчтәлеккә, мәгънәгә җитди игътибар бирү.

**Өченчедән,** әдәби китаплар белән бергәттән татар балалар китабы тарихында моңарчы күрелмәгән, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән, вакыйга булырдай **өр-яңа серияләр оештырылды**. Иң кечкенәләр өчен «Нәниләргә бүләк», «Минем беренче

китабым», «Рәсемнәрне үзең буя», «Рәсемле дөнья» һ.б., балалар бакчалары өчен «Имәнме, мәктәп!», «Син мәктәпкә әзерме?», «Санарга өйрәнәбез» һ.б., мәктәп балалары өчен «Табигатькә сәяхәт», «Шәхесләр», «Туган якны өйрәнү», « Спорт», «Рәсем ясарга өйрәнәбез» һ.б. серияләр бүген дәүләт нәшриятының йөзен билгели.

**Дүртенчедән, энциклопедик характердагы заманча проектлар** да гамәлгә ашырыла башлады. Аларга «Балачак энциклопедиясе», «Матур булырга теләсән», «Тәмле сүз. Итагатьле булу серләре», «Татар халык иҗаты» һ.б. китаплар һәм серияләр керә.

**Бишенчедән,** ике (татар һәм рус), өч (татар, рус һәм инглиз) телдәге китаплар басыла башлады.

**Алтынчыдан, СД-китаплар басылды.** Мәсәлән, Резеда Вәлиеваның «Мактанчык Кот-кот» китабында авторның әкиятләре тәкъдим ителә, балалар андагы рәсемнәрне буйый да, СД-дисктан әкиятләрне авторның үзе башкаруында тыңлый да алалар.

**Җиденчедән,** сирәк кенә булса да **картон, җыелма (раскладушка)** китаплар да басыла башлады. Нәшрият аларны каты катыргы белән дә чыгару теләге бар, ләкин республикада әлегә бастыру технологияләре юк.

**Иң мөһиме, бүген Татарстанда дәүләт нәшриятларында басыла торган барлык балалар, яшүсмерләр китаплары да һәр елны «Татмедиа» агентлыгы тарафыннан төзелгән һәм Татарстан Хөкүмәтенең махсус карары белән расланган «Социаль әһәмияткә ия китаплар исемлеге»нә кертелә һәм дәүләт тарафыннан тулысынча финанслана.**

Китаплар хакында сүз чыккач, **республикабыздагы гонорарлар һәм китап тарату сәясәте** хакында әйтеп китү кирәктер. Татарстан Язучылар берлеге бу мәсьәләләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов алдына узган елның ноябрендә куйган иде. Әле менә шушы көннәрдә генә, Президент кушуы буенча, Татарстан Министрлар Кабинетында республикабыз язучыларының гонорарларын арттыру һәм басылган китапларны зарури рәвештә китапханәләргә тарату хакында махсус карар проекты әзерләнде. Ул тиз арада кабул ителер дип уйлыйбыз.

**КЫСКАСЫ,** республикабызда татар балалар әдәбияты, татар балалар китабы үсү өчен дәүләт һәм аның махсус программалары, профильле нәшриятлары, редакцияләре, остаханәләре, медиа-ресурслары һәм электрон матбугат чаралары, иҗади берләшмәләре, теле һәм радиостудияләре, әдәби һәм интерактив проектлары— барысы да үз эшен эшли, билгеле бер мохит һәм вәзгыять тудыра.Боларга Хөкүмәт тырышлыгы белән җайга салынган «Яшь ТНВ» программасының гамәлдә булуы, курчак театрларының, балалар, яшүсмерләр драматургиясенең һәм сәхнә сәнгатенең елдан-ел көчәя, активлаша баруы, «Балалар Дөньясы» дигән глобаль проект-учреждениенең төзелеп бетеп, якын арада сафка басачагын да өстәргә кирәктер... Иң мөһиме, Язучылар берлеге бар. Берлекнең балалар әдәбияты секциясе гөрләп эшли, аның төп максаты булып бүген дә талантлы яшь буын тәрбияләү кала.

Әлбәттә, **проблемалар да җитәрлек:** язучыларны ничек актив иҗатка тартырга, аларны ничек итеп яңа буын балалар психологиясенә алып керергә? Дәреслекләрне ничек итеп заман таләпләре буенча, яңа буын әдипләре әсәрләре нигезендә төзи башларга? Ничек итеп хөкүмәт заказы буенча басылган балалар китапларын махсус нормативлар нигезендә барлык мәктәпләргә, китапханәләргә алдыруны тәэмин итәргә? Балаларның иҗат йортлары системасын ничек кире кайтарырга? Ничек итеп балалар матбугатын стимуллаштыруның, аның тиражларын арттыруның яңа принципларын һәм чараларын эшләргә һәм гамәлгә куярга?Ничек итеп балалар иҗатын һәм балаларга юнәлдерелгән әдәбиятны бала укырлык һәм үзе дә иҗади процесста катнашырлык итеп электрон ресурсларга урнаштырырга? Ниһаять, ничек итеп татар баласының милли йөзен, милли рухын, образлы фикерләвен, иҗади омтылышларын, әдәби тоемын саклап калырга?

Бу сорауларның барысына да җавап бер генә:

**Балалар әдәбиятын, балалар китабын һәм балалар матбугатын үстерү концепциясен эшләргә һәм аны хөкүмәтнең бюджеттан финанслауны күз уңында тоткан махсус карары һәм программасы рәвешендә игълан итәргә.**

Алдагы елларда татар әдәби җәмәгатьчелегенең төп максаты шул булырга тиеш!

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,**

*Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультанты:*

Бер дәүләт эшлеклесенең «процесс пошел» дигән канатлы гыйбарәсен күпләр хәтерлидер әле. Нинди процесс ул, нигә кузгалган?—без аны берничә ел үткәч кенә—кодрәтле зур империя таркалып, мәңге бетмәс сыман тоелган партия юкка чыкканнан соң гына аңладык. Сәясәттән әдәбиятка күчсәк, бүген без әдәбиятыбызны бар итәбезме, әллә барны юк итәбезме, булганны үстерәбезме, әллә корытабызмы—беркем дә төгәл генә кистереп җавап бирмәс. Шунысы гына ачык: процесс бар—әдәби процесс диюем;—ул хәрәкәттә.

Бер караганда, яшәү белән үлем мәсьәләсен кабыргасы белән кую, йә алай булыр, йә болай булыр дип нәтиҗәләр ясарга чакыру бөтенләй урынсыз кебек. Әдәбиятыбыз үсә, каләм тибрәтүчеләр саны арта, унышларыбыз күз алдында дип—ә алар чыннан да бар,—куанырга да булыр иде. Әдәби процессны шуннан да күреп була: бездә остаханәләр (аларның саны алтау) гадәттә тәкъдим итү максатыннан җыела. Йә без кемне дә булса Язучылар берлегенә әгъзалыкка, йә ел да бирелә торган берәр әдәби премиягә тәкъдим итәбез. Мин бу сүзләрне һич тә ирония белән әйтмим. Бездә Язучылар берлегенә керергә теләүче кешеләр һаман да күп—димәк, алар ни дә булса яза, язсә элек язган, язсә язарга җыена. Бу—гаҗәп бер күренеш! Язучылык һөнәренең дәрәҗәсе төште, әсәр өчен тиеннәр генә түләнә, йә бөтенләй түләнми, дип зарлана-зарлана язалар. Икенче яктан бу күренешне бик җиңел аңлатып була: һәвәскәрләр, графоманнарга язган өчен түләү кирәкми, бары тик профессионаллар гына гонорар өчен яза. Чөнки гонорар алар өчен—хезмәт хакы, ансыз алар тормыш итә алмый. Гадәттә мондый авторлар язудан башка бүтән һөнәр башкарырга сәләтсез дә була.

Мин шуннан чыгып әйтәм: бүген безнең әдәбиятны һәвәскәрләр, үзешчәннәр әдәбияты дип кыенсынмыйча әйтеп буладыр. Һәм әдәби премияләргә дә без каләмдәшләребезне шушы хакыйкатьне онытмыйча тәкъдим итәбез.

Һәвәскәрләрнеке дип әдәбиятны хурларга да, зурларга да ярамый. Һәвәскәр дип кемне күздә тотасың бит. Күп кенә чит илләрдә дә һәвәскәрләр әдәбиятның умырткасын хасил итә. Мәсәлән, шигырь язып, бер генә илдә дә тамак туйдырып булмыйдыр. Шагыйрьләр анда да, гадәттә, яшәү чыганагын бүтән өлкәләрдә: укытуда, нәшрият эшендә, журналистикада һәм әдәби тормышка якын башка һөнәрләрдә таба. Ләкин поэзия бүгенге дөньяда бер генә әдәбиятның да кимәлен билгеләрми. Кимәлне проза билгели. Ә шигърият ул әдәбиятның дәрәҗәсен күрсәтә.

Узган елның ахырында проза остаханәсендә кызыклы сөйләшү булган иде. Анда Л.Хәмидуллин, Т.Галиуллин, Р.Кәрами кебек өлкәннәр дә, урта буын язучылар да катнашты. Яшьләр юк иде. Безнең яшьләр, гомумән, җыелышларга йөрергә яратмый. Югыйсә үзара аралашу, фикер алышу, бәхәсләшү язучы өчен һава кебек кирәк. Мондый очрашулар—әдәби процессның бер өлеше. Менә шушындагы әңгәмәне башлаганда остаханә җитәкчесе Камил Кәримов болай диде: «Безнең проза хәзер иң түбән ноктада, дип әйтергә була. Соңгы ун елда даими иҗат белән шөгыльләнүче тугыз-ун прозаик бар. Болар—өлкән яшьтәге кешеләр. Алар да язудан туктаса, «Казан утлары» журналын чыгару да проблемага әйләнергә мөмкин. Кайбер прозаиклар, телевизорда сериаллар караганнан соң, язарга утыра, дигән тәэсир кала. Алай дисәң, телевизорда гел детектив, ләкин бездә ул да юк. Киң колачлы эпик әсәрләр турында мин әйтмим дә инде. Социаль юмор да юк. Инде журналда конкурс игълан иттек, шуна алданып яна әсәрләр тумасмы... Прозада ниндидер хәрәкәт булсын өчен нишләргә?»

К.Кәримовның җаны әрнеп биргән соравына җавап табуы җиңел дә, авыр да. Прозада ниндидер хәрәкәт булсын өчен язарга кирәк! Җавапның бу иң җиңеле. Әгәр дә инде прозабыз, димәк әдәбиятыбыз нигә мондый хәлгә төште, дип сәбәпләрен эзли башласак, шактый вакыт сарыф итәргә туры килер иде. Мин шунысын гына беләм: әсәр иҗат итәр өчен язучыга үзенең кирәклеген тоеп яшәргә, үз укучылары барлыгына ышанырга кирәк. Укучылар күктән төшми, шедеврлар гына язып ятсаң

да аларны тапмаска мөмкин. Татар әдәбияты актуаль булсын өчен потенциаль укучыны мәктәптә үк татарча укыту, милли рухта тәрбияләү зарур. Укучылар гына түгел, булачак язучылар да шул мохитта гына үсеп чыга ала. Без бүген берничә яшь кешенең әдәби уңышларына сөенәбез икән, аларның пәйда булуы туксанынчы елларда булган җанланышка, татар теленең статусы күтәрелүгә бәйле.

Ә хәзер без сәяси сәхнәдә нәрсә күзәтәбез? 2000 елдан соң без татар тормышында реакция хөкем сөргәнен күрәбез. Бу ни өчен мөмкин булды? Чөнки татар тарихының иң хәлиткеч чорларындагыча, «яңа морзалар» үз рәхәтлекләрен милләт язмышыннан өстен куйды, меркантиль мәнфәгатьләр җинеп чыкты. Мондый шартларда татар әдәбиятының киләчәге турында сөйләү бик авыр. Һәркемгә мәгълүм, аның киләчәге милләтнең киләчәгенә тәңгәл.

Татар халкының холык-фигылен ачып бирә торган дүртьюллык бар:

*Усал булсаң, асарлар.*
*Юаш булсаң, басарлар.*
*Урталыкны тота белсәң,*
*Ил агасы ясарлар.*

Минемчә, соңгы ике юл үз-үзебезне аклау, юату өчен әйтелгән. Нәрсә ул урталык? Эндәшми калумы, тел тешләп торумы? Кемдер һөҗүм иткәндә, кемдер качканда читкә китеп басумы? Татар XVII гасырдан бирле гел урталыкны сайларга тырыша, ләкин аны һич тә ил агасы ясамыйлар. Урталык юк—йә өстә буласың, йә аста! Безнең тамырларны берәм-берәм кисә баралар, без һаман тел тешләп торабыз. Инде ике университеттагы татар факультетларын берләштереп бер бүлеккә калдыралар, татар мәктәпләрен күпләп ябалар, бездән тавыш-тын чыкмый. Телне артык озак тешләп торсаң, ул бөтенләй өзелергә мөмкин. Хәер, өзелмәгән микән инде...

Хәлбуки халкыбызда, дөресрәге аның татар булып калган өлешендә, милли рухның көчле булуын туксанынчы еллар күрсәтте. Без аларның ышанычын аклый алмадык. Дөресен әйткәндә, татар университеты ачылмау да, латин әлифбасына вакытында күчә алмау да һәм башка реаль ниятләр дә Татарстан җитәкчелегенең үз вакытында ихтыяры җитмәүдән тормышка ашмады.

Киләчәккә дә өмет белән карарлык түгел. Урыс күршеләр җитәкчелектә татарларның абсолют күпчелек булуыннан зарлана. Ләкин бу җитәкче татарларның шактый өлеше татарча укымаган, татар мәдәниятен белми торган, белмәү генә түгел, ана түбәнсетеп карый торган кешеләрдән тора. Һәркемгә мәгълүм, милләтне этник чыгыш түгел, ә мәдәният билгели. Мәдәниятләр дуслыгы, культуралар диалогы дип күпме генә сөйләнсәк тә, кешелек тарихы мәдәниятләрнең көрәшеннән гыйбарәт. Әлеге көрәш яшәешнең һәр өлкәсендә дә бара, һәм ил агасы булам дип, аннан читләшү һич тә мөмкин түгел. Син икенең берен сайларга тиеш. Иң аянычлысы шул—татар халкы хәзер ике милләткә бүленде.

Мин җитәкчелек турында юкка гына сүз кузгатмадым. Ун ел тирәсе типкедә йөргәннән соң Нурислам Хәсәновның «Золым» романы «Казан утлары»нда дөнья күрде. Аның дөньяга чыкмый торуы әдәби әсәрнең бөтенләй үк буш сүз түгеллегенә бер ишарә. Югыйсә, вакыйгалар авыл җирендәге бер район масштабында гына бара. Әдәби яктан хилафлыклар булуга карамастан, әсәр тормышны дөрес тасвирлау ягыннан үзенә җәлеп итә. Тормыштагы гадәтигә әйләнгән сөмсез, ертлач хакимият ияләрен, чиновникларны әсәрдә күреп, иске танышларны очраткандай, чын күңелдән сөенәсең. Бу әсәрне автобиографик роман дип тә атап буладыр, чөнки автор үзгәртеп кору елларында үз районына кайтып газета редакторы булып эшләгән иде. Ни генә дисәң дә, язучыга яңа тәэсирләр, яңа мохит кирәк шул.

К.Кәримовның «Игезәкләр йолдызлыгы»нда исә тарих сәхнәсенә яңа Олуг Мөхәммәт үзе чыга. Биредә масштаблар, гомумиләштерүләр колачлырак. Ә кырыс реализм сюрреалистик картиналар белән сипләнә.

Фицджеральдның «Яшь бай» дигән хикәясендә «Бай кешеләр сезнең белән безгә охшамаган», дигән җөмлә бар. Шул җөмлә аркасында Һемингуэй үзенең якын дусты Фицджеральд белән арасын өзә. Алда телгә алган әсәрләрне укыганда шул җөмлә

искә төште. Чынлыкта кешеләр бер-берсенә бик тә охшаш. Тәкъдир аларны нинди шартларга куя—хикмәт шунда гына.

Өлкәнрәк яшьтәге каләмдәшләр хәтерлидер—мәрхүм Диас Вәлиев үзен «татар язучысы» дип раслатыр өчен заманында буза куптарып йөргән иде. Әйтерсең, нинди язучы, кем язучысы икәненне ниндидер оешмалар, аерым шәхесләр билгели ала. Татар кешесе татар тормышы турында урыс телендә яза икән—ул кайсы халык язучысы? Әгәр дә әсәрләрендә татар тематикасы юк икән, этник тамырларын татар булган өчен генә, син татар язучысы дип санала аласынмы? Мондый проблема бездә генә түгел. Бүген мөстәкыйльлек алган Казакъстан, Украина, хәтта Грузияләрдә дә бу хакта вакыт-вакыт бәхәсләшеп торалар. Мин бу бәхәскә керергә теләмим. Шуны гына искә төшерәсем килә: урта гасырларда шигърият теле фарсы теле саналган һәм төрк шагыйрьләренең күбесе фарсыча язган. Хәзер аларның мирасы өчен төрки халыклар белән фарсылар арасында ызгыш бара. Ләкин төрк телен фарсыга көндәш югарылыгына күтәрә алган Нәваине без шагыйрьләр шаһы дип саныйбыз.

Шунысы гыйбрәтле: татар язучылары урыс теленә тәрҗемә ителеп шөһрәт казанырга өметләнсә, урыс телендә язучы татар кардәшләребез ата-баба телендә дөнья күрергә омтыла. «Казан утлары» журналында аларның әсәрләре әледән-әле безне куандырып тора.

Бүтән телләрдә язылган кайбер әсәрләрне татар теленә тәрҗемә иткән хәлдә (бу эш соңгы елларда бөтенләй туктады диярлек), безгә төрле заманнарда язылган иң яхшы татар әсәрләрен чит телләргә, иң әүвәл, әлбәттә, урыс теленә тәрҗемә итүне системалы рәвештә гамәлгә куярга кирәк. Аңа сарыф ителәсе акча мәдәният миристрлыгы бюджетының бер пунктын хасил итәргә тиеш. Спорт командалары Татарстанны дөньяга танытуда роль уйный, билгеле. Ләкин иң башта илне дә, милләтне дә дөньяга үзенчәлекле мәдәнияте таныта. Мөстәкыйль илләрдә үз мәдәниятләрен чит илләрдә таныту белән, мәдәният министрлыгыннан гайре, тышкы эшләр министрлыгы, илчелекләр шөгыльләнә. Безгә дә, әлбәттә, үз мөмкинлекләребездән чыгып бу эш белән шөгыльләнергә кирәк. Аннары безнең бит әле татар әдәбияты белән кызыксынган, әмма татарча укый алмаган кан кардәшләребез дә житәрлек. Минемчә, бу мәсьәлә белән Мәдәният министрлыгы каршында аерым комиссия шөгыльләнсә яхшы булыр иде. Һәм алар тәрҗемә итәр өчен башка халыклар алдында йөз кызармаслык әсәрләрне сайлап алырга тиеш.

«Дружба народов» журналында (№ 5) Алексей Соломатинның Татарстан поэзиясе турында уйлanулары мәкалә рәвешендә басылып чыкты. Ул анда моннан өч ел элек дөнья күргән рус телендәге антологиягә таянып, татар поэзиясе турындагы фикерләре белән дә уртаклаша. Урыс телле поэзиядән аермалы буларак, ди ул, татар шигъриятенә консерватизм хас, форма җәһәтеннән эзләнүләр анда юк диярлек; татар фольклоры образларына мөрәҗәгать итмәгән хәлдә, татар шагыйрьләренең әсәрләрен тулаем бер фольклор дип атарга була. Автор татар шигъриятенең провинциальлегенә дә ишарә ясый. Ә Татарстанның урыс поэзиясе яңа эзләнүләре белән гомумрәсәй агымына кушылырга омтыла икән. Минемчә, автор төшенчәләрне буташтыра. Татар поэзиясе мөстәкыйль, ул читтәге бернинди агымга да кушылырга омтылмый. Татар шагыйрьләренең башкаласы—Казан. Ә урысча язучылар, кайсы ачыктан-ачык, кайсы эчтән генә, Мәскәүнең тануына, анда нәшер ителүгә өметләнә. Алар өчен әдәби башкала—Мәскәү! Провинциализм иң беренче нәүбәттә икенчеллекне аңлата.

Кайбер тәнкыйтьчеләр бездә шәрекъ аһәңнәре яңгырый башлавын да мөстәкыйльлегебезгә янау дип кабул итә. «Көйчеләр даирәсендә көнчыгыш аһәңнәренә турылатып «милли» җыр тәпәләгән сыман, көнчыгышның суфичыл шигъриятенә тәкълид көчәнүләр очраштыра башлады. Тукай үзе, ялгышмасам, татарлыктан тайпылып, ятларга авышып каләйләнүләрне, вәзенле акыл сатуларны яратмаган»,—дип яза Рөстәм Зарипов. Ялгышасың, кем, гражданин Рөстәм. Уйлап карыйк әле: Тукай үзе кем ул? Ул, хәзерге татар поэзиясе кебек үк, халык авыз иҗаты белән шәрекъ шигърияте синтезеннан үсеп чыккан шәхес. Тукайның шигъриятенә яңадан игътибар итегез! Ул нинди формалардан файдалана? Тулаемы белән шәрекътән килгән шәкел түгелме соң?

Бүген робагыйларның, газәлләрнең артуына сөенергә генә кирәк. Безгә бер якка авышудан куркасы юк. Мәсәлән, «Казан утлары» журналының соңгы санында Ренат Харисның искиткеч сонетлары дөнья күрде. Татар шигъриятенең кимәле югары, түбә тирән. Әлбәттә, аңа тәрҗемә антология укып кына бәя биреп булмый.

Татарстан китап нәшриятының әдәби мираска мөнәсәбәте сөендерә. Соңгы бер-ике елда Х.Туфанның 5 томлыгы, Һ.Такташның 3 томлыгы, Г.Камалның 3 томлыгы, Н.Исәнбәтнең 3 томлык «Татар халык мәкальләре», М.Гафуриның «Сайланма әсәрләре» дөнья күрде. Г.Тукайның 6 томлыгыннан 2 томы кулга килеп ирешә. Сугышта һәлак булган язучыларның әсәрләре «Каһарман каләме» дип аталган китапта нәшер ителде (Төз. В.Нуриев). Бай мирасыбызның кайбер өлеше янәдән халкыбызга кайтуы сөенеч, билгеле. Бу сөенечкә күләгә төшерәсе дә килми. Ләкин әйтмичә дә ярамый: бу басмалар,—Х.Туфанның томлыкларыннан кала, ә алардагы кимчелекләр турында мәрхүм Р.Мостафин язып чыккан иде,—инде күптән башкарылган гамәлләрнең нәтиҗәсе. Бүген безнең Тукайны янача шәрехләрлек белгечләребез дә юк хәтта. Әдәбият институтында берничә текстолог утыра. Алар нәрсәгә генә өлгерсен? Шул ук вакытта бездә эшкә яраксыз дистәләгән фән кандидаты бар.

Балалар өчен китаплар нәшер итү эшендә дә җанлану сизелә. Бүген бу хакта сүз булыр. Шулай да бер теләк әйтәсем килә: коллектив җыентыклар белән бергә аерым авторларның китапларын да күбрәк нәшер итәсе иде. Чөнки һәр авторның үз йөзе, үз сүзе, үз энергетикасы. Кайберләре туры килмәгәндә баланың психикасына зыян да салынырга мөмкин.

Рүзәл Мөхәммәтшинның «Каралама» һәм Лилия Гыйбадуллинаның «Тынлык кайтавазы» җыентыкларын, юка гына булуларына карамастан (бәлки шуңа күрәдер дә әле), мин татар шигъриятендә ике зур вакыйга дип кабул иттем. Башка яшьләрнең дә беренче җыентыкларын (мәсәлән Йолдызның, Эльвира Һадиның) якын киләчәктә дөньяга чыгарырга иде.

Сүземне Истанбул язучысы Сәет Фаикның бер нәсере белән тәмамламакчы булам:

«Җирдә әле тормыш яралып кына килә торган заман иде. Кешеләр ауга чыга, ут эзли. Ә мин учак янында утырам, борын эченнән мыгырдап, акчарлак үлеме турында җыр чыгарам. «Бу тагын күпме эшсез утырыр, күпме хыялланырга була?—дип шаулашты бар кабилә.—Үле акчарлакка карап безгә әкият сөйләүдән туктарга вакыт аңа!» Алар шулай диде көндез, кояш өстә балкыганда. Һәм менә караңгы төштә, учакларда чыбык-чабык кул чәбәкләп янды, еракта диңгез шаулады һәм акчарлаклар ачыргаланып кычкырды. Мин янә җыр башладым, үле акчарлак турында җыр. Сагыш биләгән кешеләр бер-берсенә сыенды.

Шуннан соң берничә көн мин җәтмәләр тегеп маташтым, балык тоттым. Кичкә мин шулкадәр арый идем, әле сагышка, әле шатлыкка өртелгән җырларымны җырлый алмадым. Һәм бер иртәдә, ауга киткәндә, кешеләр мине уятмаска булды».

Учак тирәсендә татарча аңлаучы берәү генә калганда да без үзебезнең үлгән акчарлагыбыз турындагы җырны җырлаудан туктамабыз. Чөнки ул акчарлак кына түгел, ерак гасырлардан күчкән безнең хыялыбыз да.

**Равил РАХМАНИ,**

*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының бүлек җитәкчесе:*

Үзгәртеп кору, суверен республикага әверелү кебек гаять зур, мөһим вакыйгалардан соң, безнең милли әдәбиятта да гасырлар буена көтеп алынган кардиналь үзгәрешләр булыр кебек иде. Кызганыч, тарихи язмыш биргән бу иркен шартларда, чирек гасыр вакыт үтеп китсә дә, вакыйга булырлык әлләни эшләр майтарганыбыз күренмәде. «Рубин» белән «Ак барс», «Зенит», «Динамо», «Уникс»ның чемпион булуын исәпкә

алмаганда, билгеле. Безнең чор балалар әдәбиятын Сталин диктатурасы да юк итә алмаган 20-50 еллар әдәбияты яисә «җепшеклек чоры» дип аталган 60-70 еллар әдәбияты фонына куеп карасак та, чагыштыру һич кенә дә соңгы еллар әдәбияты файдасына түгел. Дөрес, әдәбиятыбызда бу чорда нык үсеше күзәтелгән бер жанр булды булуын, ул—публицистика. Монда М.Юныс, Ф.Бәйрәмова, Ф.Баттал, А.Хәлим, З.Зәйнуллин, Р.Зәйдулла кебек бер плеяда авторларының милли фаҗигане искәрткән заман авазы яңгырады. Ишетүчесе булгандырмы, юкмы, әмма бу—соңгы еллар милли әдәби хәрәкәтенең, һичшиксез, горурлыгы. Әлеге үсешнең килеп чыгуы, безгә калса, бик табигый. Шундый зур потенциал мөмкинлеге булып та, шундаен тар, кысынкы, кысаларга куып кертелгән шартларда яшәүче, шундый зур өмет-хыялга бирелеп тә, кабат ярык тагарак янында торып калучы башка милләт җир йөзендә тагын да бармы икән?!. Ә башка жанрларда хәл нәкъ киресе—без үзебезнең мокытлык традицияләрен уңышлы дәвам иттек. Балалар әдәбиятын алсак, бирелә дә йоклатылган милләт рухына тугры калдык, әдәби-сәнгать ягыннан, һичшиксез, тагын да арткарак чигендек. Бу чорда Тукай, Алиш дәрәҗәсендәге әсәрләрне табармын димә. Балалар әдәбияты ул—җәмгыятьнең лакмус кәгазе кебек, аны конфет биреп кенә алдап булмый. Милләт сулышының һәр тирбәлешен—аның демократик яки коллык казанышларын, рухи күтәрелеш-төшүләрен ул, үтә сизгер сейсмограф кебек, бик төгәл чагылдыра.

Бу чорда балалар шигъриятендә һәм психологик яктан, һәм шигърият ягыннан Р.Миңнуллинның шактый зур уңышларга ирешүен әйтеп үтәргә кирәк. Әмма бу казанышлар да үзгәртеп кору китергән күтәрелештән бигрәк, гомуми психологик һәм эстетик ракурста табылган уңышлар булуы белән характерлы. Балалар прозасында һәм драматургиясендә исә без андый югарылыкны да бөтенләй күрмәдек шикелле.

Туксанынчы елларда А.Хәлимнең «Өч аяклы ат» кебек чынбарлыкка кыю үтеп кергән югары дәрәҗәле чәчмә әсәрләре күренә башласа да, алар, ни өчендер, дәвамлы булмады. Балалар прозасы кабаттан үзенең ашыкмас, кабаланмас, билгеле кысадагы канәгать, урта кул бер үсеш эзенә килеп төште. Юк түгел, бар ул балалар прозасы. Әмма, нигездә—ел йомгаклары өчен бар. Ә 25 еллык—тулы бер үсеш этабы ераклыгыннан караганда, уңышлар, кызганычка каршы, күзгә күренеп кечерәя.

Шулай да мин, сөйләшү предметлы дәвам итсен өчен, һич булмаса, дистә еллык яңа гасыр әдәби продукциясенең үземә укырга насыйп булган кайбер үрнәкләренә тукталып үтәргә кирәк табам. Үсмерләр әдәбиятына кереп тормастан, сүземне ике төрле яшь үзенчәлегенә караган әсәрләргә юнәлтергә уйлыйм.

Беренчесе—нәниләр әдәбияты. Тормыш материалын мәктәпкәчә яшьтәге бала хасиятләре таләбенә туры китереп югары сәнгать әсәре тудыра алу—гаять авыр, җаваплы эштер дип беләм. Монда белем һәм коры теләк кенә булу аз, автор үзенең натурасы белән үк шул сабыйлык стихиясендә яшәргә тиештер. Мин Рифә Рахманның «Онытырмын, димә...» (2010) китабына кергән шундый биш хикәясе белән танышып чыктым. Сорап алып, Нәҗибә Сафинаның беркайда басылмаган 9 хикәясен укыдым. Һәр ике авторның да нәни бала күңелен чагылдыру осталыгын, сәнгатьчә эшләнеш ягыннан да кызыклы гына әкият-хикәяләре барлыгы күренде. Әмма, миңа калса, авторлар 3,4,5 яшьлек бала дөньясы белән әле барыбер бербөтен булып кушылып бетә алмаганнар. Хәер, аларның максатлары да бераз икенчерәк: Рифәдә бу тема үзенең сабый чагын искә төшерү рәвешендә, Нәҗибәдә «әби—бәби» мөнәсәбәте аша яктыртыла, ягъни һәр икесендә чиста нәниләр әдәбияты тудыру максат итеп куелмаган. Бәлки, шуңадыр да, бу әсәрләрдә авторларның—артык акыллы, артык күп белүләре комачаулап тора. Ә бу жанрда йөз процентлы Абдулла Алишлык таләп ителә. Шигъриятә, билгеле бер поэтик шартлылык белән эш иткәндә, аларның бу яшь өчен дә уңышлы яза алуларын беләм, ә чәчмәдә—күңел дөньяң тоташ бер кечереш булып кәгазьгә агылганда, сабыйга әверелеп бетүе ифрат кыендыр, күрәсең. Һәрхәлдә, бу урында Белинский әйткән «балалар язучысы булып туарга кирәк» дигән фикернең хаклыгына тагын бер кат ышанырга кала. Сабыйлар өчен язуы Тукайга җинел, Алишка җинел, чөнки аларга бу үзенчәлекле дөньяга күчеп торасы юк, алар тумыштан—сакаллы сабый, даими шушы самимилектә.

Кулыма Айгөл Әхмәтгалиеваның «Болытта җиләк үсә» (2008) дигән бәләкәй китабы килеп керде. Монда, киресенчә дияр идем мин, авторның әле язучылык каләме тиешле тәҗрибә алып бетермәгән, әмма үз герое халәтенә кушылу ягыннан ул бернинди шик-шөбһә уятмый. Китапка кергән тугыз хикәясеннән алтысы әйбәтуртача, берсе табылып җитмәгән, «Болытта җиләк үсә», «Әби, Илнур һәм шигырь» исемле ике хикәясе тәмам өлгереп җиткән чын нәниләр һәм балалар хикәясе буларак кабул ителә. Айгөлнең әлегә классик хикәясе юк, әмма ул аны язарга инде әзер. Ул үзенең жанрын, үз героеның яшен тапкан, инде бөтен эшен ташлап дигәндәй, иҗатына җитди карап, аңлы төстә, эзләнүчән-максатчан берничә дистә ел шушы өлкәдә утырырга, профессиональ иҗатка күчеп тир түгәргә кирәк.

Яшь язучыбыз Рөстәм Галиуллинның «Гипнозчы малай» (2008) китабын кызыксынып укып чыктым. Баштагы унлап хикәясе беркаптырмалы, беркатлы, йомшак хикәяләр. Инде автордан күңел суынып, китапны ташлар вакыт җиткәндә генә, соңгы 4-5 хикәясе җанны азрак җылытты... Димәк, язу мөмкинлеге бар. Әлбәттә, баштагы хикәяләрне бөтенләй чыгармаганда, автор отасы гына иде. Яшь әдип алынасы биеклеге, үзенә ябышачак талантлылык дәрәҗәсе, милләте алдындагы максатлары турында күз карасыдай кайгыртырга тиеш, минемчә. Кая ашыгырга? Сан түгел, сыйфат турында кайгыртып, дөнья коткысына бирелмичә, иң башта өлгерү чорын үтү хәерлерәк түгелме соң?!.

Гөлназ Вәлиеваның әкиятләр жанрында ясаган кызыклы тәҗрибәләре оригиналь булулары белән күңелне җәлеп итә. Уңышлары да күз алдында: «Тылсым» китабы, журналлардагы әкиятләре. Авторның 5-6 телне камил белүе безнең өчен аеруча кыйммәтле. Шушы жанрдагы эзләнүләрен туктатмый дәвам итсә, аңа тәрҗемә эшләрен дә кушса, милли әдәбиятыбызны баету һәм пропагандалауда яшел юл үзе ачылып тора сыман. Күңелендәге «милләткә хезмәт итү» дигән изге ният кенә саегып калмасын иде.

Инде урта яшьтәге мәктәп балаларына багышланган кайбер китап һәм авторларга тукталып китик.

Иң элек игътибарыгызны Рәшит Бәшәр иҗатына юнәлтер идем. Поэзиядә дә, чәчмәдә дә ул актив эшли. Үз геройларының яшен дә, эш-шөгылен, фикерләү үзенчәлеген дә, үз жанрын, үз хикәяләү стилен дә инде тапкан чын балалар әдибе. А. Алиш премиясенә лаек булуы да шул хакта сөйли. Авторның «Ачык капка» (2004) китабына кергән—әле теге гасыр азагында ук язылган дүрт повестен кызыксынып укып чыктым. Әйбәт әсәрләр. Мина калса, аларның бердәнбер кимчелеге—ул да булса, классик дәрәҗәгә күтәрелә алмауларында. Мөгаен, үзебезнең каршылыклы замана җиле җитеп бетмидер... Бу хакта, әлбәттә, иң беренче чиратта, автор үзе кайгыртырга тиеш. Китапның башында 2003 елда язылган «Адашкан кош тавышы» хикәясе дә урнаштырылган. Ул менә нәкъ бүгенге көн проблемаларын үзәккә куюы белән отышлы. Әсәр авторның үткен каләмле заман язучысы була алуына тәмам ышандыра.

Икенче бер талантлы яшь балалар язучысы, моннан берничә ел элек Алиш бүләге алган Алмаз Гыймадиевның «Хуш, Тамчыгөл!» исемле китабы 2000 елда ук басылып чыккан иде. Соңгы еллардагы иҗаты белән дә танышырга теләп, үзенә мөрәҗәгать иттем. Әмма ул бүгенге сөйләшүгә материал бирмәскә булды. Мин монда фаҗига күрмим. Яшь әдипнең әле тормышында күп төрле иҗат этаплары булыр. Димәк, язучы үз-үзен эзли. Икенче китапның беренчесеннән дә авыррак язылуы яхшы мәгълүм. Алмазга табигатьтән зур мөмкинлекләр бирелгән, икенче иҗат чорына күчеп, безне әйбәт әсәрләре белән тагын да сөендерер дип ышаныйк.

Инде өченче А.Алиш премиясе лауреаты Вакыйф Нуриевның 2007 елда басылып чыккан «Жиденче палата» китабы хакында берничә фикеремне әйтеп китим. Китапны укыганда, ни өчендер, аны «Алтынчы палата» авторы белән дә гел янәшә куеп барасы килде. Юмористик хикәяләрендә, чынлап та, тормыш дөреслеген ачуда ниндидер охшашлык та бар сыман. Дөрес, Вакыйфның геройлары—балалар, әсәрләрендә фаҗигале ноталар да азрак. Әмма хикәяләре мавыктыргыч, кызыклы. Җитди әсәрләре дә эшләнешләре ягыннан көлкеле хикәяләреннән ким түгел. Китапта өч повестьте урын алган. «Әбиемә—әфлисун» повестен мин соңгы елларда

балалар өчен язылган иң яхшы чәчмә әсәрләрнең берсе дияр идем. Автор баланың әбисенә карата булган тирән, эчкерсез мәхәббәтен гаять тәэсирле, сәнгатьле, милли рухлы итеп тасвирлый. Вакыйфның классик әдәбиятка якынлашуында төп киртә булып, минемчә, аның билгеле бер кысаларда яшәп, шуннан чыга алмавы тора. Әлеге кыса хәтта калган ике повесте сюжетына да килеп керә: берсендә төрмәгә һәм кешеләр мөнәсәбәте тоткынлыгына эләккән Тимерхан тормышы, төп нәни геройның рухи дөньясы да үзенең гомерен коткарып калган бу кешегә кылган игелеге Павлик Морозов дәрәҗәсеннән узмый; икенче повестьта да нәкъ шул чикле кыса—больница палатасы, тормыш исә шуның эченә генә килеп керә сыман. «Әбиемә—әфлисун» әсәрендә язмыш авторга бу кысаларны үтеп чыгу мөмкинлеге биргән. Нәни геройның мәхәббәте дә ил күләме масштабындагы вакыйгалар эчендә тирән, саллы, детальле кичерешләр яссылыгында формалаша. Димәк, язучыга алга таба да иҗатында философиядә булсын, психологиядә булсын—әнә шундый кысаларны тарсынган, оригиналь чишелеш сораган тормыш материалы белән эшләү сораладыр.

Инде икенче жанрга—әдәби тәнкыйтькә күчсәк, өлкән буын әдәбият галиме Фатима Ибраһимованың XX йөз башында мәктәп-мәдрәсәләрдә укылган әдәби ядкарьләребезне бергә җыйнаган «Мирасыбызны туплау юлында» (2010) китабының басылып чыгуын күрсәтергә кирәк.

Яшь галимәбез Ләйлә Минһаҗеваның да татар балалар әдәбиятын өйрәнүгә караган хезмәтләре басыла тора. Күптән түгел бу темага ул докторлык диссертациясен тәмамлады. Тәнкыйть остаханәсендә без аны Язучылар берлегенә дә тәкъдим иттек.

Әдәби тәнкыйтькә кагылышлы төстә тагын Айдар Хәлимнең ике саллы китабын атап үтәсем килә. Аларның «Сез беләмсез кая барганны?» дигәне 2005 елда, «Татар балалар шигърияте» һәм «Орчык малай Биктырыш» китабы 2010 елда дөнья күрде. Беренчесендә автор «Безнең заман герое» темасына ирекле уйлануларын, милли әдәбиятыбыз алдына дөнья классикасы югарылыгыннан торып куйган житди-кырыс таләпләрен бәян итә.

Китапның икенчесе турыдан-туры безнең бүгенге сөйләшү темасына карый. Милли әдәбиятыбыз язмышын кайгыртып, изге теләк белән язылуы, мәсьәләгә, шулай ук, мәдәни традициябез һәм дөнья әдәбияты үлчәмнәреннән чыгып якын килүе, иҗатыбызда таләпчәнлекне арттыруга юнәлтелгән бик күп үрнәк һәм гыйбрәтле мәгълүматның туплануы—хезмәтнең, һичшиксез, уңышы саналырга тиеш.

Шуның белән бергә, мин биредә китапның уртак милли эшкә зыян салган якларын да, ягъни бер мичкә балга бер кашык дегет кушып бирелүен дә күрсәтеп китми булдыра алмыйм.

Әдәби тәнкыйть—әсәргә, автор иҗатына анализ ясау, объектив бәя бирү ул. Тәнкыйть мәкаләсе язу—әдәби процесска судья-хөкем чыгаручы булу дигән сүз. Аның иң беренче бурычы—һичшиксез, гаделлек, үз мәнфәгатьләренне тулысынча читкә куеп тору. Үз иҗат кредоңны алга сөреп, аның белән башкаларның иҗат принцибын бәреп егарга маташу, автор фикеренең хаклы булу-булмавына да карамастан, тәнкыйтьче уставының иң беренче пунктыннан читләшү дигән сүз.

«Без татарлар шундый инде...» дип, шушы авыр жанрда әдәбиятның лидерына әверелгән шагыйрьләр иҗатының изүенә барып ябышуны мин дөрес гамәл дип санамыйм. Каш ясыйм дип күз чыгару—кемгә файдалы соң? Үзара нәрсәдер бүлешүнең Тукай—Ибраһимовлар, Исхакый—Кәримиләр һ.б. мисалында мәгънәсезлеген без үз язмышыбызда бик яхшы аңладык түгелме соң инде?! Милләтнең әчке бүленүенә китергән мондый гамәлләрне эшләмәү—уртак эшебезнең бисмилласы булырга тиеш иде, югыйсә. Гүя, безнең алда башка көрәшер кара көчләр калмаган диярсең...

Сөйләгәннәрдән һәм логик нәтиҗәләрдән чыгып, мин җыелыш игътибарына түбәндәге биш тәкъдимемне җиткерәсем килә:

1. Үзгәртеп корудан соңгы 25 ел эчендә татар балалар әдәбиятының тиешле дәрәҗәдә классик әсәрләр белән баетылмавы күңелдә житди борчу тудыра. Нәниләр

әдәбияты үсешен үз агымына куюның фаҗигале нәтиҗәләргә китерүе аның житди дәүләт игътибарына алынырга тиешлеге хакында искәртә.

2. Әдәби иҗат продукциясенең заман югарылыгында булмавы, классиканың да заман күзлегеннән чыгып бәяләнмәве, «тоташ савытлар» законы нигезендә, мәктәп укыту дәреслекләрендә дә чагылыш тапмый калмый. Бүген кичекмәстән татар балалар әдәбияты тарихын язу, башлангыч сыйныфлар өчен уку һәм әдәбияттан системалы нигезе булган өр-яңа заман дәреслекләре төзү бурычы килеп баса.

3. Бүгенге көндә иң мөһим проблемаларның берсе— укучы баланың индивидуаль йөзен, аның шәхесен саклап калу. Глобальләштерү, компьютерлаштыру заманында исә аны халык массасының уй-фикерсез бер шөребе, робот итүгә бөтен шартлар тудырылган. Әлеге гомум агым-педагогик диктаттан коткару өчен, 20-25 укучылы зур класслар эчендә дә 5-6 баладан торган максатчан юнәлешле уку, иҗат, шәхес төркемнәре оештыру отышлы булыр иде. Талантларның бик иртә—3-4 яшьтән үк—ачылуын һәм ачарга кирәклеген исәпкә алсак, моның әһәмияте тагын да арта. Монда хикмәт укучы санында гына яисә укытучыларның, дәрескә кереп, әзер фикерләрне көчләп укучыга тагуда гына түгел, хикмәт уку-укыту процессының төп герое һәм әйдәп баручысы укучы баланың үзе булырга тиешлегендә. Шәрекъта гомер бакый остазны шәкерт үзе сайлап алган. Уку юнәлеше, күләме шәкертнең мөмкинлеге һәм теләге белән бергә килештереп эшләнгән. Укуның нәтиҗәсе дә шуна күпкә нәтиҗәлерәк булган. Чит телләрне өйрәнгәндә, музыканың солфеджио, гармония кебек катлаулырак төрләрен үзләштергәндә, һәртөрле спорт секцияләрендә ул хәзер дә шулай.

Гомум укытуда да, бигрәк тә ярым иҗади әдәбият дәресләрендә методиканың болай координаль үзгәреше безнең милләт өчен аеруча отышлы булачак. Ул чагында класслар кечкенә дип кайгырырга түгел, киресенчә, бала белән эшләү мөмкинлеге артуга сөенергә генә кала. Мәскәүнең чираттагы уйлап бетерелмәгән закон-таләпләренә дә кечкенә мәктәпләрне кушмау белән түгел, ягъни оборона тотып түгел, әлеге шәрекъчә яңа укыту принцибы белән үзебез-үзебезгә һөҗүм итеп каршы торырга кирәк.

4. Мәктәпләрне компьютерлаштырдык дип мактанган министрларның сөенечен уртаклашырга да мин бик ашыкмас идем. Урынлы-урынсыз кулланунын, бигрәк тә бу эшкә башлангыч сыйныфларны, әдәбият, тел предметларын сөйрәп кертүнең файдасыннан зыяны күбрәк булуын исбатлап тору кирәк түгел дип беләм. Башта шәхес, белгеч әзерләргә кирәк. Компьютерга өйрәнергә бер ай вакыт житә, әмма компьютер белән бозылган баланы инде иҗади фикерләүгә түгел, гади җөмлә төзергә өйрәтергә дә, тулы бер гомер җитмәячәк. Аның саулыгы, максатчан яшәеше, үз телен, үз милли культурасын, кыйбласын табигый үзләштерелергә тиешлеге хакында әйтеп торасы да юк. Компьютердагы БДИ сораулары һәм җаваплары, инша текстлары, аларга укучының үзлегеннән иҗади өстәргә тиеш булган, әмма инде күптән әзерләнеп куелган үрнәкләр... Үз халкын зур педагогик кәмит-уенда катнаштырып, гомерлеккә бер калыпта яшәргә өйрәтеп калдыру—ил җитәкчелегенең төп куйган максаты шул дип уйларсың?!

5. Халкыбыз күңеленә табигатьтән җыр-моңга, шигърияткә эчке омтылыш дәрте салынган. Әмма бик еш очракта әлеге сәләтнең шул башлангыч һәвәскәрлек дәрәҗәсендә торып калуы да беркемгә дә сер түгел. Җыр-музыкада да, әдәби иҗатта да шулай. Бик күпләрнең балачак мавыгуы урта һәм югары үсеш этабына җиткәндә үк тукталып кала. Югары уку йортлары булган Казанда да олы шагыйрьләребезнең үсмәве, монда килгәннәренең исә таралып-вакланып бетүе очраклы түгел. Казан—урыслашкан һәм чиновниклашкан башкала. Монда шагыйрьләр урыслаша һәм чиновниклаша ала, әмма аларның кабат татарлашканнарын да, чиновникларның кабат шагыйрьгә әверелгәннәрен дә әле күргән булмады. Шуңа күрә милләтебезне, милли культурабызны, шигъриятебезне, балалар әдәбиятын саклап калыйк дисәк, безгә Казаннан читтә дә милли-иҗади культура үзәкләрен саклау һәм оештыру мөһим. Халык тормышында, хәер, ул шуңа таба бара да инде. Мин биредә яңа оешкан театрларны, әлегәчә үтеп килгән төрле иҗади форумнарны истә тотам. Республикабызда без бүген, әйтик, кимендә бер-берсе белән ярышырлык җиде

әдәби-иҗат үзәге оештырырга тиешбез дип беләм. Казанда, Әлмәттә, Чаллыда бар инде. Бүген исемнәре телгә алынган авторлар да нәкъ шуны раслап тора. Боларга өстәп Арча төбәгендә, Буа төбәгендә һәм тагын ике төбәктә (бәлки, Актаныш-Мөслим-Минзәлә һәм Чистай-Нурлат-Аксубай яки Саба төбәгендә?) әдәби-иҗат үзәкләре оештыру иҗатның урта этабын җанландыруга зур өлеш кертә алыр иде. Ә инде аларны үзешчәнлектән чыгару өчен югары профессиональ координатор-белгеч белән тәэмин итү мөһим. Һәрбер үлү, таркалу—идеянең юкка чыгуы белән бәйле. Без 25 ел элек хыялланган Казан әлегә үзен акламады. Димәк, идеянең янасы кирәк, милли рух үсешенә тагын да көчлерәк яна дулкын кирәк.

Бүген без даһи Тукаебызның юбилеен тантана итәбез. Әмма Тукай дөнья әдәбияты югарылыгына ялгыз чыкмаган. Без «20 йөз башы әдәбияты» дип йөрткән дистә ел татар культурасына уннарча классик әдибен, йөзләгән уникаль шәхесләрен биргән. Ә без бүген әдәби мирасыбызга, хәтта шау-шулы үзгәртеп корудан соң да, чирек гасыр дәвамында ничә генә классик әсәр өсти алдык икән?!. Яна Тукайларны өмет итсәк, без башта, яна үсеш чорында, дистәләгән классик әдибебезне әзерләргә тиешбездер. Ә инде даһилыкка килгәндә—монысын бирү-бирмәүне бары тик бер Ходай үзе генә хәл итә!

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**

*ТДГПУ доценты:*

...Сүзебезне дөнья әдәбиятында кин таралган әниләр турындагы әсәрләргә бәйләп башлыйк. «Әни кирәк», «әни кирәк» дип җырлыйбыз, бу—һичкайчан искермәячәк тормыш кануны. Һәр баланың һәр яшәеш көненә индерелергә тиешле сүзләр. Әниләр турында шул кадәр күп язалар, без инде кемнең ничек язганлыгын аера алмас хәлгә килә башладык. Әмма әдәбиятның чаралары бер генә түгел бит! Ни өчен «әниләрен яратучылар» яна алымнар эзләмиләр? Бер үк әйберне кабатлап тору ялыктыра бит! Ни өчен бу турыда матур итеп, янача, образлар аша, хәтта шаккаттырырлык итеп әйтмәскә? Эзләнәләрме бүген балалар өчен язучылар, әллә бер-берсен кабатлап кына утыраламмы?

Ә бүген үрнәк булырлык әтиләр турында әсәрләр бармы? Дөрес, бу темага онытылганда бер язып куючылар очрый. Үз вакытында Ж.Дәрзаман да башкалардан аерылыбрак, үрнәк ата образын бирергә омтылды. Мисал итеп, аның «Тылсымлы чүкеч»ен китерергә мөмкин:

*Әти сукса, нык суга,*
*Кадактан да ут чыга.*
*Каян килә мондый көч,*
*Тылсымлыдыр бу чүкеч.*

Балалар әдәбиятына бүген тирәнтен һәм һәрьяклап эзләнүләр җитми. Сорау туа: ни өчен Даниил Хармс, Самуил Маршак, Корний Чуковский гаҗәеп сурәтләр, образлар аша укучыларга матур фикерләр җиткерә алганнар? Ә бүгенге безнең әдәбиятка ул җитешми. Фикерне турыдан-туры әйтү—ул бит әдәбият эше түгел! Образ бит сынландырганда, сындырып (смешение), рикошет ясап чагылдырганда гына туа. Кызыклы ситуацияләре дә ясалсын! Даниэль Дефоның «Робинзон Крузо»сы, Свифтның «Гулливер сәяхәте», Жюль Вернның «Капитан Грант балалары»—шушы экстремаль ситуацияләрдә җинүче булып чыккан яшь геройларны күреп, күпме буыннар нык булып тәрбияләнеп үскәннәр. Бер әсәрдә дә авторлар үгет-нәсихәт укымаганнар, билгеле бер ситуациягә балаларны ыргытканнар гына. Кем булып каласын, язмыш үзе күрсәтә синен кемлегенне. Әдипләр шуны әйбәт чагылдырганнар.

Ә Габдулла Тукаебыз?!. Быел Тукай елы. «Шүрәле»дә нәни герой Былтыр образында үзен күрә. Ул үзен ничек тотар иде? Аның шул хакта уйлаячагын Тукай белгән.

«Су анасы»—бу урында яшь героебыз, әлбәттә, бераз ялгышты. Кызыкты бит кеше тарагына! Ни хәл итәсең, барыбыз да кызыгып яшибез. Актуаль мәсьәлә. Әмма нәтиҗәсе бик әйбәт:

«Йә иясе юк дип, әйберләргә тими башладым». Ә бүген бөтенләй башка философия: «Йә иясе юк, чәлдереп калыйм», дип яшиләр. Һәм болар балалар әдәбияты проблемасы гына түгел. Ә кисәтергә Тукаебыз юк!

Бу кыйбласыз заманда балалар әдәбияты гына бу җинаятьләр белән көрәшә алмый, әлбәттә. Гомумән, әдәбиятның моңа көче җитми! Ә балалар әдәбиятына ни кала...?

Халык авыз иҗатына игътибар кирәк. Бераз бар ул, әмма бездә әлегә бу тиешле дәрәҗәдә түгел. Дөнья әдәбиятына мөрәҗәгать итсәк, ил буйлатып беренче әсәрләр дә фольклорга таянып язылган. Ян Амос Коменский халык авыз иҗатына таянып үлмәс «Мир в картинках»сын яза, дөньякүләм мәгълүм француз Шарль Перро, халык әкиятләрен эшкәртеп, барлык милләт балалары укуы өчен кызыклы итә. Геройлары эшчән, түзем, тапкыр, киң күңелле. Тормыш чынлыгы фантазия белән үрелеп, үзәктә тора. Әкиятләр нигезендә—халыкның үз балалары өчен иҗат иткән әсәрләре, тормышның сәнгатьчә чагылышы.

Үзебездән бер мисал:

*...Баш бармак. Бер. Әткәйгә.*
*Әткәй—өйдә баш кеше.*
*Имән бармак. Монысы—*
*Әнкәемнең өлеше.*
*Урта бармак—өченче.*
*Бусы инде, билгеле,*
*Әбиемә тиешле.*
*«Әбкәем», дип кадерләп*
*Эндәшәбез без аңа*
*Йомшак урын әзерләп*
*Утыртабыз уртага.*
*...Чәнти-чәнти—чәнтикәй,*
*Ул да, мин дә бәләкәй!..*

Начармыни? Юк бит, нәкъ менә татар рухына җавап биргән кыйммәтләрне балалар фольклорыннан алып, үзәккә куя белә М.Газизов!

Яисә, икенче мисал. Моннан өч ел элек, VI сыйныфта укучы кызым дәрескә кирәк дип, ятлау өчен миннән шигырь сорый. Үзе сайлап алсын дип, балалар әдәбияты әсәрләреннән төзелгән ике томлык хрестоматияне бирдем. 15-20 минуттан, кызым, «ятладым, сөйлимме?», дип яныма килде. Күңеленә хуш шигырьләрне бик тиз отып алуын белсәм дә, гаҗәпкә калдым. Ә сер гади генә икән! Лирик әсәр ике юлдан гына тора, «Минем шигырь түгәрәк, әнә бара тәгәрәп». Ни өчен нәкъ менә әлеге шигырьнең сайлануы, әлбәттә, табышмак түгел. Баланың игътибарын форма үзгәлеге үзенә тарткан. Алар бит гадәти шигырьгә ияләнгән. Ә биредә—түгәрәк шигырь. Бу баланы әдәбият белән кызыксындыруның бер алымы түгелмени? Аерым авторлар еш кына әсәрләрен укучы алдына сорау куеп тәмамлыйлар. Бу да үзенчәлекле күренеш, уңышлы куелган сораулар укуны кызыклы һәм шатлыклы итә, аңа бала чын күңелдән җавап табарга омтыла, канәгатьлек хисе кичерә.

Фольклорга таянып иҗат ителгән, халыкчан әсәрләребез, Аллага мең шөкер бар, уңышларыбыз бар. Әмма күпчелек бит бер урында таптанырга ярата. Балалар пьесаларында Т.Миңнуллин халык авыз иҗатыннан килгән геройларны уңышлы кулланып, үрнәк биргән иде. Соңгы елларда Ф.Яруллин, Г.Гыйльманов, Р.Корбан, Р.Мингалим пьесаларында матур гына, кызыклы ачышлар белән очраштык. Г.Гыйльмановның (үзе дә «Татар мифлары» китабы авторы) стенада көн күргән Бүкәй турындагы «Булат нигә яхшы укый?» әсәрләре мәктәп сәхнәсендә күп куелды.

Безнең әдәбиятыбызда фәнни-фантастик, детектив, мажара жанрында эшләүчеләр бармак белән генә санарлык, уңышларыбыз да аз. Италияле Коллодиның (Карло Лоренцини)—фәнни фантастика кысаларында язылган «Пиноккио мажаралары»н искә төшерик. Ул бездә А.Толстой эшкәртүендә «Алтын ачкыч яки Буратино мажаралары» буларак билгеле. Автор әсәрен башта Буратиноның асылу вакыйгасы белән тәгалләргә теләгән. Укучылар бик зур тавыш куптаргач кына автор әсәрен дәвам итәргә мәжбүр була. А.Конан Дойл да «Шерлок Холмс мажаралары»нда, төп героен карангылыкка, бушлыкка озатып, әсәренә нокта куярга уйлый. Әмма укучыларның ризасызлыгы шул дәрәҗәгә җитә ки, язучы үзе ук курка кала, янадан героен тормышка кайтарырга мәжбүр була. Ни өчен Г.Кутуйның «Рөстәм мажаралары» повесте уку өчен бүген дә кызыклы? Чөнки ул реаль тормыш та кебек, юк та кебек. Укымыйлар дип әйтмәгез, мондый кызыклы әсәрләрне балалар укый.

Уңышларыбыз да бар. Ул күбрәк прозада бала психологиясен тирәннән ачу белән бәйләнә. Сыйныфтан тыш укуларда балалар В.Нуриевнын хикәяләрен бер тында укып чыгалар, бәхәсләшәләр, көлешәләр. Ф.Яруллинның тормыш проблемаларын бала кичерешләре аша ачуы үзе генә дә ни тора! А.Гыймадиев, Л.Лерон, Р.Газизов, Й.Миннуллина иҗатлары кызыклы, балаларча, гади.

Гражданлык, патриотик тәрбия мәсьәләләрен яктырту балалар әдәбиятында күптәннән килә, әмма соңгы елларда әлеге тема беркадәр сүрелде. Дөрес, балалар көен көйләгән булып, балалар кебек кыланган булып, бүген күп шигырьләр языла. Ерак эзләп йөрисе түгел, «Мәйдан» журналының соңгы битләрен актарыгыз. Анда балаларны артык кечкенәгә санап, аларча «межелдәү» мисалларын күп күрерсез. Ә балалар үсә. Бездән артыграк белеп үсәләр. Һәм укыйлар...

Әдәбият исә балаларга һаман да элекке юнәлештә тәэсир итәргә, тәрбияләргә тырыша.

Бу турыда уйланучыларга мин «Большие мамочки: сын как отец» дигән Америка фильмын карарга тәкъдим итәр идем. Әтисе башта улына бер дә юл куймый, аны үзенчә тәрбияләмәкче була. Тегесе тыңламый. Әмма икесе дә үлем куркынычы астында калгач, әти кешенең тормыш тәҗрибәсе, кыюлыгы аркасында гына үлемнән котылуларын күреп, шуны аңлап, улы әтисенең ныклы таянычына әверелә. Димәк, балалар өчен язам дисән, үзен күп бел, тормышны, аның кануннарын өйрән.

Аннары, балалар язучысы булсаң, төрле өлкәләрдәге могҗизалардан хәбәрдәр бул. Сәяхәт ит. Сәяхәт турында китаплар укы. Жюль Верн кебек. Чит илгә генә түгел, тере язучы күрергә тилмергән татар авылларына, балалар бакчаларына, мәктәпләргә йөр. Язучы һәм мәктәп арасында бүген бәйләнеш нык түгел. Әмма, ничек кенә булмасын, чор язучылары геройларының характерларын мәктәп хәлләре аша да сурәтләргә тиеш.

Гаделлек тантанасы турында күп яз. Дөрес, бүген дөньяда гаделсезлек өстенлек итә. Бүген заман геройлары Мисырда, Туниста, Ливиядә гаделлек өчен көрәшә. Безнең язучыларыбыз бу турыда берни белми, язмый дияргә була.

Дини тәрбияне дә әдәбиятта куллан. Диннең риваятьләре, сүрәләре, аятьләре күп төрле әдәби образларга әйләнеп, яшьләрне тәрбияли ала. М.Фәйзуллинаның «Гаилә әлифбасы» бар. Ф.Яхиннын «Пәйгамбәрләр тарихы» бар, Аллаһы Тәгаләбезне зурлаган хикәяләре бар. Аның «Ак әбиләр догасы»—исеме генә дә ни тора! Менә өстәп, Дүсем авылы ак әбиләренең зикер әйтеп, Коръән чыгып, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сораулары, теләк кабул булып, могҗиза туу үзе үк сер, могҗиза түгелмени!?

Хезмәт тәрбиясе. Совет чорында бу тема әдәбиятта уңышлы гына гәүдәләнә иде. Бүген бөтенләй юк. Болай ярамый бит, торгызырга кирәк!

Үрнәк алырлык геройлар, батырлык үрнәге кирәк. В.Сухомлинский юкка гына хезмәтләрендә баланың үз-үзен тәрбияли башлавы өчен аның үзенә беркадәр охшаган үрнәк герой кирәклегенә басым ясамый. Тормыш тәҗрибәсе әле зур булмаган бала, җәмгыятьтә формалашу өчен үрнәк эзли.

Балалар әдәбиятында менә борчыган мәсьәләләрнең бер өлеше менә шул.

**Рафис КОРБАН,**

*Татарстан Язучылар берлегенең балалар әдәбияты остаханәсе җитәкчесе:*

XXI гасырга аяк баскач без балалар өчен иҗат итүче яшьләребез арасыннан унлап кешене язучылар берлегенә кабул иттек. Тагын әле балалар өчен иҗат итә бу дип безне шатландырган 7-8 исем күренеп тора. Ун елда егермегә якын яңа исем—бу бик күңелле күренеш! Ләкин бүген шушы залда утыручылардан: «кемнәр соң болар?» дип сорасак җавап бирә алыр идегез микән? Унай җавап ала алмавыбыз да бик мөмкин. Чөнки, ник дигәндә, бу егермегә якын яшь балалар язучыларының өч-дүртеннән калганы барысы да—районнарда яшәүчеләр. Ә бит читтә булгач, уртак проблемаларны уртага салып сөйләшүләрдән дә читтә торасың дигән сүз; яңа язылган әсәрләрне дөньяга чыгару да кыенрак; алар берлек үткәрә торган чаралардан да читтә торып калалар. Кыскасы, үз «шулпаларында» гына кайнашып яталар. Мин Азнакай, Лениногорски, Түбән Кама, Алабуга, Сарман, Чистай, Аксубай кебек районнарның ерак авылларында яшәп ятучы язучыларыбызны күз алдында тотып әйтәм.

Әдәбият мәйданында беренче шигырьләре әле алтмышынчы елларда ук күренә башлап та, берлеккә бары тик 2003 елда гына кабул ителгән Вәсимә Хәйруллинаның шигърияттә җиң сызганып эшли алырдай яшь гомере авыл мәктәбендә укытучы булып узган. Ул бары тик пенсия яшенә житкәч кенә янадан кулына каләм алып, шигырьләр яза башлады һәм балаларга бер-бер артлы биш-алты китап бүләк итте. Безнең балалар әдәбиятында пенсия яшенә житеп, балалар шигыренең классик үрнәкләрен иҗат иткән Зәкия Туфайловабыз бар. Вәсимә Хәйруллинадан да шундый шигырьләр көтәргә хаклыбыз. Ләкин, кызганычка каршы, аның китапларында инде таныш, каядыр укылган образлар белән генә очрашырга туры килә.

Соңгы елларда берлеккә кабул ителгән Миннеруй Гайфуллина-Хәбибуллинаның да балалар әдәбиятында үз сүзен әйтерлек иҗат мөмкинлекләре бар. 2009 елда «Мәгариф» нәшрияты аның татар халык әкиятенә нигезләнеп язган «Зөһрә» дигән шигъри әкиятен аерым китап итеп бастырып чыгарды. Мавыктыргыч, шигъри, матур тел белән язылган әкият.

Берлеккә шулай ук бер-ике ел гына элек кабул ителгән Зөләйха Минһаҗеваның да балалар өчен шигырь һәм әкиятләре шактый кызыклы, мавыктыргыч. Ул аларны күбесенчә «Мәйдан» журналы аша, нигездә Чаллы төбәге балалары өчен генә тәкъдим итә. Зөләйха нәни укучыларны дөнья белән, әйләнә-тирә табигать, хайваннар дөньясы белән таныштыра. Шул ук вакытта Зөләйханың шигырьләре җентекле редактор күзеннән үткәрүне дә таләп итә.

Узган гасырның туксанынчы еллары азакларында, япь-яшь килеш кабул ителергә өлгергән кызларыбыз Сөмбел Гаффарова белән Лиана Әмирхановаларның әдәбияттан бөтенләй читләшүе дә гафу ителмәслек хәл. Ә бит аларга зур өметләр багланган иде. Шәхсән мин үзем Сөмбелдән талантлы, мавыктыргыч, шаккатып һәм сокланып укырлык әкиятләр көтеп калам. Аның беренче китабы безгә шулай өметләнергә мөмкинлек биргән иде.

Балалар өчен хикәяләр иҗат итеп мәйданга чыккан яшьләребез турында да сүз әйтмичә кала алмыйм. Шулар арасыннан мин Айгөл Әхмәтгалиева, Рөстәм Галиуллин, Айсылу Галиева, Айсылу Имамиева, Лилия Закирова исемнәрен канәгатьләнү белән санап үтәргә телим. Айгөл белән Рөстәмне без үз арабызга кабул иттек. Алар бүгенге көндә, берсе—Чаллыда, икенчесе—Казанда, безнең иң мәртәбәле журналларыбызда җиң сызганып үзләренең әдәби-иҗтимагый эшчәнлекләрен алып баралар. Аларның Шәһит Әхмәдиев, Идрис Туктар, Габделхәй Сабитов, Габдулла Шәрәфи, Гариф Галиев, Ләбибә Ихсанова, Роза Хафизоваларны алыштырырдай әдипләр булып житешүләрен көтеп калабыз.

Бу исемнәр янына мин тагын Илшат Сәйфуллин дигән егетебезне өстәгән булыр идем. Ләкин, кызганычка каршы, балалар өчен матур гына хикәяләр язып, 2007 елда Татарстан китап нәшриятында «Жиденче дәрес» исемле китабын бастырып чыгарган егетебез, тормышында зур хата ясап, Чечня жиренә урыс тәртибе урнаштырырга

киткән жиреннән әйләнеп кайтмады, һәлак булды. Илшат нәниләр өчен кызыклы гына шигырьләр дә яза иде. Кызганыч...

Илшат белән бер үк вакытта, шулай ук талантлы гына хикәяләр китабын чыгарган Лилия Закирова да каядыр югалды. Шәхсән мин белмим, берәр районга китеп, берәр мәктәптә балаларга белем биреп ятамы, әллә кияүгә чыгып, бала үстерәме? Бәлки киләчәктә бер табылыр, килеп чыгар әле.

«Авылдан килгән мендәр» дигән шигырьләр китабы чыгарып, балалар шигъриятендә үз сүзен әйтә башлаган, Илдар абый Юзеев «балалар шагыйре булыр бу егет» дип, зур өметләр баглаган Ленар Шәех тә соңгы елларда балалар өчен язудан читләшебрәк тора. Ленардан, чыннан да, бик әйбәт балалар шагыйре чыккан булыр иде. Ләкин ул зурлар өчен иҗат итүне мәхкүль күрә булса кирәк.

Соңгы ун елда берлеккә кабул ителгән яшьләр арасында, минем уйлавымча, балалар өчен иң талантлы һәм иҗатында кызыклы образлары, матур табышлары, әйтер сүзе булган шагыйрә, мөгаен, Резидә Шәриповадыр. Резидәнең Чаллы гәзит-китап нәшриятында 2003 елда чыккан «Сандугач керсә күңелгә» дигән шигырьләр һәм шаян хикәяләр китабын укыганым бар иде. Шул китабыннан ук күңелдә «әдәбиятка үз язу алымы, үз сүзе булган шагыйрә килә» дигән уй туган иде. Ә инде балалар өчен язган шигырьләрен укыгач, тагын бер сөендем. Әдәбиятка Бари Рәхмәт, Әхмәт Фәйзи, Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин кебек шагыйрьләребез традицияләрен дәвам итәрдәй талантлы автор килә. Күптән түгел идарәдә Резидәне Язучылар берлегенә кабул иттек. Инде Язучылар берлеге әгъзасы булгач Резидәгә үз иҗатына таләпчәнрәк карарга, ашыкмыйчарак, тырышыбрак язарга кирәк.

Балалар өчен кызыклы, мавыктыргыч әкиятләр китабы чыгарган Айсылу Имамиева, әдәбият сөючеләргә «Ялкын» журналында басылган повесть-хикәяләре белән таныш. Әле әйтелгән исемнәргә өстәп Түбән Кама каласында яшәп ятучы, «Кама таңнары» әдәби берләшмәсен яңадан торгызып, бу төбәктә бердән, әдәби хәрәкәтне җанландыру өчен тырышып йөрүче, икенчедән, балалар өчен кызыклы гына шигырь китаплары бастырып чыгарган Илзирә Вәлиуллина; Әлмәт нефтьчеләр каласында балаларга белем бирү белән бергә, матур-матур шигырьләр иҗат итеп, инде дүрт китап (икесе Татарстан китап нәшриятында) бастырып чыгарырга өлгергән Резида Фәрхетдинова; шул ук Әлмәт районының Кәләй авылында укытучы булып эшләп, зурлар һәм балалар өчен шигъри әкиятләр китабы бастырып чыгарган Зинаида Захарова; әле мәктәптә укыган чагында ук Татарстан китап нәшриятында һәм «Мәгариф» нәшриятында инде дүрт китабын бастырып чыгарган, хәзерге вакытта Казан югары уку йортларының берсендә белем алучы Азнакай кызы Римма Шәехова исемнәрен дә атарга була.

Тагын бер мәсьәләгә тукталып үтәсем килә.

Быел мин өч яшьтән җиде-сигез яшькәчә булган нәниләр өчен журнал чыгара башладым һәм шуңа реклама ясыйм дип күп кенә районнарда, мәктәпләрдә, балалар бакчаларында очрашуларда йөрергә туры килде. Очрашуларга болай да күп йөрим. Быелгы очрашулар күңелдә бик авыр тәэсирләр калдырды. Беренчедән, Казан мәктәпләрендә, гимназияләрдә, балалар бакчаларында, гәрчә татар мәктәпләре, татар гимназияләре, татар бакчалары дип аталганнарында да, нигездә урыс телендә сөйләшәләр, дәресләр урыс телендә генә бара, татарлык сүздә генә. Икенчедән, күп кенә мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укытучылары дигәннәре дә, хәтта үз районнарыннан чыккан Тукай премиясе лауреатларын әйтеп бирергә кыенсыналар. Балалар бакчаларында көн үтсенгә йөрүче тәрбиячеләр тулып ята. Баланың туган телендә сөйләшергә өйрәнеп үсү-үсмәве андый тәрбиячеләр өчен әллә бар, әллә юк. Алар татар язучыларын белмиләр. Китап укымыйлар. Матбугатка язылмыйлар. Күп мәктәпләрдә соңгы егерме елда хәтта укытучылар үзләре тере язучы күрмәгәннәр. Язучыларыбыз «тел бетә, милләт бетә» дип лаф орган булалар, ә менә шул телне саклап калу өчен хезмәт итә торган мәктәпләргә барып та караганнары, үз укучылары белән очрашканнары юк. Шөкер, мәктәпләргә балалар язучылары күп йөри. Бигрәк тә гәзит-журнал тирәсендә эшләгәннәре. Ә бит телне, милләтне саклау балалар язучыларының кайгысы гына булырга тиеш түгел! Элек берлектә

пропаганда бүлеге бар иде. Рәфкать Кәрами язучыларны укучылар белән, халык белән очрашуларга йөртә торган иде. Китап сөючеләр җәмгыяте бар иде. Шул җәмгыять укучылар, эшче-яшьләр белән төрле очрашулар уздыра торган иде. Пропаганда бүлеген дә, китап сөючеләр җәмгыятен дә берлек каршында яңадан оештырырга була бит. Үзебезнен китапларыбызны да, гәзит-журналларыбызны да пропагандап, рекламалап, сатып йөрергә бер дигән мөмкинлек! «Китап сатылмый, китап кибетләре юк» дип зарланабыз. Ә үзебез моның өчен бер нәрсә дә эшләргә җыенмыйбыз да, теләмибез дә. Әлбәттә, бу эшне кемдер оештырырга тиеш. Ә ул оештыручы безнең Язучылар берлеге булырга тиеш. Югыйсә нигә кирәк ул безнең берлегебез?! Сүземне түгәрәкләп, кабат балалар әдәбиятына әйләнеп кайтам һәм тормышларын язучылык хезмәтенең икенче пландарак торган, ләкин яңа кеше тәрбияләүдә, ә безнең очракта туган телебезне, милләтебезне саклап калуда бәһаләп бетермәслек эш башкаручы балалар язучыларына тагын бер мәртәбә зур рәхмәт белдерәсем килә!

## Фәнни-гамәли конференциянең резолюциясе

*Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге 2011 елның 20 маенда әдәби ел йомгаклары кысаларында «Балалар әдәбиятының торышы һәм үсеш перспективалары» дигән темага фәнни-гамәли конференция үткәрделәр. Конференциядә катнашучылар бу чараның әдәбиятка яңалык алып килү, аның үсешен, киләчәген кайгырту, каләм ияләренең, әдәбият галимнәренең, киң җәмәгатьчелекнең игътибарын балалар әдәбиятын үстерүгә юнәлдерү максатында әһәмиятле вакыйга буларак билгеләп үттеләр.*

*Докладлардан һәм чыгышлардан күренгәнчә, балалар өчен язылган әсәрләрдә—роман, повесть, хикәя, әкият, шигырь, поэма, пьесаларда—гуманизм идеяләрен, гомумкешелек кыйммәтләрен күздә тоткан күркәм традицияләр дәвам иттерелә.*

*Бүген балалар әдәбиятын пропагандалау, аны яшь буынга ирештерү, язучыларыбызның әсәрләре аша балага әхлакый, милли тәрбия бирү, аның эстетик зәвыгын үстерү, аны әдәпкә өйрәтү глобальләшү, оптимальләштерү, ягъни татар мәктәпләренең азаюы, татар теле, татар әдәбияты дәресләренең кыскартылуы, мәктәптә уку-укыту программаларында төгәл фәннәргә, чит телләргә өстенлекле юнәлеш бирү шартларында бара. Әмма укыту-тәрбия процессындагы мондый шартлар әдәбиятның ролен киметергә тиеш түгел. Баланың интеллекты, фантазиясе, күңел сафлыгы ни дәрәҗәдә булуы әдәбиятка турыдан-туры бәйле. Безнең балалар әдәбияты—зур традицияле, күренекле әдипләргә, рухи хәзинәбезгә кергән әсәрләргә бай әдәбият. Ул бүген дә үз миссиясенә тугры. Шулай да вакыйга булырлык әсәрләр аз. Әсәрләрдә укучыга үрнәк һәм гыйбрәт булырлык күренешләр, детальләр табу, әйтәсе фикернең кыскалык-төгәллеге, образлылыгы, тасвирлау өслүбенең тыгызлыгы, мәгънә тирәнлеге, балалар психологиясенә сизгерлек җитенкерәми. Милли тәрәккыят өчен катлаулы, каршылыклы бу чорда балалар яратып укырлык, аларның заманча таләпләренә җавап бирерлек әсәрләр иҗат итү әдипләребезнең бурычы, намус эше булуын, ә татар әдәбияты һәм татар теле дәреслекләрен хәзерге заман таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә камилләштерү кирәклеген искәртү зарур. Балалар әдәбияты әсәрләренең заман югарылыгында булмавы, булганына да әдәби тәнкыйтьнең игътибарсыз калуы, классиканың да заман күзлегеннән чыгып бәяләнмәве дәреслекләрнең сыйфатына тискәре йогынты ясый.*

*Әдәбият алдында үз телен һәм тарихын, халкыбызның гореф-гадәтләрен камил белгән, милли культурасын җуймаган балалар тәрбияләү бурычы тора.*

*Баланың күңеленә табигатьтән әдәби сүзгә, җыр-моңга, шигъриятькә омтылыш, сизгерлек һәм эчке тоемлау салынган. Аны күрә белү, үстерү зарур. Моңа ирешүнең иң үтемле чарасы—халык авыз иҗаты, бай фольклорыбызның*

*матур үрнәкләре белән сугарылган, югары сәнгать дәрәҗәсендәге әсәрләр иҗат итү.*

***Төп докладларны, чыгышларны тыңлап фикер алышканнан соң фәнни-гамәли конференция түбәндәгеләрне тәкъдим итә:***

***—татар балалар әдәбиятын һәм матбугатын үстерү буенча Дәүләт концепциясе эшләү һәм бу юнәлештә Дәүләт программасы төзүне республика җитәкчелегенә тәкъдим итү;***

***—гуманизмның якты идеяләрен, тормыш оптимизмын тирән чагылдырган, балаларны актив тормышка әзерләүдә, аларда милли хис, әхлакый тотрыклылык, зәвык, хезмәткә иҗади караш, җаваплылык тойгысын тәрбияләүдә зур роль уйный торган, югары сәнгать дәрәҗәсендәге әсәрләр иҗат итү;***

***—балалар әдәбиятына битараф мөнәсәбәткә чик кую, бу юнәлештә әдәби тәнкыйтьне үстерү, әсәрләргә үз вакытында һәм тиешле бәяне бирү;***

***—балалар өчен язылган әсәрләрдә халык авыз иҗаты, фольклор үрнәкләрен киңрәк файдалану;***

***—әдәби әсәрләр язганда дини тәрбия мәсьәләләренә, Коръән сүрәләре, аятьләр, хәдисләргә ешрак мөрәҗәгать итү;***

***—дәреслекләрне классик әдәбиятның һәм бүгенге заман язучылары иҗатының иң матур үрнәкләре белән камилләштерү;***

***—язучыларның мәктәп һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре белән бәйләнешләрен ныгыту;***

***—балалар өчен язылган әсәрләргә массакүләм мәгълүмат чараларында киңрәк урын бирү;***

***—«Татмедиа» республика агентлыгы кысаларында балалар әдәбиятын һәм балалар матбугатын үстерү буенча грантлар системасын булдыру;***

***—Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә балалар өчен әдәби сайтлар ачу һәм аны финанслауны дәүләт тарафыннан тәэмин итү;***

***—Татарстан китап нәшрияты тематик планында «Балалар әдипләре» дигән яңа серия ачу һәм ел саен кимендә ике балалар язучысының күләмле җыентыгын бастырып чыгару;***

***—меценатларның балалар әдәбиятын үстерүне кайгыртуын дәүләт дәрәҗәсендә оештыруны тәкъдим итү;***

***—мәктәп яшендәге талантлы иҗатчылар өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең күренекле балалар әдибе Шәүкәт Галиев исемендәге махсус премиясен булдыру;***

***—балалар язучыларының активлыгын үстерү максатында аларның иҗатларын стимуллаштыру, республика күләмендә әдәби конкурслар үткәрү, матди ягын дәүләт тарафыннан финанслау.***

# М

**МӘҺДИЕВ** Мөхәммәт Сөнгать улы (1.12.1930, Арча р-ны Гөберчәк ав.— 112.6.1995, Казан, туган авылында җирләнгән, язучы, әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1964), ТРның халык язучысы (1993). Руханилар нәселеннән. 1930 еллар башында гаиләсе репрессияләргә дучар була һәм өйләреннән куып чыгарыла. Әтисе НКВД лагерьларында һәлак ителә. М. Казан педагогия ин-тын тәмамлый (1959). 1954-59 елларда Арча районы урта мәктәпләрендә татар әдәбияты һәм тарих фәннәре укыта. 1960 тан Казан ун-тында, 1963-91 дә татар әдәбияты кафедрасы доценты. М.нең фәнни эзләнүләренең төп юнәлеше—1920 нче еллар башында иҗтимагый-мәдәни мохит. 1960 еллар башында ук М. вакытлы матбугатта татар халкының иҗади мирасына, 1920 еллар татар әдәбиятының күренекле вәкилләре (Г.Сәгъди, Гали Рәхим, Г.Гали, Г.Нигъмәти, Ф.Сәйфи-Казанлы) турында җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уяткан тәнкыйди мәкаләләр бастыра, 1967-70 тә «Галия» һәм «Буби» мәдрәсәләре турында, татар мәгърифәтчеләре: бертуган Бубилар, Р.Фәхретдин, З.Камали, Г.Баруди, Ф.Кәрими турында язып чыга. 1960 нчы елларда М. татар укучысына С.Рахманколый исемен «ача» һәм аның хикәяләрен туплап «Мәлиха куаклыгы» (1979) җыентыгын нәшер итә. М. тагын Ф.Агиев, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Ә.Хәсәни һ.б.ның тормыш һәм иҗатлары турында китаплар һәм мәкаләләр, «Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе» (1982, автордаш), «Әдәбият һәм чынбарлык» (1987), «Реализмга таба: 20 йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре» (1989), «Социальные корни таланта: из истории татарской литературы в годы нового революционного подъема и первой империалистической войны» (1990) исемле монографияләр авторы да. М. үзен «Без—кырык беренче ел балалары» («Казан утлары ж-лы, 1968) дигән беренче повесте белән үк үзенчәлекле иҗади стиле булган язучы итеп танытты. Аңа нечкә лиризм, юмор, тел бизәкләү чаралары хас. Әсәрләренең төзелеше: сюжет корылышы һәм лейтмотивларның роле үзгә. «Кеше китә—җыры кала» (1979) повестеның геройлары—авыл кешеләре, вакыйга Бөек Ватан сугышы чорында бара. Тылдагы фидакарь хезмәт һәм яу кыры батырлыклары, кайгы һәм шатлык, хыянәт һәм чыдамлык кебек кыйммәтләрне күрсәтеп, автор әсәр геройларының берсе авызыннан әйттергән төп идеяне алга куя: «Туган ил өчен мондый авыр вакытларда йомшаклык күрсәтү ярамый, кеше булып, ир булып калырга кирәк. Шул чакта нәсел-нәсәбең, туган җирең, туган авылың да исән-сау булыр». Аның «Фронтовиклар» 1973; русча тәрҗемәдә «Большая земля под крылом», М., 1974) романы, «Каз канатлары» (1975) повесте, «Ут чәчәге» (1980) һәм «Мәңгелек яз» (1982) романнары татар әдәбияты тарихында вакыйга буларак кабул ителде. Әдәби тәнкыйть М.не «туган як җырчысы» дип атады, авыл һәм аның кешеләре турында ул шундый җылы һәм аларны яратып яза, аларның йомшак якларын һәм кимчелекләрен дә читләтеп үтми, кайчак аларны көлке утына да ала. Еллар үтү белән язучының иҗади манерасы да бераз үзгәрә төшә. Юмордан тыш аның әсәрләрендә ачы сатирик штрихлар да күренгәли башлый, лиризм белән беррәттән сентиментальлек һәм сагыш, үткәннәрне сагыну хисе көчәя төшә. М. иҗатында «үз» күңел дөньясы гәүдәләнеше булып үткәннәр тора, бу язучы һәм аның геройлары өчен генә түгел, ә халык өчен дә көч, терәк булып тора. «Торналар төшкән җирдә» (1983) һәм «Бәхилләшү» (1990) повестьларында үткәннәр мотивына инвариант булып мәңгелек кыйммәтләр тора, аларга кешеләрнең бу дөньядан мәңгегә китү, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, көнкүреш детальләренең юкка чыга бару мотивлары туры килә. 1980 еллардагы актуаль сәяси һәм иҗтимагый-көнкүреш проблемаларны чагылдырган «Борчулы өч көн» исемле бердәнбер пьесасы 1983 тә Татар драма һәм комедия сәхнәсендә куела. Чит илләргә сәяхәте тәэсирендә дөнья күргән «Җир йөзендә алты кыйтга» (1992) әсәре юлъязма жанрында язылган; чит ил тормышын үзенеке белән капма-каршы куеп әдип үз халкының рухи кыйммәтләрен чагыштырып күрсәтә. Гомеренең соңгы елларында М. «Ачы тәҗрибә» (1993) исемле мемуарлар язу

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

белән мәшгуль булды, ләкин беренче китабын гына бастырып өлгерде. Анын әсәрләре күп тапкырлар кабат басылып чыктылар, берничәсе рус теленә тәрҗемә ителде. 1990 елда М.кә «Бәхилләшү» һәм «Торналар төшкән жирдә» повестьлары өчен Г.Тукай исем. ТР Дәүләт премиясе бирелде. 2000 дә Гөберчәк авылында язучынын музей-йорты ачылды.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 5 томда. К., 2009.

Әд.: Мөхәммәдиев Р. Гадиләр, гадәтиләр // Якутлар табыладыр вакыт белән. К., 1983; Миннуллин Ф. Яшьлекне сагыну // Балта явызлар кулында. К., 1994; М.Мәһдиев: язучы турында замандашлары. К., 2004.

*Д.Ф.Заһидуллина, Р.Ә.Мостафин.*

**МЕЛОДРАМА** (грек. melos—жыр һәм drama—хәрәкәт), 1) драматургия жанры; үткен интригалы, гадәттән тыш эмоциональ, яхшылык һәм явызлык кискен каршы куелган пьеса. Анда катнашучылар искитәрлек язмышлар, гадәттән тыш көчле хисләр б-н аерылып торалар, чынга охшамаган катлаулы ситуацияләргә тап булалар. Язмышнын күптөрле шаяруларына карамыйча, унай геройлар һәрвакыт жинүгә ирешәләр. М.да музыка кин кулланыла (тора-бара анын роле күзгә күренерлек булып кими). Франциядә 1790 нчы еллар ахырында, Россиядә 1820 нче еллар ахырында барлыкка килә. Татар драматургиясендә М. жанрына беренчеләрдән булып М.Фәйзи мөрәжәгать итә. Анын «Кызганыч» романтик М.сында гашыйк булган геройлар гадәттән тыш хәлләргә юлыгалар. Алар жан-тән б-н бер-берсен яраталар, милләткә хезмәт итү теләге б-н яшиләр. Мәхәббәт хисенен тирәнлеге, трагик коллизияләр, табигатьнен сәерлеге, сагышлы жыр-музыка тамашачыга көчле эмоциональ тәэсир итүгә юнәлтелгән. М.Фәйзинен «Тәкъдирнен шаяруы» (1913), «Асылъяр» (1920), «Адашкан күнел» (1923), К.Тинчуриннын «Зәнгәр шәл» (1926) һ.б. пьесалары М. жанрына карый. 1960-80 елларда М. жанрынын жанлануы Х.Вахит, Ш.Хөсәенов, Т.Миннуллин, И.Юзеев һ.б. ижатларында күзәтелә. 20 йөз азагы—21 йөз башы татар драматургиясендә Р.Сәгъди («Сынган беләзек», 1997), И.Мәхмүдова («Син минем бергенәм», 1997), Т.Миннуллин («Эзләдем, бәгърем, сине», 2001) һ.б. актив эшли. 2) Катнашучыларнын сөйләме (диалог һәм монолог) б-н кушылып бара торган музыкаль-драматик сәхнә әсәре. Европада кин таралыш 18-19 йөз башында ала. Татар драматургиясендә беренче музыкаль пьеса—М.Фәйзинен «Галиябану»ы (1917). Тора-бара андый әсәрләр музыкаль драмага карый башлыйлар (К.Тинчуриннын «Кандыр буе», 1932 һ.б.).

Әд.: Татар совет театры: Очерклар. К., 1975; Әхмәдуллин А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; Нуруллин И. XX башы татар әдәбияты. К., 1982.

*Ә.М.Закиржанов.*

**МЕЛУЗНИКОВ** Анатолий Александрович (2.4.1909, хәзерге Иванов өлкәсенен Кинешма ш.—5.11.1958, Казан), язучы. 1932 дән Казанда яши. 1933 тән «Красная Татария» («Кызыл Татария») г-тасы редакциясендә, 1947 дән башка г-таларда, «Чаян» ж-лында эшли. Балалар өчен язылган «Без шулай яшибез» («Так мы живём», 1952), «Полкан белән Васька» («Полкан и Васька», 1952), «Кошлар, хайваннар һәм жәнлекләр хакында» («Про птиц, животных и зверей», 1959) исемле шигъри жыентыклар, «Өч әкият» («Три сказки», 1957), «Мәсәлләр һәм фельетоннар» («Басни и фельетоны», 1958) исемле китаплар авторы. Рус теленә К.Нәжми, Г.Кутуй, Ә.Исхак, С.Баттал, Б.Рәхмәт, Ж.Тәржеманов, З.Нури, Н.Арсланов һ.б. шигырьләрен тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**МЕЛЬНИКОВ** (Мельников-Печерский) Павел Иванович (псевд., Андрей Печерский) (25.10.1818, Түбән Новгород ш.—1.11.1883, Түбән Новгород губерниясе, Ляхово а.), язучы. 1837 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1839 дан Түбән Новгородта яши, раскол тарихын өйрәнә. 1841 дә Мәгариф министрлыгы (С.-Петербург) каршындагы Археографик комиссиясенен мөхбир әгъзасы исемен ала. 1845-50 елларда «Нижегородские губернские ведомости» г-тасында эшли. 1847 дән Түбән Новгород генерал-губернатор каршындагы махсус вазифалар йөкләнгән чиновник, 1850 дән Эчке эшләр министрлыгында эшли. Раскольникларнын скитларын кансызлык б-н жимерүчесе булып таныла. 1866 да отставкага чыга, «Северная пчела» ж-лында эшли, «Московские ведомости» г-тасында, «Русский вестник» ж-лында языша. Тарихи хезмәтләр, тарихи-этнографик очерклар, хикәяләр авторы. Төп хезмәте—«Урманнарда» («В лесах») һәм «Тауларда» («На горах») (1871-74, 1875-81 елларда «Русский вестник» ж-лында басыла) дилогиясендә 19 йөз уртасы Идел арты һәм Тау ягы тормышы, кәсепләр, старообряд сәүдәгәрләр көнкүреше, жирле халыкнын гореф-гадәтләре, раскольниклар скитлары һәм яшерен секталар турында яза.

Әс.: Собр. соч.: В 8 т. М., 1976.

**МЕМУАРЛАР** (франц. memoires—истәлекләр), авторга замандаш булган

үткән вакыйгалар һәм билгеле шәхесләр турындагы истәлекләргә нигезләнеп язылган документаль әдәбиятның бер төре. М.ны түбәндәге үзенчәлекләр аерып тора: фактларга таяну (фактографичность) (авторның үзе күргән-белгән реаль шәхесләр һәм вакыйгалар турында язуы), материалның ретроспективлыгы (еш очракта үткән вакыйгалар турында языла, авторның тормышы һәм иҗатына нәтиҗә ясала). Татар әдәбиятында М. ның барлыкка килүе 20 йөз башына карый. Беренче М. итеп Р.Фәхретдиннең «Асар»ен атап була. Сәяхәтнамә жанрында язылган әсәрләрдә М. элементларын күзәтеп була, мәс., Р.Фәхретдиннең «Исмәгыйль сәяхәте», З.Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт», Ф.Кәриминең «Истанбул мәктүбләре». 1930 нчы елларда Г.Камал «Минем персональный пенсионер булуым тарихы» һәм «Яза башлавым тарихы» әсәрләрен яза. Татар мемуаристикасының чәчәк аткан чоры сугыштан соңгы елларга туры килә: М.Әмирнең «Без бәләкәй чакларда», «Хатирәләр урманы», Ф.Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», Р.Ишморатның «Сайрасын тургайлар», «Гомер сукмаклары», А.Расихның «Яшьлек эзләрем», Х.Мөҗәйнең «Сугыш язмалары» һ.б. Фактларның төгәллеге һәм дөреслеге буенча М. документлар һәм фәнни язмалардан калыша, ләкин субъективлык элементлары һәм фактларның тулы булмавы авторның көчле индивидуаль «мин»е, сүз остасының тасвирланган вакыйгаларга карата мөнәсәбәте б-н компенсацияләнә. Моңа мисал булып Ә.Еникиның «Соңгы китабы» тора. Аерым очракларда М.ны автобиографик романнан яки повестьтан аеруы авыр була. Ләкин М.ның чикләре никадәр тоныкбулса да, аны жанр буларак авторның нияте буенча билгеләп була. Мәс., М.Мәһдиевнең «Без—кырык беренче ел балалары» китабын М.га никадәр якын булса да, аны автобиографик повесть дип санарга кирәк, чөнки автор өчен иң мөһиме—үз тормышын хикәяләү түгел, гәрчә үз буынының күмәк портретын иҗат итү. Автобиографик повестьлар рәтенә ш.у. Г.Бәшировның «Туган ягым—яшел бишек» әсәрен кертергә була. М. матур әдәбият, публицистика һәм фәнни әдәбият киселешендә тора. Татар әдәбияты һәм мәдәнияте эшлеклеләре (Г.Тукай, М.Җәлил, Һ.Такташ, С.Сәйдәшев һ.б.) турындагы күп төрле истәлекләр барыннан да элек аларда китерелгән фактларның яңалыгы һәм әһәмияте б-н аерылып торалар, шуңа күрә андый китаплар фәнни-публицистик әдәбиятка карый. М. жанрында күп кенә бүгенге көн авторлары да яза (Ш.Галиев, Б.Камалов, Ә.Галиев, Ш.Маннапов, Р.Батулла һ.б.).

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1958.

*Р.Ә.Мостафин.*

**«МЕҢ ДӘ БЕР КӨН»**, мажаралы хикәятләр җыентыгы; урта гасыр фарсы әдәбияты истәлеге. Төзелеше б-н «Мең дә бер кичә»не хәтерләтә: «кысалы» композиция, төрле дәрәҗәдәге хикәяләрне каймалап алган, кермә хикәяләр. Ике җыентыкта да берүк геройлар катнаша, берүк яки охшаш геройлар кулланылган, тәңгәл сәнгати чаралар файдаланылган. Ләкин, аңа карамастан, «Мең дә бер көн» мөстәкыйль идея-эстетик әһәмияткә ия. Мәсәлән, «Кылаф берлә Диләрә», «Кылаф берлә Турандук», «Малик» хикәяләре татарчага Казанда XX йөзнең 1 нче чирегендә Ш.Рәхмәтуллин тарафыннан тәрҗемә ителәләр.

Әд.: Миннегулов Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Ғәп Фән

Фирдәвес Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Карабай

Карабай авылы Апас районында, район үзәге Апастан 12 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Иске Йомралыдан—1, Каратун тимер юл станциясеннән—21, Тәтеш пристаненнән 26 чакрым ераклыкта урнашкан.

1908 елда Д.Корсаков бастырып чыгарган жыентыкта Карабай авылы икенче исеме белән Йомралы дип искә алына һәм анда 66 йомышлы, 18 чукындырылган татар яшәве күрсәтелә.

Карабай авылы халкы күршедәге Әнәле, Иске Йомралы, Идрәс, Дүртиле авыллары халкы белән берләшеп июнь башында Шыкма жыенын бәйрәм иткән.

Авыл оешкан вакытта биредә калын урман булган, иген игү өчен урман төпләргә туры килгән. Халык телендә сакланган Беренче төптәге ышна, Икенче төптәге ышна, Өченче төптәге ышна атамалары басу-кырларның урманнан чистартылганын күрсәтеп тора.

Заманында авылның югары өлеше көчләп чукындырылган. Ләкин авыл кешеләре яна куелган рус исемнәрен, яңа диннәрен бик тиз ташлаганнар. Шулай да чукынган кешеләрне татар зиратына күммәгәннәр. Аларның үз зираты булган. Хәзер ул зират басу уртасында калган. Аннан бераз арырак иске татар зираты бар. Хәзер бу зиратлар икесе дә караучысыз калган һәм мәйданнары елдан-ел кими бара.

Авылдан бер чакрым ераклыкта гына Үләмә суы ага. Үләмәгә Табалан суы килеп кушыла. Авыл халкы аны икенче төрле Инеш дип атап йөртә. Ул авылны икегә бүлә.

Авыл янында Шомыртлы күл бар. Бүгенге көндә ул сазлыкка әйләнеп бара, хәзер анда су коенып булмый. Шулай ук күл буенда үсеп утырган шомырт агачлары да юк инде. Күлнең суы бары тик яз көннәрендә генә була. Ә кыр үрдәкләре күл янына, бер иләнгән жирләренә һаман киләләр әле.

Элегрәк авыл уртасында да күл булган. Хәзер ул бөтенләй кибеп беткән, күл истәлеге булып урам исеме—Киби урамы калган. Күл дә Киби дип аталган булган.

Карабай һәм Пүчинкә авыллары арасында Кызыл Яр дигән урын бар. Бу—елга яры. Авыл картлары сөйләве буенча, элек монда нииндидер бик каты сугыш булган, бөтен жир үлекләр белән тулган, кан елга булып аккан. Шуңа бу урын Кызыл яр дип йөртелә, һәр елны әбиләр монда килеп дога укыйлар. Казыган вакытта бу урыннан кеше сөякләре дә чыга икән.

## Карамалы

Карамалы авылы Әлки районында, район үзәге Базарлы Матак авылыннан 25 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Иске Камка авылыннан—7, тимер юл станциясе Нурлаттан—60, Болгар пристаненнан 93 чакрым ераклыкта урнашкан.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Карамалы атамасы тарихи белешмәләрдә шактый искә алына.

XIII йөз мәгълүматларын эченә алган Д.А.Корсаков белешмәсендә авыл Исамбай, шулай ук Кармала дип аталган, аның Кармала суы буена утыруы искәртелә. Авылда 61 йомышлы, 2 керәшен татары яшәгәнлеге билгеләнә.

Олылар сөйләвенә караганда, авыл урнашкан җирдә элек карама агачлары күп үскән. Шуңа авылга Карамалы исеме бирелгән. Авылны нигезләгән бабалар элек Иске йорт дигән урында торганнар. Хәзер анда яшәүче юк. Сабантуйлары шул урында үтә. Ул бик матур җир, төрле агачлар белән әйләндереп алынган. Анда чияләр, алмагачлар һәм шомыртлар үсә. Тирә-ягыннан су камап алган. Анда Төпсез күл һәм Кара күлләр җәелеп ята. Алар икесе бергә тоташып суларын Чирмешән елгасына коялар. Моннан башка авыл янында тагын Коры Әнҗерә, Шүрәле елгалары, Ак балчык сазы, Мүк сазы, Мулла чишмәсе, Якын чирәм, Куб һ.б. исемдәге географик берәмлекләр бар.

Авылда элек-электән мәчет эшләгән, ул хәзерге мәктәп бакчасы эчендә булган. Аның хәзер нигезе генә калган. Мәчетне колхозлашу чорында сүтеп, мәктәп төзегәннәр. Мәктәп йортында элек авылның бае яшәгән, аның өе әле дә саклана, ләкин бай йорты буларак түгел, ул хәзер мәктәп мастерское. Бай йорты янында 2 кое булган, алар хәзер дә бар, ләкин балалар төшеп китмәсен өчен алар каплап куелган һәм аннан су алмыйлар.

Авылда хуҗалыклар саны 100дән артык, аларда 140 ир-ат һәм 138 хатын-кыз яши.

Авылда берданбер чишмә бар. Ул чистартылган, өстенә өй дә салып куйганнар, кырыйларына коймa тотканнар. Чишмәгә төшү юлларына нараттан баскычлар ясалган.

## Кибәхуҗа авыллары

Исемнәрендә Кибәхуҗа берәмлеге булган авыллар Теләче районында урнашкан. Олы Кибәхуҗа авылы район үзәге Теләчедән 9 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Кече Кибәхуҗадан—2, Арча тимер юл станциясеннән—27, Казаннан—103; Кече Кибәхуҗа авылы Теләчедән—7, тимер юл станциясе Арчадан—29, Казаннан—105; Югары Кибәхуҗа—җирле үзидарә советы үзәге, ул—Теләчедән 12, Арчадан 20, якындагы пристань исәпләнгән Балык Бистәсеннән 66 чакрым ераклыкта урнашкан.

Кибәхуҗа авыллары тарихи чыганакларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш телгә алына.

Олы Кибәхуҗа һәм Кече Кибәхуҗа авыллары Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Казан өязенең теркәү кенәгәсендә (1602-03 еллар) Кече Кибәхуҗа авылы искә алына. Һ.В.Йосыпов Кибәхуҗа авылы зиратында XVI йөзгә, ә Югары Кибәхуҗаныкында XIV йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташлары таба. 1766—1861 елгы мәгълүматларны эченә алган Генераль ызанлау документларында Олы Кибәхуҗа һәм Кече Кибәхуҗа (Макса һәм Түлешкә елгалары ярларына утырганнар) авыллары атамалары теркәлеп калган.

1867 ел 4 июль көне белән Кибәхуҗа авылы атамасы тагын бер тарихи чыганакта искә алына. Ислам диненә чыгарга теләгән керәшеннәр патша Александр IIдән үтенеп рөхсәт сорыйлар.

Керәшен Кибәхуҗасы яки Олы Кибәхуҗа Макса ярында, Җөри сәүдә юлы өстендә урнашкан. Авылдагы 122 йортта иске керәшеннәрдән 395 ир-ат һәм 397 хатын-кыз яшәгән һәм 1865 елда алар һәммәсе дә исламга чыкканнар. Кече Кибәхуҗа авылы халкы белән алар бер авыл җәмгыятендә торганнар. Христиан дине тоткан заманаларында алар үзләреннән җиде чакрым ераклыктагы Әче мәхәлләсендә исәпләнгәннәр. Авыл халкы татар хатын-кыз күлмәкләре тегеп тормыш алып барган. Шул максаттан, алар Казан, Оренбург, Уфа губерналары авылларына чыгып киткәннәр.

Кече Кибәхуҗа яки Түбән авыл дип аталганы шул ук елга буенда һәм шул ук сәүдә юлы өстендә булган. Андагы 47 хуҗалыкта ислам динендәге 134 ир-ат һәм 117 хатын-кыз көн күргән. Алар Олы Кибәхуҗа халкы белән бер авыл җәмгыятендә торганнар.

Югары Кибәхуҗадагы 92 хуҗалыкта иске керәшеннәрдән 282 ир-ат һәм 291 хатын-кыз яшәгән. 1895 елда алар барысы да исламга кире кайтканнар. Югары Кибәхуҗа һәм Керәшен Кибәхуҗасы авыллары арасындагы борынгы зиратта ике кабер ташы табылган.

Кибәхуҗа авыллары халкы күршедәге Иске Мичән, Яна Мичән, Олы Шынар, Кече Шынар, Югары Симет, Түбән Симет, Тимершык, Мингәр, Сабай, Чулпыч, Түлешкә, Казаклар һәм Оет авыллары белән берләшеп, Шынар җыены яисә Симет җыены үткәргән.

Тарихи чыганакларда көчләп чукындыру нәтиҗәсендә халыкның бик күп җәфа чигүе күрсәтелә.

Олы Кибәхуҗа авылының утырган урыны матур. Чишмәләре, янында урманы, балыклы елгасы, ундырышлы басу-кырлары бар. Авылның рәсми исеме—Олы Кибәхуҗа, халык телендә аны Яңа авыл дип йөртәләр.

Олылар сөйләвенә караганда, авылга нигез XII йөздә салынган. Авылны нигезләүчеләрнең исеме Көббәхуҗа һәм Кадеркол була. Элек чишмәләр бәреп торган Мазар елгасы башында Көббәхуҗа нигез салган. Кадеркол нигезләгән авыл Галдоргыл елгасы буена урнашкан. Кадеркол авылы озакламый яшәүдән туктый, халкы Көббәхуҗа авылына килеп утыра. Көббәхуҗа авылы бик зурая.

Казан ханлыгы яулап алынгач, Көббәхуҗа авылы халкы да чукындырыла. Чукындырылганнан соң авыл Макса буйлап Мишәгә таба бер чакрым арырак күчеп утыртыла. Авылның исеме дә үзгәрә. Ул Кибәхуҗа дип атала башлый. Халык чукындырылса да, ислам динен тотуын дәвам итә. Авылга Бикуш карт килә, ул яшерен рәвештә исламны ташламаска өндәү алып бара. Бикуш карт фәлсәфә фәннәре докторы, профессор Я.Г.Абдуллинның бабасы була. Рәсми рәвештә исламга чыгарга теләүчеләр 80 тал чыбыгы белән суктыруны кабул итәргә тиеш булалар. Бикуш карт та 80 тал чыбыгы белән суктырыла, исән кала һәм ачыктан-ачык ислам дине тота башлый. Бу җәза ислам диненә күчкән һәрбер кешегә эләгә. Күп кеше моны күтәрә алмый, үлә, теләмәгәннәр Себергә сөрелә. Исламга кире кайту 1864 елдан 1880 елга кадәр дәвам итә. Шушы еллар эчендә авыл тулысы белән исламга күчеп бетә.

1905 елга хәтле авылда мәчет төзелми. 1905 елда авылга Арча бае мәчет һәм мәдрәсә салдыра. Мәчет манарасы 1939—40 елларда киселә.

Элек авылда чишмәләр бик күп булган. Авыл кырыена ук терәлеп наратлык үсеп утырган. Колхозлашу елларында бу наратлык утынлыкка киселгән, чишмәләре беткән. Ул урында бары бер генә чишмә сакланып калган. Ул—Изгеләр чишмәсе. Чишмә тимер рәшәткә һәм агачлар белән әйләндереп алынган. Авыл кешеләре дога кылу өчен мәчеткә һәм Изге чишмәгә йөриләр. Авыл яныннан Макса елгасы һәм Чишмәле елгасы ага.

Авыл янында Алып баба чабата каккан тау бар.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ИМӘННЕҢ ДӘ ИМӘНЕ ИДЕ...

ИБРАҺИМ САЛАХОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ибраһим Салахов—татар әдәбияты тарихында тормыш һәм иҗат юлы катлаулы, драматик хәлләргә бай булуы белән аерылып торган әдипләрнең берсе. Казан педагогия институтында белем алган елларында ук әсәрләре белән танылып килгән һәм 1937 елда гаепсезгә кулга алынган әдип күпчелек әсәрләрен үз биографиясенә таянып иҗат итә. Шул сәбәпле, И.Салахов иҗатын дөрес аңлау һәм бәяләү өчен аның тормыш юлын да яхшы белергә кирәк. Үзен «халык традицияләренең—кайгы, горурлык һәм куркаклык, кешелеклелек һәм вөҗдансызлык картиналарының тере шаһите» дип атаган язучыбызга быел 100 яшь тулган булыр иде. Әмма әдип 1998 елның 7 июлендә вафат булды.

...И.Салахов 1911 елның 30 августында Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә эшче гаиләсендә дөньяга килә. Башта Күкчәтау шәһәрендәге Мортаза мулла мәдрәсәсендә, аннары мәдрәсә ябылгач җидееллык татар мәктәбендә белем ала. И. Салаховның 70 еллыгына багышланган мәкаләсендә аның сабакташы, олугъ шагыйрь Нури Арсланов, көз көне укулар башлангач, татар мәктәбенең шәһәр халкы өчен мәдәният йортына әйләнүе һәм И.Салаховның төрле кичәләрне оештыруда, мәктәп стена газетасын чыгаруда актив катнашуы турында язган иде. Әдипнең беренче әсәрләре дә әлеге стена газетасында дөнья күрә. Иҗат эшенә алынуын И.Салахов үзе «Еллар сәхифәсе» дигән истәлегендә Г.Ибраһимов исеме белән бәйли. Эш шунда: кечкенәдән әдәбият белән кызыксынып китеп, «Ак юл», «Сөембикә», «Ан» журналлары белән бергә, Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми», «Казакъ кызы», «Безнең көннәр», «Кызыл чәчәкләр», «Алмачуар» кебек әсәрләрен дә ул кызыксынып укый. Шулар тәэсирендә аңарда да язу теләге туа.

Күкчәтау җидееллык мәктәбеннән соң, 1928—1931 елларда И.Салахов Казан педагогия техникумында белем ала, шул елларда шигырь, әдәби парчалары белән матбугатта еш катнаша. Техникумнан соң «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй»), «Кызыл яшьләр» газеталары редакцияләрендә эшли. Ул шулай ук—«Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналын нигезләүчеләрнең берсе.

Армиядән соң, 1935—1937 елларда, язучы Казан дәүләт педагогия институтында укый. Истәлекләрдән күренгәнчә, И.Салахов иң алдынгы студентлардан саналган. Үз вакытында педагогия институтының тел-әдәбият факультеты деканы, профессор, күренекле тәнкыйтьче, бик күп татар зыялылары кебек үк шәхес культы корбаны булган Галимҗан Нигъмәти, мәсәлән, «яхшы укыйлар, иҗат эше белән шөгыльләнәләр» дип, Хатип Госман белән И.Салаховка институтның тулай торагыннан санаулы гына ике кешелек бүлмәнең берсен бирә.

Институтның III курсында укыганда, Октябрь революциясенең 20 еллыгына институт колоннасын бәйрәм демонстрациясенә алып чыгу И.Салаховка тапшырыла. Әмма бәйрәм алдыннан гына ул, гаепләнеп, кулга алына, һәм аның ун елдан артык гомере «халык дошманы» булып төрмәдә, лагерьларда үтә. «Минем исемсез улыма хат» шигырендә И.Салахов үзе әлеге еллары турында түбәндәгечә язды:

*Минем тормыш кояш төсле якты,*
*Май аедай матур башланды.*
*Ләкин...*
*Кара болыт басты аның күген*
*Аякларга богау ташланды.*

Газаплы сөргеннән исән калып туган ягына кайткач та, аңа туган шәһәре

Күкчәтауда торырга рөхсәт ителми. Ул комендатура урнашкан Кызыл Яр авылына жибәрелә, анда һәр көнне хакимият әһелләренә барып, качып китмәгәнлеген расларга тиеш була. Шундый шартларда да әдип язуын ташламый, кечкенә хикәяләр, истәлекләр, очерклар яза. 1956 елда исә СССР Югары судының хәрби коллегиясе, И.Салахов эшен янадан карап, 1937 елгы хөкем карарын юкка чыгара.

И.Салахов үзенең «Йөрәктәге яралар» мәкаләсендә «Казан—минем рухи бишегем, йортым. Мин анда язучы буларак тудым һәм «үлдем»,—дип язган иде. Чыннан да, Казан педагогия институтында укыганда кулына ныклап каләм алган Ибраһим, баштарак шигырьләр яза, аннары иҗат көчен пьеса, повесть жанрларында сынап карый. Утызынчы еллар әдәби процессында актив катнашу язучының тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе артуга, каләменең дә шомара баруына булыша. Нәтиҗәдә авторның бер-бер артлы «Ярату» (1936) пьесасы, «Дуэль» (1937), «Мәхәббәт һәм өмет» (1937) повестьлары, «Постта» (1937) шигырьләр җыентыгы бер-бер артлы дөнья күрә.

И.Салахов иҗатының беренче чорын тәшкил иткән утызынчы еллар аның иҗади эзләнүләренә, әлбәттә, тирән эз сала. Ягъни ул тудырган әдәби дөнья, геройларның тирәлеге, тормыш материалы да илдә хакимлек иткән идеологиягә яраклаштырып күрсәтелә, геройлары да шул заман идеалларына хезмәт итәргә омтыла.

1937—1956 еллар аралыгында ун елга ирегеннән һәм биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгән И.Салахов иҗат эшеннән аерылып тора. Ул бары 1956 елдан, ягъни акланганнан соң гына кабат ныклап иҗат эшенә керешә һәм тиз арада күп кенә лирик шигырьләр иҗат итә. Тиздән аның «Дала дулкыннары» (1957), «Күкчәтау җырлары» (1961) дигән шигырь җыентыклары, «Төн кызы» (1971) исемле хикәяләр, очерклар, легендалар җыентыгы, «Мәхәббәт картаямы?» (1980) повесте, «Күкчәтау далаларында» (1965), «Имәннәр тамыр җәйгәндә»(1985) романнары, Фәхретдин бине Мифтахетдин, Г.Ибраһимов, С.Атнагулов, Г.Гали, Г.Нигъмәти һ.б. күренекле шәхесләр турында истәлекләре, әдәбият тарихына караган материаллары, балалар өчен хикәяләре дөнья күрә. Аның «Күкчәтау татарлары» исемле публицистик хезмәте исә Казакъстан татарларының формалашу тарихын ачыклауда, гомумән, чит җирләрдә яшәүче татарлар тормышын өйрәнүдә әһәмиятле чыганак һәм башлангыч булып тора.

Утызынчы еллар башында ук кулына каләм алган булса да, И.Салахов иҗаты озак вакытлар әдәби-фәнни җәмәгатьчелекнең игътибарыннан читтәрәк кала бирде. Бары тик «Казан утлары» журналында «Тайгак кичү» роман-хроникасы дөнья күргәч кенә әдипнең иҗаты белән ныклап кызыксыну башланды. Роман мона кадәр татар әдәбиятында объектив чагыла алмаган чорга—Сталинның шәхес культы елларына, тоталитар системаның асылын ачуга—багышланган иде.

Мәкалә-истәлекләрдән күренгәнчә, «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре») язылып беткәч тә әле байтак еллар тимер сандыкта, алмагач төбендә күмелеп ята. Бу вакытларны автор соңрак: «бәлки тоелгандыр: төбенә кульязмамны күмгәч, алмагач ачы алмалар бирә башлады кебек. Язларын бакча шау чәчәккә төренгәндә, алмагачым миңа хәсрәттән чәче агарган кеше булып күренде»,—дип искә алды.

«Колыма хикәяләре» романы җәмәгатьчелек тарафыннан әдипнең шәхес культы чорына караган беренче әсәре дип кабул ителде. Әмма болай дип карау һәм бәяләү хакыйкатькә хилафлык булыр иде, чөнки әдипнең «Күкчәтау далаларында» һәм «Колыма хикәяләре» әсәрләре тема ягыннан байтак дәрәҗәдә аваздаш. Соңгы романында яктыртылган мәсьәләләрне ул инде 1965 елда басылып чыккан «Күкчәтау далаларында» ук башлый һәм һәр ике очракта да үзенең шәхси биографиясенә таяна.

Роман жанрындагы беренче тәҗрибәсе булган «Күкчәтау далаларында» әсәрендә, әсирлектәге елларында сак эш итәргә, алдын-артын карап фикер йөртергә өйрәнгән әдип, хикәяләүне ике планда алып бара: беренче планда рәсми идеология рухына туры килгән чирәм җирләрне үзләштерүне яктырта һәм бу әсәр эчтәлегенең күзгә бәрелеп торган өске катламын тәшкил итә. Шул ук вакытта, шушы рәсми идеология битлеге астында автор, үзенең шәхес культы елларында кургән-кичергәннәренә нигезләнеп, совет системасының гаделсез якларына да игътибар юнәлтә һәм бу хакта хикәяләү әсәр эчтәлегенең икенче катламын хасил итә. Әлбәттә, язучының үзенә менә шушы икенчесе якынрак һәм мөһимрәк. Романның вакыт сынавын үтә ала торган кыйммәте дә шушы катлам белән бәйләнгән. Бу яктан «Күкчәтау далаларында» алтмышынчы еллардан татар прозасында чагылыш таба башлаган яңа бер тенденциягә килеп кушыла.

Сүз тоталитар системаны безнең әдәбиятта да теге яки бу формада яктырта башлау турында бара. Боларга мисал итеп Э.Касыймовның «Гомер ике килми», Г. Ахуновның «Идел кызы», М.Хәсәновның «Язгы ажаган» романнарын китерергә мөмкин.

И. Салаховның үзе әйтергә теләгән төп фикерне, сталинизм чорының җинаятьчел сәясәтен киң җәмәгатьчелеккә җиткерү өчен Кукчәтау далаларында бара торган үзгәрешләргә мөрәҗәгать итүе очраклы хәл түгел. Чөнки дөньяга карашлары шактый тирәнәйгән һәм җитлеккән И.Салахов алтмышынчы еллардан иҗат эшенә тагын да җитдирәк төстә алына. Дөньяга карашларның җитлегүе аңарда, тормышны тагын да киңрәк колачлап, масштаблырак итеп сурәтләү, тормышка тарихи яссылыкта карау омтылышын көчәйтә. Ә бу яктан, күп вакытлар чирәм җирләрне үзләштерү тарихи әһәмиятле акт итеп каралды. Һәм аның шундый әһәмиятен дә калкурак күрсәтергә омтылып, әдип мәсьәләгә тарихи яссылыкта якын килә, ягъни бүгенгене үткән белән бәйләп һәм чагыштырып күрсәтергә омтыла.

«Колыма хикәяләре»ндә исә шәхес культы чорының бөтен мәкерлелеге, социализм идеяләреннең гарипләнүе, Сталин һәм аның тарафдарлары тудырган системаның совет кешесен кол дәрәҗәсенә төшерүләре авторның аянычлы язмышы аша ачылган. Төп герой Ибраһим Салахов белән бергә, вакыт, динамика, вакыйгалар—автор фикереннең үзәгендә тора. Һәм алар шул чорның панорамасын тудыралар.

Геройның үсеш юлы гади түгел. Һәм бу ышандыра да. Чөнки әсәрдә шул чор сулышы нык сизелеп тора. Үзе дә сизмәстән чорның юкка чыгару сферасында калган, Сталин режимы корбаны булган И.Салахов озак вакытлар Сталинга тугры булып кала. Кулга алынгач та әле студент егет, язылачак әсәренә сюжет уйлап, балаларча болай дип фикер йөртә: «Көтмәгәндә Ходай үзе төрмә капкаларын ачты бит әле. Тик миңа төрмәгә кертмичә кайтарып җибәрмәсәләр генә ярар иде (бар план җимерелә бит), роман бетмичә ярты юлда калачак».

Әмма илдә урын, дәрәҗә өчен, кешеләр язмышын хәл итүчеләр рәтендә булу өчен гади күзгә күренми торган көрәш барган бу чорда, ирекка чыгу җиңел булмый. Җәзалар чиктән ашканда кеше характеры, холыклар арасында булган аерымлыклар югала, диләр. Шуңа күрә В.Гроссманның бер герое, төрмәдә намуслы кешенең намуссыз кешедән аермасы—беренчесенең начар эшләрне теләмичәрәк кенә эшләвеннән аерыла, дигәнрәк фикер әйтә. Мөгаен ул үзенчә хаклыдыр. Чөнки тоткыннарның язмышлары бер-берсеннән аерылмый, аларның язмышлары уртак.

Әгәр «Колыма хикәяләре» әсәрендәге образлар системасын төп ике лагерьга: Сталин һәм аның тарафдарлары белән тоткыннар лагерена бүлеп карасак, моның шулай булуы ачык күренә. Чөнки автор тоткыннарны сындырыр өчен эшләнгән басымның төрле формаларын оста итеп сурәтләп бирә алган.

Әсәрдә геройлар гаеп тануның берничә вариантын үтә. Кыйнаулар, ач тоту, кешелек горурлыгын таптау, көне буе бастырып тоту һ.б. алымнардан соң ярым аңын җуйган тоткын тикшерүче язган кәгазьләргә кул куя. Һәм нәрсәгәдер өметләнеп судны көтә. Башкалар белән бергә И.Салахов та югары юридик орган безнең гаепсез булуыбызны аңлар дип ышана. Әлбәттә, арада кайберәүләр хөкемнең инде чыгарылган, судның әзер карарга кул гына куячагына төшенәләр.

—Гаепләү кәгазен алдыгызмы?

—Мин халык дошманы түгел, бервакытта да...

—Молчать!

...Чыннан да суд дигәннәре ... шушымы? Мин бит судта сорашырлар? Аз булса да сүзләремә колак салырлар? Хакыйкатьне ачарга тырышырлар дип өметләнгән идем ләбаса».

Әмма нәкъ менә шушы формада, «халык дошманнары»на суд һәм Ф.Алмакаевның ялган күрсәтмәләр бирүе нәтиҗәсендә, И.Салахов 58 статья нигезендә гаепләнә: 10 ел аерым режимдагы төрмәгә ябылу һәм төрмә срогын тутырганнан соң биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм калдыруга хөкем ителә.

«Колыма хикәяләре»ндә әсәрнең буеннан-буена сузылган, җыелма, күзгә күренмәс, шартлы ике образ бар: көч куллану һәм курку. Курку—әсәр персонажларының хәрәкәтләре белән идарә итә. Курку, куркытып тору әсәрнең сюжет, композиция факторы буларак, тоткыннарның эчке дөньялары, хәтта әһәмиятсез вакыйгаларның да юнәлешен билгели.

Көчләү—тоталитар системаның төп нигезе. Мәҗбүрият җәмгыятьтә аерым бер курку атмосферасы гына тудырып калмый, бәлки аларны үзенең коралына, берберсенә әләк (донос) язу коралына әйләндерә. Бу фикеребезне дәлилләү йөзеннән, мисалга Бикчәнтәев образын китерү дә җитә.

Эчке, рухи дөньясы, тышкы кыяфәте белән дә ерткычларга охшаган бу шәхеснең бөтен вәхшилеген И.Салахов әле әсәрендә ачып бетермәгән, бик кечкенә генә өлешен биргән икән. Чөнки шушы ук әдип белән бергә бу елларның авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән Е.С. Гинзбург «Текә маршрут» («Крутой маршрут») әсәрендә әлеге образны түбәндәгечә бирә: «Бушка узган берничә сеанстан соң, Бикчәнтәев бик эшлекле кыяфәт белән, үзем гаебемне танымау сәбәпле, иртәгәдән минем гаебемне ачуны шаһитләр ярдәмендә башлап җибәрәчәген белдерде. «Күркә бәбкәсе»нең бу хәбәре көлке иде... Бу вакытта ул сарыкныкы кебек мыйкылдап, аңгыралык чәчеп торган тупас танавы белән ялтырап, өч телефон аппараты торган өстәл артында бик эшлекле кыяфәт белән утыра иде».

Е.С.Гинзбург белән күзгә-күз китереп сорау алудан югалып калган Дьяковның «белмим», «ишеткән идем» кебек сүзләрен Бикчәнтәев түбәндәгечә редакцияли: «Әйе, мин редакция каршысында яшерен контрреволюцион группа эшләп килгәнен раслыйм!». Китерелгән өзектән күренгәнчә, Е.С.Гинзбург һәм И.Салаховның бу адәмгә биргән бәяләре туры килә.

Әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан Сталин репрессияләре турында язылган китаплар арасында уңышлы дип бәяләнгән «Тайгак кичү» («Колыма хикәяләре») фаҗига-хроникасы И.Салахов иҗатының иң югары ноктасы булды һәм 1990 елда ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек дип табылды.

И.Салаховның игътибарга лаеклы күләмле әсәрләреннән тагын берсе—«Имәннәр тамыр җәйгәндә» (1986) романы. Әлеге әсәр XIX гасырның сиксәненче елларыннан алып, XX гасырның егерменче елларына кадәрге чорны колачлый. Тарихи мәгълүматларга таянып, автор шул вакытларда Казакъстанда яшәгән татар казакъларының революцион көрәшкә катнашып китүләрен, гражданнар сугышы елларында күрсәткән батырлыкларын ачуны максат итеп куя. Әлеге идеяне яктыртуга тарихи яссылыкта килеп, башта татар казакъларының үткәндәге тормышын, хезмәт кешесенең физик һәм рухи яктан изелүен, көрәш тойгысының үсә баруын тормышчан күренешләрдә һәм җанлы, иң әһәмиятлесе, тарихи шәхес образларында чагылдыра.

Гомумән алганда, И.Салаховның дәвамлы һәм нәтиҗәле иҗат юлы татар әдәбиятының, бигрәк тә аның прозасының үзенчәлекле сәхифәсен тәшкил итә. Ул, совет дәверендә зур кыенлыкларга һәм гаделсезлекләргә очравына карамастан, әдәбиятта үз йөзен саклап калды, илдәге катлаулы хәлләр турында гадел сүзне әйтә алды.

И.Салаховны язмыш төрле яклап сынады: аңа газабын да, шатлыкларын да мул итеп бирде. 1998 елның 8 апрелендә Казакъстанның яңа башкаласы Астанада (Акмолада) аның тормышында тагын зур вакыйга булды. Вафатына берничә генә ай кала ул, Казакъстан президенты Нурсолтан Абиш улы Назарбаев сүзләре белән әйтсәк, «Казакъстан халкы өчен зур хезмәт, татар, казакъ һәм рус әдәбиятлары арасында ныклы күпер салудагы эшчәнлеге өчен» «Парасат» сүзе («Алтын дуслык») ордены белән бүләкләнде. «Парасат» казакъчадан «тирән фикер», «яңалык», «ачыш» мәгънәсендә тәрҗемә ителә. И.Салахов бу бүләккә чын мәгънәсендә лаек иде.

Әдипнең үлеме уңаеннан матбугатта басылган некролог түбәндәге юллар белән тәмамланган иде: "Явыз үлем, күп һөҗүмнәр итсә дә, җиңә алмаган батырны, ниһаять, арабыздан йолып алды. Себернең рәхимсез усал җилләре, Колыманың тимер режимнары тез чүктерә алмаган татар әдәбиятының имәндәй нык каһарман әдибе Ибраһим Салахов хәтердә мәңге сакланыр».

—Яхшылык эшлә дә, суга сал, халык белмәсә, балык белер,—ди халык әйтеме. Ибраһим Салахов дигән олы затның якты истәлегенә багышланган бу мәкаләне дә нәкъ менә әлеге сүзләр белән тәгаллисе килә.

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**
*КДПУ доценты.*

# «АЛГА—ГАСЫР ТИРӘНЛЕКЛӘРЕНӘ!»

ФАЯЗ ХУҖИНГА 60 ЯШЬ

*Фаяз Хуҗин республикабызда гына түгел, Рәсәйдә, чит илләрдә дә яхшы билгеле шәхес. Аны олы галим, археолог, тарихчы буларак беләләр. Юбилее уңаеннан аның белән әңгәмә корырга хәзерләнеп йөргәндә башыма бер фикер килде: Фаяз Хуҗин турында болай да аз язылмады инде, татар телевидениесе дә чит итми—гел күрсәтеп торалар үзен, китаплары, фәнни мәкаләләре һәм ачышлары аша күпләргә мәгълүм, ни өчен әле галимне башка яктан, мәсәлән, гади кеше (бәлки, артык гади дә түгелдер) буларак күрсәтмәскә? Гомумән, кем ул, нинди кеше ул Зәй районының Карман авылында туып-үскән Фаяз Хуҗин? Тарих төпкелләрендә казынучы археолог бүгенге көн һәм киләчәк турында ничек фикер йөртә?*

—Тарих белән кызыксынуым 5нче сыйныфта укыганда ук башланды, моңа укытучым Мөнәздәһә апа Кәримова «гаепле». 1812 елгы Ватан сугышында җиңүебезнең 150 еллык юбилеена ул 7нче сыйныф укучылары белән тарих кичәсе үткәрде. Ни өчендер, төп чыгышны миңа, 5нче сыйныф баласына тапшырды. Ул биргән материалларны укып чыктым, ятладым. Чыгышым аңа ошады, матур сөйләден, диде. Аннан соң тарих түгәрәгенә язылырга киңәш итте һәм миңа авылыбыз тарихын язарга кушты. Бу эшне дә, Әхмәтхуҗа бабамнан, авыл картларыннан сораштыра-сораштыра, яхшы гына башкарып чыктым кебек. Мөнәздәһә апа, күрәсез, беренче укытучым була.

Югары сыйныфларда укыганда тарих дәресләрен Фәхразый абый Ситдыйков алып барды. Ул үз фәненә бирелгән чын тарихчы иде. Киләчәктә тарих укытучысы буласы килүемне иң беренче итеп аңа әйткәч, бик сөенде, миңа өстәмә укырга дип берничә китабын биреп торды. Институтка укырга кергәч, хәтерлим, сөендерим әле дип башта сыйныф җитәкчем Фәгыйлә апа янына, аннан соң Фәхразый абыйга чаптым.

Әмма минем тарихчы булып китүемдә Ирек Таһир улы Уразаев хәлиткеч рольне уйнамады микән? Ул параллель сыйныфта укыта иде, сирәк булса да кайбер дәресләрен тыңларга туры килде. Гаҗәеп киң эрудицияле, бигрәк тә хәзерге заман тарихын тирән белүче, кыяфәте белән Маяковскийга охшаган чибәр, акыллы бер укытучы иде. Укучыларның кумиры инде менә. Ирек абыйның бөтендөнья колониаль системасы һәм аның таркалуына багышланган дәресен һаман да оныта алмыйм әле. Гомерем буе аңа охшарга тырышып яшәдем. Мине якын итте, институтта укыганда да, Казанга килсә, хәлләремне белешеп китә иде. Хәзер дә без аның белән дуслар.

**—Институтта уку чорыннан ук атаклы профессор Альфред Халиков остазыгыз, киңәшчегез булган...**

—Без аның белән гел бергә булдык. Бер кабинетта эшләп утыра идек, җәен айлар буе экспедициядә йөрдек. Баласы кебек якын күрде мине. Һәрхәлдә, мин шулай сизә идем. Гадилеге белән алдырта иде ул. Беренче чиратта, әлбәттә, бөтен барлыгын, гомерен яраткан фәненә багышлаган олы галим иде. Вакчыл булмады, кешедән көнләшмәде, хезмәттәшләре арасында абруе гаять зур иде. Бик күп һәм нәтиҗәле эшләде. Арабыздан бик иртә китте шул, 65 яше генә тулган иде әле. Альфред Хәсән улының хезмәтләре хәзер дә безнең өчен юл күрсәткеч булып тора. Аның күп санлы шәкертләре рәтендә йөрү минем өчен бик зур дәрәҗә. Исеменә тап төшермәскә тырышам. Без, археологлар, аның истәлеген кадерләп саклыйбыз.

**—1972 елда Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлаганнан соң Сез бит әле бераз туган якларыгызда—Кадер мәктәбендә укытып алгансыз. Ул чорлар хәтерегездә сакланамы?**



—Ничек инде сакланмасын, яшь чаклар—юләр чаклар, тормыш мәшәкатьләренең ни икәнен белмәгән иң күнелле вакытлар бит ул. Укытучылар коллективы дисеңме, укучыларымы—һәрберсен сагынам, оныта алмыйм. Кайберләре белән озак еллар хатлар алышып тордык. Мөмкинлек булганда кайтып та килгәлим, телефоннан да аралашып торабыз. Безнең мәктәптә Шәйхулла Шәяхмәт улы Шәяхмәтов, Мөнәздәһә Газиз кызы Гомәрова, Зөлфирә Шәйхетдин кызы Борһанова, Михаил Иванович Никитин кебек талантлы педагоглар эшләде. Концертлар, спектакльләр куеп йөрдек. «Шоңкар»да (Ә. Атнабаев әсәре) мин төп рольне башкарган идем хәтта. Ул якларга тагын бер кайтып килергә йөрим әле.

**—1974 елдан башлап, Сез—Казанда. Әле аспирантура да үтмичә, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшли башлагансыз. Хыялыгыз тормышка ашты, димәк?**

—Шулай булды шул. Күрәсең, Биләрдәге казу эшләре вакытында Альфред абый мине сынаган булгандыр, бу егеттән археолог чыгачак дип уйлагандыр. Әйе, хыялым тормышка ашты кебек. Әмма мәктәптән, балалар шау-шуыннан аерылу бик авыр булды миңа. Урамда иртән мәктәпкә ашыгучы кызыл галстуклы пионерларны күрсәм, күземнән яшьләр чыга иде. Күнектем тагын. Экспедициядә дә шул ук яшьләр—күбесенчә студентлар эшли. Янәшәмдә—фән дөньясында инде танылып өлгергән археологлар. Кабинетлар борынгы табылдыклар белән тулган—бөтенләй икенче дөньяга эләктем! Аллага шөкер, бүген дә шул дөньяда кайнашам һәм ул яктан үземне бик бәхетле саныйм.

**—Үзегезгә бәя биреп карагыз әле: хезмәтләрегез татар халкының урта гасырлар чорына караган тарихына нинди яңалыклар өстәде?**

—Бу сорауга җавап бирү җиңел түгел. Менә уйлап карагыз: егерме ел мин, Альфред Хәсән улы җитәкләгән экспедициянең җитәкче урынбасары буларак, Биләрдә эшләдем, аннан соң ун ел «Казан кремле» археологик экспедициясенә җитәкчелек иттем. Калган вакытымда Суварда, Җукәтауда, борынгы Чаллыда казу эшләре үткәрдем. Алабугадагы тикшеренүләр дә миннән башка гына булмады. Нәтиҗәсе фәнни мәкаләләр, китап-монографияләр, төрле конференцияләрдә, конгрессларда ясалган чыгышлар белән генә тәгалләнмәде: Биләр шәһәрлеге дәүләт карамагындагы музей-тыюлык итеп расланды, Казанның һәм Алабуганың 1000 еллык юбилейлары билгеләп үтелде, һәм иң әһәмиятлесе—халкыбыз тарихының

әлеге кыйммәтле ядкәрләре бүгенге көндә халыкара туристлык үзәгенә әйләнеп баралар. Икенчерәк төрле әйтсәк, археология табыш китерә башлады. Фән ачышларсыз була алмый. Биләрдә мин, мәсәлән, борынгы кирмән диварларын тикшердем, болгар археологиясендә әлегә бердәнбер булган, унынчы гасырда корылган юрта эзләрен таптым, Казан кремлендә Кол Шәриф мәчете һәм Казан ханнары күмелгән төрбә (мавзолей) хәрабәләрен казыдым һ.б. Болары һәркемгә аңлашыла торгандыр дип уйлыйм.

Минем фәнни концепцияләргә килгәндә исә, алары менә болай: Биләр—Болгар, ягъни X—XI гасырлардагы беренче башкала проблемалары, урта гасыр шәһәрләренең барлыкка килү вакытын ачыклау методологиясе, элгәреге болгарларның утрак тормышка күчү процессы, татар халкының (һәм чуашларның) этногенезында Идел Болгарстаны һәм Алтын Урданың урыны һ.б.лар—хәзерге көнгә кадәр бик тә бәхәсле мәсьәләләр булып тора. Бу проблемаларның һәрберсенә минем үз карашым бар, әмма каршы якның фикерләре белән дә исәпләшмичә ярамый. Яңа табылган материаллар кайчак иске карашларны үзгәртеп тә куялар. Кыю фикерләр һәрвакыт тәнкыйтьләнә инде ул. Моннан куркырга ярамый. Кайсы галимнең концепциясе дөресрәк—бусын киләчәк күрсәтер. Тыйнаксызлык дип бәяләмәгез, минем үземә шулай тоела—хезмәтләремнең бер өлеше булса да киләчәктә барыбер үз урынын табачак.

**—Мәгълүм булганча, узган ел Болгарда һәм Зөя шәһәр-утравында «Яңарыш» программасы буенча реставрация һәм төзелеш эшләре башланып китте. Бу эшләрдә археологлар да катнаша, әлбәттә. Болгардагысы әле аңлашыла, Зөя утравында сакланып калган һәм Иван Грозный, православие дине белән бәйле борынгы архитектура корылмаларын торгызуга исә ризасызлык белдерүчеләр дә бар. Бу мәсьәләләргә сез ничек карыйсыз?**

—Бик уңай карыйм. Мине бигрәк тә Зөя шәһәр-утравында башланып киткән эшләр куандыра. Мәсьәләгә төрле яклап, колачлырак карарга кирәк. Биредә бит уникаль архитектура истәлекләре тупланган. Аларны күрәләтә жимерү—урысныкымы ул, татарныкымы—бу очракта әһәмиятле түгел,—җинаять. Төзүчеләр белән бергә биредә археологлар да эшли. Кызыклы гына ачышларыбыз бар. Мәсәлән, моңа кадәр Свияжскины урыслар төзи башлаган дип уйлыйлар иде. Безнең археологлар исә Казан ханлыгы чорына караган катламнар таптылар, бу тирәләрдә хәтта инде монголларга кадәр үк болгарлар яшәгән авыл урыннары булган. Бу ачышлар бит татар тарихына яңа төсмерләр өсти. Иң мөһиме—менә шул ачышларны дөрес, гадел тикшереп, анализлап, яңалыкларны халыкка җиткерү.

Хәл итәсе мәсьәләләр дә бар. Безне иң борчыганы—реставрация-төзү эшләрен тизрәк төгәлләү сылтавы белән Зөя шәһәр-утравының да, Болгарның да кыйммәтле борынгы культура катламнарын җимертү. Төзүчеләр артыннан (дөресрәге, алдыннан) без өлгерә алмыйбыз, ашык-пошык эшләргә мәҗбүрбез. Теге яки бу корылманы кайда урнаштыру мәсьәләсен тикшергәндә дә, башка проектларны караганда да археологлар белән артык киңәшләшеп тормыйлар. Экспертлар комиссиясенә, мәсәлән, Болгар археологик экспедициясенең җитәкчесен кертергә дә кирәк тапмаганнар. Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгының гыйльми советы утырышы да үткәрелмәде. Түрәләрнең «сами с усами» позициясе безне бик нык гаҗәпләндерә.

**—Фаяз абый, әнә шундый берьяклы, бары тик матди якны гына күз уңында тотучыларга тарихи үткәнебезнең мөһимлеген төшендерү җәһәтеннән ныграк эшләргә кирәк түгел микән? Соңгы елларда сезнең шундый рухтагы язмаларыгызны еш кына газета-журнал битләреннән укыйбыз, чыгышларыгызны телевизор экраннарыннан, радиодан күрәбез, тыңлыйбыз...**

—Бу эшкә мин чыннан да бик җитди карыйм. Төптәнрәк уйласаң, популяр мәкаләләр язу галим кешенең эше түгел. Нишлисең, язучы юк. Фән яңалыкларын халыкка җиткереп барырга бик кирәк! Телевидениедән чыгыш ясардай галимнәребез дә бар—тел белмиләр. Максатымны бик изге дип саныйм—һәр татар үзенең тарихын,

ерак бабаларының тормышын белергә һәм алар белән горурланырга тиеш. Кешедә үз тарихы белән горурлану хисе булмаса, халкының киләчәгенә өмет юк.

**—Мәктәп укучылары өчен дәреслекләр, студентлар өчен уку әсбаплары, методик кулланмалар язуны да шул ук фәнне популярлаштыру өлкәсенә кертеп карарга ярыйдыр?**

—Бик авыр һәм кирәкле эш бу. Укытучылар күрә—профессиям дәреслекләрнең эчтәлегендә дә чагыла. Рәсемнәрдә археологик табылдыкларны, борынгы архитектура корылмаларын, төрле реконструкцияләрне күбрәк бирәм. Текстның теле балалар өчен җиңел аңлаешлы булсын дип тырышам. Әлегә кадәр тәнкыйть сүзләре ишеткәнем булмады. Шунысы гына бик борчый: мәктәптә татар тарихын укытырга сәгатьләр юк хәзер. Бердәм дәүләт имтиханнарында Россия тарихы гына булгач, Татарстан тарихын укытып та тормыйлар. Бу бигрәк тә рус мәктәпләрендә шулай. Киләчәктә мондый хәл бетәр дип өметләнәм.

**—Фаяз абый, һич көтмәгәндә үзегезнең туган дип әйтерлек институтыгыздан китеп, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында эшли башлавыгыз гаҗәпләндерде...**

—Педагогика университеты да туган йортым кебек якын. Мин бит заманында шунда укыдым, дөрес, ул вакытта институт статусында иде әле ул. Монда элегрәк тә студентларга лекцияләр укый идем. Аннан соң, мин бит ни әйтсәң дә педагог, һәрвакыт укучылар, мәктәп укытучылары арасында кайнашам. Педуниверситетның тарих факультетында эшләүче укытучыларның да күбесен белә идем. Проблемалар килеп чыга, әлбәттә. Эш күбәйде, кафедра мөдире итеп сайлангач, бигрәк тә. Фәннән аерылмадым, Аллага шөкер. Тарих институтында да эшләвемне дәвам итәм.

**—Педагогика университетын, югары белем бирү системасын камилләштерү максатыннан чыгыптыр инде, Казан федераль университетына куштылар. Дәүләтнең бу адымын хуплыйсызмы?**

—Юк. Төрле яктан уйлап карадым—һич тә хуплый алмыйм. 135 еллык тарихы булган атаклы педагогика университетын юкка чыгару—ахмаклык. Мин моны үзебезнең милли белем бирү системасын таркатуда чираттагы адым дип саныйм. Мине бигрәк тә Казан дәүләт университетында кайчандыр академик Миркасыйм Госманов башлангычы белән ачылган һәм уңышлы гына эшләп килгән татар тарихы һәм филологиясе факультетының таркалуы борчый. Факультет деканы Искәндәр Гыйләҗевның протестын аңлыйм һәм хуплыйм.

**—Сезгә алмашка кемнәр килә, Фаяз абый? Остазларының эшен дәвам итәрдәйләре бармы араларында?**

—Шәкертләрем күп, Аллага шөкер. Дистәләгән, йөзләгән студентлар да минем шәкертләрем бит. Ә инде яшь галимнәр тәрбияләүгә килсәк, эш болайрак тора. Археологияне без «элитный» фән дибез. Безнең профессия кешеләре күп түгел. Тарих институтында минем унлап шәкертем бар. Шуларның бишесе—тарих фәннәре кандидатлары, икесе диссертацияләрен тәгәлләп киләләр, калганнары яшь әле, аспирантурага узган ел гына керделәр. Минем өчен шунысы куанычлы, шәкертләрем хәзер үзләре инде әйдәп баручы археологлар. Айрат Ситдыйков—хәзер хәтта минем җитәкчем дә, Тарих институтының Археологик тикшеренүләр үзәге җитәкчесе, Казан Федераль университетының археология һәм этнология кафедрасы мөдире; Альберт Нигамаев—доцент, Алабуга дәүләт педагогика университетының филология факультеты деканы. Икесе дә докторлык диссертациясе язалар. Наил Нәбиуллин—минем Җүкәтаудагы тикшеренүләремне дәвам итүче археолог. Нурулла Гариф—язучы, аны барыгыз да беләсез инде, Казан ханлыгы тарихы буенча уңышлы гына эшләп килә. Әле узган ел гына диссертациясен яклаган Ренат Вәлиев—иң яраткан шәкертем (араларында иң яше, чөнки), бик булдыклы, перспективалы егет. Зөфәр Шакировтан күпне өмет итәм, искиткеч тырыш, бөтен эшкә шуны кушалар,

әллә никадәр экспедицияләрдә эшләп алды инде. Күрәсез, барысы да татар егетләре, өйләнеп, матур гына гаилә корып җибәрделәр. Бер-берсе белән бик дуслар, туганнар кебек яшиләр. Кыскасы, бу өлкәдә горурланырлыгым бар.

**—Фаяз абый, шәкертләрегезнең тормыш коруларына да шулкадәр сөенәсез. Чын галимнәр нинди рәк тормыш алып бара икән—профессор, тарих фәннәре докторы Хуҗин гаиләсе белән дә таныштырыгыз инде?**

—Хатыным Гөлнур—Чистай кызы, озак еллар укытучы булып эшләде, башлангыч сыйныфларда укытты. Бик яраттылар үзен, коллективта да, укучылар һәм ата-аналар арасында да абруе зур булды. Хәзер пенсиядә инде. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укып йөри. Кызым Айшә Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университетын тәмамлады. Архитектор-дизайнер белгечлеге алып чыкты. Хәзер шул профессиясе буенча эшли. Кияүдә түгел әле. Матур гына яшәп ятабыз. Гаиләмнән уңдым, күз генә тимәсен. Археолог кеше өчен бу бик мөһим, ни өчен дигәндә, мин бит җәйләрне гел өйдән читтә, экспедицияләрдә үткәрәм, бакчада яшелчә үстереп ята алмыйм. Мине аңлыйлар. Үзем ярыйсы ук көйсез кеше: эшләп утырганда сүз катмасыннар, өстәлемдәге кәгазьләрне урыныннан күчереп куймасыннар, өй эшләре белән артык мәшәкатьләмәсеннәр... Галим кешенең акчасы да инде аның, кешегә әйтергә оялырсың, билләһи. Соңгы елларда гына бераз юньгә керә башладык. Авыр чаклар да күп булды—түздек. Менә шундый хатыным, аннан да әйбәтрәк кызым булмаса, белмим, бу кадәр дәрәҗәләргә ирешә алган булыр идем микән. Уңышларымның яртысы—аларныкы, һич арттырып әйтмим.

**—Фаяз абый, сез, әлбәттә, күбрәк борынгы тарихыбыз белән мәшгуль. Археологны бүгенге сәясәт кызыксындырамы? Татар халкының киләчәген ничегрәк күзаллыйсыз?**

—Сәясәткә һич тә кагылмас идем, ләкин ул үзе миңа кагыла, дип язган иде Әмирхан Еники бер мәкаләсендә. Әйе, сәясәттән качып булмый. Телевизорын да караштырам (күбрәк «Россия» программасын), газеталар да укыйм («Новая газета», «Аргументы и факты» ишеләрен, татар газеталары «тешсез», түрәләрне мактаудан уза алмыйлар), кайчак мәгълүматларны интернеттан да алам. Бүгенге вәзгыять мине бик тә хафаландыра, тынычлыгымны җуйдыра. 1991 елгы революциядән соң олигархлар хакимияте барлыкка килде, дәүләт халыктан бөтенләй йөз чөерде, киләчәккә өметебез кимегәннән-кими бара. Җәмгыятебездә әхлаксызлык хөкем сөрә: бөтен җирдә алдау, талау, урлашу, икейөзлелек. Өстәвенә эшсезлек, хәерчелек. Моны барыбыз да белеп-күреп торабыз. Аңлашыла ки, мондый илнең киләчәге юк. Фән, мәгърифәт, мәдәният кебек өлкәләрне өстенлекле рәвештә үстермәсәк, бетәчәкбез. Ә мона ышаныч аз.

Беренче президентыбыз әйбәт иде, гел мактап тордык үзен—ул моңа, чыннан да, лаек иде. Бер кавым «суверен» дәүләттә дә яшәп алдык хәтта. Әмма без, Мәскәү белән артык көрәшеп тормыйча гына, күп авырлыклар белән яулап алынган суверенитетыбыздан үз теләгебез белән диярлек баш тарттык, колхозларыбызны таратып, җирләрен инвесторларга өләштек, авылларыбызны һәлакәт алдына китереп бастырдык. Без «сайлаган» депутатлар Конституциябезне җиңел генә үзгәртеп бетерделәр. Тукай торган тарихи кунакханәне җимереп ташлаганда да, Матбугат йортыннан журналистларны, язучыларны куып чыгарганда да, Иске Татар бистәсен хәрабәләргә әйләндереп ташлаганда да... телсез булдык. Бу галәмәтләр өчен президентыбызны вакытында тәнкыйтьли алмадык, курыктык. Халык бит хәзер күп нәрсәгә битараф, аның үз кайгысы кайгы.

Милләтебез өчен көрәштә яңа президенттан да артыгын өмет итеп булмастыр, ахрысы. Бездә халыкка кирәге булмаган зур спортка артык игътибар юнәлтелә. Дөрес, икътисад үсә диләр, әмма аннан безгә ни файда—халык моны сизми, тормыш хәлләре әлегә һаман начарлана гына бара.

Мине бигрәк тә мәгариф өлкәсендәге хәлләр борчый. Бүгенге реформалар дөньяда иң камил дип табылган белем бирү системасының нигезенә балта чаба. БДИ һәм компьютерлар белән артык мавыгу мәктәп балаларының аңын томалый,

сәламәтлеген какшата, мөстәкыйль фикерләү сәләтен кимәтә. Хөкүмәт үзенә коллар әзерли. Болар—бик куркыныч нәрсәләр. Югары уку йортларына әзерлексез абитуриентлар килә, надан «белгечләр» тәрбияләп чыгарабыз, аларның бик азы гына үз профессиясе буенча эшкә урнаша.

Халкыбызның киләчәгеме? Милли мәсьәләләрдә бүгенге сәясәт дәвам итсә, татарлар руслар арасында бик тиз эреп юкка чыгачаклар. Хәлебез бик мөшкел. Татар моны бетмәсә, әле Сабантуйлар үткәреп торганда, сәләтле яшьләребез булганда... халкыбыз югалмас дип үз-үзебезне тынычландырып торудан туктарга кирәк. Ачыгыз күзегезне, карагыз хакыйкатьнен йөзенә—телебез югала, татар мәктәпләре бетүгә йөз тота. Мәгариф министры, БДИны уңышлы тапшыру өчен фәннәрне мәктәптә, югары сыйныфларда русча укытырга кирәк, ди. Фаҗига түгелмени бу?! Ничек көрәшергә? Нәтиҗәсе булырмы? Шикләнәм. Шулай да татар зыялыларына, бәйсез мәгълүмат чараларына өмет итәм әле бераз.. Бәлки, яшьләр арасыннан яна милли лидерыбыз да килеп чыгар? Безгә Фәндәс Сафиуллин кебек депутатлар кирәк...

**—Өметсезлеккә бирелмик әле, Фаяз абый! Әңгәмәбез ахырында, әйдәгез, сезнең киләчәк ниятләрегез турында сөйләшеп алыйк.**

—Беләсез инде, 2005 елга кадәр мин иң зур экспедицияләрдә эшләдем, археологик казу эшләренә җитәкчелек иттем. Казан кремленнән соң, табигый ки, янадан Биләргә әйләнеп кайтырга теләдем. Тик казу эшләренә, совет чорындагы кебек, бюджеттан акча каралмаган, студентлар яши торган база җимерелеп юкка чыккан... Биләр бит ул тегенди-мондый гына объект түгел, Болгар иленең башкаласы! Әле никадәр юньләп тикшерелмәгән һәм бәхәсле мәсьәләләре бар аның! Болгардан кала икенче халыкара туристлык үзәге булырга тиеш анда! Шуны аңлап бетермиләр. Кыскасы, Биләрдә эшләр туктатылды. Бу каланы яңадан күтәрәсе иде. Шуны эшли алсам, калганына үкенмәс идем, шәт. М.Ш. Шәймиев җитәкләгән «Яңарыш» фондына өметем зур. Ишетүемчә, үзе дә Биләрне торгызырга тели икән.

Ниятләрем мулдан, әлбәттә. Яна китаплар, фәнни мәкаләләр язу, төрле конференцияләрдә докладлар бедән катнашу, аспирантлар белән җитәкчелек итү... Казан кремле материалларын фәнни әйләнешкә кертеп бетерәсе бар. Карачай-Черкесиягә, Кырымга борынгы болгар истәлекләрен өйрәнергә чакыралар. Алтай якларына барып кайтырга, тарихыбызның тагын да борынгырак катламнарын ачарга хыялланам. Алга—гасыр тирәнлекләренә! Бераз сәеррәк яңгырый торган бу сүзләрне үземнең тормыш девизым дип саныйм.

**—Әңгәмәбезне менә шул оптимистик нотада тәмамлыйк та инде, Фаяз абый. Эчкерсез җавапларыгыз өчен рәхмәт сезгә. Эштән тәм табып яшәргә язсын, алдыгызда тагын да кызыклырак ачышлар көтеп торсын! «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре һәм укучылары исеменнән олы юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм!**

*Әңгәмәдәш*—**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН**

*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

# БӘЛӘКӘЙ ГАТАШ

## Яшьтәш малайлар белән

Безнең авыл астрономик затлы, югары, матур Марс исемен йөрткән кебек (күрше Сәет авылы малайлары безне нигәдер Максимнар ди иде. Колхоз исеменнәндер—нәни Марс авылы М.Горький колхозына керә), малай-кызларының исеме дә бик заманча янгырый иде: Илмир, Вилмир, Илфир, Фрикс, Ревинер, Вадим, Рифель һ. б.; ә кызлар—гел Рима да Клара, Тамара, Фина, Рикана (алар авылда берничә! Реганадан алынмады микән?), Лия, Вилия, Лилия... тагын бер гаҗәеп исем: Лифә... 1928 елда гына урман аланына күрше Гомәрдән күчеп утырган яна авыл ул Марс, шуна кеше исемнәре дә янача кушылырга тиеш булгандыр дип уйлап йөрдем мин. Үземә килгәндә, Ходай саклап, Закирә апа (Хәтми абыемның хатыны): «Рәдиф дигән исем бик матур, шуны кушыгыз», дигән. Мин март азагында туганмын, ә үз уллары сентябрьдә туып, аңа Вилмир исеме эләгә. Рәдифнең чып-чын шигърияткә бәйле икәнен белгәч (рифмадан соң кабатланып килүче сүз яки сүзтезмә), Закирә апага рәхмәтләр укыдым, билләһи! Ә миннән өч яшькә өлкән булган игезәк абыйларыма гади генә Рәшит һәм Рәфит исемнәре эләккән (хәер, Рәфит дигән исем дә безнең якта—Башкортстанда гына бугай...).

Шул. Әлегә үсәбез, әтиләре сугышта үлгән сугыш чоры балалары, ятимнәр без. Әнкәй әйткәнчә, «кызыл әрмис балалары...» Авыр чор, ачлык, авырулардан балалар күпләп кырылган чор бу. Абыйлар капка шакып хәер сорашкан саилчеләргә (теләнчене бездә шулай диләр!): «Бездә эпи юк, умачи гына бар»,—диләр икән. Мин үземне белгәндә ул «умачи» да күп түгел иде. Хәтердә шуңа күңелгә ашау уе белән бәйле, ризык көткән көннәргә баглы истәлекләр килә (Салтыков-Щедринның утрауга илтеп ташланган ике генералы да шулай бит! Иске газета табып, ни укысалар да—ашау, банкетлар турында килеп чыга... Берсе ачлыктан, дустының орденын алып, йотып җибәрә... Шаярма, ачлык бу).

Шул, үз-үземне белгәндә бу мәсьәлә кабыргасы белән алга баскан, тирә-юнь, табигать тә тик ашарга яраклы әйберләре белән күңелгә кергән иде. Җиләккә барулар, кузгалак, кымызлык, какы җыю, балтырган ашы. Әмма кычытканны (бездә «кечерткән» диләр!) ашамыйм, «чага, чага», дип елыйм икән (юләр!). Ә менә дусларым—туганым Вилмир, күрше Илмар, тагын Илфир дуслар, яшьтәшләр—әтиле... димәк, әпиле. Бигрәк тә Илмар юмарт иде. Еш керә, кесәсенә нәрсәдер салган була. Ипи инде!

Рәшит белән Рәфит рәсем ясарга оста. Кәгазь кисәгенә бик матур этюдлар ясап биреп, Илмарга «рәхмәтләрен белдерәләр». Мин исә кеше башы, ниндидер абстракт, хыялый адәм сурәтләре ясарга яратам. Сүз унаеннан, шул «иҗат»ка беренче укытучым «бишле» куя иде. Хәзер оялып, кызарам... Яшьтән хәтерем әйбәт иде, ахры: җыр дәресләрендә дә гел башлап җырлыйм, ул чордан барлык популяр җырларның («Бөдрә тал», «Щорс турында җыр» һ.б.) сүзләрен әйтеп бирәм. Укытучым янә «бишле» куя, көем-моным булмаса да... Менә ул сүз кадере! Рәхмәт укытучыма!

Ә хәзергә без уйныйбыз, Илмар ниндидер бер тимер табып, алып кергән дә, шуны

ихатада жирдән йөртә, уйната... Вакыт-вакыт серле итеп әйтеп куя: «Здичь!»—ди. «Здесь» дигәне булган, мөгаен... Без дә кабатлыйбыз... Аннан тагын ипи телеме чыга. Каян күрде, ничек белде икән ул шулай үзе уйлап чыгарган миноискатель белән яшереп куелган әйберләрне табып булганын? Илмар яшьтәшне мин (романтик җан!) үсә төшкәч, Александр Матросовның Уфа яшүсмерләр колониясендә укыганын белгәч, авылдан качып, шундый колониягә китәргә, «кеше булырга» өндәгән идем. Башта ризалашкан кебек булса да, кемдер колониянең ни икәнен сөйләп аңлаткан, ахры!—соңыннан кире уйлады. Кызык, нәрсәнедер теләмәсә, ул аска карап аягын җиргә ышкый, суккалап тора иде. Ә кышын чаңгысын карга батырып, тидереп, икеләнүен шулай баса иде.

Унбиш яшьләрдә Илмар Үзбәкстандагы туганнарына—Сорхандәрья өлкәсенә китте. Бер биш елдан артык яшәп кайтты. Мине сагынып язган хатында «эшли башлап, беренче получкадан сина узбекский финка, Алла бирсә!» дип язган иде. Бәхеткә күрә ул «бүләк» вәгъдә булып кына калды, безнең якларга кайтмады...

Шул: Илмар дусның әтисе гел атлы эштә, йә бригадир, йә «лесник», йә ферма мөдире. Атны тугаргач, илтү, тышаулау—Илмар өстендә. Ул мине дә үз артына атландыра, йөгәнсез атны тышау белән куалый... Кечкенә таудан төшеп, инеш аша сикереп чыкканда егылып калулар истә. Ә тауга менү—бу юлы үзем генә!—җилне тоеп, ат ялына ябышып, каядыр башка дөньяга ашу кебек хәтердә калган. Рәхмәт Илмарга! Тагын бер истәлек: без чыбыркы очына дип тышауланган атларның койрыгыннан кыл йолкып ала идек. Әле дә ярый тибә торган тайларга ябышмадык, кылын йолыкканны да сабыр гына кабул иткән карт бияләргә бу рәхмәтебез булсын! Әлеге дә баягы: «Эздичь!»

Быел кышын район мәктәбеннән Марска, «шагыйрь эзләрен» күрергә укучылар килгән алар, авылда сорашырга туктаткан беренче кеше Илмар булган. Хатирәләрне ул ничек яктырткандыр, әмма Марстан кунаклар бик канәгать булып киткән...

## Беренче сәяхәтләр

Үскәндә минем кушаматым «җен» иде. Нигә шулай булгандыр, аңламыйм. Әмма холык кызу иде, дуслар белән еш талашып, сугышып, гел бозылышып тора идем. Шуңа күрә, ахры, күрше Сәет авылыннан безнең Марска килгән малайлар белән дә таныштым (алар медпунктка киләләр. Трахомага каршы профилактик чаралар ясала, «күзне кыралар»—малайларны елаталар иде). Шуннан килгән Шамил, Вадик, Вилмир, Вил исемле малайлар истә. Шамил дигәне кесәсенә урманнан торна кузагы тутырып килә, безне сыйлый иде. Туганым Вилмир белән без дә Вадикны авылларына барып күрдек. Килгәндә җиләк җыеп киләбез (күчтәнәч!), аннан бергә уйныйбыз, сугышып китәбез. Сәетләр усал, елгыр, булдыклы малайлар. Дүртенче класска без укырга Сәеткә барачакбыз—анда җидееллык мәктәп, Карл Либкнехт исемендә. Сугыш чорында мәктәп ябылып торган, хәзер бәләкәйләрдән алып армиягә китәсе «күсәк»ләргә кадәр шул мәктәптә укып йөри, зур авырлык белән булса да тәрбия алалар иде. Без, Марслар да шул мәктәпкә сабакка йөрдек. Мәктәптән кайтуга, янә чабабыз: Сәеттә клубта йә кино, йә уен була (олылар йә укытучылар спектакль куя!), үзебез дә концерт оештырабыз. Сәет юлында бу кичәләргә без әлеге туганым Вилмир белән йөрдек.

Вилмир матур җырлый, соңыннан гармун уйнарга да өйрәнде. Мин шигырь (декламация) сөйлим, спектакльләрдә катнашабыз. Бергә җырлыйбыз да. Ә бию—юк, бездән биюче чыкмады. Яшьтән үк мәктәпнең оста гармунчысы булган Флүр классташым:

—Бәй, бии дә белмәгәч, нишләп Сәеткә кадәр килеп, уенга катнашып йөрисез әле?—ди. Йә, нәрсә әйтеп була инде моңа? Ә Сәет тарта. Көненә өч мәртәбә килгән чаклар булды, һич арлаусыз менә!

...Бездән ерак түгел Гомәр, Ташкүпер, аннан Илек авылына да махсус күрер, малайлары белән танышыр өчен бардык. Әле кызлар дигәнне уйга да алган юк! Ислан дигән авылга да поход ясадык, аны туганнары шунда яши торган Илфир дустыбыз оештырды. Балык тоттык, яңа дуслар таптык, авылга да инде киләчәктә үзебез укыячак урта мәктәбе булган Талбазы аша кайттык. Ин матур сәяхәтләр иде бу!

## Марс мәктәбендә. Баз капкачы...

Беренче укытучым—яңа гына сугыштан кайткан лейтенант, аксап (безнеңчә, титаклап) йөргән, «үкчәсез летчик» дип без яратып кына кушамат биргән ягымлы гына абый иде. Без, бәләкәчләр, аның күзенә карап, артны кысып кына утырганда, кемдер сыната... Абыебыз, сугыш терминнарын онытмаган әле:

—Газ җибәрдегез,—дип куя.

Миңа мөнәсәбәте әйбәт иде. Велосипед алып, шуна атланып йөри башлагач, безне яңа утыртылган нарат үсентеләрен чистартып, йомшартырга алып барганда, багажнигына утыртканы булды (мин каударланып сикереп менгәндә «спис»кә яланаякны сыдырттым, әле дә истә!). Эштә дә шаярабыз. Артык ачуланмый, әмма күзгә карап: «Обезьян мәллә син?»—ди. Кайтканда җырлап кайтабыз. Дәрестә дә, тәнәфестә дә җыр.



*Кызыл мәйданда мавзолей*
*Утыра ямансулап.*
*Ленин ята мавзолейда*
*Йокыга талган кебек.*

Соңгы сүз «сымак» булырга тиеш дип әйтеп карыйм (рифма, ритмны аңлый башлауның башы булганмы бу?), килешергә теләмиләр. Шуңа үч итептер:

*Ленин бабай маңгай чәчен*
*Ак ефәк белән үргән.*
*Ун яшендә закон төзеп,*
*Илле яшендә үлгән.*

дип җырлап җибәрдем. Әмма «нәни хулиганлык» ясадым: «маңгай чәчен ак б.клар белән үргән» дип җырладым (ямьсез сүз өчен гафу итә күрегез!). Бу заман—Павлик Морозов культы чоры иде. Әләкләшү бик табигый булган заман. 10-15 укучы йөгереп кереп, шунда ук укытучы абыйга җиткерделәр. Мине кертеп кара такта янына бастырдылар. Абыйның агарганчы кызганын күрдек; мине җилтерәтеп тиргәде, орышты да идән асты капкачын күтәрә башлады. «Беттем, базга сала икән» дим. Ә баз тулы күселәр (бездәгечә—«комак»лар)! Күрше авылда бер тәртипсез малайны базга салып, онытканнар, ә иртән карасалар, сөякләре генә ята ди... Шуны уйлап, кычкырып елап җибәрдем. Абый бераз күтәреп торды да, бу юлы базга салмады. Ә бездә бер кызык хәл булган иде инде. Шундыйрак диюем. Бер «тәртип бозган» малайны шулай, базны ачып, инде төшерергә җыенганда гына медкомиссия белән ак халатлы апалар килеп кермәсенме! Укол салыргадыр инде... Ачык базга карап:—Нәрсә булды?—дип, бик гаҗәпләнделәр. Абый да югалып калмады:

—Каләм (безнең якта карандашны шулай атыйлар) төшкән иде...—диде ул. Без дә берни дә дәшмәдек. Теге «тәртипсез» малай да. Ә ул елларда каләм, кәгазь бик дефицит, малайларның үзара:

—Оныттыңмы, узган ел яшел каләм очы биргән идем сиңа. Кайчан кайтарырсың?—кебек сүзләре була иде. Әйе, «яшел каләм очы»... Матур сүз бит?! Шулай, «каләм төшкән иде» шул. Абыйның урыны җәннәттә булсын!

## Безнең «Тарзанлык». «Дамалар»...

Укыган беренче китабым «Ал чәчәк» әкияте булды. Аксаков повестеннан. Шуннан китте: китаплы гомер, бәхетле балачак, хыял, аннары—шигырь юлы. Башы—«Ал чәчәк»тән. «Урман җанвары, Диңгез пәрие» образы миңа, «Жен»гә бик якын бит инде. Азак шаһзадә була ул. Гомер буе яраттым мин бу әкиятне. Соныннан аның татар халык әкиятләреннән алынганын да чамаладым. Ә җиде класс тәмамлап, өйдә узган «иҗади» бер елымда бу әкияттән пьеса әвәләдем. Үз авылыбызда куйдык. Режиссеры—үз туганым Вилия апа. Рольләрдә дә авылдаш

кызлар. Авторны әйткәндә халык бик сәерсенде. Сөенде димәс идем. Соныннан концерт куйдык. Вилмир белән бергә «Кодача» җырын башкарганда, ике тавышка башлап, тукталдык. «Бродяга» киносы бик модада иде, мин дә Рәшит Бейбутовтан откан «Авара я» дигән җырны (ничек оялмаганмын?!) «башкардым». Пьеса драма «ерак китте»: Талбазыга, сигезенче класска баргач та, игътибар булды. Ә Сәеттән (үзем мәктәбен тәмамлаган кадерле авыл!) укучылар пьесаны (дәфтәремне!) сорап алдылар. Рольләрне бүлеп, өйрәнә дә башлаганнар, тик мәктәптән кемдер «цензор» булып, рөхсәт итмәгән. Шулай итеп, драматурглык тәҗрибәсе дә тәмам булды—башкача пьеса язмадым инде, ә «Ал чәчәк» һаман күнелдә якты бер сагыш, мон, беренче мәхәббәт кебек яши бирә.

***



Шуннан—«Тарзан» киносы килеп керде безнен авылга. Әллә дүрт серия булды инде? Колхоз гаражында күрсәтәләр. Ә без, малайлар, жир астыннан юл казып, билетсыз кердек. Әмма арабыздан берәү сатты:

—Абый, абый! Әнә теге почмактан, юл салып, астан керәләр!—дип әләкләде ул киномеханикка. Ахырдан ул юлны күмделәр. Шуннан соң без гараж ишеге астыннан (кино башлангач!) шуышып керә башладык. Ничек сыйганбыз диген?! Ә «Тарзан» киносын карарга бөтен авыллар чаба иде. Тәэсире шундый зур булды: болай да агачлы, урманлы авыл Тарзан тавышы белән яңгырый башлады. Күрше апалар әнкәйгә зарланып, «Рәдифегез бигрәк ачы кычкыра, куркып китәм», диләр икән. Ә агач ботаклары, каен «лианалары»на күчеп йөрү, агачтан агачка сикерүләр? Агач башыннан гына «юешләү»ләр дә булгалады, бусы Тарзаннан да арттырып җибәрү иде булса кирәк.

...Бу хәлләргә 60 еллар чамасы узгач, мин бу иске фильм дискларын кулга төшереп, берүзем утырып карадым... Әүвәлгечә, яратып, табигать белән берегеп, хыялларыма кайтып яратып карадым. Әмма атаклы «Тарзанча кычкыру» онытылган иде. Хәер, әйләнә-тирәдәгеләр дә аңламаслар иде инде...

***

Ул чакта без «Яшь гвардия» белән дә шашкан идек. Китабы белән дә, киносын карап та. Авылда үзебез дә шундый бер «гвардия» оештырырга тырышып карадык. Әлеге Вилмир белән икәү: ул—Сережа Тюленин, мин—Олег Кошевой. Стахович ролен кеше табалмадык. Илмарны «кыстап» карыйм, «стахановчы»дан алынган ул фамилия» дип шыттырам. Ышанмый, аягын җиргә ышкып тора да тора, ризалашмыйча... Ахырдан Вилмир белән кәгазьдән кисеп, буяп, бер кызыл флаг әзерләдек тә, безнең каршыдагы йорт—Фәрху әбиләрнең өй түбәсенә кадарга булдык. Барып чыкмады: без түбәгә үрмәли башлауга, өйдән: «Кем йөри анда? Каяле»—дигән ачы тавышлар ишетелгәч, флагны калдырып, качып китәргә туры килде. Гвардия дә төзелми калды. Иң кызыгы: анда безнең яшьтәш кызларны чакырып карасак та, алар безне малайсытып, риза булмадылар. Кызларның иртә өлгергәнен, аларның күнеле бездән зуррак, рәтле егетләрдә булганын без үсә төшкәч кенә аңладык. Ә бездә—«кызыл» уен дәрте генә иде әле.

***

Күпме китаплар укып, хыялый бер дәрт-романтика белән янып, үземне шигъри дөньяда тойсам да, реаль дөнья кешеләре, бигрәк тә кызлар минем өчен кул җитмәс, серле, мин аңламаган дөнья булды. Әле башлангычта ук алар күпне белгән, аңлаган, ахры. Миннән алда утырган кызның артка борылып, мине ирештереп сөйләшкәне исемдә: «Син, Рәдиф, олылар халкының бер-берсе белән серле, төнге мөнәсәбәтен күз алдына китерә аласыңмы? Мин үлсәм дә моны күз алдыма китермәс идем...

нинди оят бит, әйеме?»—дигән иде ул. Мин дә, котым очып: «Әйе, әйе! Мин дә үләр идем оялудан!»—дип, олыларны гаеп итеп сөйләдем. Үзем: «Ә үскәч, өйләнгәч, ничек оялмыйча шул эшләргә барырмын икән? Нинди газап көтә мине алда, Ходаем» дип, куркыныч уйларга бирелә идем. Ә бу классташ кыз үсә төшкәч тә мине үртәүдән тәм таба иде. Мин инде гашыйк күзләре белән, үземчә бик эффектлы итеп карап, текәлеп тора башласам:

—Күрмәс күзләрең белән алай карап торма миңа. Прошу!—дигәне истә. Югыйсә, күз игы рәтсез булса ла, матурлыкка карарга, сокланырга ярый бит—шагыйрь буласы кешегә.

***

Китаплар укып, андагы гадәтләрне, сүзләрне кулланырга тырышу да уңышка илтмәде. Төрле образлардан дулкынланып, мәктәп юлында (Сәет авылына) очып йөргән чагым. Мин үземне кызлар янында бер паж—Керубино санап, аларны бер-бер графиня дип тоеп, шулай эндәшәм:

—Рөхсәт итегез сезнең шлейфны (күлмәк итәгең дип тә аңлатам) күтәреп барырга, мәрхәмәтле дамалар?!—дим.

—Нинди «дома» ул? Без сиңа өймени?

—Күлмәк итәген (оятсыз!) күтәрүдән ни максатың?—дип, минем китаби «рыцарьлык»ны да тиз суыттылар. Беркатлы, бәхетле вакыйгалар! Мәктәп юлы, шул яшьтәш кызлар һаман да югарыда, биектә кул җитмәс саф йолдыз булып яна әле. Шулар шагыйрь иткәндер мине, бәлки?

Аларга мең-мең рәхмәтем!

***

Беренче мәхәббәт мина әлеге үзебез йөреп укыган Сәеттә килде. Китаплар укып, романтик хыял белән янган малайга илаһи кыз сурәте генә җитми иде. Һәм ул килде! Инде Сәеткә көненә өч бара башладык үзебезнең яшьтәшләр белән. Шунсы кызык: без гашыйк булган кыз—барыбызныкы да бер иде. Әкияттәге кебек! Әмма кая бу турыда белдерү, хат язу, йә башка берәр «ысул»... Җитмәсә, Сәет авылы малайлары бик усал, сугыш чукмары. Үзләре безнең авыл кызлары белән йөри менә, ә безне сөйләштермәсләр дә иде. Гаярь егетләр булып үсте, дәртле, уен-җырга, гармун уйнарга оста булды Сәетнекеләр. Башка авылга барып сугышу да берни түгел иде аларга. Менә шундый авылның иң матур кызына гашыйк булып кара инде! Яшерен яну, хисләр дөрләве бу. Һичшиксез, шигырь язарга дә шушы беренче мәхәббәт этәрде. Шагыйрьнең ни икәнен әле аңлау да булмаган чакта...

*Мин кимәдем шушы яшькә җитеп,*
*Матур чалбар, матур күлмәкләр.*
*Әмма матур—җаным... Шул җанньымы*
*Матур кызлар әллә сөймәсләр?*

«Шушы яшькә» дигәнем дә ун-унике яшьләр булгандыр. Нәкъ менә Мирсәй Әмирнең «Тун ачуы»ндагы кебек. Йә Том Сойерның беренче «гыйшкы»: Бекки Тэтчер өчен өзгәләнүләре... Аһ, ул Том Сойерга иярүләрем! Еллар үтеп, инде Талбазыга, урта мәктәпле авылга йөри башлагач, бу беренче хисләр турында идеал иясенә, җаен туры китереп, бер кызык хатирә итеп сөйләдем дә. Ул вакытта Талбазы авылы күгендәге йолдызларны саный идем инде. Ләкин тегесе дә, бусы да, шигърият дигән олы дөньяга этәреп, үзләре дә белмичә, мәңгегә мәҗнүн иттеләр... Йә, ни әйтәсең аларга?!

# ИШЕК ШЫГЫРДАВЫ

ХИКӘЯ

Тагын ишек шыгырдады. Тукта, аяк тавышы аның ишек төбендә туктады түгелме соң?

—Әй, көтеп ятудан да начар эш юк,—дип уйлап та бетерә алмады, өметен сындырып лифт ишеге ачылды. Төнге кунак өске катка менеп китте. Тагын юк, ул түгел икән.

Борчылып сәгатькә бакты. Унбер тулып килә икән.

—Кайда йөрер бу бала,—дип үз-үзенә сөйләнә-сөйләнә,Галия торып ук утырды.

Янәдән ишек шыгырдады. Бу шыгырдау аны күпмегәдер тын торырга мәҗбүр итте.

—Юк, монысы да булмады.—Галия үз эченнән догаларын укый-укый, җылы юрганы астыннан башта уң аягын, аннан сул аягын чыгарып идәнгә басты. Акрын гына адымнар белән тәрәзәгә юнәлде. Төннең соклангыч матурлыгына күз тидерүдән куркып, як-ягына төкеренеп алды. Урамда көз, алтын көз икән ләбаса, матур, бик матур иде. Үзалдына елмаеп, эченнән генә үзен-үзе орышып та алды:

—Их, шушындый төнне буй җиткән егетне дүрт стена эчендә тотып кара син,—диде.

Әнә, уйнап-көлешеп, икәү кайтып киләләр. Егетләр арасында улын танымады.

—Юк, монда да юк,—дип көрсенеп куйды. Булса, таныр иде бит инде. Подъезд төбендә озак кына гәпләшеп торганнан соң, егетләрнең берсе ишеккә юнәлде. Ишек тә аның кулын танып, оялчан кызлар кыланмышын чыгарып шыгырдап куйды.

Урамда тынлык. Агач яфраклары гына, соңгы минутларының җитүен сизеп, үзара сөйләшәләр. Гәпләшеп кенә калмыйлар, җил искән саен берсен-берсе ашыктырып, җир хозурыннан урын алырга ашыгалар кебек.

Галиянең игътибарын ерактан ишетелгән аяк тавышы бүлде. Ул бөтен игътибарын килүчегә юнәлтте.

Юк, улы түгел шул. Озын буй, килеш-килбәтен китереп атлап кайта берәү. Кемнеңдер улы, бердәнбере бит инде,—дип уйлап та бетерә алмады, бу төнге кунак та алар йорты ишегенә табан атлады. Чит кеше кулын сизгәндәй, ишекнең шыгырдавында Галия үзгәреш сизде.

Ана үз-үзенә сөйләнеп юаныч тапты.

—Син дә кеше көтеп уткәрәсең, ишек. Кемнәр генә синең келәнне килеп тартмаган да, кемнәр генә төрле уй-теләк белән сине ачып кермәгән. Шатлыгын да, бәхетен дә, кайгысын да күргәнсеңдер син үз гомереңдә. Ләкин һаман шул ук шыгырдау. Ачып керүчеләр кебек дуамал да, холыксыз да түгел син, ишек. Син гел бер. Ләкин, дикъкатьләбрәк тыңласаң, төрле кешегә төрлечә шыгырдыйсың түгелме соң?

Әнә, җирдәге яфракларны саный-саный тагын берәү кайтып килә. Ишеккә килеп җиткәнче, әллә аягы таеп китеп, әллә инде хәле мөшкел булып, ишеккә килеп үк бәрелде. Ләкин ишеккә нәрсә, үз вазифасын җиренә җиткереп башкара. Бу юлы ул керүчегә каерылып ук ачылды. Галия ишекнең шыгырдавында хәтта сөенү чаткыларын да сизде.

Күз күремендә тагын яшьләр пәйда булды. Галия алар арасында таныш йөрү чалымнарын эзләде. Берәү бар, уң кулын сулына караганда ныгытыбрак селкеп атлаучысы улыдыр, мөгаен. Әйе, шул!.. Яшьләр таралышырга ашыкмадылар, подъезд төбендә гәпләшү дәвам итте.

Улын күреп тынычланган Галия йокы бүлмәсенә юл тотты. Кичке көзгә урам серлелегеннән соң үзенә йокы чакыра алмый ятканда ул таныш шыгырдауны ишетте. Улының исән-сау кайтуын белдереп, Галиягә ишеттерерлек итеп, шатланыплар шыгырдады ишек!

**Роза ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА-ХӘМИДУЛЛИНА**

*Әдәби эстафета Балык Бистәсе районының Ямаш мәктәбендә*

## Үткәннәргә хат

Бәлки, Тукай яки синекедәй
Шигырьләрдә юктыр осталык,
Ләкин шушы кыска юлларымда,
Һади, сиңа карыйм тукталып.
Сезгә шулай «син» дип эндәшкәнгә
Берүк рәнҗемәсен күңлегез,
Сез бит барча кеше йөрәгенә
Якын бер зат булып кердегез.
Син дә алдан бөек булмагансың...
Син дә сабыйларча уйнагансың...
Бөеклекне сиңа, даһи Һади,
Кемнәр генә биреп калдырган соң?..

Киләчәккә җибәрелгән хатлар,
Һади, безгә килеп җиттеләр.
Син язганнар инде безнең баштан
Җилләр кебек, сыйпап үттеләр.
Килмәде шул җиргә коммунизм:
Байлар калды яшәп байларча,
Ярлылары ярлы булып калды...
Шулай дәвам итәр алгача.
Син теләгән якты ышанычлар,
Бик кызганыч, чынга ашмады.
Язмыш безне кырык яктан алып,
Кырык якка кире ташлады.

Үткәннәргә язган бу хатыма
Син, әлбәттә, җавап язмассың.
Бар халкыңа сәлам юллагансың,
Инде бурыч бездә калмасын.

**Рөстәм САФИН**

## СНАРЯД КЫЙПЫЛЧЫГЫ ТОТЫП КАЙТКАН УЛ...

Алсу таң атып килә. Һәркем тирән йокыда. Чик сакчылары гына уяу. Тик көтмәгәндә аларның тынычлыгы бозыла. Өстән самолетлар очып үтә, җир өстендә бомбалар шартлый башлый, артиллерия, пулеметлар телгә килә. Чик сакчылары сугышка күтәреләләр. Бу 1941 елның 22 июнь иртәсе була.

Күзаллаулар, уйлар, җиргә сызылган буразналар сыман, бер-берсенә ялганалар. Минем алдымда 20 яшьтә сугышка кергән дәү әтиемнең истәлек язмалары.

«Безгә окоплар казырга куштылар. Күрәчәккә каршы, казып бетерә алмаган идем, шулвакыт бер снаряд шартлаганы ишетелде. Минем аяк белән кулны яндырып, итекне алып чыгып китте. Ул снарядтан биш кеше яраланган, өч кеше үзләре чыгарлык. Без—ике кешене, күтәреп яраларны бәйләгәч, агач төбендә калдырып киттеләр. Ачык кыр, бер түбәнтен урын. Төнлә яңгыр яуды, әле ярый минем плащ-палатка бар иде. Иртән күзәтәбез, бер җан иясе дә күренми. Шулай итеп, өченче тәүлеккә китте, безне алырга килүче дә, яннан узучы да булмады. Төнлә безнең часть чигенгән, башка часть алып чыккандыр дип безне эзләп маташмаганнар.

Теге өч төннең берсендә күккә карап ята торгач, үзебезнең авылның тау башындагы ике йолдызын күрдем. Берсе олы, бик якты, икенчесе кечерәк, сүрәнрәк иде. Шул йолдызларга карап еладым, чөнки мин үлем көтеп ятам, ә безнең әти-әниләр, туганнар моны белми. Их, хәбәрләшеп булсын иде!..

Танк астында калган танкка ата торган мылтыкны эзләгәндә безне табып алып, кыр госпиталенә озаттылар. Аяк сызлауга чыдап булмый. Төнлә операция ясап, уң аякны, тездән кисегез дип яларсам да, боттан кистеләр».

1944 ел. Дәү әтием—типсә тимер өзәрдәй булып сугышка киткән егет—туган

ягына кайту юлында. Бер аяксыз, кулында снаряд кыйпылчыгы. «Мине нинди киләчәк көтә? Исәплеләр, кайгы-хәсрәтләр вагон тулы минем янда»... Шундый тойгылар белән Казанга, аннан район үзәгенә кайтып җитә. Авылга хәбәр итәләр. Тик дәү әтиемне килеп алырлык ат табылмый авылда! Нинди гамьсезлек инде бу? Ватаны өчен көрәшкән, саулыгын югалткан кешегә аз гына җылы мөнәсәбәт тә җитә иде бит югыйсә.

Кайтканының икенче көнендә Миңнехан бабам (дәү әтиемнең әтисе) «уфалла» арбасы белән улын алырга килә. Тик дәү әтием әтисенә тарттырып кайтырга риза булмый. Протезларны арбага салып, култык таяк белән кайтырга чыга. Бәхеткә каршы, ат очрый.

Ни хикмәт, I группа сугыш инвалиды булса да, кешеләр арасында авыртуны яшерә, авызлыклап тота алган әле дәү әтием. Милли бәйрәмебез—Сабан туенда аяк көрәштерү буенча аңа тиңнәр булмаган! Якташларына оста шахматчы, матур тавышлы җырчы буларак та билгеле ул. Бер генә мәҗлес тә аның җырлавыннан башка узмаган.

Күңел төшенкелегенә бирелмичә, Күгәрчен, Зәңгәр күл, Шомбыт, Балтачта (ул авылларга велосипед белән йөргән) хисапчы булып эшләгән ул. 1958 елдан 1989 елның мартына кадәр туган авылы Ямашта хисапчы ярдәмчесе вазифасын башкарган.

Аллага шөкер, эче тулы исәп-хәсрәт белән кайткан дәү әтиемә дөнья бәһасе, фәрештә җанлы кеше туры килгән. 1946 елның 8 маенда укытучы, Күгәрчен авылы кызы белән гаилә корганнар.

Дәү әтием белән дәү әнием бик матур яшәделәр. Дүрт бала тәрбияләп үстерәләр, өстәвенә, үлгән сеңелләренең ике баласын да кеше итәләр. Кызганычка каршы, дәү әтием хәзер вафат инде. Каберендәге биек ак мәрмәр ташы аның тормыштагы мәһабәтлеген хәтерләтеп тора.

**Таңсылу МОСТАФИНА.**
*15 яшь.*

# ТИЕН МАЛАЕ ЧИК-ЧИК

Борын-борын заманда түгел, безнен заманда яшәгән ди, булган ди тиен малае Чик-чик. Ул эшләргә яратмаган, әнисен дә тыңламаган. Көне буе уйнаган, күңел ачкан. Бер көнне әнисе аңа:—Улым, эшләрем бик күп, өлгерә алмыйм, су алып кайтып бир әле,—дигән.

—Бик барыр идем дә, вакытым юк шул, мультик карыйсым бар,—дигән Чик-чик. Әнисе бик арыса да суга киткән. Икенче көнне әнисе:

—Улым, чикләвек җыярга булыш әле,—дигән.

—Иртәгә җыешырмын, мин хәзер иптәшләрем белән футбол уйныйм,—дигән һәм чыгып йөгергән тиен малае. Ә әнисе тырышып-тырышып чикләвек җыйган. Чик-чик кояш баегач кына арып-талып өенә кайткан. Аның бик тә ашыйсы килгән.

Әнием, тамагым бик ачты, чикләвек бир әле,—дигән ул.

—Вакытым юк, иртәгә бирермен,—дигән әнисе. Чик-чик ач калган.

Шулай ул, Чик-чик, эшләмәгән ашамый!

**Рания ГАЯЗОВА,**
*4нче сыйныф укучысы.*

## Кеше исемендәге чәчәк

Ни хикмәт, обсерваториядә диплом эшемне башкарган чагымда ук гади күз белән дә күзәтерлек ике комета күк йөзендә пәйда булды. Берсе, аны беренче булып күзәткән ике астрономның исемнәре белән Аренд-Роланд кометасы дип аталганы, шундый зур һәм якты иде ки, шаклар катып, сокланып карап торуларымны һич онытасым юк. Кайчагында, торышына бәйле буларак, аның искиткеч озын койрыгы ярты күк аша зенит яныннан алып горизонт кырыена тиклем сузыла иде. Икенчесе, Мркос кометасы, андый ук якты булмады, әмма барыбер аны күктә гади күз белән күреп була иде. Диплом эшемнән читкә тайпылып аларны күзәтүдә катнашу мөмкин түгел иде, әмма соңыннан, дипломлы белгеч сыйфатында эшли башлагач, остазым төшереп алган фотоларны бик җентекләп тикшереп, аларның күк сферасы буенча хәрәкәт траекториясен билгеләүче координатларын исәпләп чыгардым. Шулай итеп, тәүге фәнни мәкаләләрем вузда укуымны тәмамлаган елда ук дөнья күрде. Хәер, үзем аларны эпизодик эшләр генә дип санадым, чөнки төп темам Ай динамикасын өйрәнүгә багышланган иде.

Шуңа карамастан, бик мавыгып башкардым бу «очраклы» эшемне. Чөнки профессор Дубяго сөйләгән Галлей кометасын өйрәнү тарихы һәрчак исемдә булды. Үлчәү приборы артында бөкрәеп утырулар да, арифмометрда эчпошыргыч хисаплаулар да арытмый иде.

Гринвич астрономы Эдмунд Галлей дүрт гасыр дәвамында күзәтелгән кометаларның егерме дүртен сайлап ала, Ньютон тәкъдим иткән ысулны кулланып, аларның орбиталарын исәпләп чыгара. Ул өч кометаның орбиталары бер-берсенә бик охшаганлыгын күрә һәм бу очракта Кояш тирәсендә эллиптик орбита буенча йөри торган, 75 яисә 76 ел саен Кояшка якынаючы бер генә периодик комета күзәтелә дип фараз кыла. Чираттагы визит 1758 елда булачагын әйтә.

Галлей күрсәткән ел якынлашуга бу мәсьәлә «көн кадагы»на әверелә. И.Ньютонның ачышларыннан соң кометага зур планеталар Юпитер белән Сатурнның тарту көче тәэсир итәчәге һәм кометаның орбитасы, шул унайдан периодының да шактый үзгәрәчәге дә көн кебек ачык була. Франциянең даһи математигы Алексис Клод Клерога, астрономнар Галлей кометасын алдан әзерләнеп, «коралланып» каршы алсын өчен, бик катлаулы һәм бик күп вакыт таләп иткән хисаплау эшләрен башкарырга туры килә. Көнен төнгә ялгап, ашарга тукталганда гына бераз ял итеп эшләгән галимгә талантлы математик, күренекле сәнгать остасының хатыны мадам Гортензия Лепот булыша. Зур планеталарның тәэсире комета йөрешенең периодын арттырганы ачыклана. Орбитасының перигелий дип атала торган Кояшка иң якын ноктасын комета 1759 елның март аенда уза. Күзәтүләр 1758 ел ахырында башланып, чираттагы елның июнь аена кадәрле дәвам итә.

Шулай итеп, И.Ньютон ачыклаган бөтендөнья тартылыш законы тагын бер кат ныклап исбатлана.

Бу тикшеренүләр өчен галимнең ярдәмчесенә бик үзенчәлекле бүләк «биргәннәр». Ерак илләрдән кайтарылган, анарчы Франциядә билгеле булмаган, матур чәчәкләр белән бизәлә торган куакларга мадам Лепотның исемен биргәннәр. Шулай итеп, мөхтәрәм укучыларыбыз, белегез һәм онытмагыз: гортензия чәчәге астрономия, механика һәм математика белән тарихи бәйләнештә тора.

**Ким ШАКИРОВ**

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@yandex.ru*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

## 1984

**1 гыйнвар.** Яңа елны Нурсөя белән икәү генә каршыладык. Коймак белән чәй эчтек. «Голубой огонек» карадык. Төнге сәгать икегә чаклы карарга түземлек житте. Аннан яттык, ләкин күрше-тирәләрдән радио-телевизор гөрләп ишетелеп торгач, йокы алдырып булмады. 4 ләрдән соң бер «Тазепам» эчтем. Анынчы да бер таблетка эчкән идем. Бишләр тирәсендә йоклап кителгән. Иртән 10нчы яртыда тордык.

Яңа елны каршылап утырганда Равил Шәрәфиев шалтыратты. Как раз «Яңа ел утлары»н карап бетереп (ә ул тапшыруны Р.Шәрәфиев белән Р.Мотыйгуллина алып барды) шуның турында сөйләшеп утыра идек. Равил Шәрәфиев белән минем «Автомобиль»не уйнаган чордан ук яхшы таныш булсак та өйләргә шалтыратышкан юк иде. Шалтыратышу болай башланды.

Бервакыт шулай кемдер Мәскәүдән шалтырата: «Бу Равил Шәрәфиевлар квартирасымы?»—ди. «Юк,—мин әйтәм.—Ялгыш җыйгансыз. Яңадан шалтыратып карагыз»,—дим. «Менә шушы номер белән Р.Шәрәфиевка шалтыратмассыз микән?»—дип миңа Р.Шәрәфиевнын телефон номерын бирде. «Мин нишләптер аңа әләгә алмыйм»,—ди. Шуннан мин ул биргән номер белән Р.Шәрәфиевка шалтыраттым. Шул чакта гына аның артист Равил икәне искә төште. Менә шуннан соң без аның белән шалтыратышкалый башладык.

**2 гыйнвар.** Кичә кич Әхмәт белән Мәдинә килделәр. Малайлары Искәндәрне дә иярткәннәр иде. Әхмәтнең Мәскәүдә «Млечный путь» дигән шигырьләр җыентыгы чыккан. Ә Мәдинәсенең «Детская литература»да коллектив җыентыкта «Возмужание»се. Китапларын алып килгәннәр. Көнләшеп куйдым. 25 ел язып Мәскәүдә шигырь китабы (үзебездә дә юк икән) чыгарган юк әле. «Современник»ка подстрочниклар җибәрдек инде, бәлки, 2-3 елдан чыгар. Менә бу Мәдинәләр чыккан коллектив җыентыкка минем дә балалар өчен язган бер повесть керергә тиеш иде бит. Г.Ахуновка илттердем Нурсөядән. Ул каядыр өстәл тартмасына салып куйды да онытты. Гариф Ахуновны кешеләр мактаса да, миңа бер яхшылык та эшләмәде ул. Ул Союз председателе чагында СССР Югары Советына сайлаулар булды. Союз председательләрен һәрвакыт депутат итеп сайлыйлар. Гариф абый да СССР Югары Совет депутаты булды. Власть зур, СССР язучылар Союзында секретарь. Китаплары чыгу белән русчага тәрҗемә ителә. Хәтта «Хәзинә»се буенча кинофильм төшерелде. Ул властьта йөргән чагында Нурсөя аның янына барып: «Гариф абый, безнең фатирга телефон керттерә алмассызмы? Ул Фәнис өчен аяк булыр иде»,—дигәч, Г.Ахунов: «Мине Чистай округы сайлады, Язучылар союзы түгел»,—дип Нурсөяне елатып кайтарды. Шуңа күрә мин Мәскәүдә китап чыгару турында сүз кузгатмадым. Кем генә председатель булса да.

*Дәвамы. Башы 1нче санда*

Ә теге «онытылган повесть» турында янадан сүз булмады. Бу повестьның ул җыентыкка керми калуына үземнән бигрәк Нурсөя уфтанды. «Тагын бер әйберең тәрҗемә ителәдер иде»,—ди. Тәрҗемә иттерү кирәген кирәк инде. Рус укучылары килә. Чирек гасыр язып, укучыга күрсәтерлек шигырен булмагач, алар ни уйлый инде. Рәтле язучы булса күптән русчага тәрҗемә ителер иде дип уйлый, әлбәттә. Тәрҗемә ителүнең язуга караганда да катлаулырак икәнен һәр кешегә аңлатып йөреп булмый бит.

**3 гыйнвар.** Эч пошып тора. Соңгы вакытта бер әйбер дә язган юк. Бүген «Тозлы тамчы»ны нәшриятка илттердем. Кичә Ш.Галиев белән сөйләшкән идем, 1986 ел планына кермәс диебрәк торды. «Шигырь китапханәсе»ндә без елына бер генә китап чыгарабыз, берәү керде инде, ди. Аннары ул союз аша үтәргә тиешле икән әле. Правлениегә хат язарга кирәктер инде.

Кичә Нурсөя «Гурзуф»ка путевка алып кайтты. 11гыйнвардан 23 енә чаклы. Бу былтыр «Ялкын»да конкурста җиңгән өчен бирелгән бүләк инде. Бушлай булырга тиеш иде, 30% түләттеләр, җитмәсә әле путевкасына «35 яшьтән өлкәнрәкләрне салмыйбыз» дп язганнар икән. Гурзуфтан коры барып буш кайтсаң, ник беренче урынны алдым икән, диярсең. 10сына самолетка билет беткән, поездга алырга кала инде. Симферопольга чаклы ике тәүлек тыркылдасаң, аннары борып кайтарып җибәрсәләр, Нурсөягә ял була инде бу. Ялдан аның бер дә бәхете юк. Бер елны Ленинградка җибәргән идем, баруга чирләгән. Өстәвенә барасы кеше (Вечтомова) өйдә булмаган. Берәүгә квартирага кереп, атна торып, эттәй арып кайтып керде.

Икенче бервакыт Үзбәкстанга җибәргән идем, Зөлфия апа мамык җыярга йөртеп җанын алган. Өченче ел Васильево ял йортына 2 путевка алып бирдем тулы бәясе белән. Гел яңгырлы вакыт булды. Шушында исән-имин барып кайтса, яңадан беркая да җибәрмәскә кирәк лучше. Икәү тыныч кына яшәгәндә ни пычагыма кирәк бу ял йортлары. Бу Гурзуфы әле ял йорты да булып чыкмады. Халыкара яшьләр лагере. Спорт киемнәре алып килергә кушканнар. «Син анда гел беренче булырсың инде, монда минем өчен төрле җиргә чабып, спортчы булып беттең инде»,—дип шаяртып алдым.

Кичә Сафуан абый Муллагалиев кергән иде. Рәшит Әхмәтҗановның квартирасын ремонтлап биргән. Тегесе аның шигырьләрен бераз редакцияләгән бугай. «Бу китап артыннан йөреп, машина алырлык акча бетердем инде»,—ди Сафуан абый. Нәрсәгә кирәктер аңа шул китап. Тыныч кына үз эшен эшләп йөрсә ярамаганмы. Дүрт елдан артты инде йөри башлаганына, әле китабының эзе-юлы юк. Кулында бер дигән һөнәре бар. Гомумән, бу иҗат дигән нәрсә кызык инде. Кеше шуңа бирелсә бөтен дөньясын оныта.

**10 гыйнвар.** Кичә Нурсөя Кырымга китте. «Ялкын» үткәргән конкурста җиңгән өчен «Спутник» дип аталган халыкара лагерьга путевка бирделәр. Путевкасы 12 көнлек. Нурсөя чирләп тә тора иде, җитмәсә поезд белән барырга әле. Самолетка билет булмады. Ике тәүлек тырык-тырык барырга инде мескенкәйгә. Чирләгәндә юлда йөрүләре бер дә рәхәт түгел бит.

Нурсөя чыгып киткәч шундый күңелсез булып калды. Йөрәк әллә нишләп китте, әйтерсең бөтенләйгә киткән. Гел бергә торып шул хәтле күнеккәнмен инде мин аңа. Аннан башка яшәүне күз алдына да китерә алмыйм.

Бүген башлаган хикәяне дәвам итәрмен дип уйлаган идем, рәт юк, язып булмады. Көчкә-көчкә генә бер-ике хат язып куйдым. Хәтта көндәлеккә дә тотынасы килми.

Эшлисе эшләр күп. Р.Вәлиева беркөнне хикәяләрне бик ошаттым дип шалтыраткан иде, хәзер инде әллә ничәсен алыштырырга иде, дип маташа. Юмористик әйберләрне бик ошатмаган. Югыйсә анда ярамаслык әйберләр юк иде инде.

5 гыйнвар көнне әнине Баян җизни китерә килде. Аннары җизни кичә үк Арчага Хәлидә янына киткән иде, чирләп кайткан. Температурасы 38,5. Чирле көйгә Баулыга кайтып китте. Бырыбызны да кырып салырга дип, җин сызганып килгән быел безгә грипп. Бер көз көне чирләгән идек бит инде без. Күрәсең, килгәндә дә, киткәндә дә безгә керми китмәскәдер исәбе. Кайбер кешеләр бик үз итеп бетермәсә дә чир ярата безне.

**13 гыйнвар.** Борын һаман юеш. «Әпчехи» дип ятам.

Кичә кичке 10нарда Нурсөядән телеграмма килде. Әйбәт кенә килеп життем дигән. Ул да чирләп чыгып киткән иде, терелгәндерме, әйтмәгән.

Бу ике көндә «Бәрелеш»не яздым. Тәмамладым инде. Кабат карап чыксам, берәр жиргә жибәрергә булыр.

Кичә 115 мәктәп директоры Нина Ивановна шалтыратты. Туган ил турында русчага тәрҗемә ителгән шигырьләрен юкмы, безнең бер укытучы сезнең иҗат турында доклад язарга жыена иде, ди. Карап куярмын, ике атнадан шалтыратырсыз, дидем.

38 мәктәптән ике кыз килде. Каникул вакытында бөтен класслары белән Мәскәүгә барганнар, Островский музеенда булганнар. Укытучыларына кофе алып кайтырга кушкан идем, бер банка кофе алып кайтканнар. Күбрәк алып кайтсак акчасын әллә бирә, әллә юк дип уйлаганнармы?! Кешедән бушлай әйбер алган юк иде ансы.

**15 гыйнвар.** Кичә «Бәрелеш»не янабаштан карап чыктым. Бераз шигырьне машинкада бастым. «Социалистик Татарстан»га һәм радиога әзерләдем. Бүген менә үзебезнең озын эшләрдән соң шуларны конвертладым һәм тагын ике хат яздым. Кичә Нурсөя шалтыратты, ләкин ярты сүзен ишетеп булмады. Шулай да шалтыратуына бик сөендем. 26сында кайтырга тиеш. Ансыз бик күңелсез. Вакыт тизрәк үтсен өчен үземне эш белән күмәргә тырышам. Иртәгә бер иске хикәяне эзләп табып, шуна яңа концовка уйлый башларга кирәк.

Быел кыш жылы. 2-4 градуслардан артмый диярлек. Бүген бераз буранлап тора.

Кичә Баян жизни шалтыратты. Теге көнне самолеты 3 сәгатькә сонарып очкан. Чирле килеш өч сәгать көтүе рәхәт булмагандыр.

Рәшит Әхмәтжанов кергән иде. Китапка сүз башы язмассың микән ди. Язармын, дидем. Шигырьләрен кертсә, хәзер шактый вакыт аның өстендә утырасы булыр. 85 нче елда биш табаклык китабы чыгарга тиеш икән.

**16 гыйнвар.** «Узган еллар кайтавазы» дигән хикәянең азагын икенче төрлерәк итеп яздым. Машинкада басып куясы бар. Нурсөядән хат килде. Бүлмәләрдә икешәр катлы нарылар, салкын, дигән. Ял не везет аңарга. Солдат казармасы кебек жирдә нинди ял булсын инде. Бөтенләй салкын тидереп кайтмаса ярый. Үзе минем турыда кайгыртып ята әле, әллә чирләденме, әллә нинди төшләр күрдем, дигән. Мине үләр дип кайгыра башласа, мин аңа һәрвакыт: «Шейникларны атом бомбасы да ала алмый»,—дип шаяртам. Муен позвоночнигы сынганнарны врачлар «шейник», аркалары сынганны «спинальник» дип йөртәләр.

О. күрше кереп утырды. Әниләрен үлгән абыйларының хатынында торалар. Монда шуның исеме белән ничә кешегә квартира алып бирделәр дә, хәзер әниләренең кирәге бетте. Кызларына сыймаган әби ире үлгән киленгә бик тансык түгелдер. Авыл жирендә бит әле аның туалеты да тышта. Ваннасына кайнар су да агып тормый. Мунчага күтәреп алып барырга кирәк. Киләсе килмәгән очракта да алар аны үзләренә алып килергә бурычлы югыйсә. Н. ике бүлмәле квартирада бер кызы белән генә. Болар өч бүлмәле квартирада өчәү. Үсеп, кеше булгач, әниләр артык йөккә әйләнә шул.

**17 гыйнвар.** Төшемдә песи баласы иркәләгән идем. Нурсөя шалтыратырга булган. Ул шалтыраткач күңел күтәрелеп китте. Бер хикәя башлап куйдым. Әлегә исемен шартлы рәвештә «Кайту» дип куйдым. Рәтле исем тапсам алыштырырга булыр.

Нурсөя барында төшемә песи баласы керсә, берәр кыз килә яки берәр кыздан хат ала идем.

**18 гыйнвар.** Хикәямне дәвам иттем. Уң як яңакка әллә нинди биз чыккан, бармак башы хәтле. Муеннан өстәрәк, борылырга да комачаулый. Кинәтрәк борылсаң, икенче ягына «әйләнә» дә авырта башлый. Күчеп йөри торган нәрсә.

**20 гыйнвар.** Хикәямне тәмамлап куйдым. «Хужа» дигән исем куштым. Ярыйсы чыкты шикелле. Ләкин үземнең рәт бик шәптән түгел, теге биз һаман бетми. Шешкә әйләнеп бара. Бу ике төндә йокы бик начар булды. 18е көнне кич йоклап китәр алдыннан гына Баян жизни килде. Ул монда обкомга йомыш белән килгән. Килгәндә машиналары ватылып жәфаланганнар. Соңарганнар.

Кичә тагын йоклап китүгә ишек шакыйлар дип сискәнеп уяндым. Әллә жизни китә алмыйча кире кайтты микән, дип уйладым. Шаку ишектә түгел икән. Әллә өстә, әллә аста шакыйлар иде. Сәгатькә карадым. 1нче 15 минут.

Бүген Нурсөяне төшемдә күрдем. Икәүниндидер стена өйдек. Кирпечтән. Цементлар изеп. Нурсөя юлга да кирпечләр түшәп маташты. «Аста бушлык калмыймы, машина баскач кирпечләр ватылырлык булмасын»,—дип мин өйрәткәләп тә маташтым әле. Нәрсә генә керми инде төшкә. Язып куярга ярамаганнары да керә. Фәйзи жизни: «Мин бөтен күргән төшләремне язып барам,—ди.—Оятлыларын да»,—ди.

**22 гыйнвар.** 20 се көнне кичкә таба бик каты чирләп киттем. Температура 39,4 булды. Нурсөя әйтә иде: «Син һәрвакыт җомга көн кич белән чирлисең»,—дип, бу юлы да шулай булды. Төнлә йоклап булмады. Әнидән кура җиләге кайнаттырдым. Төнлә бер литрлы термосны бушаттым. Ә икенче көнне иртән температура 38,2 булды. Һаман температура төшмәгәч, врач чакырттым. Ул кичке 5ләрдә генә килде. Картрак кына бер апа. Фамилиясен Агупова диде бугай. Килеп кергәч, бераз аптырап утырды. Яңактагы биз ару гына шешкән иде. Үзе тышкы яктан кызармады да. «Нигә кичә чакыртмадыгыз врачны, шундый югары температура белән разве врач чакыртмыйлар?»—ди.

Яңактагы бизне тоткалап карады да: «Гаҗәп,—ди,—гадәттә йә тамак асты бизе, йә колак арты бизе шешенә иде. Мин сезгә ничек ярдәм итәргә дә белмим,—ди.— Температураңны төшерергә «Ругавитат» дигән укол ясыйм. Тик сезнең кай жиргә кадарга, ул бит биш кубик»,—ди.

Уколын ясап кулга компресс ясады. Аннары янакка компресс куйды. «Тик мин моны бик шикләнеп кенә куям, борчыса алып ташларсың, ә иртәгә мин хирург җибәрермен»,—диде. Төнлә тагын шалтыратып хәлне белеште. «Температураң төштеме?!—ди. «Төште»,—дим. «Үлчәдеңме, болай үлчәмичә генә әйтәсеңме?»—ди. «Үлчәп тормадым. Тән алай кайнар түгел хәзер»,—дидем.

Сүзендә тора торган врач икән, хирург җибәргән. Якшәмбе көн булуга карамастан, хирург килде. Бу вакытта инде яңактагы бизнең шеше кайта башлады. Хирург, элек килгән егет Мөнир Габделфәтович, көненә ике тапкыр ашаганнан соң яртышар таблетка аспирин эчәргә кушты. Ялкынсынуны бетерә ул, ди.

Бүген төшемдә Нурсөяне күрдем. Яна төсле телевизор алган икән. Телевизоры әйбәт күрсәтә, экраны зур.

Төшемдә телевизор күргәнгәдер инде, Сафуан абый минем бәләкәй телевизорны сорап кергән. Йөз сумга сатып җибәрдем. Мин гел шулай, төшемдә ни күрсәм, өнемдә шул нәрсәгә бәйле берәр вакыйга белән очрашам.

Нурсөяне сагындым, шуңарга чирләгәнмендер әле. Врачларга хатынымны сагындым, шуңа бер дә рәтем юк, чиргә иммунитетым кимеде дип булмый бит инде.

*Өемнең һәр почмагыннан*
*Сагынуым карап тора:*
*«Курешергә әле фәлән*
*Көн бар»,—дип санап тора.*

Теге врачның тагын бер кызык нәрсәсен язмаганмын икән. Укол ясагач ампуласын әнигә бирде дә: «Берәр жиргә куегыз, үзегезнең дәвалаучы врачыгызга күрсәтерсез»,—диде.

**5 февраль.** 22 гыйнварлардан соң янакның шеше бик каты үсә башлады. Сызлавына түзәр хәл калмады. 25ендә Чуприна килде, ә 26сында хирург Хәлил Галимович шешне карап китте. «Ярырга иртәрәк әле, дүшәмбегә хәтле түз»,—диде. Бу пәнҗешәмбе иде. Дүшәмбене ничек җиткергәнне үзем генә беләм. Дүшәмбе кич хирург килде, бернинди инструментлары юк, ярмый китәргә маташа. Температура 39,2. «Инструментларыгыз стерильный булмаса, кайнатыгыз»,—дип бик каты торгач, скальпелен спирт белән ышкып шешне ярып җибәрде. Бер тәлинкәгә якын (аш тәлинкәсе) үлек акты. Ярып бер сәгатьләп үтүгә температура 38гә калды. Ул төнне

бераз йокладым, ләкин врачлар чыгып киткәч тә Нурсөя сәгать саен перевязканы алыштырып торды әле. Коточкыч әшәке исле үлек акты. Хәзер шешне ярганга бер атна, үлек агу бераз кимеде. Шулай да тегеләр ясап киткән перевязкалар белән чыгышып булмый. Хирург атна буена һәркөн килеп ярасын актарып китте. Хәзер янакның тишегеннән тешләр күренеп тора. Кайчан ябылыр бу. Яраны юдырырга дигән дарулары авыз эченә тула. Перевязкалары алар китүгә төшә. Нурсөя көненә 2-3 тапкыр бәйли янакны.

Союз тирәсеннән юри дә беркемнең килеп чыкканы юк. Югыйсә Нурсөя нәшриятка баргач минем чирләгәнне әйтеп кайткан бит инде. Берәр өлкәнрәк агайның теше сызласа да янына портфель күтәреп чабалар. Ә мин үлем белән күпме тартыштым. Беләк мускуллары тагын 1 см га нечкәргәннәр. Элек ун кулныкы 18, сул кулныкы 19 см иде. Беләкнең әйләнә озынлыгы. Хәзер ун кулныкы 17 см, сул кулныкы 18 см. Нурсөянең бармагы житә мускулны уратып алырга.

**8 февраль.** Хирург килеп (сестра белән) перевязка ясап китте. «Яраң мин уйлаганга караганда тизрәк ябыла»,—ди. Үлеге юкмы икән дип, тишеген актарып, бизләрне баскалап карады. Үлек чыкмады. Юынырга ярыймы әле?—дип сораган идем, түзик инде беразга, ярана су тимәве хәерлерәк, ди.

Бүген М.Маликова шалтыратып хәлне белеште. Килергә жыенабыз, килеп булмый, ди.

Ярый инде, хәзер яра төзәлүгә таба киткәч күнел күтәренке. Янда һәрвакыт кайгыртып торучы Нурсөя булгач, дуслар юклыгы сизелми. Врач үзләре бәйләп киткән белән эшләр шулай унайга китте дип уйлый. Ярадан үлек туктаусыз агып ятканда сәгать саен перевязкалар алыштырганны белми ул.

Бу атнада хирург көн аралаш килде. Тагын жомга чакыртырга кушты. Тәнгә янадан бераз көч керерме—әлегә көндәлеккә берничә жөмлә язганда да куллар калтырый. Үлемнең кырыена килеп житкән идем. Ничектер: «Их, тагын бераз яшисе иде»,—дигән уй да тумады. Үлсәм дә, калсам да барыбер сыман иде.

Хирург шешне яргач бер колба тутырып канлы үлекне алып китте. Анализ ясарга. Рак түгелме дип шикләнә. Янак бизләре (щитовидная железа) бик куркыныч ул, ди.

**13 февраль.** Беркөнне Бикә китапнын корректурасы килгәнлеген әйтеп шалтыраткан иде, укырлык хәл юк. Редактор гына карап төшереп жибәрсен инде дидем. Һаман хәл керми әле. Яра да төзәлеп бетми. Тагын бер ун көн барыр, ахры. Хәзер хирург атнага ике килә. Хирургка үземнең ике китапны бүләк иттем. «Татарча укый беләсезме?»—дигән идем, «Яңалифтән башлап барысын да укыйм»,—ди.

Беркөн «Казан утлары»ннан Рашат Низамиев шалтыратты. Жиңүнең 40 еллыгына хикәягә конкурс үткәрәбез ди. Сезнең конкурсларда жинә торган гадәт бар иде, катнашыгыз әле, ди. Катнашсаң ярар иде дә, тотып язарга көч юк. Тизрәк жәйгә чыксак бәлки бераз жиңеләйтер сыман.

Нурсөя дә соңгы вакытта бик ябыкты. Ашказаны, бавыры авырта. Өстәвенә кышка керде исә кычына башлый. Аякларынын тиресен ертып бетерә. Мин дә чирләгәч аңа бигрәк тынгы юк.

Перевязканы соңгы вакытта «Винилин», ягъни Шастоковский бальзамы белән ясыйбыз. Исе бик әйбәт булмаса да агып чыкмый, урынны, өс-башны пычратмый. Төзәтү ягы гөлжимеш маеннан бәлки бераз кайтышрактыр. Ә бәлки кайтыш та түгелдер. Мондый яра бер айсыз төзәлми дигән иде бит врач та.

Кичә, ягъни 13енә каршы төндә бик каты температура күтәрелеп китте. 39,6 булды. Иртән 38,7гә төште. Кич 38ләр тирәсе иде. Узган төнне Нурсөяне кырык тапкыр торгызырга туры килде. Кура жиләгеннән компот кайнатып, аспирин эчеп яттым.

Язып булмый, хәрефләр сикерә. Бу көннәрдә Нурсөя дә, мин дә, әни дә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын укыдык. Китап бик әйбәт чыккан. Бу шундый бер уникаль басма булып калыр, ахры.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## *Укучы сүзе*

«Казан Утлар»ы журналында басылган бер әсәр (шактый вакыт узса да, һич онытылмый) игътибарымны аеруча җәлеп итте. Ул да булса, хөрмәтле язучыбыз Зәки Зәйнуллин язган «Лотфулла солдат» бәяне (повесте) (2010, 11-12 саннар). Мөмкинлектән файдаланып, бу әсәрнең авторына һәм аның журнал вариантын жиренә житкереп бастырып чыгаруда катнашкан редакция хезмәткәрләренә рәхмәт әйтәсем килә. Автор бу яңа әсәрен яшүсмерләргә килешле итеп язган. Шуңа карамастан, мин, олы кеше, үземә күп кенә яңалыклар таптым аның эчтәлегеннән. Рәхәтләнеп укыдым әсәрегезне, Зәки әфәнде!

Сүз уңаеннан әйтим әле, әсәрне укып чыккач, авторга соравым туды. Соравымның асылы: «Бәлки, автор, бәянен яза башлаганда, аның хәзерге көндә җәмгыятебез өчен куркынычлы афәткә кагылышлы булуын үзе дә уйламагандыр?». Бу афәт—хәзерге Рәсәй армиясендәге «дедовщина» проблемасы. Соңгы елларда гына «дедовщина» аркасында Татарстаннан хәрби хезмәткә алынган күпме яшь егетләребез армиядан йә үлеп, йә инвалид булып кайттылар. Минемчә, югарыда әйтелгән афәтнең очы яшьләр армия хезмәтенә психологик яктан әзер булмаганлыкка барып чыга. Яңа коллективта, бигрәк тә ирләрдән генә торган хәрби коллективта, яшь кешегә үз-үзен куя белү бик кирәк нәрсә. Инде Лотфулла мисалына килсәк, ул хезмәт иткән чорда (1905-1906 еллар) патша армиясендә яшь солдатны беренче көннән үк хәрби хезмәткә кыйнап өйрәтү таралган булган: «рукоприкладство» алымы. Бу алым белән солдатны өйрәтүне офицерлар, фельдфебельләр башкарган, һәм аның шулай булуы «Лотфулла солдат» бәянендә берничә мисалда күрсәтелгән.

Китап сөючеләргә киңәшем шул: бу әсәрне укыгыз, анда яшьләребезгә файдалы, гыйбрәтле мажаралар бәян ителгән. Героебыз Лотфулла үзе хезмәт иткән ротада югарыда әйтелгән «рукоприкладство» алымына каршы чыга һәм бу көрәштә җиңүгә ирешә.

Зәки Зәйнуллинга киңәш итеп шуны әйтәсем килә: әсәрегезне аерым китап итеп бастырып чыгарганда, эчтәлегенә кагылышлы итеп, тышлыгын һәм китап битләрен 5-6 рәсем белән бизәсәгез иде. Рәсемле китапны укыганда арылмый. Гомумән, рәсемнәр белән бизәлгән яңа китапны кулга алу һәм аны уку үзе бер бәйрәм бит ул.

**Мансур ҖӘЛӘЛИЕВ**
*Казан*

**Редакциядән.**
*Хат авторы игътибарына З. Зәйнуллинның бер мәкаләсен тәкъдим итәбез: «О дедовщине в армии России». Ул аның «Сражения внутри Советской Армии» (Казан, 2007) дигән китабына кергән.*

## Әдип Маликовның тууына 90 ел

1921 елның 16 августында Башкортстанның Янавыл районы Югары Чат авылында мөгаллим гаиләсендә туган Әдип Маликов сигез сыйныфны тәмамлагач үзе дә мөгаллимлек һөнәре алырга ниятләп Пермь шәһәрендәге Татар педагогия училищесына укырга керә.

1939 елда училищедан соң Пермь өлкәсенең Барда районы Солтанай авылы мәктәбендә укытучы булып эшли башлый, әмма солдатка каралу вакыты килеп житү сәбәпле—армиягә алына. Ул армиядә хезмәт иткән вакытта Бөек Ватан сугышы башланып, аның гаскәри хезмәт вакыты жиде елга сузыла. 1945 елның августында разведка төркеме командиры сыйфатында Сахалин утравының көньяк өлешен японнардан азат итү сугышларында катнашып ул «Батырлык өчен» медаленә лаек була.


Әдип Маликовның каләм тибрәтүе әле үсмер чагында ук башлана, сугышка кадәр Татарстан, Башкортстанда чыга торган газеталарда шигырьләре басыла. Шәхес һәм шагыйрь буларак формалашуга тормышта күргән-кичергәннәре дә ярдәм иткәндер. Аның сугыш афәтләрен чагылдырып иҗат иткән «Атаудагы хисләр» поэмасы шунын ачык мисалы.

Сугыштан соң Әдип Маликов Казанга килә, Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире булып эшли. 1949 елда ул Татарстан Язучылар берлеге юлламасы белән Мәскәүнең М.Горький исемендәге әдәбият институтына укырга китә.

Әдип Маликов тормышындагы тагын бер мөһим чор—Әлмәт чоры иҗатында зур урын алып тора. Әлмәттә яши башлавының беренче елларында ул биредә әдәби иҗат берләшмәсе оештыра. 1963 елда әлеге иҗат берләшмәсе нигезендә Әлмәт Язучылар оешмасы барлыкка килә. 1965-1967 һәм 1971-1981 елларда Әдип Маликов әлеге оешманың җаваплы сәркатибе булып эшли. Ә.Маликовның нефтьчеләр тормышын яктырткан «Тамчы» (1956), «Фәрдәнә» (1958), «Гайшә апа» (1959) һ.б. поэмалары дөнья күрә. Әдип Маликов зур төзелешләр, яңа калалар, аларның фидакарь кешеләре турында шигырь-поэмалар гына иҗат итеп калмыйча, чәчмә әсәрләр дә яза. «Сахалин язмалары» (1948), «Кайнар эзләр» (1956), «Гашыйклар юлы» һ.б. Әлеге әсәрләр барсы да аерым бер җыентыкларда урын алып («Без кояшны юлда каршылыйбыз: сәяхәт язмалары»—1964), («Шигырьләр һәм поэмалар»—1971), «Гомер мизгелләре»—2001) һ.б. татар әдәбиятында лаеклы урын алалар. Аның әсәрләренең төп геройлары—хезмәт кешеләре. Татар шигъриятендә нефтьчеләр образын беренчеләрдән булып Ә.Маликов сурәтли.

Бөтен гомерен әдәбиятка багышлаган, аны яңа тема, яңа образлар белән баетуда үзеннән зур өлеш керткән Ә.Маликов 1979 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек була, 1959 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Мөхтәрәм язучы 2009 елның 23 апрелендә Әлмәт шәһәрендә вафат була һәм шунда җирләнә.



*Мәккә шәһәрендәге Изге Кәгъбә ташы әйләнәсендә дөньяның төрле кыйтгаларыннан хаҗ кылырга килгән халык ташкыны.*



*Габдрахман Әпсәләмов (1911-1979)—Совет әдәбиятының иң популяр язучыларының берсе. 1960 елда төшерелгән рәсем.*



*Мәшһүр музыкант-гармунчы Фәйзулла Туишев (беренче рәттә, уртада) композиторлар һәм музыка белгечләре белән бергә. 1939 ел. Казан.*



*Россия Президенты Борис Ельцин һәм Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Идел буенда. Июнь, 1996 ел.*



*40-50 елларда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының баш редакторы булып эшләгән әдәбият галиме Гази Кашшаф (1907-75). 60нчы еллар ахырында төшерелгән фото.*



*Татар язучылары һәм тугандаш республикалардан килгән әдипләр Татарстан урман хуҗалыкларының берсендә. Сулдан беренче—Сәйфи Кудаш, өченче—Мөхәммәт Гайнуллин, уртада төрекмән Берди Кербабаев, казах Жубан Мулдагалиев; уңнан беренче—Әдип Маликов һәм Галимҗан Латыйп. Узган гасырның 80нче еллары.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ГӨРЛӘП УЗДЫ САБАН ТУЙЛАРЫ

Халкыбызның иң төп бәйрәме—Сабан туе бәйрәме елдан-ел, географик яктан киңәеп, дөньякүләм танылу ала бара. Быел ул, Татарстаннан тыш, Россиянең 55 төбәгендә һәм 23 чит илдә үткәрелде. Шуларның берничәсе турында кыскача мәгълүмат биреп узабыз.

***

**25 июнь. Казан.** Татарстан Сабан туенең төп мәйданы быел Идел буе районындагы каенлыкта узды. Бәйрәмдә Россия Президенты Д. Медведев та катнашты. Аның белән янәшә Татарстан Президенты Р. Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин һәм башка бик күп рәсми кешеләр бар иде.

Башта алар Татарстан халыкларының традицион көнкүреше, мәдәнияте һәм кухнясын чагылдырган йортлар белән таныштылар, йортларның берсендә Россия җитәкчесе милли түбәтәйне киеп карады һәм чәкчәктән авыз итте. Тимерчелек йортында ул кулына чүкеч алды һәм чүкеп дага ясады. Аннары даганы һәм чүкеп ясалган Россия гербын ана сувенир итеп тапшырдылар.

Россия Президенты Сабан туенда катнашучыларны бәйрәм белән котлады. «Сабан туе—борынгы бәйрәм, тикшеренүчеләр фикеренә караганда, аның 1000 елдан артык тарихы бар. Шул ук вакытта Сабан туе һәрчак яшь бәйрәм. Сабан туе өлкәннәрне дә, яшьләрне дә үзенә җәлеп итә. Анда һәркем үзенең иң яхшы сыйфатларын күрсәтергә тырыша. Бүген һәркайсыгызның күңеле күтәренке булуын телим. Сабан туе биргән энергия запасы, тарихи рәвештә татар мәдәниятен, ә бүген инде тулаем зур илебезнең мәдәниятен туендырган энергия сезгә ел дәвамында яшәргә ярдәм итсен»,—диде Д. Медведев. Россия Президенты чыгышын татарча «рәхмәт» дип тәмамлады.

Быелгы Сабан туе, ныклы әзерлек белән оештырылганга күрә, күпменле тамашачылар күңелендә кабатланмас бәйрәм булып хәтердә калырлык булды.

***

**2 июль. Екатеринбург.** Россиянең төрле төбәкләрендә уздырыла торган федераль Сабантуйларның—бу унберенчесе. Бөтенроссия статусы алган бу бәйрәмдә Татарстан Президенты Р. Миңнеханов, Башкортстан Президенты Р. Хәмитов, Свердловск өлкәсе губернаторы А. Мишарин катнашты.

Екатеринбургта Сабантуй мәрәкәсе бер көн элек башланды. Свердловск өлкәсенең дәүләт академия театрында бөек шагыйрь Габдулла Тукайның 125 еллыгына һәм федераль Сабантуйның ачылышына багышланган тантаналы кичә булды. Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт уен кораллары оркестры, Свердловск өлкәсе һәм Татарстанның җыр һәм бию ансамбльләре, танылган җырчылар сәхнә тотты. Габдулла Тукай шигыренә язылган җырлар яңгырады. Узган ел «Түгәрәк уен» халыкара татар фольклор фестивалендә катнашып, халкыбызның милли аһәңнәрен тыңлап «аһ» иткән Свердловск өлкәсе губернаторы бу юлы да соклануын яшермәде. «Өлкәдә барлыгы 142 милләт вәкиле яши. Татарлар руслардан кала сан ягыннан икенче урында тора. Мин даими уздырылып килүче «Урал халыклары көне» бәйрәмендә бик теләп катнашам. Татарлар эштә дә, үзләренең милли традицияләрен саклауда да һәрвакыт беренчеләр рәтендә булдылар»,—диде ул.

Чын мәгънәсендәге интернациональ бәйрәмнең программасы гаять бай булды. Зур мәйдан янында күргәзмә рәвешендә оештырылган милли йортлар тезелгән иде. «Татар өе»ндә кунакларны тальян моны каршы алды. Биредә татарныкын гына түгел, башкорт, казах, мари, удмурт, рус, хәтта немецларның да милли йортларын күрергә мөмкин иде.

***

**2 июль. Мәскәү.** Быел бәйрәм яңа мәйданда үтте. Шуңа да карамастан, «Коломенское» дәүләт музей-тыюлыгында алма төшәрлек тә урын калмаган. Халык шау-гөр килеп күңел ачты. Татарстанның рәсми делегациясе составында Премьер-министр Илдар Халиков, Татарстанның (Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, Россия Дәүләт Думасы Рәисенең беренче урынбасары Олег Морозов, Чаллы мэры Васил Шәйхразиев бар иде. Чаллылылар Мәскәү халкына бүләк тә әзерләп барган. Бәйрәм мәйданында автошәһәрнең «Горзе-

ленхоз» эшчеләре әзерләгән «татар авылы» эшләде. Аны бер атна эчендә салып бетергәннәр. Авылда хәтта бәрән, кәҗә, үрдәк, казлар да йөгереп йөри иде. Чәчәк бәйләмнәреннән исә «КамАЗ» йөк машинасы һәм Эйфель манарасы ясаганнар.

ТР Хөкүмәте рәисе Илдар Халиков мәйданга җыелучыларга Татарстан Президенты Рөстәм Миннехановның котлавын җиткерде. Ул быел Мәскәүнең мәдәни тормышында булган зур вакыйга—Габдулла Тукайга һәйкәл ачу чарасын да искә алды. Премьер-министр әлеге эштә катнашучыларның кайберләренә Рәхмәт хатлары тапшырды. Төп мәйданда кызу көрәш барса, җыр-бию яратучылар концерт мәйданчыкларында күңел ачты.Сәхнәдә Татарстан һәм Башкортстан артистлары чыгыш ясады.

### ТӨРКИЯДӘ ТУКАЙ БӘЙРӘМЕ

Инде хәбәр ителгәнчә, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендә Татарстанның рәсми делегациясе Төркиядә булып кайтты. Кардәш илгә сәфәр кылучылар арасында ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, башка рәсми затлар һәм республикабызның мәдәният хезмәткәрләре бар иде.

Югары дәрәҗәдәге беренче очрашу Төркия дәүләте башлыгының Анкарадагы резиденциясендә булды. Анда ил Президенты Абдуллаһ Гөл Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм республикабыз делегациясе әгъзалары белән очрашты. Сөйләшү барышында республика арасындагы икътисади һәм мәдәни хезмәттәшлеккә кагылышлы күп кенә мәсьәләләр тикшерелде.

Рәсми сәфәр кысаларында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Анкарада Төркия Бөек Милли Җыены (парламенты) тышкы элемтәләр комиссиясе рәисе Морат Мәрҗан, Төркия мәдәният һәм туристлык министрының беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы Ниһат Гөл, Анкара губернаторы урынбасары Хәйретдин Балдтыоглу белән очрашып сөйләште.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм республикабыз делегациясе әгъзалары Анкара үзәгендәге «Аныткабер» мемориаль комплексында булды. Почетлы каравыл озатуында Фәрит Мөхәммәтшин Төркиянең күренекле дәүләт эшлеклесе Мостафа Кәмал Ататөрк җирләнгән урынга узды, аның төрбәсенә чәчәкләр салды.

Биредә кунакларга Азатлык сугышы музееен да күрсәттеләр. Шушы ук көнне республикабыз делегациясе әгъзалары «Казан» татар җәмгыятендә үткәрелгән очрашуда да катнашты. Төркия башкаласы үзәгендә Габдулла Тукай бюстын ачу тантанасын ТЮРКСОЙ халыкара оешмасы ярдәме белән шәһәр мэриясе оештырган иде. Һәйкәл ачу мәрасимендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Анкара мэры Мелих Гекчек, ТЮРКСОЙ генераль директоры Дүсен Касеинов, Төркия мәдәният һәм туристлык министрының беренче урынбасары вазифаларын башкаручы Ниһат Гөл, Россиянең Төркиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Владимир Ивановский, Татарстан делегациясе әгъзалары, башка рәсми затлар катнашты. Тантанада ясаган чыгышында Фәрит Мөхәммәтшин һәйкәлне куярга булышлык күрсәтүчеләрнең һәммәсенә дә республикабыз халкы исеменнән ихлас рәхмәт белдерде. Габдулла Тукайның бронза скульптурасы авторы Асия Миннуллина, архитекторы—Александр Лопаткин. Архитектура-төзелеш эшләре, бюстны кую, аның тирәсен тәртипкә китерү чыгымнарын исә тулаем Анкара мэриясе күтәргән.

Аннары Габдулла Тукайның 125 еллыгына багышланган бәйрәм Татарстан сәнгать осталары концерты белән Анкара опера һәм балет театры бинасында дәвам итте.

Татарстан делегациясе Истанбул шәһәрендә Г.Тукай исемендәге паркны ачу тантанасында да катнашты. «Габдулла Тукайның 125 еллыгына багышланган чараларның берсе шәһәребезнең гүзәл урынында үтүе белән мин чиксез горурланам»,—диде Истанбул мэры Кадир Топбаш.

Тантана ахырында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе һәм Истанбул мэры парк алдына таш куюда катнашты. Анда мондый мәгълүмат язылган: «Бу парк Истанбул мэриясе карары белән бөек татар шагыйре Габдулла Тукай исемен йөртә. Биредә шагыйрьгә һәйкәл куелачак».

Истанбул шәһәренең тарихи үзәгендә, Солтанәхмәт мәйданы янында Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга һәм Сабан туе бәйрәменә багышланган тантаналы чаралар үткәрелде. Анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Истанбул мэры Кадир Топбаш, Россиянең Истанбулдагы генераль консулы Алексей Ерхов, ТЮРКСОЙ генераль директоры Дүсен Касеинов сәламләү сүзләрен ирештерде. Бәйрәмдә Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле, республикабыз сәнгать осталары чыгыш ясады.

### ИЗГЕ БОЛГАР ҖЫЕНЫ

18 июньдә Болгарда Ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгән көнгә багышланган бәйрәм чаралары узды. Бирегә Татарстан-

нын төрле районнарыннан, Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән кунаклар жыелды, тантанада сәясәтчеләр, дин әһелләре катнашты. Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов жыелган халыкны сәламләп, бәйрәм белән котлаганнан соң, Болгарны торгызу эшләрен башлап җибәрүче Минтимер Шәймиевкә олы рәхмәтен белдерде һәм Болгар тарихи музей-тыюлыгына ике микроавтобус бүләк итте.

Бәйрәм чаралары кысаларында сәхабәләр жирләнгән урынга мемориаль истәлек билгесе куелды. Жыелган халык өчен вәгазьләр һәм Коръән укылды, мөнәҗәтләр, борынгы татар жырлары башкарылды. Шулай ук осталар шәһәрчегендә һөнәрчеләр эшләнмәләре һәм сувенирлар сату оештырылды, хәләл ризыклар, мөселманнар өчен кирәк-яраклар тәкъдим ителде.

Болгар жирендәге бу бәйрәм 1995 елдан бирле уздырыла. Халык аны Изге Болгар жыены дип атап йөртә. Ел саен бу чарага килүчеләр арткannan-арта. Мәсәлән, былтыр бу көнне Болгарга 26 меңнән артык кеше жыелган булган. Тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне торгызучы «Яңарыш» фонды рәисе Минтимер Шәймиев сүзләренә караганда, Изге Болгар жыенын алдагы елга тагын да дәрәжәлерәк итеп оештыру күздә тотыла. Шулай ук киләсе елга биредә Болгар мәчете һәм мәдрәсә ачарга ниятлиләр.

### «СӘЛӘТ» ЮГАРЫГА ҮРЛИ

Татарстанда сәләтле укучыларны үзенә жыйган бик шәп лагерь бар, ул—«Сәләт». Ижтимагый башлангычтан юл алып, зур нәтиҗәләргә ирешкән, киң масштабта таралган мондый лагерь дөньяда башка юк. Аның оештыручысы Жәүдәт Сөләймановның башкарган эшләре ни дәрәҗәдә кирәкле булуы вакытлар узу белән тагын да ныграк аңлашылыр. «Сәләт»не лагерь гына дип атап булмый, ул—татар яшьләрен берләштерүче, милли рух сагында торган көчле агым. ТР Президенты Рөстәм Миннехановның да «Сәләт»кә игътибар күрсәтеп, Биләрдә узган быелгы фестивальгә килүе тикмәгә түгел.

Биләргә килгәч, Рөстәм Миңнеханов иң беренче итеп Изге чишмәгә барды, аннары укучылар яшәгән палатка шәһәрчеген карады. Шулай ук анда Лаешта урнашкан «Йолдызлы» («Звездный») сәламәтләндерү лагерен, «Фәнсар» яшьләр академик шәһәрчеге һәм «Иске Казан» укыту-сәламәтләндерү, тарихи-һөнәрчелек комплексының презентацияләрен дә күрсәттеләр. «Фән» чатырында Президентыбыз студентлар белән экология, энергия саклanышы, атом энергетикасы хакында сөйләште. «Кинәш» чатырында «Сәләт» хәрәкәте активистлары ТР Президентына үзләрен борчыган сорауларны турыдан-туры бирә алдылар. 2013 елгы Универсиада, беренче Татарстан космонавты турында һәм «Сәләт» хәрәкәте бинасын яңартуга кагылышлы сораулар яңгырады.

«Сәләт» фестиваленең үзәк мәйданында катнашучылар әзерләгән сәламләү тантанасы күрсәтелде. ТР Президенты Рөстәм Миннеханов: «Мин сезне бу фестивальдә күрүемә чын күңелдән куанам. Республикабызда алдынгы карашлы һәм сәләтле яшьләр барлыгын күрү сөендерә. Нәкъ менә шушындый яшьләр Татарстанны алга әйди»,—дип, «Сәләт»кә килгән укучыларны сәламләде һәм ике компьютер сыйныфы бүләк итте.

Быел «Сәләт»кә республиканың барлык район һәм шәһәрләреннән 600дән артык укучы килгән. Ә 1998 елдан бирле «Сәләт» фестивалендә ун меңнән артык укучы, студент һәм аларның ата-аналары катнашкан.

### МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ ЖЫЕНЫ

Татарстанда мөселман яшьләре фестивале башланды. Фестиваль, традициягә тугрылыклы калып, Кол Шәриф мәчетендә ачылды.

Быел фестиваль Казан янындагы Петровский бистәсендә урнашкан «Регина» кунакханәсендә дәвам итте. Ә берничә ел дәвамында әлеге чараны уздыру урыны итеп Болгар сайланган иде.

Быел фестивальне ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министрлыгы, татарларның федераль милли-мәдәни мохтарияте, ТР мөселманнары Диния нәзарәте, Россия Ислам университеты, «Идел» яшьләр үзәге ТР Президенты каршындагы Дини берләшмәләр белән эшләү идарәсе ярдәмендә оештырды.

Фестиваль мөселман яшьләрен берләштерү һәм жәмгыять эчендәге проблемаларны хәл итәр өчен, мөселман яшьләре арасында хезмәттәшлекне жайга салуны максат итеп куя.

Яшьләр жыенында Россия төбәкләреннән, Татарстан районнарыннан 150 делегат катнашты.

### КҮҢЕЛЛЕ ХӘБӘР

Казан Россия буйлап сәяхәт итү өчен иң яхшы туристлар шәһәре унлыгына кергән. Баштагы өчлеккә Мәскәү, Петербург һәм Сочи керсә, дүртенче урынны Екатеринбург били. Исемлекне Краснодар, Калининград, Новосибирск, Владивосток дәвам итә. Казан исә тугызынчы урында. Рейтингның азагында—Новгород.

### БЕЗНЕКЕЛӘР АКШ ЖИРЕНДӘ

24-26 июнь көннәрендә Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, Татарстанның Дәүләт Советы де-

путаты Ринат Закиров, Татарстан Дәүләт Советының мәдәният һәм фән, мәгариф, милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев һәм Татарстанның сәнгать осталары Рөстәм Асаев, Ринат Вәлиев һәм Гөлшат Имамиева Америка Кушма Штатларында булып кайтты. 24 июнь көнне Нью-Йоркта шул җирлектәге милләттәшләребез катнашында конференция узды һәм анда Америка континенты татарлары ассамблеясе төзү турында килешенде.

### МӘДӘНИ ДУСЛАРЫБЫЗ АРТА

23 июньдә Казан мэры Илсур Метшин Пермь өлкәсенең Хөкүмәт йортында Татарстанның «Мәдәни альянс» проектына керүе хакындагы килешүне имзалады. Былтыр Пермь һәм Санкт-Петербург хезмәттәшлегеннән башланып киткән әлеге чарага быел Казаннан башка, Тверь, Самара, Тольятти, Уфа, Екатеринбург, Түбән Новгород, Киров һәм Ульяновск шәһәрләре килеп кушылды. Киләчәктә килешү әгъзалары уртак мәдәни проектларны тормышка ашырыр, дип көтелә. Аларның иң мәртәбәлесе—Россиянең иң яхшы шагыйрьләре, музыкантлары, артистлары катнашындагысы 2013 елда «Мәдәни Универсиада» кысаларында Татарстан башкаласында узачак.

### ШӘРӘФЛЕЛӘР РӘТЕ ИШӘЯ

Быел дүрт шәхескә «Казан шәһәренең Мактаулы гражданины» исеме бирелү турында карар кабул ителде. Аның билгеләре һәм, шушы исем бирелү турындагы таныклык һәм акчалата бүләк 30 август — Республика һәм Шәһәр көнендә тапшырылачак.

Әлеге мәсьәлә Казан шәһәр Думасының VI сессиясендә каралды. Аның буенча тәкъдим чыгышы белән мэр Илсур Метшин чыкты.

Казан шәһәренең иң югары бүләкләренең берсе булган мактаулы исемгә композитор Софья Гобәйдуллина, 131нче лицейнең элеккеге директоры Иван Савельев, Россия Фәннәр академиясенең Казан физика-техника институты директоры Кев Салихов, «Татэлектромонтаж» ААҖ генераль директоры Юрий Солуянов лаек дип табылды.

### ДӨНЬЯ БЕЛСЕН ӨЧЕН

Билгеле булганча, «Татар ПЕН—үзәге» ЮНЕСКО химаясендәге Халыкара язучылар ассоциациясе—«ПЕН-клуб»ның региональ оешмасы. «ПЕН-клуб» ел саен үткәрә торган халыкара конференция делегатларына тарату өчен инглиз телендә татар әдәбияты үрнәкләре тупланган китаплар бастырып чыгара. Шушы максаттан язучыларыбыз әсәрләреннән тупланган антология, әкиятләр һәм татар халык авыз иҗаты үрнәкләре җыентыклары, шулай ук берничә язучыбызның аерым китаплары инглиз телендә нәшер ителде. Алар «ПЕН-клуб»ның Мексикада, Шотландиядә, Германиядә, Финляндиядә, Македониядә, Норвегиядә, Словениядә һәм Австриядә үткәрелгән халыкара конференцияләрендә таратылды. Гадәттә һәр конференциягә 140лап илдән делегация килә, һәр илдән 4-6 делегат катнаша. Аларның барысы да Татарстан китаплары белән бик кызыксыналар һәм үз илләренә алып китәләр. Шулай итеп, ел саен татар әдәбияты үрнәкләре тупланган меңгә якын китап дөнья халыкларына таратыла.

Быелгы «Тукай елында «Татар ПЕН-үзәге» татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү буенча «Җыен» фонды белән бергәләп, бөек шагыйренең өч әкиятен («Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык», «Печән базары, яхут яна Кисекбаш») татар, рус, төрек һәм инглиз телләрендә бастырып чыгарды. Бу ике иҗтимагый оешма әлеге «Өч әкият» китабын Тукайның тууына 125 ел тулган олуг юбилейга багышлап нәшер итте. Китап төсле бизәлештә, яхшы кәгазьдә, югары сыйфатлы итеп басылган.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны берлек рәисе Илфак Ибраһимов алып барды. Утырышта катнашучылар Мөштәри урамында урнашкан Язучылар йортында ремонт эшләренең барышы белән танышты. Утырышта Гөлчәчәк Галиева («Газзәбану» китабы өчен, «Идел-Пресс» нәшрияты, 2010 ел); Әсгат Сәлах («Балыкчы малайлар», Татарстан китап нәшрияты, 2009, «Дорога берез», «Сүз» нәшрияты, 2010, «Последний вальс», Татарстан китап нәшрияты, 2011) һәм Әлмәт дәүләт нефть институты каршындагы әдәби берләшмә—«Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте һәм Татарстан Язучылар берлегенең Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби бүләгенә—язучы Айгөл Әхмәтгалиева, татар язучыларының проза әсәрләрен тәрҗемә итеп төрек телендә китап чыгарган Фатих Котлы, шагыйрь, тәрҗемәче Наил Ишмөхәммәтов Сажидә Сөләйманова исемендәге кызыксындыру премиясенә; югары уку йортларында белем алучы яшь язучылар Булат Ибраһимов, Айгөл Закирова, Илһам Шәрипов, Алсу Мингалимова, Ләйсән Фәтхетдинова Сажидә Сөләйманова исемендәге стипендиягә тәкъдим ителде.

«Глядя на Вас...» («Идел-Пресс» нәшрияты, 2009) дигән китабы өчен шагыйрә Александра Кашина Гавриил Державин исемендәге Бөтенроссия премиясенә тәгаенләнде.

Утырышта катнашучылар юмор-сатира

язучыларның иҗатын активлаштыру максатында Актаныш муниципаль районы хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлегенең Гамил Афзал исемендәге әдәби премиясен булдыру турында килеште.

### ЛЕВ ГУМИЛЕВКА БАГЫШЛАНА

Санкт-Петербургта бөек галим, тарихчы-этнолог, тарих һәм география фәннәре докторы, шагыйрьләр Анна Ахматова белән Николай Гумилевның улы Лев Гумилевка багышланган «Лев Николаевич Гумилев» дип аталган китапны тәкъдим итү булды.

Әлеге чара Лев Гумилевның музей-фатирында оештырылды. «Татарлар Ватанга хезмәттә» дигән гомум баш астында нәшер ителгән әлеге китапның авторы—Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Шамил Әхмәтшин. Биредә автор галимнең үтә дә сикәлтәле тормыш юлын тасвирлый. Китапта Лев Гумилевның әнисе белән хат язышуына тулы бер бүлек багышланган. Басма фоторәсемнәр белән бизәлгән. Китапны тәкъдим итүдә Төркия Республикасының Санкт-Петербургтагы генераль консулы Мехмет Чинар да катнашты.

### РАДИО РАДИУСЫН КИҢӘЙТӘ

10 июльдән башлап «Яңа Гасыр» радиосын Татарстанның башкаладан иң ерakта урнашкан төбәкләрендә дә тыңлап була.

«Татарстан—Яңа Гасыр» җөмһүриятебезне 100 процентка колачлау турында биргән вәгъдәсен үтәде,—диде телерадиокомпаниянең генераль директоры урынбасары Тәлгат Сабитов.—Кайбер районнар «Яңа Гасыр» радиосы картасында ак тап иде, хәзер алар һәрвакыт безнең дулкында булачак».

«Яңа Гасыр»ның радиусы киңәю радиога татар телен пропагандаларга зур мөмкинлек ача. Бигрәк тә туган телен оныта башлаган яшьләргә янәшәләрендә татарча сөйләп, җырлап торган радио булышчы булыр. Мәдәниятебез, тарихыбыз, динебез турындагы тапшырулар исә хәбәрдарлык мәйданын киңәйтер.

10 июльдән башлап, Татарстан тулысынча «Яна Гасыр» карамагында. Әлмәт—92,9 РМ, Буа—100,3 РМ, Чүпрәле—91,0 РМ, Нурлат—105,7 РМ, Чирмешән—107,7 РМ.

### ЧӘЧЕЛСӘК ТӘ, БЕЗ БЕРГӘ

***

Быел җәй Колыма төбәге тормышында ике мөһим вакыйга булды. 24-25 июнь көннәрендә бу якларга Татарстаннан делегация килде. Татарстан Президенты каршындагы дин эшләре идарәсе башлыгы Марат Гатин, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Ирек Шәрипов, танылган җырчы Рамил Миндияр бу көннәрне Магадан шәһәрендә төзеләчәк беренче мәчеткә нигез ташы салу тантанасында һәм Сабан туе бәйрәмендә катнаштылар. Әлеге эшләрдә әйдәп йөрүчеләр—«Алтын ай» татар-башкорт оешмасы активистлары. Оешманың рәисе—Магадан шәһәр Думасы депутаты, эшмәкәр Рафаэль Фатыйхов. Аның сүзләренә караганда, милли оешманың 20 еллык тарихы бар, ул шәһәр үзегендә аерым бинага ия булып, уңайлы шартларда эшләп килә.

***

Эстония татарлары Татарстанга килде. Алар Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты бинасында очрашуда булдылар. Сигез кешедән торган делегация составында Эстония татарларын берләштерүче «Ида-Вирумаа» иҗтимагый оешмасы вәкилләре иде. Бу оешманың идарә әгъзасы Светлана Мөхәммәтҗанова Эстониядә яшәүче татарларның тормышы хакында сөйләде һәм тарихи ватаннары булган Татарстанга килүдән алган тәэсирләре белән уртаклашты.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Мәңге яшь борынгы Казан.

*Дүртенче биттә:* шагыйрь **Рөстәм Зәкуан**.

# Яңа китаплар




**Клара Булатова.** Сайланма әсәрләр: 2 томда.—Казан: Татар, кит.нәшр., 2011. 250шәр бит. Тиражлары—1500 данә.

Күренекле шагыйрә Клара Булатованың моңа кадәр дә байтак китаплары дөнья күргән иде. Ә бу ике томлык иң саллы, иң тулы басмалар, чөнки аларга шагыйрәнең төп әсәрләре тупланган. I томга шагыйрәнең төрле елларда язылган лирик фәлсәфи шигырьләре, җырлары һәм поэмалары кергән. II томның яртысыннан күбрәге шигырьләр, ә икенче өлешен «Вәкил» исемле повесть, истәлекләрдән—«Искәндәр кыйссасы» һәм хикәяләр тәшкил итә.

Китапның мөхәррире—И.Ногманов, рәссамы—Р.Хәсәншин.




**Мәүлидә Хуҗина.** Равил Фәйзуллинның шигъри дөньясы.—Казан: «Сүз» нәшр., 2011.—232 б. Тиражы—500 данә.

Ижевск шәһәрендә яшәүче галимә, филология фәннәре кандидаты Мәүлидә Хуҗинаның бу хезмәте, исеменнән үк күренгәнчә, халык шагыйре Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган. Китапта шагыйрь иҗатының эволюция этаплары, камилләшү юллары күрсәтелә, аның татар әдәбиятында, үз чоры шигъриятендәге урыны, шигъри сурәтле фикерләүгә алып килгән яңалыклары билгеләнә. Китап татар шигърияте, 60-90 еллар әдәбияты буенча лекция укучыларга, Р.Фәйзуллин иҗаты, иҗат лабораториясе буенча махсус курс алып баручыларга, филология факультеты студентларына, аспирантларга, гимназия, колледж һәм мәктәп укытучыларына ярдәмлек була ала.



Рөстәм Зәкуан

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)